


# Казан утлары

3.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

●

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

3

1983

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

**С. ХӘКИМ.** Шигырьләр . . . . . . . . 3
**Г. КАШАПОВ.** Җир җылысы. Повесть . . . . . 9
**К. КӘРИМОВ.** Алдавыч күз. Кечкенә повесть . . 51
**М. ВӘЛИЕВ.** Икенче каттагы бүлмә. Новелла . . 70
**Б. СӨЛӘЙМАН.** Абу баба. Хикәя . . . . . . 77

СЕРГЕЙ МИХАЛКОВКА 70 ЯШЬ

**С. МИХАЛКОВ.** Шигырьләр, мәсәлләр . . . . . 93

**Н. ИЗМАЙЛОВА.** Шигырьләр . . . . . . . 97
**Э. МӨЭМИНОВА.** Язмышлар. Шигырьләр . . . 99
**А. МИНҺАҖЕВА.** Шигырьләр . . . . . . 102
**Э. ШӘРИФУЛЛИНА.** Шигырьләр . . . . . . 106

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Р. ГАЗИЗОВ.** Шигырьләр . . . . . . . . 109

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

**М. ХӘБИБУЛЛИН.** Елның бер көне. Очерк . . 112

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕН ХАЛЫК ЭШЕ

**К. ТИМБИКОВА.** Мәсүфәнекеләр һәм Пивник. Очерк 116
**Ф. БӘЙРӘМОВА.** Тегермәнче турында баллада 126

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

**Л. ИХСАНОВА.** Юл кешесе — юлда . . . . . 130
**М. ЕЛИЗАРОВА.** Сәламәтлек сагындагы майор 135

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Р. МОСТАФИН.** Перспективаны югалтмыйк . . . 139
**Ф. ГАЛИМУЛЛИН.** Мөмкинлекләр бар! . . . 146

ӘХМӘТ ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

**Н. ЮЗИЕВ.** Гаҗәеп талант . . . . . . . 150
**Н. МАДЬЯРОВ.** Әхмәт Фәйзи Кырлайда . . . . 159

ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

**Җ. ДӘРЗАМАНОВ.** Тормышка мәдхия . . . . . 161
**Ә. ЗИННӘТУЛЛИНА.** Кызыклы да, гыйбрәтле дә 162
**Г. МОРАТОВ.** Сабыр канатлары . . . . . . 163
**Р. НӘБИЕВ.** Революция каһарманы . . . . . 164

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Ш. АБИЛОВ. Низами һәм татар әдәбияты . . . 166**
**С. МИХАЙЛОВА. Давылга таба . . . . . . . . 172**

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**М. ГАЙНУЛЛИН. Мөхәммәт Галинең туууына 90 ел 177**
**Р. ИШМОРАТ. Зәйни Шәһиморатовның тууына 70 ел . . . . . . . . . . . . . . . . 179**

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

**И. ЗАРИПОВ. Туган көн. Юмористик хикәя. . . 180**

ТАТАРСТАН АТОМ ЭЛЕКТР СТАНЦИЯСЕ ТӨЗЕЛЕШЕ — ЖУРНАЛНЫҢ ӘДӘБИ ПОСТЫ

**Әдәби постта беренче очрашу . . . . . . . 186**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 191**

**Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192**

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

---

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 7/XII-1982 ел. Басарга кул куелды 11/II-1983 ел. ПФ 07009. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Ю-511. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

# Сибгат Хәким

●

Белоруссиядән башлап,
Гел кырлар, кырлар, кырлар...
Күңелдә зур вакыйгалар,
Күңелдә ГДРлар...

Польша җире, ап-ак карабодай,
Ызанында утыра кыз, егет...
Онытылды бар да, барам узып
Мәхәббәтләренә кызыгып.

*Июль, 1981*

## Көнбатыш Берлин. Бисмарк

Көнбатыш Берлин. Бисмарк.
Тукталдым биш минутка.
Ләкин һич хөрмәт йөзеннән
Түгел шул Бисмаркка,
Юк миндә бернинди хөрмәт
Сугышлар символына.
Ничек тә саклап каласы
Иде бит сине, дөнья.
Бисмарк уяу, шулай ук
Дөнья да уяу, беләм.
Язганнар һәйкәлгә куе
Кып-кызыл буяу белән:

«Бисмарк — канечкеч дуңгыз...»
Ишеттем мыркылдауны.
Узалар яшьләр, һәйкәлдән,
Юк, сөртми беркем канны.
Яңгырый сугышка протест,
Юл куйсаң пруссакка,
Тупларны борыр иде ул
Яңадан безнең якка.
Юк миндә бернинди хөрмәт
Сугышлар символына.
Ничек тә саклап каласы
Иде бит сине, дөнья.

*19 август, 1982*

## Йөрим Берлин вокзалында

Йөрим Берлин вокзалында,
Без күптәннән дуска — дус.
Йөрим бер баштан бер башка,
Адым саен «Ost» та «Ost».
«Ost» ул «Көнчыгыш». Пошынып
Укыйм эчтән «Ost»ларны.
Шул «Ost»лар искә төшерә
Узган зур сугышларны...
Уйларым сугыш кырында,
Минем ышануларның,
Кузгалып шушы вокзалдан
Киткән эшелоннарның
Бер очы Харьковта кебек,

Мин сугышчы — окопта.
Шул эшелоннар килә күк
Якынлашып Харьковка.
Туктаусыз гүли рельслар,
Туктаусыз гүли җирем,
Тоям якында йөземә
Бәрелгән үлем җилен...
Йөрим Берлин вокзалында,
Онтылган үч алулар,
Нигә шул чаклы дәһшәтле
Брезентлы эшелоннар?
Туктыйлар поездлар килеп,
Кайнар соң сулышлары,

Чыгып бетмәгән шикелле
Әле дә сугыш пары.
Йөрәккә кадалган минем
Еллар шул «Ost»лар булып.
Каядыр эшелоннар кук
Агыла өстән болыт.

*Август, 1982.*

## Берлин стенасы

Берлин стенасы уза
Йортлар, подъездлар аша.
Карыйм Көнбатыш Берлинга,
Алга ят йөзләр баса.
Шушында очраша күзләр,
Ничаклы ачу-йөзләр!
Дуга кырларын әйләнеп,
Бер-берсен ашый күзләр.

Таныш йөз... Моның артыннан
Сагалап өч көн йөрдем,
Өч көн күзәттем Дугада,
Ничек, дим, ычкындырдым.
Хәзер дә аның билгеле
Хөкемнән ычкынасы;
Арада сузылган еллар
һәм Берлин стенасы.

*Июль, 1982.*

## Берлин, төн. Берлин тын...

Берлин, төн. Берлин тын. Ап-ак кар.
Әйтерсең, үлмәгән, сау барсы.
Кич яуган ап-ак кар өстендә
Мусалар, Алишлар шәүләсе.
Берлин, төн. Берлин тын. Ап-ак кар.
Чыгалар шәүләләр чатлардан,
Кушыла төркемгә Курмашлар,
Кушыла Симайлар, Саттарлар.
Атлыйлар урамнар буенча.
Атлыйлар, барысы уникe.
Кычкырам елларның түреннән:
Егетләр, сез кайсы илнеке?
Берлин, төн. Берлин тын. Ап-ак кар.
Урамнар тагын да шомлырак.
Атлыйлар... Башында шул Муса,
Туган ил, син ерак, син ерак.

*17 август, 1982.*

## Фронтовик һәм каз бәбкәләре

*М. Мәһдиевкә*

Чирәмдә каз бәбкәләре,
Караучысы... фронтовик.
Фронтовик артында басып
Тора сугыш — зур тарих.

Чирәмдә каз бәбкәләре,
Тик шуларда гамь-кайгы.
Бар иде егет чаклары,
Узды еллар, картайды.

Шәһәрләрне азат итте,
Төрле илләр язмышын
Хәл итте, кайтты, картайды,
Караганың каз булсын.

Гөнаһсыз, нарасый дияр,
Сөеп сүзләр әйткәләр,
Узган сугышлар турында
Берни белми бәбкәләр.

Йөриләр чемченеп чирәм,
Сап-сарылар, йомшаклар...

Урамда бер үзе исән,
Ул сакламый, кем саклар.

Фронтовик, Дуга солдаты,
Артиллерист, ат кадәр.
Сөйләнә: икенең берсе,
Я сугыш,— я бәбкәләр.

*1981.*

## Аккош күлендә сагыш, моң...

Аккош күлендә сагыш, моң,
Юксынып сорый урман:
Гасырның үзе кебек чал
Кайда, дип, синең Туфан?
Үзем дә эзлим, шушыннан
Узган эзләрен беләм.
Чәчәкләр карый күземә
Туфан күзләре белән.
Ул юкта ромашкаларга
Кунмаган хәтта тузан,
Сыйпыйм, башларыннан сөеп
Сыйпаган кебек Туфан.
Аккош күлендә сагыш, моң,
Юксынып сорый урман:
Гасырның үзе кебек чал
Кайда, дип, синең Туфан?

*23 август, 1982.*

## КамАЗ алмагачлары

Сез — безнең узган яшьлеккә
Бу җирдә алмаш бары,
Сездә дәвамы яшьлекнең,
КамАЗ алмагачлары.
Киләсез урамнар буйлап,
Әйтерсең, загстан сез,
Язмышның үзе белән дә
Шушында танышкансыз.
Сез аяк баскан җир — КамАЗ.
Тамырлар чыккан шуннан...
Дисәләр:
— Кайдан?
Әйтегез:
— Дәверләр капкасыннан...
Сез — безнең узган яшьлеккә
Бу җирдә алмаш бары,
Якты, хәерле юл сезгә,
КамАЗ алмагачлары.

*Август, 1982.*

## Төш иртән су буйларына

Каратыйм дисәң үзеңә
Авылда тәкәбберне,
Авылда түгел, илеңдә,
Җиреңдә фәкать берне,
Төш иртән су буйларына,
Эзлә, күзәт талчыгып,
Тибрәнер сандугач басып
Сайраган яшь тал-чыбык.

Үз шуны, күрсәтмичә сук
Тәкәббер беләгенә,
Иңәр сер шул чакта аның,
Иңәр сер йөрәгенә.
Бел шуны, сиздермә ләкин,
Йөр һаман саклап серең,
Шул көннән башлап гомергә
Синеке тәкәбберең.

*Июль, 1982*

## Ялганчы бүрәнә

Осталар йорт башлаганда
Хуҗаны, бу бәндәне
Бер кызык итик дигән күк,
Беренче бүрәнәне
Күмәләр, аннан шаяртып
Көләләр: күр әнә, дип,

Ята нигездә күмелеп
Ялганчы бүрәнә, дип.
Мине дә күмәрләр бер көн,
Кирәкми күмәргә күп.
Ятасым килми кабердә
Ялганчы бүрәнә күк.

## Алмагач

Таралган нигез. Таралган
Йорт-нигез. Идән-сайгак
Күптән юк. һәркем кергән дә
Кирәген алган сайлап.
Таралып шүреләр ята,
Калдырча, суса, кылыч...

Станок куй да киндерне
Сугарга шунда кереш.
Бакчада бер төп алмагач.
Корган очы, кәүсәсе.
Килә шул алмагач белән
Кул биреп күрешәсе.

*Июль, 1982*

## Карама

Йөрәктән сагыш белән моң,
Ярсып кан тама төсле,
Урманы калдырып киткән
Ялгыз карама төсле

Торамын кыр уртасында,
Гел уйлан, сагын икән,
Көр чагың — бергә шаулаган
Шул урман чагың икән.

*Август, 1982.*

## Ялгызлык

Бу картның көндәлек юлы:
Йорт, тыкрык, иске зират.
һәркөн тикшереп тора кук
Кайчан дип минем чират.
Тәрәзә турыннан уза,

Гүя күп'күргән рәсем,
Шәйлим гөлләр арасыннан
Селкенгән куләгәсен.
Элек печән чабар иде,
Урагын урыр иде.

Элек юлы озын иде:
Йорт, Идел, Одер иде...
Ялгызлык... хәзер өч көнгә
Капка келәсенең бер
Шыкылдаганы ишетелсә,

Картка көн ачылды, бел.
Уенда колхозлар төзи,
Кора кыр станнары.
Юк, үзе түгел — ялгызлык
Теләгән дошманнары.

*Июль, 1982*

## Тәлгат дус

Тәлгат дус, авылдаш минем...
Керешеп «Бисмилла»дан,
Бөкрәеп кабер ташына
Мәрхүмнең исемен язган.
Кайсының Бибигарифә...
Кайсының Рәхмәтулла...
Бетергән: «Үзе бер алла
Булсын,— дип, рәхмәтендә».
Язган... Асылда бит авыл —
Хезмәтчән, тырыш токым...

Язган хөрмәтләп, гадәттә,
Үлгәч, итмиләр хөкем...
Язган... Уйлары тоташкан
Сугышка — атасына...
Барсына язган әтисе
Ташыннан башкасына.
Миңа да язар... Елмаеп:
Я, ни бар җир яме күк?
«Башка берни дә кирәкми»,
Дип җырлап җибәрер күк.

*Август, 1982*

## Өшегән бәрәңгеләр күк

Мин ятим, миннән калганнар
Бар да шат, үзем беләм.
Карыйм авылым күгенә
Бала чак күзе белән.
Карыйм декабрь кичендә,
Үпкәм зур декабрьга,
Юк, ипи әгәр, онытмам
Кергәнче шул кабергә.
Декабрь күңелдә калды
Ачлык символы кебек.

Еладым үксеп төшемдә
Мин солы оны күреп.
Әнидән сорап еладым
Әй, солы коймагын мин,
Декабрь, сабый җанымны
Ник иртә кыйнадың, дим.
Берсе авылым өстенә
Аударган йөге белән;
Өшегән бәрәңгеләр күк
Йолдызлар җемелдиләр.

*11 август, 1982*

●

Бүген монда Бакый күргәзмәсе,
Бүген монда хуҗа — Урманче.
Йөрдем олы сәнгать дөньясында,
Йөрдем тәмам күңел булганчы.
Бу күргәзмә — үзе зур бер тарих,
Кайнар сәлам миннән рәссамга.
Моң дөньясын ачып бирә алмам
Мин — бичара, күпме язсам да.

Үзен кайчак мин охшаттым аның
Җәен кырда кызу кояшта
Арыш арасыннан килеп чыккан
Мәһабәт зат Хозер Ильяска.
Калын тарих урманнары аша
Атлап бара кебек Урманче,
Шунда туган бөек «Сагыш»ларын
Шигъри җаным саклар үлгәнче.

*Март, 1982*

# Әби һәм козгын

Ziратта туктаусыз сузып
Кычкырса козгын әгәр,
Борчыла йөз яшьлек әби:
«Япмады авызын, каһәр.
Бар әле, карап кер әле...»
Эндәшә оныгына:
«Кай якка карап кычкыра,
Ни гөнаһ шомлыгына?»
Оныгы чыгып керә дә
Юанып, өскә карап,
Әби, ди, козгын кычкыра
Югары очка карап.
Нәтиҗә чыгара әби:
«Үлемнән калмый кеше.
Ибраһимгадыр, авылда
Ул карт — иң карый кеше...»

Тавышы тынды дигәндә,
Кычкырып куя козгын.
«Кай якка карап кычкыра,
Карап кер әле, кызым».
Оныгы, күрсә-күрмәсә,
Түбән очка, ди юри.
Бик авыр сулый да әби,
Гөлҗамалга дип юрый.
«Алла рәхмәтендә булсын,
Бик дус идек яшьлектә».
Шомлы козгын өне килә,
Тотындисә тәсбихка.
Әби, ди, оныгы көлеп,
Козгын гел алга карап,
Нишләптер кычкыра бүген
Безнең урамга карап.
Уйланып утыра әби
Килгәндә кызарып таң.
«Балалар авырыйдыр әле
Тыкрыкта кызамыктан».
Козгынның язын зиратта
Бала чыгарган чагы.
Түгел, ди әби, башыма
Бәла чыгарган чагы...

*Март, 1982*

# Газиз Кашапов

# ҖИР ҖЫЛЫСЫ

ПОВЕСТЬ

I



Сентябрь ахырлары иде.

Сибеп-сибеп, үзәкләргә үтеп, салкын яңгыр ява. Күк йөзен кургаш сыман авыр болытлар томалап алган. Ничәнче тәүлек инде — көнен дә, төнен дә — ява да ява. Хәер, быел аның язы — яз, җәе җәй төсле булмады.

Язгы чәчү өч атнага соңга калды. Бер-ике көнгә, яисә атна-ун көнгә генә дә түгел бит, тып-тулы өч атнага. Эшнең рәте-чираты китте, вакыт чикләре буталды. Май башында чәчәсен июнь кергәч чәчтеләр. Җирне әллә ничәшәр кат тырмаларга туры килде. Бүген әзерләгән, әбиләр чәче кебек тип-тигез тарап, тырмалап куйган басу өстенә иртәгә, уч иткән сыман, тагын яңгыр сулары сибелде, аннары епшек кар явып үтте. Дүрт-биш сәгатьтән жылытып җибәрүгә, җир өстенә, тоташ күл булып, су җәелде. Көннәр көйләнә бугай дип, шөкер кылып, эшкә керешсәләр дә, җайлап-көйләп бер-ике әйләнүгә, Мәрәҗән тавы ягыннан кара болытлар кабарып чыга, тагын яңгыр тотына. Җен ачулары чыккан тракторчылар сукрана-сукрана авылга кайтырга мәҗбүр була. Шулай итеп, чәчүне июнь ахырында, гадәттә, сабан туйлары була торган көннәрдә генә тәмамлап чыктылар.

Шуны гына көткән диярсең, ялтырап-көлеп кояш чыкты. Бер атна эчендә җирдәге дым-суны күкләргә очырды. Җир өсте куна тактасыдай катып китте. Эч пошуы бераз басылмасмы дип, идарә янына җыелган ир-ат, карт-коры арасыннан кайсыдыр берсе саксызланып: «Кара туфраклы җир шулай инде ул, яңгыр яуса, боткага, яумаса аэродромга әверелә»— дип ычкындырды. Яшен яшәгән, шушы җирдә туып ил кичергәннәрнең барысын да кичергән Закирҗан карт шундук, чукмар башлы таягын тегенең күз алдында уйнаткалап:

— Син, энем, ата-баба җиренә тел-теш тидерәсе булма. Бездәгедәй җир бүтән беркайда да юк ул. Тәртә кадап куйсаң, бер атнада тарантас үсә торган җир бит ул безнең җир, ди иде минем мәрхүм бабай,— дип дуларга кереште.

Закирҗан картны кордашлары көч-хәл белән тынычландырып, өенә таба озаттылар. Ә ул барыбер тиз генә бирешергә теләмәде:

— Һе, кара син аны, танау асты кипмәгән, май урынына ипигә яксаң ашап туймаслык туфракны яманлаган була бит тагы,— дип сукрануында булды.

Игеннәр шытып чыгалмыйча интегәләр иде, тырмага төштеләр, йомшарттылар җирне. Эш бетеп, ике көн узган иде, тагын яңгыр тотынды...

Аннары август керде, әмма басулардагы игеннәр ямь-яшел килеш күк йөзен томалаган болытлар астында кояш нурына зар-интизар булып кала бирделәр. Игенче нишләргә, кая барып сугылырга белмәде. Механизаторлар сыза һәм урман буйларында байтактан күрелмәгән, машина тәгәрмәченнән биек үләннәрне кызулык белән чабып ташладылар да җыя алмыйча интегеп беттеләр.

Шулай да ничәмә-ничә буыннарның маңгай тире белән сугарылган җир мәрхәмәтсез кыланмады. Басу юлларыннан армый-талмый йөгерүче җәенке борынлы «УАЗ»ларны күмәрлек булып үсте игеннәр. Картлар гынамы, әлеге басуларда фән кушканча эшләп, картограммалар ясатып иген игүче агрономнарның да исе китте. Тик бу шатлык озакка бармады. Ничек җитте шулай печәнне җыештырганнар гына иде, өстән кушылганга күрә, чамасыз күп чәчелгән борчак колхозчыларның йөрәгенә кара кан булып төште, санаулы көннәрне уздырып, өлгерә алмыйча интекте. Һаваның көйсезлеген вакытлыга санап, урып-җыюга тиешенчә яхшы хәстәрләнә алмаган хуҗалыкларның хәле хөртиләнде. Закирҗан картның: «Ышанмагыз бу җәйгә, оланнар, ышанмагыз. Уңыш котырыр быел, ләкин әрәм-шәрәмгә китәр»,— дип юравы дөрескә чыкты. Аның бу сүзләрен ишеткән Хәйдәр Яруллин беркөнне урам уртасында туктатып:

— Син, бабай, үзеңнең сынамышларың белән заманнан артка калгансың инде. Хәзер колхозда унбиш-уналты комбайн, алар янында тагын никадәр машина-трактор, шулар барысын да хәл итә. Кешеләр күңеленә коткы салма,— дип кисәтте. Идарә члennары картның юравы юш килмәгәе, комбайннарны юеш игеннәрне суктырырдай итеп көйләргә кирәк, дип әйткәләсәләр дә, Яруллин көлде генә. Моңарчы унбиш-унсигез центнердан артмаган арышның быел егерме биш-утыз центнер уңыш бирәсен чамалап караганнан соң, кеше сүзен бөтенләй тыңламас булды. Әмма тикшерү өчен суктырып караганнан соң, уңышның тагын да күбрәк чыгачагы мәгълүм булды. Ләкин... Закирҗан карт та гомерен бер дә юкка уздырмаган икән. Күкрәп үскән игеннәрне түкми-чәчми генә җыеп алып, амбарларга тутыру насыйп булмады...

— Күкнең төбе тишелгән,— диде күпне күргән карчыклар.

— Касманауларыгыз күкне бозып бетерделәр. Моңарчы меңәләр дә төшәләр иде, хәзер әнә яртышар ел ходай тәгаләгә тынычлык күрсәтмиләр. Йөриләр шунда...

Тик колхозчыларның мондый сүзләр белән мавыгырга вакытлары юк иде. Чынлап та, хәлләр көнләп түгел, сәгатьләп кискенләште. «Дуслык» колхозы уракка хәзерлексез чыкты. Комбайннар беренче көннәрдән үк ватылып тора башлады.

Сентябрь ахыры житте, уракның яртысы гына бетте. Көзге чәчүне ничек җитте шулай башкардылар...

Шундый көннәрнең берсендә «Дуслык» колхозына, каян җил ташлагандыр, өлкә газетасыннан корреспондент килеп төште. Ул үзе шушы авылда туып, урам-тугайларда яланаяк йөгереп, тирә-якка даны таралган Кушкаен чишмәсеннән су эчеп үскән Дамир Хафизов булып чыкты. Өске иренен томалаган куе мыегын сыпыргалап, үзенең «газет җанлы» кеше икәнлеген бик тиз таныттты ул. Шәһәрдә йөргән җиңел туфлиләрен резин итекләргә алмаштырды да, лаштор-лоштыр килеп, басуларны, ындыр табагын айкап чыкты. Колхозчыларның олысы-кечесе белән сөйләште, механизаторлар янында аерата озын-озак булашты. Хәтеренең ныклыгына ышанмагандай, күргәнен-ишеткәнен тышына рәсемнәр төшерелгән калын блокнотына теркәп барды. Хәер, соңрак нинди максат белән килеп чыгуы ачыкланды аның. Кайчандыр миллионер булып

тирә-юньгә шаулап торган хуҗалыкның соңгы елларда артка тәгәрәве, быелгы уракка тиешенчә әзерләнмәүләре, колхоз председателе Хәйдәр Яруллинның атналар буе «югалып» торуы, кәеф-сафа корып йөрүе турында язылган хатны тикшерүе икән.

Юкка вакыт уздырып йөрмәгән булып чыкты, китүенә атна тулар-тулмас борын өлкә газетасының икенче битендә тозлы-борычлы мәкалә басылды...

Өченче көн тоташ яуган яңгырдан интегеп, вакыты җитәр-җитмәс авыл өстенә ябырылган күе эңгер-меңгергә карамыйча, комбайн-тракторларын көйләп йөргән механизаторлар янына мәкалә басылган газетаны Таһир Вәлиуллин алып килде. Мамыктай йомшак сары чәчләрен туздырып, өзек-өзек искән җилгә арты белән басты да, барысына да ишетелерлек итеп, тозлы-борычлы урыннарын сузыбрак, кычкырып укый башлады.

Таһир тирәсенә җыелган механизаторлар бер-берсенә карарга кыймыйча, салкынча җил китергән алма исләрен дә сизмичә басып тордылар. Ул арада караңгылык куера төште. Актарылып иңгән болытлар авыл тәрәзәләреннән күренгән якты нурларны тагын да кечерәйтеп күрсәтәләр иде.

— Әйе, авылдашлар дип тормаган бу, биргән кирәкне,— диде комбайнчыларның берсе, эшкә күңел бирүдән битәр баш төзәтү турында кайгыртырга яратучы Мотыйгулла.

Аның фикеренә кушылырга ашыкмадылар. Мондагылар хәлнең кискенлеген аңлый, кичекмәстән чара күрергә кирәклеген сизенеп йөриләр, әмма соңгы елларда күңелләрен күк йөзендәге болытлар кебек томалый башлаган битарафлыктан арына алмыйлар иде әле.

— Болай булгач, оланнар, Яруллинның башыннан сыйпамаслар инде,— дип куйды комбайнчы Шиһабетдин, чамасыз куе, сары кашларын җыерып.

Үсмер еллары сугыш чорына туры килеп, бишенче классның яртысыннан узалмаган, югары белемле кеше булмаганга инженер урынына куелган шофер Минап Ризаев «газет җан»ның бу эшен яратмыйча:

— Газетага язарга, тәнкыйтьләргә кем дә оста аны,— диде, үзенең үтә калын тавышы белән тирә-юньдәгеләрне сискәндереп.— Вот ул үзе кайтып эшләп күрсәтсен, оештырып карасын, запчасть тапсын, аннары безнең белән, ничә еллар буе шул колхозны үз җилкәләрендә күтәрүчеләр белән аяк терәп сөйләшеп карар иде!..

Кырыкмаса кырык эшең кырык төштә ярылып ятканда кеше исеме белән авыз чайкаучы бүтән күренмәде. Механизаторлар арасында әлегрәк тә «болай барсак, озакламый барып чыгабыз да чыгабыз инде», дип борчылучылар байтак иде. Шуңадырмы, быелгы өзеклек барыбер яхшыга илтмәс дип, үзгәреш көтеп яшәүчеләр бу юлы дәшмәделәр...

## 2

Ачып куелган тәрәзә рамына таң атар-атмас йокысыннан уянган күгәрчен килеп кунды. Кош авырлыгыннан тәрәзә теләр-теләмәс кенә ябыла башлады. Күк күгәрчен пар канатын салмак кына җилпеде дә күтәрелеп китте.

Төнге бер тулып узгач кына район үзәгенә кайтып кергән Сабир Салихович Гайнуллин — район комитетының беренче секретаре — эш урынында, әчке бүлмәдә ял итә иде, кәефе кырылып торды. Хәер, шатланырга урын да юк. Акъяр районы урып-җыю, терлек азыгы хәстәрләүнең барышы белән республикада иң соңгы урыннарның берсендә. Ашлык тапшыру планы да үтәлми...

Нигә, нишләп болай килеп чыкты соң әле бу?

Гайнуллин менә ничәнче тапкыр инде үз-үзенә шундый сорау бирә, ләкин, күпме генә уйласа да, җавапның төгәлен таба алмый иде. Райондагы хуҗалыкларның бер ишесе, бер үк шартларда эшләп тә, кышлатуга җитәрлек терлек азыгын хәстәрләп куйды, икенчеләре моңа ирешә алмады. Урып-җыюда да шундый ук хәл килеп чыкты. Алдынгы хуҗалыклар сентябрь башында ун-унике көнлек аяз көннәрдә игеннәрнең сиксән-туксан процентын җыеп алды, ә арттагылар... Әнә бит, бөтен республикада кайчандыр шаулаган «Дуслык»ның бүгенге хәлгә төшүен ничек аңлатырга? Һава шартлары гына гаепләме? Һичшиксез, район комитетының, иң элек Сабир Гайнуллинның да гаебе бар бу очракта. «Дуслык»ның артка таба тәгәрәвен күрмәде түгел, күрде бит ул. Ләкин... Хәйдәр Яруллинны, үзенең полкташын, тиз генә алып ташлый алмады. Аның хәмер белән мавыгуын, кешеләргә дорфа бәрелүен, тагын бик күп нәрсәләрне сизмәде түгел, сизде. Колхозчылар да аның «югалгалавын» җиткерделәр. Ниһаять, Хәйдәр Яруллин райком бюросына «җылынган» килеш килде. Каты шелтә бирделәр үзенә. Эшләсә, булдыра алмый торганнардан түгел, кем ялгышмый, дип уйлады Сабир Гайнуллин, полкташының тоткан җирдән өзәргә яратуын искә төшереп.

Гайнуллин тәрәзә янына ук килде дә, бая күгәрчен төшеп япкан ягын ачып, мәшәкатьләрдән талчыккан йөзен салкынча һавага, тыгыз дымлы җилгә куйды.

Радиодан өлкә газеталарына күзәтү тапшыралар иде. Акъяр районын атадылар. Кеше күңеле, борчулы хәбәр буласын белеп, сизенеп торса да, ышанмый, шатлыклысын көтә, өмет итә бит ул. Әмма бу юлы, Сабир Салиховичның уйларын бүлдереп, «Дуслык» колхозындагы эшләрнең шәптән булмавын, өстәвенә Хәйдәр Яруллинның үз вазифаларына салкын каравын, район җитәкчеләренең моны күрмәмешкә салышуын әйттеләр, артталыкның сәбәпләрен берәм-берәм күрсәттеләр. Дөрес анысы, Сабир Гайнуллин өчен яңалык түгел иде болар. Ләкин үзең белү бер хәл, ә бөтен республикага мәгълүм булу икенче нәрсә...

Хак сүзләр, җанны әрнетә торган сүзләр. Соңгы бишьеллыкта өченче тапкыр инде Акъяр районы ил алдындагы изге бурычын, икмәк тапшыру планын үтәп чыга алмый.

Аңлашыла ки, мондый хәлнең сәбәпләре, эшләр бераз җиңеләя төшкәч, ачыкланыр. Кичәге бюро утырышы Сабир Салиховичка күп нәрсәне яңабаштан ачыкларга ярдәм итте. Дөресрәге, кичәге утырышта Сабир Салихович ничә елга беренче тапкыр Хәйдәр Яруллинга катгый таләп куйды. Моңа хәтта бюро әгъзаларының да беркадәр исе китте, чөнки алар беренче секретарьның Яруллинга каты бәрелмәскә тырышуын беләләр иде...

Сабир Гайнуллин армия хезмәтеннән соң үзләренең районына кайтып комсомол эшенә керде. Аннары район комитетына инструктор итеп күчерделәр. Ул арада укуга сәләтле, зирәк егет авыл хуҗалыгы институтын бетереп агроном дипломы алып кайтты. Телгә остарды, егетне күреп алдылар да югары партия мәктәбенә җибәрделәр. Аннары берсеннән берсе җаваплырак эшләр, вазифалар чоры башланды. Аның Акъяр районына беренче секретарь булып килгәненә дә инде дүрт елдан артыграк вакыт узды.

Кичәге утырышка кызмача килгән Хәйдәр Яруллинга каты шелтә биреп, эшеннән алырга дигән тәкъдимне раслап кул күтәргән чакта полкташларның күзләре очрашты, карашлары кисеште. Билгеле, Яруллинның хәзерге эшләрен аклап, колхозны шушы хәлгә җиткерүен, кешеләр күңеленә битарафлык салып, иң җаваплы вакытта вазифалардан качуын аклап, берничек тә аклап булмый иде. Сабир Гайнуллинның

үткәннәр хакына бүгенгегә күзен йомарга кодрәте дә, намусы да кушмады.

Сабир Салихович икенче каттагы тәрәзәдән кырлар өстенә кара күләгәләр булып ябырылган сузынкы авыр болытларга карап, җаваплы эшләрдә эшли башлаганнан бирле беренче тапкыр, дилбегәнең кулыннан ычкына баруын сизде. Болай да сүлпәнрәк характерлы, тымызык күңелле кеше җаны-тәне белән калтыранып куйды.

Бүлмә ишеге, үч иткәндәй, шыгырдап ачылды да беренче секретарьны сискәндереп чынбарлыкка кайтарды. Шул ук мизгелдә, һәрвакыттагыча җыйнак киемле, мөлаем йөзле секретарь кыз кереп, чакырылган кешеләрнең утырышлар залында җыелуын, атналык планерканы башларга мөмкинлеген әйтте.

Гайнуллин, гадәттәгедән авыррак, салмаграк адымнар белән утырышлар залына кереп китте. Сүзне бүгенге санда басылган мәкаләдән башлады, «Дуслык»тан кем килгәнлеген күзләре белән эзләде. Берәү дә юк иде... Һич көтмәгән төштән Сабир Салихович мәкаләдә күрсәтелгән кимчелекләр турында түгел, ә өлкә газетасыннан килгән корреспондент белән «Дуслык»ка барган яшь инструкторны битәрләүгә күчте. Теге, бичара, күптән түгел генә бер хуҗалыкның комсомол оешмасын җитәкләгән егет, ни әйтергә белмичә, баскан җирендә тораташтай катты да калды...

Яшь инструктор тагын ниләр ишеткән булыр иде, ярый әле секретарь кыз кереп коткарды. Ул күбәләк сыман ярым очып, ярым атлап Сабир Салихович янына килде дә «обкомнан шалтыраталар» диде.

Өлкә комитеты секретаре Сабир Гайнуллинга телефоннан бер генә җөмлә әйтте:

— Егерме минуттан Әлмәттән кайтучы вертолет Акъярга төшәр, шунда килеп торыгыз.

Колак төбендә пиип-пиип дип сузган тавышны тыңлый-тыңлый, Сабир Салихович: «Урып-җыю... икмәк тапшыру планы яна... өстәвенә тагын әлеге мәкалә»,— дип уйлап алды. Аннары залга чыкты да җыелган җитәкчеләрне хуҗалыкларына кайтарып җибәрде...

## 3

Шул ук иртәдә әлеге мәкаләнең авторы Дамир Хафизов әллә нинди, аңлашылмас тойгылар белән уянды. Күңел дигән нәрсә нидер сизенә, борчыла, сәбәпсезгә шатлана да иде кебек.

Торыргамы, юкмы? Бераз ялкауланып ятмакчы иде дә, кинәт бүген җыелачак санга мәкалә язып бирәчәге исенә төште.

Икенче мизгелдә инде ул, күптән күнегелгән гадәтенчә, сул кулы белән одеалын стена ягына әйләндереп салды, йомшак келәм өстенә торып басты. Хафизов ишек катындагы кечкенә тумбочка астыннан гантельләрен барып алды, тәрәзәнең ярты ягын ачып күнегүләр ясарга кереште. Бу аның шулай ук күптәнге гадәте, хәтта районнарда йөргәндә дә калдырмый торган ихтыяҗы иде. Редакциядә эшләгән өлкән иптәшләре дә белә аның бу гадәтен. Пресса йортында соңга калып эшләгән көннәрдә, баштагы мәлне күпләрне гаҗәпләндереп, коридор тәрәзәсен ачып күнегүләр ясарга керешә иде Хафизов. Тора-бара аның сәерлекләренә ияләштеләр тагы. Хәтта аңа иярүчеләр дә табылды. Очлы сакал, өске ирене аша авызына кērәм-кērәм дип торган әйләнмәле кара мыек җибәргән, әдәбият бүлегендә утыручы сотрудник хәзер инде Хафизовның үзеннән дә уздырып җибәрә...

Күнегүләр ясаганда, аннары ваннадагы душ астында салкын тамчыларга рәхәтләнгәндә дә иртәнге тойгылар югалмады, бәлки тагын

да көчәя төшеп, дулкынлануга әверелде: «Нәрсә булыр бу?»— диде Хафизов юыну бүлмәсендәге көзге алдында яңакларына күбек сөртеп кырынып торганда. Кичәге мәкалә шаукымы түгелме икән? Булыр да. Әнә бит, гомере буена авыл хуҗалыгын күтәрү юлларын күрсәтеп, авылда иген иккән белгечләрне өйрәтеп язган бүлек мөдире Мостафа Мөдәррисов үзенең көл сыман чәчләрен кирәк-кирәкмәскә артка сыпыра-сыпыра: «Кайбер урыннарын йомшартасы иде дә моның, ярар, калсын алайса», дип уздырды. Хәер, планерка вакытында баш редактор мәкаләне яклап чыкмаган булса, Мөдәррисовның уздырырга уе да юк иде бугай... Шәйхи Хәлиуллович күзләрен кыса төшеп, елмаер-елмаймас тыңлап утырды да: «Бирергә кирәк моны», дип кырт кисте. Ә кичә иртә белән планеркада Хафизов мәкаләсенә иң югары балл биреп, «алтын каләм» конкурсына элеп куйгач, Мөдәррисов аксак аягына гадәттәгедән ныграк авыша төшеп йөрде. Төшке ял вакытында бильярд сугучы хезмәткәрләрнең Хафизов мәкаләсен мактавын ишеткәч, «Һе, авыл хуҗалыгы бүлегенең кайчан йоклап ятканы бар», дигән булып, тизрәк бүлмәсенә кереп китте.

Хафизов бераздан Иске урам янындагы бакча аша узганда, аннары Свердлов урамыннан кольцога таба менгәндә, этешә-төртешә троллейбуска кергәндә дә әлеге тойгылардан тулысынча арына алмавына аптырады.

Казан елгасы аша салынган күпернең нәкъ уртасында Хафизов утырган троллейбус бер-ике мәртәбә дырык-дырык итеп тартылгалады да бөтенләй туктап калды. Озын ялы җилкәләрен томалаган, зәңгәрсу төстәге джинсы кигән троллейбус йөртүче егет алгы ишектән чыгып өскә таба карап торды да: «Ашыгучылар булса, җәяү бара торыгыз»,— диде. Кешеләр сукрана-сукрана юл кырыендагы сукмакка сибелделәр. Арттан килгән троллейбуслар, шартларга җитешеп тулганга күрә, алар яныннан тизлекне әкренәйтергә куркып, узып китәргә ашыктылар.

Шулай итеп, кешеләр килгәнче материалны язып бетерермен дигән өмет юкка чыкты. Аның каравы, Хафизов әллә кайларга кадәр җәйрәп яткан елга ярында балык тотып утыручы агайлар белән гәпләшеп алды. Үзе дә кармак сабы тотып чүгәләп торды. Дөрес, башкалар җименә әледән-әле килеп торган балыклар, аның кармагы тирәсенә әйләнеп тә карамады. Барыбер, иртәнге саф һавада, су буенда утыру үзе бер рәхәт икән. Хафизов моңа шатланды гына, тагы кайчан шулай утырыр идең әле, дип юатты ул үзен, кулындагы сәгать угының тугыз ягына таба җитез генә авышканын күреп. Пресса йортына барып житкәнче, югары катка күтәрелгәнче, тагын ике-өч минут узды. Лифттан чыгып коридор башына керүгә, секретариат бүлмәсенең ачык ишегеннән җаваплы секретарьның кабаланып кычкырган тавышы ишетелде.

— Син, Хафизов, балыкчылар әртиленә языласың калган, алай бик һәвәс булгач...

Аннары, кайдан күргән бу җен күз дигән сыман, авызын ерып ишекне томалап торган Хафизов кырыеннан яны белән чыга-чыга:

— Немедленно баш редакторга!— диде дә, башын югары күтәреп, кулындагы кәгазьләрне җилләндерә-җилләндерә кайсыдыр бер бүлмәгә кереп югалды.

Хафизов өстендәге плащ-накидкасын салып, секретарь кыз Сәгыйдә бүлмәсендәге кресло артына ташлады да редактор ишеген шакыды.

Күптән түгел генә алтмышны тутырган, ләкин егетләр шикелле чандырлыгын саклаган, озынчарак битле редактор Мөхәммәтов кайсысы тагын эшләргә комачаулый дигәндәй, өстәлендәге кәгазьләрдән башын күтәрде, күзлеге өстеннән сөзеп ишек катына карады.

— Рөхсәтме, Шәйхи Хәлиуллович, чакыргансыз икән...

Редактор житез хәрәкәт белән күзлеген өстәлдәге корректурага ташлап:

— Ә-ә-ә, иптәш Хафизов, рәхим итегез, утырыгыз,— диде, аның бүген гадәттәге кырыс тавышына бәләкәй кыңгырау чыңы кушылган иде. Болай да юка иреннәре тыгыз кысылган, кашлары җыерылган, күзләре һаман шулай, маңгай астыннан сөзеп карый иде.

Хафизов редактор алдында үзен хәрбиләрчә тота, хезмәткәр белән редактор арасын сакларга тырыша иде. Мөхәммәтовның кырыслыгын күреп, аның өстәленә аркылы терәп куелган өстәл башында басып калды. Баш редактор исә, аның каршысында Хафизов әллә бар, әллә юк, тагын берничә секунд төбәп карады, кинәт торып арттагы бүлмәгә кереп китте. Андагы телефоннан кем beләндер сөйләшеп алды, чыгып урынына утыргач кына:

— Обкомга җыен, иптәш Хафизов,— диде. Бераздан тагы:— Беренче чакыра,— дип өстәде, бу ни әйтер дигән сыман, тагын Хафизовка карап нидер көтә башлады.

Хафизов кымшанмады, күзләрен яшермичә, редакторга туры карап торды.

— Ничәдә?

— Һе, ничәдә ди тагын... Вакыты житкәч әйтермен, бар, әшеңдә бул, иптәш Хафизов.

Баш редакторның тавышында кырыслык артына яшеренгән ягымлылык, киң күңеллелек сизелеп тора иде. Хафизов сул җилкәсе аша борылды да паркет идәнгә җәелгән келәм буйлап ишеккә таба атлады.

Төшке ашка кадәр бер генә юл да язылмады. Бүлек мөдире Мөдәррисов, йөзендәге астыртын елмаюын яшермичә, бер керде, бер чыкты. Ниһаять, түзмәде, искә төшергән булып:

— Сез, иптәш Хафизов, бүгенге санга әйбер бирергә тиеш идегез түгелме соң?— диде.

Аның кисәтүенә карап кына мәкалә барыбер язылмады.

Сәгать беренче яртыда барысы да ашарга төшеп киттеләр. Хафизов олы капка кадәрле тәрәзәсен ачып, үтәли искән җилдән ишек ачылып китмәсен дип, иске газета бөкләп кыстырды да дүрт битлек мәкаләне бер тын белән язып ташлады. Аннары машинисткаларга кертеп чыкты, тырышып-тырышып яшьләр газетасыннан кергән бер һәвәскәр белән бильярд бәрә башлады. Ул арада промышленность бүлегендә эшләүче, шар сугарга дигәндә өенә кайтасын онытып торган Кара Кәрим менеп житте. Аның белән турнир партиясен уйнарга керештеләр.

Төш вакыты бетәргә егерме минутлар кала, бильярд тирәсенә редакциянең барлык ир-атлары җыйналды. Соңгы шар өчен аяусыз көрәш киерәнкелектән иң югары чигенә житте дигәндә, секретарь кыз Сәгыйдә килеп:

— Хафизов абый, редактор аска төшеп китте, тизрәк, тизрәк инде,— дип өтәләнә башлады. Барысы да тынып калды, коридор тәрәзәсеннән чыгар урын табалмыйча азапланган чебен безелдәгәне ишетелеп китте. Хафизов гаҗәпләнеп күтәрелеп карады, аннары бильярд таягын җайлап кына үзенә тартты да салмак этеп алга таба җибәрде. Бәрхет чүпрәк өстендә яткан соңгы ике шарның берсе сул, икенчесе уң яктагы лузага ыспай гына барып төштеләр. Хафизов, бүлмәсенә кереп, плащнакидкасын алырга онытмыйча, салмак адымнар белән коридор буйлап лифтка таба китеп барды.

## 4

Колхозчылар, яше-карты, эшләгәне-эшләмәгәне, тыштагы яңгырга карамыйча, башка вакытлардагы кебек ялындырып-нитеп тормастан, радио аша бер-ике кычкыруга, Яңавыл уртасындагы клубка таба агы-

ла башладылар. Моннан егерме еллар чамасы элек салынган агач клуб шактый бирешкән, кайбер урыннарында нигез бүрәнәләре бүлтәеп чыккалаган иде. Берничә ел инде сипләтергә уйлап йөрсәләр дә, игенчеләр өстенә ябырылган мәшәкатьләр мондый «вак-төяк» эшләргә вакыт та, көч тә калдырмады. Клубның киң болдырында тәмәке тартып, халык җыелганны көтеп аны-моны сөйләшеп торучы ир-атлар арасыннан берәү:

— Адәм мәсхәрәсе, колхозыбыз оешканга илле ел тула, ә безнең авыл күрке булырдай клубыбыз гына да юк,— дип куйды. Ир-атларга бу җитә калды.

— «Җиңү»нең культура сарае безне дә сыйдыра, әйдәгез, аларга кушылыйк соң...

— Һе, хитрый син, кар астында калачак икмәгеңне «Җиңү»гә сыламакчы... Алырлар, бар, көт...

— «Җиңү» председателе салына башлаган культура йорты нигезен сүтеп ферма салмады шул...

— Аларда да яңгыр ява, тик алар уракны бетереп киләләр. Бүгениртәгә чөгендергә чыгарга йөриләр бугай...

— Алар җиренә яуган яңгыр юеш түгелдер...

— Чистый кеше рәтеннән чыгып рисвай булдык бит, ә...

Җыелышны озакка сузмадылар. Яңгыр явып, ындыр табагында, басуларда игеннәр юештән интегеп кара яна башлаганда, озын-озын сүз куертып утыру бик үк килешә торган нәрсә түгел иде. Игеннәрне киптерү, кырдагысын кар астында калдырып әрәм итмәү, җыеп алу өчен ашыгыч чаралар күрергә, кешеләрне әнә шул көрәшкә оештыру-туплау кирәк иде.

Колхозчыларның күпчелеге нәкъ шулар хакында ачынып сөйләде— колхоз председателен мондый вакытсызрак чакта алыштыру мәсьәләсенә аек карадылар. Чөнки эшләрне кемдер оештырырга, башлап йөрергә тиеш, ә Хәйдәр Яруллин көннәр буе югалып тора.

Әйе, халык әйтсә — хак әйтә, нишләп соң без Яруллинның кемлеген белә торып, бу хакта әлегрәк уйламадык? Нишләп соң аның вәгъдәләренә ышандык, дип уйлап утырды Сабир Гайнуллин.

Сәхнәгә комбайнчы Шиһабетдин Мөгыйнов чыкты. Халык бердәм тынып калды. Мөгыйнов гадәттә җыелышларда чыгыш ясап, нинди дә булса кимчелекләрне күрсәтмичә калмый, ул сүзен ярып әйтә белә иде.

— Колхозның мондый хәлгә калуы барыбызның намусына тап төшерә, иптәшләр,— диде ул, сүзләрен бераз сузыбрак.— Турысын әйтәм, соңгы бер-ике елда Хәйдәр Яруллин үз-үзенә артыграк ышанды. Кешеләрне санга сукмады. Безнең өчен аның мондый хәлләре яңалык түгел, иптәш Гайнуллин...

Мөгыйнов кулларын әле трибуна өстенә куеп, әле аска яшереп интегә иде. Ниһаять, ул аларны артка куйды, һәм райкомның беренче секретарена таба бөтен гәүдәсе белән борылды. Аның куе кашлары астындагы күзләре очкынланып китте.

— Бу хакта, иптәш Гайнуллин, партиянең район комитетына да мәгълүмдер дип уйлаган идек без. Чөнки авылдашлар сезгә бер генә язмадылар. Мужыт ялгышамдыр, миңа барысы да билгеле түгел, ләкин Хәйдәр Яруллинга күбрәк ышандылар, аны күбрәк тыңладылар.

Сабир Салихович, киеренкелекнең чигенә җитүен сизепмедер, аягүрә басты. Алдындагы графинга ручкасы белән суккалап алды, күкрәге тулганчы сулыш туплады да, җыелган халык өстенә туры карап әйтте.

— Елның болай килүе, иптәшләр, безнең өчен көтелмәгән хәл булды. Ләкин моңа карап акланырга җыенмыйбыз. Техниканы вакытында карасак, оештыру эшләренә игътибарлырак булсак, уракны атна-ун көндә тәгәлли ала идек. Башка районнарда да яңгыр булмады түгел,

булды, ләкин күпчелек хуҗалыклар игеннәрне безнең шикелле хурламады. Боларның барысы да, иптәшләр, анализланыр әле. Сезнең бүгенге хәлне дөрес аңлавыгыз шатландыра. Миңа калса, иптәш Ярулинның халык ышанычын акламавы икеләтә авыр, чөнки без аның белән бер полкта хезмәт иткән идек... Ул чагында ул күпләргә үрнәк иде. Аның урынына башка берәү, энергияле, белемле, авылны ярата торган кеше кирәк. Бәлки колхозчыларның үз тәкъдимнәре бардыр?

Зал тынып калды. Тәрәзәгә бәреп яуган яңгыр тамчыларының эчпошыргыч бертөрлелегә болай да киеренке хәлне тагын да көчәйтә иде. Берәү дә тәкъдим кертергә атлыгып чыкмады. Авыр тынлык тагын күпме дәвам иткән булыр иде, саф һава керсен дип ачып куелган ишектән, ни кич, ни иртә дигәндәй, этәч кычкырган тавыш ишетелде. Арыган йөзләр бераз ачылгандай итте. Шул вакыт, теләсә кайчан үз туксанын туксанларга яратучы, дуамаллыгы белән бөтен тирә-як авылларга танылган, җитмеш төрле һөнәр иясе булып дан тоткан Озын Әхмәт, салмак кына, ләкин барысына да ишетелерлек итеп:

— Сукыр әтәч саташкандыр, безнең шикелле... Урак өстендә рәис алыштырабыз...— диде.

Кайберәүләр моңа елмаеп куйды, кайсылары көлеп үк җибәрделәр. Озын Әхмәтнең әлеге сүзләреннән әйтелеп бетелмәгән мәгънә табучыларның бер дә юкка көлүе бүтәннәргә дә йокты. Сукыр әтәчнең саташкан тавышы, Озын Әхмәтнең урынлы-урынсыз чагыштыруы колхозчыларны җанландырып җибәрде. Кеше күңеленә күп кирәк мени, аны бер сүз белән моңландырырга да, дәртләндерергә дә мөмкин ләбаса.

Сабир Салихович үзе дә соңгы вакытларда күңелен биләгән авыр уйларыннан берьюлы бушанып калгандай булды. Халыкның бераз тынычлана төшүен көтеп алгач, Сабир Салихович, шахматчылар теле белән әйтсәң, алдан ук уйлап килгән «йөрешен» ясады.

— Иптәшләр,— диде ул. Аннары, тавышларның бөтенләй тынганын көтеп алды да: — Акъяр район комитеты бюросы «Дуслык» колхозының правление председателе итеп авылдашыгыз, өлкә газетасының корреспонденты Дамир Хафизовны тәкъдим итә... Ул югары белемле, элек, үзегез беләсез, авыл хуҗалыгы техникумын бетергәч, агроном булып эшләп алган иде... Моңа ничек карыйсыз?

Җыелышта баягыдан да хәтәррәк тынлык урнашты. Сабир Салихович, ни тәҗрибәле кеше, халыкның ни әйтәсен чамалый алмыйча интекте. Зал умарта күче сыман дәррәү гүләргә тотынды.

— Үзе ризамы соң??
— Үзе кайда, үзе??
— Ай-һай, шәһәрне авылга алыштырыр микән?
— Язарга оста, эшләп күрсәтсен менә...
— Тагын ялгышмабызмы??
— Сайлыйбыз, ник сайламаска? Үзебезнең авыл малае, кайтсын, эшләсен...

Колхозның партоешма секретаре Семенов җәһәт кенә урыныннан торып сәхнә артына чыгып китте. Тагын бер-ике минуттан Семенов, аның артыннан Дамир Хафизов күренде.

Ул таза гәүдәле, уртачадан биегрәк буйлы, күперел торган куе мыеклы, шундый ук чигә сакалы җибәргән, маңгае өстендә ике яклап, диңгез култыклары шикелле, чәче коела башлаган, зәңгәр күзле, ягымлы йөзле, ир уртасы бер кеше иде. Җыелыштагылар янына кергәч аның йөзе кырыслана төште, маңгаендагы өч рәт булып яткан буразналар тагын да тирәнәйде.

— Исәнмесез, авылдашлар!

Әле анда, әле монда «Саумы, исәнме?!» дигән тавышлар ишетелгә-

ләде. Аннары, залдагы тавышлар бергә кушылып, тоташ бер дулкынга әверелде.

Сабир Салихович, халык алдына башын иебрәк чыгып баскан Хафизовка сынаулы караган килеш, обкомдагы өченче көнге сөйләшүне исенә төшерде.

— Иптәш Хафизов, әйтүләренә караганда, сез хәрби хезмәттә булгансыз икән. Агроном таныклыгын да алгансыз. Белемегез дә бар. Мәкаләдән күренгәнчә, авыл хуҗалыгын яратасыз, аның өчен борчыласыз. Язганнарыгыз чын күңелдән икән... Үзегезнең районга эшкә кайтырга сез каршы түгелме?— диделәр аңа.

Бу тәкъдимне Хафизов ничектер тыныч кабул итте.

— Мин риза,— диде сугышчан боерык алгандагы сыман.

...Колхозчылар, гөжелдәүдән тынып, Сабир Салихович ни әйтер дип көтә башладылар. Ул халык арасындагы таныш йөзләрне барлагандай сулдан уңга таба күз йөгертеп чыкты.

— Менә, иптәшләр, сезгә яңа председатель...

— Беләбез, беләбез аны,— дигән тавышлар ишетелде халык арасыннан.

Гайнуллин исә тимерне кызуында сугарга теләп:

— Ышанып тапшырабызмы соң Хафизов иптәшкә колхоз дилбегәсен, әллә юкмы?— дип сорады.

Җыелыштагылар, Хафизовның кырысланган йөзенә төбәлгән килеш, берәм-берәм ризалык белдереп кул күтәрә башладылар.

Сүз биргәч, Хафизов, дулкынлануын яшерергә тырышмыйча, бераз тотлыга төшеп:

— Авылдашлар... Ышаныч күрсәтеп мине сайлавыгыз өчен рәхмәт. Мин ул ышанычны акларга тырышырмын. Иңгә-иң куеп эшләрбез, яшәрбез, колхозны өзеклектән бергәләп чыгарырбыз. Тик... холкымны беләсез, кеше исәбенә яшәргә тырышучы, устав бозучы ялкауларга көн булмас,— диде.

Кайберәүләр бу сүзләрне чираттагы председательнең «яхшы» булырга тырышуы дип уйладылар, ләкин күпчелек, бигрәк тә, кайчандыр Хафизов белән бергә эшләгән механизаторлар, аның холкын бик яхшы беләләр иде. Каршы кул күтәрүчеләр булмады...

Колхозчылар төркем-төркем булып таралыштылар. Саркып яуган салкын яңгыр туктарга уйламады да. Яңавыл өстенә ябырылган болытлар агач башларына тия язып каядыр еракка, Урал таулары ягына агыла. Басулардагы карала башлаган авыр теземнәр һамыл төбенә тагын да ныграк сеңә бара иде.

## 5

Колхоз ашханәсендә көндәге вакытка чамалап өлгертелгән аш-су куерып, савыт-саба төбенә утырып бетте. Надирә «инде килмәсләр, җыелыштан соң өйләренә таралыштылар бугай» дип, соңгы тапкыр карап кермәкче булып болдырга чыккан иде. Бер төркем ир-атның пычрак ерып ашханәгә таба килгәнен күреп алды. Һәм ашыгып эчкә атлады. Аннары, һич кирәкмәгәнгә, савыт-сабаны күчергәләргә, кая барып нәрсәгә тотынырга белмичә аптырады. Килүчеләрнең болдыр төбендәге тимер тагаракта итекләрен юып, ара-тирә сөйләшкәләп керүен ишеткәч, тәмам хәле бетеп, кече яктагы агач урындыкка утырды.

Җыелыштан кайтучыларның сүзе дөрес булып чыкты. Теге юлы килүендә Надирә аны күз кырые белән генә күреп калган иде. Хәзер бер караудан таныды ул аны. Әйтерсең, егерме ел үтмәгән, әйтерсең, озын-озак еллар аларны аерып тормаган, икесен ике якка сибеп җибәреп сынамаган... Председатель итеп Дамир Хафизовны кайтардылар, дигәч тә күңеле бик үк ышанып бетмәгән иде аның. Башта «булмас,

шул кадәр елдан соң авылга әйләнеп кайтмас, Казандагы эшен ташламас», дип уйлый башлаган иде дә, үзенең дә күптән түгел генә тиктомалдан авылга кайтуын хәтерләп алды.

«Нишләп утырам соң мин, кешеләр көрде бит инде, аш-суларым суынып беткән, җылытырга кирәк»,— дигән уй белән Надирә үзен урыныннан кузгалырга мәҗбүр итте. Ул арада килгән кешеләрнең җитәкчеләр ашый торган бүлмәгә узганы ишетелде. Ниһаять, Дамир тавышы яңгырады... Надирә ул тавышны егерме ел аша гына түгел, күкләр күкрәгәндә, мең гөрелте арасыннан да таныр иде... «Нишләргә соң, ничек чыгып күренергә, ходаем?»— дигән уй тагы бер кат ялтырап узды. Хәлсезләнүе өстенә Надирәнең башы чатный, чигәләре кыса башлады. Аннары күз алларын ниндидер кара таплар томалагандай булды. Мондый хәл Надирәне тагын да каушата төште. Шул чак кухня ягы тәрәзәсен кактылар. Надирә җиңел капкачларны ике якка ачып җибәрде. Кешеләрне бары тик ачык йөз белән генә каршылавын белгән Семенов Надирәнең төксе чыраен күреп аптырап торды. Аннары чувашча:

— Аш-суың пармы, Надирә? — диде.

Надирә сүзсез генә борылып чәнечке-кашык ала башлады. Ничәнче кат инде «менә хәзер күрешәбез, очрашабыз, гомерлеккә дип аерылышсак та, очрашабыз хәзер. Нишләргә, ничекләр генә итеп түзәргә, аны-моны сиздермәскә соң??»— дип уйлады Надирә.

Кухня ишеген чыгуга күрде ул аны. Шул мизгелне көтеп кенә торганнар диярсең, күз карашлары томырылып очрашты. Надирә ничек торган булса шулай бусагада туктап калды. Хафизов та торып басарга теләгәндәй урыныннан кузгалып куйды, янәдән утырды. Чәчәкле күлмәк өстеннән алъяпкыч бәйләгән, куе кара толымнарын җилкәсе аша салган, башына ак калфак кигән Надирәдән күзләрен алалмады. Гүя ул:

— Синме соң бу, Надирә?— дип сорый иде.

— Әйе, мин бит бу, мин Дамир...

— Син авылдамыни, Надирә?

— Син дә кайттыңмы, Дамир?

— Мин сине эзләдем, эзләдем бит, Надирә...

— Мин дә...

Хафизовның күзләрендә сагыш катыш үкенү төсмерләре чагылып китте. Аларның сүзсез, күз карашлары белән генә сөйләшүе бик озак дәвам иткән кебек булды.

Надирә өстәл тирәли йөри-йөри кунаклар алдына чәнечке-кашыклар тезә башлады. Дамир исә аның салмак хәрәкәтләрен, бераз гына калтыранган иреннәрен, еш-еш күтәрелгән күкрәкләрен йотылып карый бирде.

Сабир Салихович китәргә ашыкканга күрә идарә утырышында катнашмаячагын әйтте. Шулай да җыелган кешеләрне тагы бер мәртәбә, әле яңа гына күргән шикелле, барлап чыкканнан соң:

— Иптәш Хафизов, иптәш Семенов, идарәдә иң кискен, иң нәтиҗәле чаралар билгеләрсез дип ышанам. Без бу хакта сөйләшкән идек, кабатлап тормыйм. Иртәгә иртә белән шалтыратырсыз. Район комитеты, райбашкарма мөмкин кадәр ярдәм күрсәтер. Ләкин, турысын әйтәм, ярдәм көтеп ятмагыз, үзегездәге резервларны кыюрак ачып эшкә аһыра барсагыз хәерлерәк булыр. Райондагы кыен хәлне беләсез. Икмәк тапшыру планы өзелә... Сез, иптәш Хафизов, өлкә комитетында булдыгыз, үз колагыгыз белән ишеттегез. Шулай булгач... шулай булгач,— дип кабатлап торды да, кинәт, янәшәсендәгеләрне сискәндереп, һич көтмәгәндә, чалышма аяклы өстәлнең утызлы такталарына авыр йодрыгын төшерде.— Иптәш Хафизов, кайчан сайлануыгызга карамастан, эшләр торышы өчен җаваплылык — тулысы белән сезнең өстә. Моны бер минутка да онытмагыз.

Райком секретареның кыркулыгын белүчеләр дәшмәде. Хафизов исә мондый «кискенлекләрне» армиядә байтак күргән, ишеткән кеше — артык исе китмәде. Аның күз каралары кечерәеп, хәлиткеч бәрелешкә әзерләнгәндәге сыман, очкынланып китте. Сабир Салихович моны искәреп алды. Ул яңа председательнең уйнаклап торган яңакларына карап «моның характеры би̇решә торганнардан түгелдер», дип уйлап алды. Хафизов аңа туры карап:

— Иптәш Гайнуллин, кулдан килгәннәрнең барысын да эшләргә тырышырбыз, әлбәттә. Ләкин... текә тауга менгәндә тракторның тизлеген алдан чамалап тоташтыралар, югыйсә, тауның иң кыен җиреннән кире тәгәрәп төшүе мөмкин...— диде.

Партком секретаре Семенов өстәл астыннан Хафизовның тезенә төртеп алды. Тегесе «кискенрәк әйтеп ташладым бугай, ләкин аның һәр сүзенә баш селкеп торып булмас бит», дип үз-үзен тынычландырды.

Сабир Салихович Хафизовның ни әйтергә теләвен аңлады.

— Сезнең, иптәш Хафизов, сүзгә бай кеше икәнлегегезне газеталардан укып белә идек, инде үзегез белән сөйләшү бәхетенә ирешкәч, тәмам ышандык.... Эшегезне дә шулайрак башкарсагыз... бик әйбәт булыр иде.

Өстәл янына Надирә килеп басты. Аның кулында булары чыгып торган кәстрүл иде. Борыннарны кытыклап тавык шулпасы исе таралды. Надирә чәчәкле тәлинкәләргә аш бүләргә кереште. Хафизов аның дулкынланган йөзенә караган килеш санаулы секундлар эчендә әллә ни кадәр вакыйгаларны күз алдыннан уздырып өлгерде...

Күз ачкысыз бураннары белән хәтердә уелып калган март ае иде. Урманлы урта мәктәбендә чит авыллардан йөреп укучылар өчен оештырылган тулай торакның янәшә бүлмәләрендә яшәүче сигез кыз һәм сигез егетнең ундүртесе ул көнне авылларына кайтып китте. Дамир белән Надирә сүз куешмыйча-нитмичә тулай торакта калдылар, кайтып йөрмәскә булдылар.

Дамир тиз-тиз генә ике мичкә дә җитәрлек утын кертеп ташлады. Иртә белән ягылмаганга күрә бүлмәләрдә җылы әсәре калмаган. Өстәвенә ял көннәрендә ашханә эшләми, Минҗан апалары тары өйрәсен пешерми, димәк, тамак ягын да кайгыртасы бар иде. Анысын Надирә үз өстенә алды, Дамир мичкә ут дөрләтеп җибәрде, кәстрүлгә су салып куйды, бәрәңге әрчергә кереште. Турысын әйткәндә, Дамирлар ягында аш пешерер өчен кәстрүл белән судан башка нәрсә юк та иде. Кыз моны белә, чөнки бүлмәләрне икегә аерып торган бүрәнәләр юан булса да, урта бер төштә кул яссуы кадәр ярык бар иде. Егетләрнең барлык «серләрен» кызларга җиткереп торган «информация үзәге» санала иде ул. Ә егетләр, ни сәбәптәндер, үзләренең кычкырып сөйләшүләрен бүтәннәр ишетер дип уйлап та карамыйлар иде.

Язның башы гына әле, көн ярыйсы ук озынайса да караңгы тиз төшә. Җитмәсә, берничә көн буе дулаган буран кояш әсәрен күрсәтми, авыл кышкы ялга талган иде.

Озакламый кызлар ягыннан пешкән бәрәңге исе кереп борынны кытыклый башлады. Ул да түгел Надирә утын пуләне белән стенага суккалап тавыш бирде, ашарга чакырды. Китап белән мавыгып дөньясын онытып утырган Дамир чакыруга игътибар итмәгән иде, «сигнал» кабатлангач урыныннан торды да чәчен артка тарап кызлар ягына кереп китте.

Ут кабызмадылар, унлы лампаның куыгы шартлаган иде, мичтә янган ут яктысында авызларын пешерә-пешерә туйганчы бәрәңге ашадылар.

Март аеның җилле-буранлы төне әллә нинди, аңлашылмас могҗизалы сәер бер төн иде. Ул төнне ахырдан — Ерак Көнчыгышның кеше

үтеп чыгалмаслык урман-тайгаларында, Байкал аръягының ачы җилләре котырынган салкын төннәрдә, Кара-ком чүленең аяусыз кояшы астында бер кабым суга тилмереп үлем белән якалашкан минутларында да искә төшерде Дамир.

Күзләренә йокы кермәде. Сөйләшәсе сүзләр бетмәде. Кайдадыр, мич астындамы, тынгысыз чикерткәләр сайрашудан туктады... Гомердә беренче тапкыр туйганчы үбешү, сөйгәнеңнең якынлыгын тою Надирә белән Дамирны тәмам исертте. Алар бу бүлмәдән башка дөнья барлыгын бөтенләйгә, бөтенләйгә оныттылар. Мичтә җемелдәп киткән утлы күмерләр сыман кайнар хисләр аларны моңарчы татымаган дөньяга алып китте. Надирәнең хәлсезләнгән күз кабаклары калтыранып, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй итәләр, ләкин бер генә сүз, бер генә хәрәкәт тә аларны аера алмый иде. Надирәнең уттай кызу, тыгыз тәнендә орыну, аның кайнар сулышын тоюдан егетнең йөрәге күкрәк читлегеннән бәреп чыгардай булып тибә башлады. Тыннар кысылды. Надирәнең йомшак куллары Дамирның муенына уралдылар. Кайнар иреннәр, кабарып, түземсезлек белән бер-берсен эзләп таптылар да бергәбергә кушылдылар. Аннары алар, башка беркайчан да кабатланмаячак минутларның җиңүле тантанасын бозарга кыймыйча, бердәм тәләккә карышмыйча, караңгы упкынга таба ташландылар.

Төнге эңгер-меңгер бер куерды, тагын яктырып киткәндәй булды. Тышта котырынган җил бүлмә тәрәзәләрен калтыратып алды. Дамир да, Надирә дә берни тоймадылар, ишетмәделәр. Йөрәкләрдә кузгалган дулкын аларны ерак-еракларга, килер көннәр юлында очраган барлык киртәләрне ватарга-җимерергә чакыра иде...

### 6

Яңгыр бер көчәеп, бер иләктән иләнгәндәй вак тамчылар булып ява бирде. Әнә тегендә, Мәрәҗән тавы өстендә тагын болытлар куера. Һава да салкынчаланды, тамчылар да цинк тутырган сыман авырайдылар. Сөлчә елгасындагы су еraktан караганда яшелләнебрәк күренә. Гадәттә елга суы зәңгәрләнеп тора, җылы, йомшак була торган иде. Ләкин быел бик сирәк кешеләр генә аның суында колач җәеп йөзә алгандыр. Кайчандыр Дамир Хафизов та шушы елганы иңләп йөзә, атлар коендырырга төшә, көзге салкыннар башланып, су йөзе ялтыравык зәңгәрсу боз белән капланса, тизрәк шунда ашыга иде. Хафизов туган авылына кайтуына үкенми үкенүен, ләкин монда эшләп, үзенең күптәнге хыялларын тормышка ашыру, чит-ят якларга киткән авылдашларын мондагы хәлләрне күреп кайтырлык итүнең җиңел булмаячагын аңлый, төшенә иде. Ләкин бит кемдер эшләргә тиештер. Кемдер туган җир җылысын башкалар сизәрлек итәргә тиештер...

Хафизов туган якларына кайткач, аның урамнарында, су буйларында йөргәндә иркенрәк, тирәнрәк сулый шикелле. Йөрәк тә ничектер ышанычлырак, тигезрәк тибә, берничә ел элек булган имгәнү-сызлануларның шаукымы да онытыла кебек. Дамир аңлый, үзенең тормыш тәҗрибәсеннән белә: кеше үзенең туган-үскән, яшьлеге чәчәк аткан, олы тормышка аяк бастырган туган җирен, аның җылысын беркайчан да, теләсә генә нинди шартларда да оныта алмый. Туган җирне тою кешене беркайда да ятим итми, аның адымнарын ныгыта. Чынлап та, кешенең балачагы, аннары үсмер еллары, яшьлеге иксез-чиксез күк йөзеннән аккан һәм беркайчан да кире кайтмый торган болытлар сыман китә дә югала, ә туган җирне тою хисе кала.

Хафизовның уйларын бүлдереп, алданиндидер тавыш ишетелде. Кемдер авызын ачар-ачмас шыңшып җырларга азаплана иде. Ул да түгел, әлеге җырның мәгънәсе ачыклана төште.

Уффаларга барган чакта
Бәл-ләбәй уңда кала...

Дамир, шушы җырны ишетүгә, аның хуҗасын таныды. Озын Әхмәт иде ул. Гомер-гомергә аның авызыннан авылдашлары бүтән җыр ишетмәделәр.

Уффалардан кайткан чакта
Бәләбәй сулда кала...

Хафизов барган җиреннән туктап, каршыдагы баганага сөялеп торучы Озын Әхмәткә карады. Ул телен көчкә әйләндереп, тотлыга-тотлыга:

— Эһ-һем, персидәтел булдым дисең инде, ә... Дамир туган... Әйдә, бул, бул әйдә. Кар-ра аны, персидәтел, кар-ра... Сиңа монда ать-два әйтеп, я булмаса газетага тегене-моны язып утыру түгел... Теге вакытта... хәтерлисеңме... эһ-һем... безне шабашниклар дип мыскыллап язган идең... ә?

Хафизов исерек кеше белән сүз көрәштереп торуны артык эшкә санапмы, әллә бүтән төрле уйга килепме, Озын Әхмәтне уң кулы белән юлдан читкәрәк этәрде дә алга атлады. Әйе шул, җиденче класста укыганда бугай, Озын Әхмәтне һәм аның өч иптәшен, уттай кызу урак вакытында күрше авылга китеп бура бурап йөрүләрен район газетасына язган иде. Аның мәкаләсе янына, бигрәк тә килештереп, Озын Әхмәтне һәм аның иптәшләрен сурәткә төшереп куйганнар иде. Шул ук кичне клуб янында үз ишләре белән уйнаган төштән аны кемнеңдер тимер шикелле нык, каты кулы тартып чыгарды. Шул ук мизгелдә Дамирның күз алдында бүрек хәтле ут йомгагы хасил булды, аллы-гөлле чаткылар тирә-якка сибелде...

Аннан бирле күп сулар акты, әмма Озын Әхмәт шуны онытмаган, хәтерли икән ләбаса...

Идарә әгъзалары җыелган иде. Ишек туктаусыз ачылып-ябылып торганга яңа керүчегә игътибар иткән, борылып караган кеше булмады. Хафизов дәшми-тынмый гына өстәл янына узды, тәртипсез шаушу үзеннән-үзе тына башлады. Ул арада плащ-накидкасын салып мич артындагы чөйгә элгән Хафизов, тамагын кыргалап алды, җыелган колхозчыларны барлап карады. Тәрәзәгә бәреп яуган яңгыр шавы ишетелердәй тынлык урнашты. Хафизов берәүгә дә төбәп карамыйча:

— Иптәшләр,— диде.— Хәзер үк барыгыз да бүлмәдән чыгып унунбиш минут саф һава сулап керәсез. Һәм моннан соң бу бүлмәдә берәү дә тәмәке тартмаска тиеш,— дип өстәде һәм, кешеләрнең чыгып беткәнен дә көтеп тормыйча, бердәнбер ачылмалы тәрәзәне ачып җибәрде.

Бу моңарчы хуҗалыкта күрелмәгән нәрсә иде. Сугыштан соңгы еллардан ук килгән гадәт — председатель бүлмәсендә җыелып тәмәке төтәтеп утыруга моңа кадәр булган җитәкчеләрнең берсе дә каршы төшмәгән иде. Хәзер кайберәүләр беренче утырыштан ук шушы гадәтне җимереп ташларга җыенган Хафизовның кырыслыгын «яңа себерке яңача себермәк була», дип уйладылар. Әмма күпчелек дәшмәде, чөнки тәтенгә күмелгән бүлмәдә сәгатьләр буе утыруның әллә кайчан онытылган начар гадәт икәнен аңлыйлар иде.

Тәнәфестән соң, салкынаеп калган, ләкин еллар буена сеңгән тәмәке исеннән арына алмаган бүлмәдә Хафизов идарәнең беренче утырышын ачып җибәрде. Барысы да «тагын ни әйтер бу, ни генә әйтеп исне китәрер, яңгыр астында яткан игеннәрне ничек коткарыр икән», дип көтә башладылар. Яңа җитәкче исә бөтенләй сөйләмәде. Колхоздагы урып-җыю эшләренең шул сәгатьтәге торышы белән вак-төягеп дә калдырмыйча таныштырыгыз, дип сүзне баш агроном Вәли Гомәревкә

бирде. Үзе өстәлгә җәелгән кәгазьдәге саннарга-күрсәткечләргә төбәлде, әлеге дә баягы, куен дәфтәрен чыгарып кулына каләмен алды.

Гомәрев тәбәнәгрәк буйлы, түгәрәк йөзле, кечкенә күзле, илленең өске ягына чыккан кеше, шулай ук куен дәфтәрен чыгарды, бармагын теле белән юешли-юешли кирәкле битен эзли башлады. Гомәревнең таушалып беткән куен дәфтәрен күргәч, идарә әгъзалары, чакырылган механизаторлар, укытучы-агитаторлар, гадәттәгечә, чәнечкеле сүзләр әйтмәсәләр дә, үзара елмаешып куйдылар. Гомәревнең үз сүзләре белән әйткәндә «кесә бухгалтериясе» иде бу. Кызыксынган кеше соңгы ике-өч елда колхозда нинди орлык, нинди сортның кайсы басуга күпме чәчелгәнен, кайда, кайчан, күпме ашлама алынганын һәм тагын бик күп төрле башка мәгълүматларны аннан таба алыр иде. Аннары әлеге куен дәфтәренең тагын бер сере бар. Гомәрев әлеге «бухгалтерия»не башта карандаш белән язып тутыра, аннары икенче яктан башлап кара каләм белән яза иде.

— Дөресен әйтсәк, иптәш Хафизов, эшләр начар безнең. Аек акыл, үткер күз белән карасак, эшләр хөрти безнең...— диде баш агроном, бары тик председательгә генә мөрәҗәгать итеп. Чөнки монда утыручыларның һәрберсе эшләр барышын, чынлыкта, бөтенләй бармавын беләләр иде.— Әйе, хөрти, иптәш председатель. Менә үзегез чамалап карагыз, ниндирәк картина килеп чыга: уракка сентябрьнең башында, бүтән елларда эшне тәгалләгән вакытта төштек. Атнага якын борчак тирәсендә үтте. Беркөнне күрдегез, борчакны яшел килеш урып ташладык. Бөтен комбайннарны туплап, алдынгыларча эшлибез дип, борчакта тотасы калмаган да бит... Иптәш Яруллин, киткән кешене яманлый дип уйламагыз, «ипатовлыларча эшлибез», дип шулай кушты. Тагын мең ярым гектар арыш, көзге бодай, арпа һәм солы ята. Борчакның яртысы тезәмнәрдә үрә. Комбайннар...

Күзләрен мәгълүматлар язылган җәймәдән алмыйча, алдындагы дәфтәренә нәрсәдер сызгалап утыручы Хафизов баш агрономны шул төштә туктатты. Күзләрен йөгертеп бүлмәдәгеләрне барлады, кемнедер эзләде, таба алмагач:

— Алары турында безгә инженер сөйләсен,— диде.

Аргы почмактан кемдер:

— Безнең инженер — Насыйбулла абый былтыр кыш ук дөнья куеп бөтен эшне бозды шул. Югыйсә мондый хәлгә калмаган да булыр идек,— дип төрттереп әйтеп куйды. Бер-икесе, урынсызрак булса да, көлгәндәй итте. Ләкин, кушылучы булмагач, телләрен аркылы тешләп, тынып калдылар.

— Ярый соң, алайса, инженер вазифаларын башкаручы сөйләсен... Анысы исәндер бит...

Хафизовның теге төрттерүне шаяруга борып җибәрүе барысына да ошады бугай, алдагы урыннарның берсенә карап, беркавым көлешеп алдылар. Беренче рәттән уртача буйлы, атлы гаскәрдә хезмәт итүченекедәй кәкре аяклы, яшенә күрә шактый нык, таза гәүдәле кеше — Минап Ризаев күтәрелде. Ул председатель өстәленең бер почмагына килеп бала башы кадәрле йодрыгын куйды да гөбедән чыккан сыман юан тавыш белән сөйли башлады.

— Соң бит, иптәш председатель, ни бит. Быелгы яңгырларны бездән ким белмисез бит. Мондыйда җир өстенә комбайн кертеп буламы? Булмый. Без, иптәш Хафизов, гомер буе шушы колхоз арбасын тарткан кешеләр, хуты булса, шул кадәр мул уңышны җыймас идекме әллә? Җыяр идек. Моңарчы бит әле, кемнәрдер читтә йөри дип, ярдәм килгәнне көтеп ятмадык, эшләдек, сынатмадык...

Хафизов аның чәнечкеле сүзенә баягы кебек үк игътибар итмәде, бүлдерде дә:

— Иптәш Ризаев, комбайннарның, тракторлар паркының һәм силос техникасының ни өчен тик торганын аңлатыгыз,— диде.

Ризаевның башы белән тигез кушылган юан муены кызара башлады, ләкин тиктомалдан яңа председательгә бәйләнер урын юк иде. Шуңа күрә үз-үзен тыеп дәвам итте.

— Соң бит, ни бит, иптәш председатель. Техникага нәрсә аңа — торалар басып. Комбайннарның уникесе худта, калганнарының күчергечләр тартмасы кырылып чыкты, шкивлар, ременьнәр юк. Берсенең аккумуляторын алып киткәннәр...

Ризаев яңа председательнең урыныннан кузгалуын күреп, сүзеннән туктады, авызын ачып карап тора башлады. Хафизов бер җөмлә белән утырыштагыларның исен китерде.

— Идарә әгъзалары риза булса, колхоз техникасын урып-җыюга әзерләүдә гафу итмәслек җинаятьчел салкынлыгы өчен Ризаевны эшеннән алырга тәкъдим итәм...

Һәм Хафизов аягүрә баскан килеш уң кулын күтәрде.

Башкалар, бу ни бу, дигәндәй, бер-берсенә карашып алдылар, ләкин партком секретаре Семенов, аның янәшәсендәге берничә кешенең килешүен күреп, берән-сәрән генә кулларын күтәрделәр. Хафизов бу юлы икеләнергә урын калдырмыйча:

— Инженер вазифаларын башкаруны авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укучы иптәш Вәлиуллин Таһирга йөкләргә мөмкиндер, иптәшләр,— диде.

Шик тә юк, эшлекле тәкъдим иде бу. Таһир менә дигән механизатор, яшьлегенә күрә түгел, тырыш, һәр эшне җиренә җиткереп башкара торган егет. Идарә әгъзалары моңа каршы килмәделәр. Шул вакыт уртадагы рәттән комбайнчы Шиһабетдин «рөхсәтме» диде дә янәшәдәгеләрне этә-төртә алга чыгып басты.

— Сүз боткасы куертабыз, җәмәгать... Ярый. Уракка, чынлап та, кеше кебек хәстәрләнә алмадык, что факт, то дөрес. Хәзер нишләргә? Председатель комбайннарны тракторларга тагып өстерәтергә диме? Мин — риза. Тик аларны бит әле төзәтәсе бар, ә запчасть кайда? Минем мондый тәкъдим бар: әйдәгез уналты урынына уникене җыеп куйыйк...

Күрәсең, Шиһабетдинның бу сүзләре башкаларның авырткан җиренә тиде, гүләү көчәйде. Арткы рәттән баядан бирле кыбырсып, сүзгә кушылырга чамалап утыручы Мотыйгулланың:

— Акылың баш икән... Үзеңнекен сүтәргә бирәсеңме соң? Бирерсең син...— дигән тавышы ишетелде, аннары үзе дә торып ук басты. Элек-электән үз комбайнын күз карасыдай саклавы, шуңа күрә башкалар өчдүрт җәй үтүгә бүтәнгә күчеп утырганда да искесе белән дөбердәтеп эшли торган Шиһабетдин бу юлы:

— Бирәм, кәнишне, ник бирмәскә. Җәл түгел, элегрәк җәл иде. Элекке елларда мин алты-җиде мең центнер суктыра идем. Җиребезгә карата аз түгел иде. Быел тавыклар көләрләр бит, мең ярым белән комбайнчы исеме күтәреп йөрим... Сүтегез... эшләп торган комбайнны...

Шиһабетдин «бөтенләй чыгырымнан чыкмагаем», дигән сыман, мазут тапларына буялып беткән көрәк кулын уңайсызрак итеп селтәде дә, ишек катына барып утырды.

Яхшы комбайнчының мондый кәефе, әлбәттә, әйбәткә түгел иде. Хафизов алдындагы кәгазьгә «Шиһабетдин абый белән аерым сөйләшергә», дип теркәп куйды. Аннары бу хактагы сүзне җөпләп:

— Шиһабетдин абый тәкъдиме белән килешергә кирәк, иптәшләр. Сүз хәлиткеч удар отряд туплау турында бара. Без болай эшләрбез: иң

аз күрсәткечле комбайннарны туктатырбыз. Соңыннан кайткан запчастьлар белән аларны да берәм-берәм сафка кертербез,— дип нәтиҗә ясады. Һәм... бүлмәдәгеләрне тагын бер кат гаҗәпкә калдырып, бөтенләй икенче мәсьәләгә күчте.— Иптәшләр,— диде Хафизов, дулкынлануын җиңәргә тырышып, яңак сөякләрен уйнатып алды.— Безгә тагын менә нәрсәне хәл итәргә кирәк. Безгә, иптәшләр, берничә ел буена планга кертелеп тә, нигезеннән күтәрелә алмаган Культура йорты бинасын яңадан кузгатырга, кыскасы, бүген үк төзүчеләр бригадасы оештырырга кирәк. Түбән Камадан тиешле материал ташый башларга була. Мин бу хакта тиешле кешеләр белән сөйләштем инде, безгә ярдәм итәчәкләр. Сез моңа ничегрәк карыйсыз, иптәшләр.

Бүлмәдә үлем тынлыгы урнашты, барысы да башларын күтәреп Хафизовка карадылар. Партком секретаре Хафизовка язу сузды. «Дамир Җәләлович, хыял — яхшы, ләкин вакыты ничек бит...» диелгән иде анда. Хафизов, исе китмәгән рәвешле, кәгазьне учына йомарлады да сиздерми генә кесәсенә шудырды.

— Бу мәсьәләгә ничегрәк карыйсыз, иптәшләр?— диде.

Берничә минуттан шундый шау-шу, бәхәс купты ки, Хафизов ниндидер яңарыш бүләсен сизгән авылдашларының очынып сөйләүләрен күреп шатланды, ничек кенә шатланды әле. «Һичшиксез, дип уйлап алды ул, мондый кешеләр белән зур эшләр башкарып булачак. Колхозны күтәрү әнә шундый гомер буена җиргә ябышып яткан колхозчылар кулында, бу — бәхәссез...» Дамир үзе сугыш чорында туып үскән кеше. Аның өчен ул еллардагы шартлар, әйтергә кирәк, кыенлыгы белән күз алдына китерүе дә мөмкин тудыра торган нәрсәләр. Дөньялар үзгәрде, билгеле. Шулай булырга тиеш тә. Ләкин теге елларны кичергән кешеләр үзләренең балаларын җиңелрәк тормышка чыгарырга, үзләренә караганда яхшырак, күңеллерәк яшәүләрен тәэмин итәргә тырыштылар. Бу гаепмени? Юк, әлбәттә. Ләкин күп кенә яшьләрнең шәһәрләргә китеп, туган-үскән җирләрен ташлавын, ата-бабалары яшәгән нигезен туздыруларын ничек аңларга? Моны ничек гафу итәргә? Сәләтле егет һәм кызларның үз авылларыннан китүен Хафизов тормышның муллыгыннан, күп нәрсәләрнең җиңел генә бирелүеннән күрде. Редакция заданиеләре белән авылларга чыгып йөргән чакларда ул төгәл бер карарга килде: яшьләрнең төркемнәре белән авылдан шәһәргә китүен бары тик авылда яшәү, эшләү һәм ял итү шартларын шәһәрнекеннән ким итмәгән очракта гына туктатып булырга мөмкин. Алай гына да түгел, авыл яшьләренә үзләренең эчке дөньясын, аң-белем дәрәҗәләрен үстерү шартларын булдыру кирәк иде. Иртәме-соңмы без шуңа ирешәчәкбез. Әмма инде бик күп нәрсәләрне яңабаштан булдырырга туры киләчәк. Әлегә соң түгел, туган нигезләрне, ата-бабалар яшәгән авылларны, аларның каберләрен, ана телләрен саклап калырга соң түгел...

Хафизовның колхозчылар ихтыяҗына туры килгән сүзләреннән купкан шау-шу бераздан гына төште. Стена буендагы урындыктан озын буйлы, йомшак сары чәчләрен туздырган Таһир күтәрелде. Ул дулкынланудан кызарган йөзендәге җанлануны чак тыеп тора, техникага һәвәс булып үскән бу егет сүзсез кала алмый иде. Ул, кешеләрнең тынганын көтеп алды да:

— Хәзер безнең сүз боткасы куертып утырыр чагыбыз түгел, иптәшләр, Шиһабетдин абый дөрес әйтте. Безнең хәзер тыштагы яңгырларга, салкыннарга карамастан, гаять кайнар чагыбыз. Мин белә башлаганнан бирле булмаган авыр чагыбыз. Ләкин бу безнең ялкаулыктан, эшләргә теләмәвебездән түгел, иптәшләр. Мин механизаторлар арасында яшим, шуңа күрә аларның сулышын тоеп, теләкләрен белеп яшим. Безнең егетләр әнә санаулы сәгатьләрне дә файдаланырга тыры-

шалар. Уңышның муллыгы безне шатландырмыймы әллә? Бик шатландыра. Без киләчәктә дә шулай эшләрбез. Ләкин безнең эшне күрмәделәр. Без әлегә кадәр күбрәк үз белдегебез белән яшәдек. Теләсәк эшләдек, кемгәдер үпкәләсәк, әйтергә дә оят, иптәшләр, ватык түгел техниканы да ватык дип ычкындыргаладык. Болай булмый, иптәшләр. Сезнең алдыгызда әйтсәм әйтим инде. Иптәш Хафизов мине инженер урынына билгеләгәнгә түгел, ә күңелемдәгесен әйтим, менә күрерсез, иртәгә үк авылдан чыгып китәргә җыенган өч-дүрт егет-механизатор яңа Культура йорты салына башлавын ишеткәч тә... Ярар. Минем сүзем бетте...

Сүзен кырт кисеп урынына утырган Вәлиуллинга карап Хафизов тагын бер тапкыр шатланып куйды.

Төзү эшен белүчеләр табылды, аларны иртәгә үк идарәгә чакырырга, һәркайсы белән аерым-аерым сөйләшергә булдылар.

Идарә утырышында культура сараен төзи башларга һәм киләсе язга кадәр аны файдалануга тапшырырга дигән карар кабул ителде...

Механизаторлар чыгып киткәч тә Хафизов бригадирлар белән таныштты, аларның фикерләрен тыңлады. Аннары болай гап-гади күренгән, ләкин, нишләптер, моңарчы башка килмәгәннәрне әйтте.

— Белгәнебезчә, иптәшләр, гадәти булмаган авыр ел кичерәбез. Шуңа күрә эш алымнарын һәм формаларын төптәнрәк уйлап кулланырга тиешбез. Быелгы уңышны коткару безнең бик мөһим, ләкин якындагы бурычыбыз. Иртәгә үк, без бөтен кешене: мәктәп укучыларымы, өлкәннәрме, кунакка, ял итәргә кайткан авылдашлармы — һәммәсен басуга чыгарырга тиешбез. Нишлибезме? Теземнәрдәге игеннәрне җыеп көлтә бәйлибез. Аны әйбәтләп өеп куябыз да астан электр бастырып суктырабыз. Мөмкин эш бит бу, иптәшләр? Мөмкин... шулай булгач, минемчә, бригадирлар, идарә әгъзалары хәзер үк һәрбер колхозчының өенә кереп сөйләшергә тиешләр. Мин картлар белән киңәшеп алам. Аларны көлтә бәйләү серләрен өйрәтүче итеп куярбыз...

Шуның белән идарә утырышы бетте. Кешеләр, гадәттән тыш эш белән җанланып, урамнарга таралдылар.

Тагын ярты сәгатьтән «Дуслык»ның яңа җитәкчесе Дамир Хафизов авыл радиоузелында иде.

— Быелгы уңыш өчен көрәшнең хәлиткеч көннәре бара. Я җыеп алабыз икмәкне, я җирдә, кар астында калдырабыз. Гәрәбәдәй бөртекләрне, икмәк дигән изге нәрсәне хөрмәт иткән һәрбер кеше иртәгә иртүк, мөмкин кадәр җылырак киенеп, эшкә чыгарга, ындыр табагына җыелырга тиеш, иптәшләр,— дип башлады ул сүзен.

Колхозчылар күптәннән көткән чакыру иде бу.

## 7

Төн уртасы. Көннең көн буена аяк өстендә йөрелгәнгә арыткан, ләкин, ни хикмәттер, Хафизовның күзләренә йокы кермичә. Хәер, элекке елларда авылга кайткач та беренче төнне шулай йокысыз уздыра иде ул. Ни генә әйтсәң дә, туган-үскән җир сагындыра. Нигез йортың, атааның булмаса да, беренче мәртәбә күкрәк киереп сулаган авыл һавасының тәме искә төшә. Дөрес, моңа кадәр Хафизов туган җирен никадәр генә сагынса да, шәһәрдә торгач, андагы эшләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр иде. Күрәсең, авылларның язмышы шулайдыр инде, үзенең балаларын чит җирләргә, таш урамнарга озатып җибәрә дә, аларның ерактан сагынуларына риза булып, салмак аккан тормышы, үзенең

мәңгелек мәшәкатьләре белән яши бирә; иген игә, мал үрчетә, үзенең читтәге балаларын туйдыра...

Кунакханә янәшәсендәге урыс капкалы йорт ягыннан карлыккан тавышлы әтәч кычкырды, тагын бераздан, әлеге башбаштакның жикеренүен ишетеп, бүтәннәр дә аңа кушылдылар.

«Ризаевны ашыгыбрак алдык, ахры. Катырак бәрелдем бәрелүен, тик шулай итмичә мөмкин идеме соң? Комбайннарны вакытында тиешле сыйфат белән ремонтлау, урып-жыюга әзерләмәү сәбәпле август ахырындагы аяз көннәр бушка узганмы? Узган. Икмәк тезелмнәрдә кара көеп ятамы? Ята. Шулай булгач? Әгәр инде сиңа ышаныч белдергәннәр икән, күз карасыдай кадерле икмәкнең язмышын сиңа тапшырганнар икән, рәхим итеп күрсәт егетлегеңне, коткар икмәкне, үтә үзеңнең партия алдындагы бурычыңны. Тупла үз тирәңә шушы бурычны үтәрдәй кешеләрне. Моның өчен бераү дә сине битәрләмәс. Әмма киләчәктә кешеләр мәсьәләсенә саграк кагылырга кирәк булыр... Ләкин бит киләчәктә... ә быел Хафизовның кешеләрне тикшереп, уйланып йөрергә бер генә сәгать тә вакыты юк. Быел аңа артык сәгатьләр бирелмәгән. Вәлиуллин яшь кеше, булачак инженер. Аны чыныктырмыйча, кемне чыныктырасың...».

Төн караңгылыгына чумган бүлмәдә әле бер, әле икенче якка әйләнгәләп яткан Хафизов, кайдадыр, мич астындагы ярыкта сирәк-мирәк черкелдәп куйган чикерткә тавышын тыңлый-тыңлый, көндезге мәшәкатьләреннән тәмам арынып татлы да, бер үк вакытта үкенечле дә хатирәләргә чумды.

Ул вакытта да тышта яңгыр, тукта... тукта... яңгыр түгел, кар ява, күз ачкысыз кар бураны дулый иде. Әйе, ул кышны бураннар еш булды, ачы җилләр котырынды. Хәтта кышкы юлларда адашып үлгәләгән кешеләр дә булды дип сөйләделәр... Алар икесе берьюлы аңга килделәр, дөньяга кайттылар. Тәрәзә турысында, болытлардан арынган күк йөзендә түм-түгәрәк ай ялтырый иде. Күк йөзе ачыла башлаган, күрәсең, дип уйлап алды ул чагында Дамир. Аның каршыдагы стенага күзе төште. Эленгән көзгедә ай яктысы чагылгалап китә. Чылбырына хушбуйдан бушаган бәләкәй шешәләр тагылган сәгать теле тек-тек йөри. Юк ла, сәгать түгел, Дамирның йөрәге шулай тибә түгелме соң?

Дамир йокыдан тәмам арынып җитте. Үзенең күкрәгенә башын куеп яткан Надирәне кочаклап алды. Кызның куллары бушап, хәлсезләнеп калганны тоеп, Дамир терсәкләренә таянып күтәрелде дә Надирәгә карады. Аның озын толымнары тузгып шәрә күкрәкләре өстенә, йөзенә, иреннәренә сибелгән иде. Надирә аларны сизелер-сизелмәс хәрәкәт белән, әллә сулышы белән өрепме, битеннән, иреннәреннән куарга тырышты. Аннары инде бернәрсәгә дә үкенми торган караш белән күзләрен ачты да кыюланып Дамирга текәлде. Егет күзләрен яшермәде. Ул кызның кабарынкы, ләкин уттай яндырган иреннәренә капланды. Тагын бераздан күтәрелеп:

— Надирә — Кара толым, менә тагын өч айдан без мәктәпне тәмамлап чыгабыз, өлгергәнлек аттестаты алабыз... Беләсеңме, беләсеңме... чыгарылыш кичәсеннән соң мин сине велосипедыма утыртам да туп-туры үзебезгә алып кайтам, яме. Беләсең бит, минем әби инде сиксәнне тутырып килә. Синең кебек Кара толымны күргәч ул да бик шатланыр...

Надирәнең күзләреннән шатлык тамчылары мөлдерәп чыкты да, чуалган чәчләрен чылата-чылата, бит алмаларыннан тәгәрәп Дамирның муенына төште. Егет бер сүз әйтергә өлгерә алмыйча калды, кыз, сулкылдап елый-елый, Дамирның яшькә чыланган муенын, күкрәген үбә башлады.

— Мин... мин риза да бит, Дамир... нишләптер, күңелем шомлана минем. Күңелемдә шомлы уйлар йөри дим, җаааныыым, шомммм...

— Ташлале, шулай шомлана торган чагыбызмы безнең, Кара толым...

Надирә, бер кулы белән Дамирның күкрәгенә тотынып, аның кулларыннан арынды да чалкан ятты. Тагын озак кына дәшми торганнан соң:

— Нишләптер, куркам мин, җаным. Син бит минем бабайны белмисең, бееелмииисееең... Син бик күп нәрсәне белмисең бит әле, Дамир...

Надирә тынып калды, терсәкләренә таянып күтәрелде дә зур кара күзләрен очкынландырып Дамирга төбәлде. Әлеге караш егетнең дә күңелен шомландыргандай булды, өшетеп куйды.

— Соң әйт, Надирә, нәрсәне белмим, яшермә... Хәзер безнең сүзләребез дә, серләребез дә, уй-теләкләребез дә, кайгы-хәсрәтләребез дә уртак булырга тиештер бит, Кара толым...

— Син үзең бик белдекле, усал малайлардан саналасың. Бер генә дә ишеткәнең юкмыни соң... Синең бабаң колхоз оештырган елларда кем булганын, ячейка секретаре, совет председателе...

Дамир исә, моның безнең мөнәсәбәтебезгә ни катышы бар икән инде, дигән сыман, гаҗәпләнеп көтеп торды.

— Соң, булса ни?..

— Ә минем бабай авылның иң зур бай малае булган, үзе Түбән як мәхәлләсенең мулласы саналган... Аны синең бабаң Себергә сөргән, йорт-җирен сүттереп, совет йорты салдырган...

— Соң, Надирә, минем бабай авылда беренче коммунист икәнлеген кем белми, заманасы шундый булган, сыйнфый көрәш еллары.

— Мин боларны бик яхшы беләм дә бит, ләкин син бар әнә, миңа түгел, минем унбиш-уналты ел гомерен Себердә уздырган бабайга аңлатып кара шуларны...

Дамир боларны ишеткәч тә урын өстенә торып утырды, Надирә исә элеккечә түшәмгә төбәлеп яткан килеш калды.

— Аннан соң инде күпме еллар узган, Надирә. Синең бабаң тиешле җирдән рөхсәт алып туган якларына кайткан бит, ул бүген авылда яшәмәс иде, синең әниең дә җаваплы эштә эшләмәс иде...— диде Дамир кызга таба әйләнеп.

— Алай гына түгел, җиңел генә түгел ул, җаааныыым. Син бит үзең сыйнфый көрәш турындагы темаларны гел бишлегә генә сөйлисең... Әнигә... тимә син аңарга, Дамир, белмисең бит...

— Белмисең дә белмисең...— диде Дамир бераз үпкәләбрәк, карашын тәрәзәгә борып:— Соң әйт, әйтмичә кайдан белим ди мин кемнең нәрсә уйлаганын.

Надирә егетнең ефәк сыман йомшак чәчләрен сыйпый-сыйпый:

— Шулай шул, җаным. Сиңа әйтергә кирәк иде аны. Бәлки элегрәк тә кирәк булгандыр... Тик авылда моны бик сирәк кеше белә. Син, Дамир, ничек уйлыйсың? Менә мин, тере анам була торып, нишләп бабайда ятим үстем, ә?

Дамир бу хакта уйлап та карамаган иде. Шуңа күрә, җавап бирүдән битәр, аптырашта калды.

— Дәшмисең, җаным. Димәк, син боларның берсен дә белмисең... Бел алайса, бел...— диде Надирә һәм соңгы чиккә килеп баскан кеше, үтәргәме бу чикне, юкмы, дип, икеләнеп торган шикелле, тынып торды. Аннары бер тын белән сөйләп китте:— Утызынчы елларда ук, тегендә, Себердә, бабай үзенең кызын үзеннән ваз кичәргә күндергән.. аннары, әнине бөтенләйгә куып чыгарган... Әнкәй, хәер сорашып йөр-

гән, тәрбиясез бала булып колониягә эләккән. Шунда үскән, исем-фамилиясен үзгәрткән... Мин... мин аның беренче ирennән туган баласы... Икенчесе инде мине үз итә алмаган... Дөрес булса, мине юк итәргә, яки адаштырырга димләгән әнине. Ана кеше ничек итеп үз баласына кул салсын ди инде. Кырык җиденче елны төнлә кайтып, мине әби кулына тапшырган да, бабайга күренү түгел, өйгә кереп тә тормыйча, янә станциягә киткән. Шул вакыттан алып мине бабай тәрбияләп үстергән... Боларын син беләсең инде...

Бер авылда яшәп, ун ел бергә укып, инде өченче ел бер-берсен яратышып йөргән кызның язмышы моның кадәр катлаулы булыр дип уйлап та карамаган иде Дамир. Ул аны-моны әйтмәгәч, Надирә дә сөйләвеннән шып туктады. Бер сүзсез, озак кына уйланып яттылар. Надирә түзмәде, Дамирның битенә йомшак кулын куеп үзенә таба каратты.

— Нишләп сүзсез калдың, җаным?

Дамир тагын бер сүз дә әйтмәгәч, үрелеп аның күзләренә карарга тырышты, ләкин өлгерә алмады, егетнең көчле куллары аның ялангач җилкәсеннән тотты, битләренә актарылып төшкән кара чәчләрдән аңкыган хуш истән тәмам исерә барып, үзенә якынайта-якынайта башлады...

Атна-ун котырган буран, кешеләрнең җирдәге тормышын барыбер туктатып булмаячагын аңлаган кебек, сүнеп, тынып калган иде.

Аязып калган күк йөзеннән җилгә карап торучы салкын йолдызлар, тагын беравыктан кышкы тылсымлы табигатьне якты нурларга күмеп ялтырап чыккан кояш, соңгы суыкларга бирешергә теләмичә шыгырдап яткан ярмалы кар бөртекләре ике яшь йөрәкнең гомерлеккә дип корган якты хыялларының, уй-тойгыларының әчкерсезлеген аңлыйлар, күрәләр, һәм, һичшиксез, ишетәләр иде бугай... Югыйсә, атна-ун көн буена дулаган буран нигә туктап калды, күк йөзе ачылды, ни өчен ялтырап кояш чыкты да, ярмаланып яткан карлар ни өчен шыгырдашалар?..

Дамир йокыдан уянганда, Надирә кичә калган утыннарга ут әлеп җибәргән иде инде. Ул йомшак адымнар белән егет янына йөзеп килде, җылы куллары белән аның бит алмаларын кысып торды, ирennәрен бармак очлары белән җыеп китереп үпте дә җитез хәрәкәтләр белән урын-җирне җыярга кереште...

Әмма тормыш үзенекен итте.

Ике яшь йөрәккә бүләк ителгән бәхетле төннең санаулы сәгатьләре соңыннан әллә ни кадәр сынауларын да китерде. Ачыдан-ачы әрем суын кәсәләп түгел, чүмечләп эчертте. Аның беренче тамчылары дүшәмбе көнне иртүк, әле кайнарлыгы да сүрелеп бетмәгән ирennәргә тамдылар.

Беренче дәрес башланып китүгә Дамир белән Надирәне директор бүлмәсенә чакырттылар. Алар кыяр-кыймас кына бүлмә бусагасын атлап керергә өлгермәделәр, интернатта тәрбияче вазифаларын башкарырга тиеш булып та, анда яшәүчеләр янына атнага бер тапкыр да кереп чыкмыйча «эшләүче» Мәрзия апалары:

— Менә, күрегез, күрегез инде җир битләрне, кара йөзләрне. Ичмасам бәбәкләрен тереп кермәсеннәр иде...— дип зәһәр елан шикелле ысылдый башлады.

Барысы да аңлашылды.

Кичә алар дөньяларын онытып, җир йөзендә мәхәббәттән башка бүтән нәрсәнең буласын уйлап та карамаган иделәр. Әмма явызлыкка уралган кара бәхет аларны сагалап йөргән ләбаса...

Надирәне орыштылар-әрләделәр дә дәрескә кереп утырырга кушты-лар. Мәрзия апалары аны бер генә минутка да ялгыз калдырмаска, интернаттан алып үзләрендә тотарга вәгъдә итте.

Мәктәпнең абруен саклаудан битәр, үзенең былтыр гына ирешкән урыны өчен борчылган директор Дамирга мондый тәкъдим ясады: егет мәктәпне ташлап авылына кайтып китәргә, тагын бер елдан, әгәр үзе теләсә, имтиханнарга килергә тиеш иде. Дамир, директор бүлмәсен-нән чыгу белән, вак-төяк әйберләрен җыйды да авылына кайтып китте...

Бәхеткә каршы, уку елы бетәргә өч ай кала иң яхшы укучының сәбәпсез-нисез мәктәпне ташлавы, ниндидер юллар аша, районның мә-гариф бүлегенә барып ирешкән булып чыкты. Өч-дүрт көн узмады, Дамирның әтисе белән бер полкта сугышкан күрше авыл чувашы, роно мөдире Савелий Селиванов колхозда эшли башлаган егетне кырдан, тирес чыгарып йөргән җирдән эзләп тапты. Колхоз идарәсенә алып барып сәгать ярым сөйләште дә, районның икенче ягындагы урта мәк-тәп интернатына илтеп урнаштырды.

Апрель урталарына кадәр Дамир ерактагы Урманлы мәктәбендә калган Надирәсенә көн аралаш хат язып торды. Авылларына ял саен ашкынып кайтты, әмма Надирә кайтмады, аңардан кош теле кадәр язу да килмәде.

Түзмәде Дамир, Май бәйрәме алдыннан авылларына кайтып килер-гә, Урманлыга сугылырга булды. Күптән түгел генә язгы ташулар уз-ган иде. Авыл араларындагы вак елга күперләрен су агызып киткән, юлларның өзелгән чагы булуга карамастан, кайтты Дамир. Бата-чума булса да кайтты. Тик... аның ашкынып кайтулары юкка иде. Дамир моны авылга кайтып җитәргә биш чакрым кала ук белде. Урманлы-дан кайтучы яшьтәшләрен очратты, алар сөйләделәр.

Дамирны мәктәптән чыгаргач та, бәйрәмгә дүрт-биш көн кала, мәк-тәп ишегалдына аклы-каралы шакмаклар төшерелгән машина килеп туктый. Аңардан бер ир белән хатын төшә. Директор аларны үзе каршы чыгып ала. Озын тәнәфестән соң, дәрес бетәргә ун-унбиш минут кала, Надирәне директор бүлмәсенә чакыралар. Ул аннан елый-елый чыга да ашыгып-ашыгып әйберләрен җыйный башлый. Аннары... берни аң-ламаган яшьтәшләре белән саубуллаша, әнисенең алырга кайтуын, үзе-нең бөтенләйгә китәчәген әйтә...

Надирә аңа кош теле кадәр генәме, тулы бер дәфтәр язып калдырган икән. Сары кәгазьле төргәкне сүтәргә дә сүтмәскә дә белмичә торды Дамир. Ниһаять, кыюлыгын туплап, нәрсә генә булса да барыбер, На-дирәнең соңгы аманәте бит, төргәкне сүтеп җибәрде. Дәфтәр эченнән гөлчәчәкләр төшерелгән кызыл батист кульъяулыгы килеп төште. Нади-рәнең бүләге, ул калдырган төс иде бу кульъяулык. Аның бер читенә энҗе сыман тип-тигез хәрефләр белән кыеклап җыр язылган.

Дамир!  
Мә, кульъяулык, сөрт битеңне,  
Биткәйләрең тирләсә.  
Минем күңелем сине эзли,  
Синең күңелең эзләсә...

Надирә.

Авыл май бәйрәменә әзерләнә иде. Бөтен тирә-як кышкы йокыдан уянган, су буендагы тугайлар, авыл читендәге Олы болын, тау битлә-ре, авылның ике ягыннан урап килгән Бикчәбар һәм Коры елга итәклә-рендә бәбкә үләннәре күтәрелеп килә. Авыл басуларын кышкы усал җилләрдән биек һәм киң калкан сыман томалап торган Шомыртлык урманы белән Кәҗиникә урманы ягыннан бөтен әтрафка татлы каен сутының хуш исләре бөркелгән чак.

Кайчан һәм кем тарафыннан башлап җибәрелгәндер, моны берәү дә төгәл әйтә алмый, ләкин Яңавыл кешеләре генә түгел, тирә-күрше авыллар да язның иң күркәм бәйрәмен Сөлчә буендагы Олы болынга җыелып, бергәләшеп үткәрәләр. Бәйрәм алды кичләрендә һәм бәйрәм көнне Олы болынга яшьләр тупланалар. Нинди генә уеннар уйнамыйлар да, кемнең генә йөрәкләрдә сөю ялкыннары кабынмый бу болында? Гармун моңы иртәдән кичкә кадәр авыл урамнарын, су буйларын тутырып агыла да агыла бирәдә... Әмма Дамир өчен бәйрәм үзе дә, аның дәртле-җырлы болыны да тоташ моң-сагыштан тора иде. Шуңамыдыр, Дамир түзмәде, бәйрәм көнендәге уеннарга җыелган яшьләр арасында башын иеп йөрде-йөрде дә тиз генә өенә кайтып китте. Аннары үзе укый торган мәктәп ягына карап юлга чыкты...

Озакламый укулар бетте, Дамир да бүтән яшьтәшләре шикелле үк күптән хыялланган аттестатын алды. Ләкин аның өчен башкалар кичергән шатлыклар шатлык түгел, аңлашылмас тойгылар өермәсеннән гыйбарәт булды. Дамир тагын күпме газапланган булыр иде, билгесез, ләкин укуны тәмамлап кайтуының икенче көнендә үк аны эшкә чакырдылар, шушы араларда гына алып кайткан өр-яңа «ДТ»ны бирделәр. Һәм... ата-бабалардан калган шомырт төсле кара җир, урман артыннан күтәрелгән кабарынкы болытлар, рәшәле басулар, йөрәкләргә бетмәс-төкәнмәс көч өстәп торучы арыш һәм бодай исләре, күзләр җитеп алтынсу төс иңгән усак, өрәңге һәм миләш яфраклары, аяз төннәрне яктыртып җемелдәгән йолдызлар Дамирны тормыш дигән дәрьяга кертеп җибәрделәр...

Баягы башбаштак этәч таң беленә башлаганны хәбәр итеп кычкыргач кына Хафизовның уйлары берничә сәгатьтән башланачак киеренке һәм хәлиткеч көрәшкә әйләнеп кайтты. Соңгы елларда Яңавыл кешеләрен җылы сүз белән түгел, күбрәк административ чаралар белән «дәртләндерергә» тырышканнар. Юк, Хафизов моны үзенә кадәр эшләгән кешеләрне гаепләп әйтми. Хәер, әйтсә дә хаклы булыр иде, чөнки ул хуҗалыкның нинди хәлгә төшүен үз күзләре белән күрде. Әйтергә генә җиңел, тагын ике көннән октябрь керә, ә ике мең гектарга якын җирдә игеннәр кургаш сыман авыр яңгыр тамчылары астында интегеп ята...

Кунакханә тәрәзәсенә тыгыз караңгылык аша кызгылт яктылык сирпелде. Хафизов аны-моны уйларга өлгермәде, кайдадыр рельс кисәгенә тимер белән кага башладылар.

— Чиң-чаң, чиың-чаң...

Кемдер кунакханә тәрәзәсен шакыды. Хафизов плащ-накидкасын иңнәренә ташлап верандаunion урам як ишегеннән чыкты. Аның ялангач күкрәгенә салкын тамчылар килеп бәрелде, өзек-өзек искән җил плащ башлыгын бер күтәреп, бер төшереп уйнап алды.

— Кем ул, ни бар?

Тәрәзә шакыган кеше китеп бара иде инде, председатель тавышын ишеткәч туктады да, артына борылып, кычкырды:

— Ут чыккан, иптәш председатель, югары очта пожар...

Хафизов болдырдан төшеп ачык урынгарак чыкты да югары оч ягына карады. Чынлап та, яңгырлы күк йөзенә таба кызгылт яктылык үрмәли, ул яктан нindидер хәвефле тавышлар ишетелә иде...

Хафизов урам уртасына тупланган халыкның уртасына ук ярып керде.

— Ни бу, иптәшләр, нишләп утны сүндермисез, ни карап торасыз?! — дип каршындагы ирләргә төбәлде. Берәү дә дәшмәде, арадан берсе

нягеи күтәреп күрше өй түбәсенә таба ымлап күрсәтте. Хафизов күтәрелеп карады. Анда кулына ау мылтыгы тоткан берәү йөри, әледән-әле:

— Якын килмәгез, килмәгез дим мин сезгә. Дөмектерәм барыгызны да!— дип кычкыра иде.

— Кем ул, кем?!

Ут көчәеп урамдагыларның йөзен пешерә башлаган иде инде. Кешеләр, алар белән бергә Хафизов та арткарак чигенделәр. Комбайнчы Шиһабетдин председатель янына ук килеп:

— Утны, иптәш Хафизов, электромонтер булып эшләүче Әнгам Карбаев үзенең йортына үзе салган... Аның сәбәбе билгеле инде,— дип председательне тагын да ныграк гаҗәпкә калдырды. Ул чагында әле ул Әнгам Карбаевның хуҗалыктагы күп эшләрнең тоткасы, уңган куллы колхозчы икәнлеген белми иде. Соңрак, идарәгә кайтып барышлый гына аңа Әнгам Карбаевның хатыны Тәгъзия белән элеккеге председатель Хәйдәр Яруллинның «маҗараларын» сөйләделәр. Тагын бер ике көн үткәч тә, тикшерү вакытында, баш бухгалтер булып эшләүче Тәгъзиянең, ирен һәм балаларын ташлап, Хәйдәр Яруллинга яреп билгесез якка чыгып китүе мәгълүм булды...

Янгын сүндерүчеләр ул арада озын-озын брезент көпшәләрне янәшәдәге буага тоташтырдылар, төнге һаваны ярып движок эшли башлады. Шул мизгелдә Хафизов берәүнең күрше йорт түбәсендә мылтык белән кизәнеп йөрүче Әнгам янына таба үрмәләвен күрде. Нәкъ шул секундта үзе сизенгән Әнгам да артына борылып карады. Хафизов баскычтан үрмәләүчегә:

— Җиргә сикер, сикер!..— дип кычкырмакчы иде дә соңга калды. Әлеге тәвәккәлнең кулындагы брандспойттан көчле басым белән килгән су бәрергә тотынды. Беренче бәрем Әнгам Карбаевның биленә туры килде. Ул кулындагы мылтыгын онытып, ике кулы белән берьюлы битләрен томалады. Калай түбәдән бакча ягына шуып төшкән мылтык, түтәсе белән бәрелеп, гөрселдәп атып җибәрде. Бәхеткә каршы, бу гөрселдәүнең берәүгә дә зарары юк иде инде. Әнгамнең коралсызлануын күреп, халык дәррәү хәрәкәткә килде.

— Әйберләрен чыгарырга кирәк,— дип тәкъдим ясадылар. Ләкин мондый тырышлыкның кирәге калмаган иде инде. Кайсыдыр:

— Өйгә керәсе булмагыз. Артка чигенегез, хәзер түбә ишелә!— дип кисәтеп кычкырды. Шуны гына көтеп торган кебек, Әнгам Карбаев өенең түбәсе урталай бөгелеп төште. Аннан чыккан очкыннар югарыга сибелде, күрше йорт түбәсенә дә коела башлады. Әмма анда аларны көчле агым бик тиз сүндереп тора иде.

Хафизов янына баш агроном Вәли Гомәрев килеп басты. Аның өс-башы лычма су, күзләре янгын яктысында очкынланып-очкынланып китә, ә йөзендә елмаю иде. Хафизов таныды, Әнгамне коралсызландыручы ул — баш агроном иде. «Утырышта тыйнак кына, башын аска иеп кенә утырган иде дә, күр син аның кыюлыгын», дип уйлап алды председатель. Таң атканда инде янгын сүндерүчеләр таралышкан иде.

## 8

«Дамир! Җир йөзендә синнән дә кадерлерәк, синнән дә якынрак бер кешем дә юк минем. Көннәрем дә, төннәрем дә синең белән тулы. Кайчагында дөньяда бары тик син булганга гына яшим төсле тоела. Мин, Дамир, синә чын-чынлап үпкәли генә дә алмыйм бит. Нишләттең син мине? Сихерләдеңме, дип әйтер идем, син дә, мин дә андый тылсымнарга ышанмыйбыз. Яратам мин сине, бары тик сине генә яратырга дип ант итәм, ишетәсеңме, Дамир??

Беләсеңме, Дамир, безнең теге төнебез, март төне, кыш уртасындагы яшен кебек ялтырады да узды. Төгәл генә әйтә алмыйм, ләкин күңелемнең күзгә күренми торган кыллары белән сизәм: ул төн безнең бердәнбер сөекле төнебез булып калыр шикелле... Юк, син, Дамир, уйлама, уйлый күрмә тагын, минем сиңа булган хисләрем аз гына да кимемәде. Хәтерлисеңдер, бер кичне шулай ашханә янәшәсендәге класста кызлар белән дәресләрне аннан-моннан караштырдык та, сезгә — син дустың Кәшшаф белән «камчатка»да утыра идең,— комачауларга булдык. Ләкин ничек? Уйлаштык-уйлаштык та таптык уйлап: син бит шигырь чыгарырга оста идең, иеме? Шул Имәнле кызы Равия алданрак өлгерде. «Дамир, туктале укуыңнан, барыбер академик булалмассың, яз әле үземә генә атап бер шигырь», диде. Син, гадәтеңчә, башта югалыбрак калдың. Син бит, гомумән, кызлар алдында югалып кала идең, әйтер сүзләреңне берьюлы онытa идең. Үпкәләмә, Дамир, андый чакта синең колакларың тырпаеп, зураеп күренә иде. Ләкин син бу юлы үзеңне бик тиз кулга алдың. Аннары беребез дә көтмәгән шартны әйттең. Син Равиягә: «Минем күзләремә унбиш минут буе төбәлеп карап утырсаң, язам, ник язмаска»,— дидең. Мин шаяртасыңдыр дигән идем. Чын икән. Теге кара чутыры да, шуны гына көткән диярсең, чәчрәп чыкты да каршыңа барып утырды. Күзләрегезне төбәшеп күпме утыргансыздыр, белмим, мин башта бернигә санамаган идем, ләкин сез бер, ике, өч... биш минут шулай чекрәешеп утыра башлагач, күңелемнең әллә генә кай җирендә нәрсәдер «кырт» итеп өзелгән сыман булды. Түзмәдем, тиз генә китапларымны җыеп алдым да чыгып киттем... Соңыннан белдем инде, көнләшүем булган икән. Элек мине көнләшә белмисең, дип үртиләр иде...

Дамир! Тышта беренче гөрләвекләр мөлдерәп-мөлдерәп ага. Беренче сыерчыклар да килде инде. Мин быел сыңар сыерчык кына күрдем... Урамнарга чыгуы да күңелле. Тышта яз, яз исе килә. Инеш буендагы таллар да каралып, ямьсезләнеп калдылар. Элек игътибар итмәгәнмен... Ләкин теге көннән соң, син бер сүз әйтми-нитми китеп югалгач, мин инеш буена төшеп, таллар арасында йөрергә гадәтләндем. Син ачуланма, Дамир, нindидер бозык күңелләр түгел без, әйе бит, кадерлем... Без бер-беребезне яратабыз... Мин сиңа да, үземә дә үпкәләмим. Юк, иң беренче хисләремне сиңа, шушы хисләрнең бердәнбер иясенә бүләк итә алуым белән горурланам мин, Дамир.

Син беләсеңдер инде, Дамир, мин авылга кайтмадым, кайта алмадым. Теге көннән соң бер-ике көн үттеме, юкмы, бабай килде. Нәрсәләр генә сөйләмәде ул миңа, Дамир, синең бабаң Хафиз турында. Син дә шундыйрак, каты күңеллерәк кеше буласың бит кайчагында, әйеме Дамир? Юк, син ачуланма, минем бит хәзер синнән башка сер сөйләр бер генә кешем дә юк. Шулай булгач, барысын да синең белән уртаклашырга туры килә инде. Хәтерлисеңме, Дамир? Без былтыр, тугызынчыда укыганда, авылдан Урманлыга килә идек. Сез, малайлар, безнең кызларны, туры юлдан барабыз дип, урманның әллә нинди кеше йөрми торган төшеннән, үзегез генә белгән юлдан алып киттегез. Ул урманда, соңыннан әйттеләр, Шәкүр карак оясы дигән бер урын бар икән. Без нәкъ шунда булганбыз ул чакта. Сез, малайлар, әллә кайдан ук күрдегез. Төбе-тамыры белән актарылып ауган имәннең тамырлары астындагы бүре өнен күргәч, котларым очканлыкны беләсең иде син. И курыктым, и курыктым да соң. Ә син... курыкмадың, башыңдагы иске бүрегеңне, колакларың күренмәсен диптер инде, батырыбрак киедең дә оягa таба атладың. Бүтәннәр бармады. Син башта таяк тыгып бутадың, аннары оягa... бүре өненә керә башладың... Ничек курыкмадың соң син, Дамир? Тыннарым кысылса да, ул чакта миннән дә бәхетлерәк кеше юк иде бит, беләсең... Кемнең егете бүре өненә мылтыксыз-нисез керә ала?.. Син бераз югалып тордың, аякларыңдагы чабаталарың ат-

лагандагы шикелле алмаш-тилмәш селкенделәр, аннары артың белән үрмәләп чыктың. Синең кулларыңда, Дамир, әле күзләре дә ачылырга өлгермәгән йоп-йомшак бүре балалары иде. Алар юньләп чинаша да алмыйлар иде. Син сыртларыннан тотып күтәргәч, мескенкәйләрем, бары тик тәпиләрен генә селкеткәләделәр нәниләр. Син ул бүре балаларын нишләткән булыр идең, белмим, нәкъ шул вакытта безнең янга ике аучы килеп чыкты. Алар әлеге нәниләрнең әнисен сөйрәп киләләр иде. Балалары да безнеке, диделәр... алдылар да киттеләр.

Ә мин... ни әйтергә белмәдем, Дамир, нишләп соң шундый кешеләр була икән. Яшь-яшь балалы ананы (бүре булса да бит) үтергәннәр... Бүре — ерткыч, тик нигәдер ул да җәл бит...

Аңла... Дамир, җаным, иң кадерле кешем син минем, әле генә уйлап алдым... Әгәр дә... әгәр дә безнең дә... юк, юк, булмас, булырга тиеш түгел, иеме, Дааамиимр?..»

Надирәнең күңел дәфтәрендә моңа кадәр тип-тигез, кулъяулыктагы чигү сыман түм-түгәрәк хәрефләр белән язылган беренче язма шушы урында бетә, аннан кала эреле-ваклы язылган юллар башлана иде...

«...Сиңа булган мәхәббәтем өченниләр генә ишетмәдем инде мин, Дамир! Көн саен авыр сүз, көн дә бер тамчы агу. Нинди хәл соң бу? Ичмасам, син дә, Дамир, киттең дә олактың. Бер юл хатың-хәбәрең юк. Хәер, мин баштарак шулай уйладым, җаным. Хәзер беләм, син гаепле түгел. Язасыңдыр син. Нигәме? Бер көнне хат ташучы апаны күрдем, зур залда, директор бүлмәсе янында. Сорадым. Ул күз карашын яшереп әйтте. Юк бит, сеңелем, диде. Кулындагы газеталар арасыннан чыгыбрак торган бер хатның читендә ике-өч хәрефе күренде. Мин бит синең кулыңны теләсә нинди язулар арасыннан да таныйм. Дамир... Синең хат иде ул... Мин бүтән сүз әйтә алмадым, директор ишеге ачылып китте...

Авыр миңа, бик тә авыр, Дамир... Бабай килде, укулар беткәнче торам, ди... Интернаттан чыгарды бит ул мине, Мәрзия апаларда яшибез.

Анысына да түзәр идем әле, иң курыкканым ул түгел... Юраганым юш килә, ахрысы, Дамир. Соңгы көннәрдә бөтенләй әллә нишләдем... Күңелләрем болгана. Төрле сәбәпләр табарга тырышам, ләкин... ләкин сизәрләр, барыбер сизәрләр инде... Андый хәлне ничек яшерәсең, ди, Дамир? Ә бит мин булмас, булырга тиеш түгел, дип ышанып йөри идем...»

Икенче язма дәфтәр битендәге ике юлны бер итеп, карандаш белән, мөгаен, бер утыруда язылган юллардыр.

«Дамир! Әни һәм үги әти булып саналырга тиешле кеше кайтты. Алар мине алырга кайтканнар. Нишләргә? Бабай, астыртын, әнинең кайдалыгын гел белеп яшәгән икән... Әнкәй дә... ваз кичкән, имеш. Алар бит, Дамир, үзләренең өсләренә килгән бәла-казадан качар өчен шулай эшләгәннәр икән. Бу — коточкыч...

Шулай да... нишләргә соң миңа? Ичмасам, син дә юк. Бер-бер нәрсә уйлап табар идек... Тегеләр минем белән артык сөйләшеп тә тормадылар. Иртәгә китәбез, диделәр дә мине мәктәпкә җибәрмәделәр. Кәгазьләрне юллап йөриләр бугай... Кичә бабайның танышы — Мәрзия апа-

ның әтисе турында белдем. Ул сугыштан соң гына авылга кайткан, әлек бабайлар белән бергә булган кеше икән... Әни белән ачыктан-ачык сөйләштек. Ни турындамы? Шул инде...

Беркөнне, сагынуыма чыдый алмыйча, су буена, әрәмәлеккә төшкән идем. Агачлар шау яфракта... Һәркайда тормыш кайный. Ә минем вакыт-вакыт бөтенләй яшисем дә килми башлый... Нишләттең соң син, нишләттең мине, Дамир? Син бит шигырь чыгарырга оста идең, нечкә күңеллесеңдер дигән идем мин сине... Ә син... бүре оясын туздырган кебек... Юк, юк, Дамир, мин моңа гомеремдә дә ышанмаячакмын. Син бит усаллык белән эшләмәдең бу эшне, син бит минем шикелле үк яратасың, әйеме, Дамир?

Соңгы сүзем шул сиңа: син эзләмә мине, эзләмә, яме, Дамир. Авылда берсеннән-берсе матур, син әйтмешли, колхоз кызлары бик күп. Шуларның берсен киләчәктә тормыш юлдашың итеп сайласаң, мин риза. Мин рәнҗемәм сиңа Дааамиииир...»

## 9

Сыкранып, теләр-теләмәс кенә таң атты. Идарәдә утыручылар, корыласы планнар корылып беткәнлектән, анысы-монысы дигәндәй, һаваны сүккәләп, күршеләрдәге эшләр барышы турында гәпләшә башладылар. Беркадәр ваемсызрак булырга тырышсалар да, күңелләре тыныч түгел иде аларның. Ничектер, үзеннән-үзе шулай килеп чыкты инде, көтмәгәндә-уйламаганда купкан янгын колхозның бүгенге көен көннәрендә җаваплылыкны үз өсләренә алган кешеләрне бергәрәк туплады. Янгынны сүндергәннән соң, яңа председатель белән бергә идарәгә таба атладылар. Баш агроном Вәли Гомәрев, Таһир Вәлиуллин, партком секретаре Григорий Семенов белән берничә ветеран монда килгәч тә иртән башланачак штурм хакында тагын бер кат киңәш-табыш тотып алдылар. Ни әйтсәң дә, соңгы елларда авыл халкын мондый эшләргә күтәрергә туры килгәне юк иде.

Яктырды. Мәрәҗән тавы өстеннән авылга таба актарылган болытлар артында күк йөзе бераз ачылгандай итте.

Урта бүлмә ишегеннән берәүнең таякка таянып кергәнен искәргәч, Хафизов, өстәл артыннан торып, каршы атлады. Бусагада өстенә иске кожан кигән, башлыгы белән битен-башын томалаган, агач тамырыннан ясаган чукмар башлы таягын тоткан Закирҗан карт күренде. Ул бүлмәдәгеләргә бөтенләй игътибар итмәгәндәй:

— Кһем-кһем, энем, кем — Дамир дип әйтеп әйтимме, безнең ише карт-корыларның да үзләре оештырган колхозга керәге чыкты, аларның да эшкә ярар көне житте, диләр. Шул сүз дөресме? — диде дә башлыгын аркасына таба төшерде, кечкенә күзләрен мелт-мелт китереп, кытыршыланып беткән уң кулын колагы янына куйды.

— Дөрес, бабай, бик дөрес. Сез кирәк безгә бүген, сезнең ярдәмегез кирәк,— дип, Хафизов аңа урын тәкъдим итте.

— Кһем, кһем... алайса, без әзер, энем Дамирҗан, боер давай...

— Сезгә боерып булмый, Закирҗан бабай. Үтенеп кенә була.

— Халык юкка гына «ил төкерсә, күл була» димәгәндер. Күптән шулай кирәк иде. Башлап җибәрүче, җылы сүз әйтүче булмады, булмады...— Закирҗан карт соңгы сүзләрен әйтеп бетергәндә, бүлмә ишеге тагын ачылып китте. Кулларына кайсы урак, кайсы тагын нәрсәләрдер тоткан картлар гөлдер-гөлдер гәпләшеп кереп киләләр иде.

Алар белән сөйләшкән арада, идарә бүлмәләренә, болдыр тирәләренә колхозчылар җыелды. Тагын бераздан утырып торырга түгел, басарга да урын калмады.

Хафизов тыныч күренергә тырышса да, дулкынланудан маңгаена бөрчек-бөрчек тир тамчылары бәреп чыкканын сизде.

Күк йөзе ярыйсы гына ачылган, сүрән генә ялтырап кояш чыгып килә. Идарә эчендәгеләр дәррәү кубып, урамга атладылар. Хафизов партком секретарена:

— Григорий Иванович, китәргә команда бирер алдыннан бер-ике сүз әйтәсезме әллә?— диде.

— Юк, Дамир Җәләевич, сез кузгатучы халыкны, үзегез әйтегез...

Ләкин Хафизовка сөйләргә туры килмәде. Закирҗан картның:

— Я, авылдашлар, хәерле сәгатьтә булсын, китә башлыйк,— дигән тавышы ишетелде. Шуны гына көтеп торган колхозчылар авыл артыннан ук башланып, ерактагы урманга кадәр теземнәр сузылып яткан басуга таба кузгалып киттеләр.

Басу башында халык тагын да күбрәк иде. Идарә алдына төшеп өлгерә алмаганнары, соңга калдык дип, ашыга-кабалана туры монда килгәннәр.

Эшне Закирҗан картның «бабайлар» бригадасы башлап җибәрде. Алар халык алдына, теземнәр башына чыгып тезелделәр. Яшьлектә алган һөнәр онытыла димени, Закирҗан карт яшьрәкләрне үз тирәсенә җыйды да «лекция» укырга, шунда ук практика уздырырга кереште.

— Менә шуның кадәр учманы аласың да,— диде ул зәп-зәңгәр күзләрен ялтыратып,— көлтә бавы ясыйсың. Аның бер башын әйләндереп, киндерә ишкәндәге сыман, бөтереп ныгытасың, анна́ры менә шушылай тотып култык астына кыстырасың. Шундый ук әмәл белән икенче башын да бөтерәсең, анысын да култык астына кыстырасың...

Кеше өйрәнмәслек эш юк диләр, беренче көлтәләр тузылып, таралгаласа да, беравыктан эш көйләнә башлады. Иртәнге мәлдә акрын барган эш төшкә таба кайнарлана башлады. Кемдер учак ягып җибәрде. Җиргә ябышып яткан теземнәр урынына очлаеп-очлаеп утырган чүмәләләрне җил кага башлады.

Закирҗан карт, кожан башлыгын артка ташлаган килеш, һөҗүмгә барган солдатларына көч-куәт биреп барган командир сыман, Хафизов белән бер адымга басып, рәтләр арасыннан йөрде, киңәш бирде, үзе бәйләп күрсәтте. Карт очынып йөри, гүя ул күптән инде узган яшьлегенә әйләнеп кайткан иде.

Бераздан җитәкчеләр киңәшкә басты. Көлтә бәйләү эшнең башы гына, бәйләгән көлтәләрне чүмәләдә озак саклап булмый иде. Шул хакта уйлаштылар. Закирҗан карт тәкъдиме белән чүмәләләрне ындыр табагы артындагы чирәмлеккә чыгарырга, кибәннәргә өяргә булдылар. Вәли Гомәрев кибән астында җылылык өрдергечләр куябыз да киптерәбез, янәшәгә комбайн бастырып бер-ике көннән үк суктырырга керешәбез дип вәгъдә итте. Шулай итәргә булдылар. Кибән өеләсе җиргә киртәләрдән өй кыегы сыман корылма ясарга керештеләр. Моның өчен тагын бер отряд оешты. Төш җитәр алдыннан көлтә бәйләп баручылар авыл ягына таба әйләнеп карасалар, исләре китте. Анда, Мисыр пирамидаларын хәтерләтеп, киртләч-киртләч ике кибән күтәрелеп килә иде.

## 10

Акъярның тоташ яуган яңгырлардан изрәп, боламык сыман былчыракка әверелгән урамы буйлап берәү атын юырттырып бара иде. Аның өстендә — юештән каралган башлыклы кожан, кулында — әледән-әле ат сыртына төшеп, кызулык өстәп баручы камчы, йөзендә усаллык чаткылары сизелә, тешләре иреннәрен авырттырырлык итеп кысылган иде.

«Дуслык» колхозының инженер вазифаларыннан куылган Минап Ризаев иде ул.

Янгыннан соң каядыр югалып йөрде, өенә таң атканда гына кайтып керде һәм ни әйтергә белмичә торган хатынын гажәпләндереп, ашыгып-кабаланып өс киемнәрен алыштырды. Аннары, кая китәсен әйтмичә, ишегалдындагы баганага бәйләп калдырган атына атланды да, инеш аша чыгып, Коры елга буйлап урманга таба менеп китте.

Иренең кыркулыгына, тегене-моны уйлап тормыйча дуамаллануларына иялэшкән Мәликә бу юлы да аны-моны әйтергә, киңәш-фәлән бирергә җөрьәт итмәде. Капка төбенә чыгып карап торды-торды да, кырыкмаса кырык төштә яткан эшләрен исенә төшереп, өйгә кереп китте.

Коры елга итәгендәге чирәмнән атын камчылый-камчылый райүзәккә таба ашкынган Минапның нияте, чынлап та, изгедән түгел иде. Ул, ничек кенә булса да тиз арада үз урынына кайтып, Хафизовның гайрәтенә сукмакчы, шуңа райкомның беренче секретаре Сабир Гайнуллин аша ирешмәкче иде. Чөнки моңарчы «Дуслык»ка килгән бер генә председатель дә аңа карата шундый шәфкатьсезлек күрсәтмәде, мин-минлегенә тимәде. Авылныкылар гына түгел, читтән килгәннәр дә аның белән киеренке мөнәсәбәттә булмау ягын карадылар, күп вакыт аның сүзеннән чыкмадылар. Ә бу... үксез бозау... кайтып житәр-житмәс борын Ризаевны урыныннан куып чыгарды. Моны болай гына калдырырга ярамый, Хафизовның гайрәтенә сугып, кикриген шиңдермәсәң, киләчәктә бөтенләй адәм мәсхәрәсенә калуыңны, кая кушсалар шунда йөрисеңне көт тә тор...

Кырык алтынчы елны бугай, Минапның дуамаллыгын белгәнгә күрә, аны полевой, ягъни, басу караучы итеп куйдылар. Уракка төшкән чак иде. Сугыш елларында ачлы-туклы тору кешеләрне бәрәкәтле булырга, ашлыкның бөртеген дә калдырмаска өйрәткән иде. Игеннәрне урып-җыеп алгач та басуга, камыл арасында калган башакларны чүпләргә дип бала-чага, карчык-корчык чыга башлады. Тик... нинди агач жанлы кешенең әмере булгандыр, башак чүпләүчеләрне басудан куарга, җыелган бөртекне, янчыгы-ние белән тартып алырга тотындылар.

Минап инде аерата кансызлык күрсәтте. Бала-чага, карт-корыны айгыр белән өсләренә килеп куркытты, камчысына да ирек биргәли иде.

Беркөнне Минап Коры елга чокырыннан искәрмәстән килеп чыкты. Дөрес, малай-шалайның күбесе аны күрүгә чокыр-ерганакларга сикерделәр, ә Дамир артыграк мавыгып киткән булгандырмы, өлгерә алмады, аркасына камчы чыжлап төшкәч кенә, корт чаккан сыман читкә тайпылды. Ләкин соң иде инде, айгырның көчле кукрәгенә бәрелеп жиргә капланды. Ул да түгел, аның гәүдәсе, үзеннән-үзе күтәрелә башлады. Дамир, аңына килеп, камчы ачысыннан тулган күз яшьләре арасыннан карады. Бөтен нәрсә йөзтүбән күренә, Минап аның ике ботыннан тоткан килеш күтәреп бара икән. Сап-сары башаклар камыл арасына сибелеп кала. Малайның иңбашына кигән букчасы айгыр тоягы астында калып тартылды да муен тамырын өзә язды. Аннары дөнья караңгылыкка чумды. Соңыннан әйттеләр, Ризаев малайны баштүбән күтәреп килгән мәлгә жиргә кадап калдырган икән...

Көтмәгәндә-уйламаганда Хафизовны колхоз председателе итеп кайтаруларын ишеткәч тә Минап әнә шуларны исенә төшереп алган иде. Онытткандыр, дип уйлады. Күрәсең, онытмаган булып чыкты Хафизов аның теге чактагы «батырлыгын»...

Юыртудан адымга күчкән ат райүзәкнең олы урамыннан барган жиреннән кинәт читкә сикерде. Әлеге уйлары белән булашып барган Минап иярдә утырып кала алмыйча, юлдагы былчырак суга барып төште. Шулай да ул тезгенне жибәрмәде, сикереп торып атка кизәнде.

Юаш ат артка чигенеп, үзен өркеткән машинага арты белән килеп төртелде.

Минап туктап калган машинаны күреп, шоферның тетмәсен тетәм дип бара башлаган иде... «УАЗ»ның уң як ишеге ачылып китте, аннан Гайнуллинның пеләшләнә башлаган башы күренде.

— Исәнмесез, иптәш Ризаев. Ни иртә, ни кич дигәндәй, нишләп монда, бер-бер хәл булдымы әллә?

Көтелмәгән очрашу Минапның уйларын бераз чуалткан иде, секретарьга әйтергә дип уйлап килгән сүзләр берьюлы юкка чыкты.

— Саумысез, Сабир Салихович, караңгылы-яктылы сезнең янга ашыгуым иде...

Беренче секретарь тезген тоткан Минап янына килде. Аның авызыннан аңкыган самогон исен сизеп борынын җыерды да кискен генә әйтте.

— Ярый, Ризаев. Үзеңне тәртипкә китер дә керерсең... Озакламый бюро утырышы башлана безнең.

— Мин, мин, мигом, иптәш Гайнуллин.

Тагын унбиш-егерме минуттан Ризаев үзенең өс-башын бераз чистартып кабул итү бүлмәсенә атлады. Секретарь кыз урынында юк иде, уң яктагы ишекне шакыды да эчкә атлады.

Гайнуллин телефоннан сөйләшә иде. Ризаев аны бүлдермәскә тырышып ишек катында тораташ шикелле торды. Озакламый секретарь сүзен очлады һәм Ризаевны якынрак килергә чакырды.

— Ягез, Ризаев, ни кылды яңа председатель?..

Ризаев моны көтмәгән иде.

— Соң бит, ни бит, иптәш Гайнуллин...

Минап, каракның бүреге янар дигәндәй, вакытны сузарга, әләкләргә килүен еraграк яшерергә тырышты.

— Дөрес, иптәш Гайнуллин, яңа председатель килеп җитәр-җитмәс борын колхозның ышанычлы кешеләрен урыннарыннан куа башлады. Үзе шунда була торып бер колхозчының өен яндыртты. Алары гына ярар иде әле аның. Җыен малай-шалайны җитәкче итмәкче була. Җитмәсә, иптәш секретарь...— Ризаев әйтергә теләгәннәрен бер тын белән әйтеп бетермәкче иде, сулышы бетте. Күзләре секретарьга төбәлде. Ул икенче каттагы бүлмә тәрәзәсеннән урамга карап тора. Анда тагын яңгыр сибәли, вак тамчылар тәрәзә пыяласына бәреләләр дә тигез эзләр калдырып тәгәриләр иде. Ризаев сүземне бетерим дип тирән сулыш алды.

— Инде анысы гына аз булсамы, иптәш секретарь, яңа председатель комбайннарны сүтәргә приказ бирде, авылдагы бөтен кешене, яшенкартын аямыйча кырга куып чыгарды, чыкмасагыз, бераүгә дә көн күрсәтмәячәкмен, дип янады...

Сабир Салихович «кеше дигән зат үзенең җылы урынын саклап калу, үз кайгысын кайгырту юлында нинди генә түбәнлекләргә төшми», дип уйлап тора иде, Ризаев туктап калгач:

— Сөйләп бетер, Ризаев, бик кызык бу,— диде.

— Халык кызык диmi шул, иптәш Гайнуллин. Болганышалар, күпме җәфа чигеп торгызган комбайннарны сүтәргә кем риза булсын ди...

— Чынлап та кызык бу, Ризаев. Мин болай ук булыр дип уйламаган идем. Черт побери, кызык, иптәш Ризаев...

Гайнуллин бөтен гәүдәсе белән Ризаевка таба борылды. Аның йөзендә кырыслык ята, йокысызлыктан кызарган күзләрендә усал очкыннар чагыла иде.

— Син, Ризаев, җавап бир әле. Ни өчен безнең район бүгенге хәлгә төште, ә? Яңгыр бит ул тирә-күршеләргә дә ява...

Секретарьның һәр сүзен җөпләп кабул итәргә, аны теләсә нинди очракта да, теләсә нинди эшнең дә җаен, серен белергә тиешле һәм



Тәгил Хаҗиәхмәтов рәсеме

белә дип санарга өйрәнгән Ризаев мондый сорауны көтмәгән иде. Бер Ризаев каян белсен аны, тиешле кешеләре бар, райком, райбашкарма бар, алар уйласыннар... Ул, күзләрен мөлдерәтеп секретарьга караган килеш, әнә шулай уйлады.

— Я, Ризаев, ничек уйлыйсың, әйт әле фикереңне...

— Мин бит, ни бит, иптәш секретарь, миңа нәрсә... Мин кечкенә кеше... эш кешесе...

Гайнуллинның болай да ачуы чыккан иде, тагын да кырыслана төште.

— Ярый, Ризаев, менә син монда кешеләр өстеннән килгәнсең, ә бит... Районның шушы хәлгә төшүендә синең дә гаебең бар.— Ризаевның ни-дер әйтергә теләп тә тукталып калуын күреп, секретарь янә дәвам итте.— Дөрес, Ризаев, райондагы эшләр өчен без җавап бирәбез. Ләкин бит «Дуслык»ның техникасын тараткан өчен син дә үз җавабыңны бирергә тиеш...

Шушы төштә Сабир Гайнуллин сүзен кырт кисте, эчтән үз-үзен дә кисәткән шикелле офтанып куйды. Ә ни өчен? Районда шактый еллар эшләп, кайчандыр колхоз хуҗалыгын тартып бара алган, ул чагында белемнән битәр тырышлык белән яшәгән, хәзер исә, белем җитмәү сәбәпле, торгынлыкка дучар булып, җаваплылыкны оныта башлаган кичәге көн җитәкчеләренә артыграк ышанган өченме? Менә шушы Ризаев кебек, теләсә нинди юллар белән үз урыннарын саклап калырга тырышучыларны вакытында күрмәгәнме? Шулай, иптәш Гайнуллин, быелгы хәлләр өчен иң беренче җавапны син бирергә тиешсең... Шулай булгач, әгәр дә синең кул астында кискен чакта инициативалы, белемле, колхозчыларны хәлиткеч көрәшкә күтәрердәй тагын бер җитәкче эшли башлаган икән, аның белән килешмәгән кичәге көн кешесенең әләгенә колак саласың икән... Син үзең дә кичәге көн җитәкчесенә әверелмисеңме икән?..

Бу уйлардан Сабир Гайнуллинның күкрәк читлеге чәнчешеп куйгандай булды. Моңарчы булганы юк иде...

— Син, Ризаев, ничек уйлыйсың, хәзерге минутта «Дуслык» механизаторлары, колхозчылар кырда микән, ә?

Ризаев башын түбән иде.

— Ә син, инженер башың белән, эш калдырып килгәнсең!

— Мин инженер түгел...

— Аңлашылды. Бик дөрес эшләгән Хафизов. Күптән шулай кирәк иде. Бар, кайт, Ризаев. Син — механизатор кеше, эш табылыр...

Ризаев теләр-теләмәс кенә урыныннан күтәрелде дә авыр адымнар белән ишектән чыгып югалды. Сабир Гайнуллин секретарь кызны чакыртып кертте, илле яшьлек гомерендә беренче тапкыр валидол соратып алды.

## 11

Җирән кашкага атланган Хафизов Кәҗинкә елгасы буеннан элдертә иде. Өс-башы юеш, тамагы ач аның, ләкин күңеле күтәренке, басуларда мөлдерәп яткан игеннәрне борынгы ысул белән булса да коткару эшенә тотынылды бит. Тик бусы әле башы гына, шуңа да карамастан эшнең болай кузгалуы, колхозчыларның икмәк язмышына мөнәсәбәте күңелгә рухи ныклык, яңа көч өсти иде. Урылмый калган басуларга кичә иртә белән ургычларны төшерделәр. Соңгы өч-дүрт көндәге темплар белән эшләсәләр, күп дигәндә, тагын бер атнадан игеннәр җыелып, кибәннәргә куелачак.

Иртән Хафизов комбайнчылар янында булды.

— Яңа председатель, яңача-искечә эшләп, безне вакытыннан элек запаска чыгарамы әллә, дип торабыз тагын, болай булгач, дөрес сүз түгел икән,— диешеп, ярым шаяртып каршыладылар аны. Председатель дә югалып калмады, турыдан туры һөҗүмгә күчте:

— Я, нишлибез соң, егетләр? Искечә эшләүләргә ышанып ятабызмы, әллә бер-бер әмәлен табабызмы?

Механизаторлар, бу тагын ни әйтер икән дигән кебек, бер мәлгә тынып калдылар. Хафизов дәвам итте:

— Сез — тәҗрибәле игенчеләр, икмәк бәясен миннән яхшырак беләсез, чөнки сез — аны үстерүчеләр. Бүген иртән исәп-хисапчылар белән сөйләшкән идем. Турысын әйтергә кирәк: быелга колхозның хәле, өстәмә кызыксындырулар белән дим, шәптән түгел. Ләкин киләчәктә без мондый хәлдән чыгарбыз дип уйлыйм...

Шул вакыт майга буялган кулларын чүпрәккә сөртә-сөртә Шиһабетдин алга чыкты һәм үзенең мул сары кашлары астыннан карап әйтте:

— Син, председатель, безне юк-бар белән бутама, значит. Колхоз хәле — безнең хәл ул. Үзебез үк чыгарбыз кеше рәтенә. Син безне әгитләп маташма, яме. Кайсы яктан башлыйбыз?..

— Суктыруны бер-ике көннән — жылыткычлар бераз эшләп алгач — башларбыз, Шиһабетдин абый, син ничек уйлыйсың?

— Дөрес, бик дөрес булыр. Без әле генә нәкъ шул хакта сөйләшеп тора идек.

Төркем арасыннан Мотыйгулланың икеләнгән тавышы ишетелде.

— Соң, өстән явып торганда урмабыз бит инде...

Аңа шундук җавап бирделәр.

— Әллә иртәгә туктый дип сиңа телеграмма җибәрделәрме?

— Җибәрмәсәләр бит...

— Шулай булгачтын...

Таһир Вәлиуллин сүзгә кушылды:

— Хафизов абый, ургычларны чыгардык, авыр булса да, үрмәлиләр. Менә мин нәрсә турында уйлыйм бит әле, Хафизов абый. Республиканың кайбер хуҗалыкларында комбайннарга резин башмак-гусеницалар кидерәләр дә трактор белән тарттырып... Кичә «Вакыт» программасыннан да күрсәттеләр... Әллә мин әйтәм...

Мотыйгулла монда да, тагын эш арттырырга тырыша бугай бу дип, каршы төшәргә җай тапты.

— Соң бит андый гусеницаларны кайдан аласың? Китегез аннан, булмаганны!

Хафизов комбайнчы Мотыйгулланың электән килгән ялкаулыгын белгәнгә, аның сүзләрен тыңлап бетермәде. Ул идарәгә телефоннан шалтыратырга ашыга иде. Акъяр районыннан кайткач, «Сельхозтехника»ның Казандагы базасына барган иде, шунда күрде бит ул Таһир Вәлиуллин әйткән резин гусеницаларны. Өеме-өеме белән база ишегалдында яталар иде. База начальнигы, корреспондент килгән форсаттан файдаланып калмакчы булып, урын биләп яталар шунда, бераүгә дә кирәкми, нәрсәгә кайтарганнардыр, дип зарланып та алган иде.

База начальнигының секретаре, Хафизовның өлкә газетасында эшләвен белгәнгә күрә, тиз тоташтырды. База начальнигы гына әлеге резин чылбырларның өлкә газетасы корреспондентына нигә кирәклеген төшенә алмыйча аптырады. Ахырдан, шатлыгын яшермичә, кычкырып ук җибәрде.

— Хет ике машина җибәр, иптәш Хафизов, урынны гына бушатсыннар,— дип ялварырга ук керешге. Хафизов уеннан кире кайтмагае дип борчыла иде бугай.

Күп тә үтмәде, җиде йөз ат көчле трактор Таһир Вәлиуллин утырган колхоз машинасын олы юлга таба тарттырып китте.

Хафизов, газетаның үз корреспонденты буларак, быел районнардан кайтып кермәде. Редакциядән әле бер, әле икенче районнан рейд ясә

тәнкыйть материаллары таләп иттеләр. Урындагы хәлләрне үз күзләре белән күргәч, Хафизовның йөрәге әрнеде. Чынлап та, дип уйлады ул еш кына, чынлап та, карап-тәрбияләп үстергән уңышны җыеп алу өчен мондый авыр елда нинди чаралар күрергә, нинди алымнар белән эшләргә иде соң? Хәзерге вакытта, техника саны, аның мөмкинлекләре чиксез сыман тоелган бер чакта, бабайлар эшләгәнчә эшләргәме? Нишләп болай соң әле? Нишләп безнең инженерлар теләсә нинди һава шартларында да игеннәрне урып, суктырып алырдай комбайннар уйлап чыгармыйлар? Нишләп соң без булган кадәресенең дә кадерен белеп бетермибез, көчне тулысынча файдаланмыйбыз? Мондый проблемаларны кичекмәстән хәл итүнең зарурлыгы аермачык түгелме соң? Бу ел әнә шушы хакыйкатьне тагын бер кат аңлата түгелме! Хафизов ничәнче тапкыр инде әнә шушы сорауларга җавап эзли, ләкин таба алмый иде.

Тормыш үзе — гаять хикмәтле нәрсә инде ул, һич көтмәгәндә Хафизовны әлеге проблемаларны хәл итәргә тиешле кешеләр рәтенә куйды.

Ә яңгыр ява да ява. Аның да ниндидер бер чыганагы, туплана торган җире бардыр лабаса. Шушы чыганакны, шайтан алгыры, шартлатып булмыймы, әнә шушы сыйсыз, салынкы болытларны ракета-фәлән белән куып тарату ысулы бар бугай бит.

Хафизов быелгы башакларның авырлыгын үз кулларында тойды. Бүтән елларда сабагы сабак, башагы башак була торган иде. Былтыр әнә икешәр тезмне бергә кушып суктырдылар, быел исә бер тезмәне икегә бүләргә туры килә... Комбайннар мондый мул уңышка ярашмаган булып чыкты, алар тезмнәрне җыңа алмыйча авыр үкерешеп-тырышып карадылар да сафтан чыга бардылар...

Хафизов, очсыз-кырыйсыз уйларына бирелеп, урман буена җиткәнен сизмичә дә калган иде. Җирән кашка урман ышыгына кергәч, тезгене бушануын тоеп, теләр-теләмәс кенә атлап барды-барды да бөтенләй туктарга булды.

Хафизов өчен бик тә таныш, истәлекле урыннар иде бу. Шушы урман буеннан өч ел буе Урманлы мәктәбенә йөрделәр. Көзге пычракларда, яңгырлы-буранлы көннәрдә алар шушы юлны сайлыйлар иде. Ни әйтсәң дә, урман арасы, ышык, ачы салкын җилләр биредә сүлпәнәя, атлавы җиңеләя иде.

Хафизов ияреннән сикереп төште дә, авылдашларының әйтүенә караганда, ике йөз яшьлек имән янына килде. Алар шушы имән янында ял итеп алырга яраталар иде. Кайсыныңдыр җиңел теле имән ышыгын «вокзал» дип атады. Шуннан соң китте инде, арып-талган чакта, «менә вокзалга җиткәч ял итәрбез» дип, имәнне алдагы максат итеп билгеләү, ашыгып атлаулар... Хәзер дә Хафизов имән ябалдашлары астына кереп, бирчәеп торган коры тамыр өстенә утырды да тирә-юньгә карады. Яңгыр... Кинәт Хафизов, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, җиргә тезләнде, берсе-берсе көрәк сыман куллары белән җирдә муртаеп тыгызланган яфракларны умырып-умырып алды, туфракны казый башлады. Ләкин җир каты, аны бармаклар белән генә чокып булмый иде. Хафизов янәшәдә яткан коры ботак сыныгын алды, җирне шуның белән тырнарга керешге. Кечерәк бер чокыр хасил булды. Аннан чыккан ярмалы кара туфракны учына алып карады, аннары чокырны тагын бераз тирәнәйтте дә кулын шунда батырды. «Гаҗәп, бик гаҗәп, дип пышылдады Хафизов. Җир куеныңдагы ярмалы кара туфрактан йомшак җылылык бөркелә иде. Председатель туфракны кушучлап алды, күз алдына ук китереп, җирдәге җылылыкның кайдан чыкканлыгын белергә теләгәндәй, текәлеп карап торды, аннары туфрак бөртекләрен бармаклары белән араларга керешге...

Шул вакыт кайдандыр:

— Что вы там ищете, абый? — дигән тавыш ишетелде.

Хафизов учындагы ярмалы кара туфракны ташларга онытып, тавыш килгән якка таба күтәрелеп карады. Аның алдында аягына аксыл төстәге резин итекләр, иягенә кадәр каплаган түгәрәк якалы кара свитер, аның өстеннән плащ киеп, башына кыекча яулык бәйләгән озынчарак йөзле, яулык астыннан кара бөдрә чәчләре күренеп торган унсигез-унтугыз яшьләрдәге кыз басып тора иде. Ул, куллары гына түгел, битләре дә туфракка буялып беткән, ләкин буй-буй сызыклы күлмәк өстеннән зур төенле, вак шакмаклы галстук бәйләгән кешегә карап-карап торды да урманны яңгыратып көлеп җибәрде. Кызның яңгыравыклы тавышы якындагы агачларга бәрелеп, беркадәр адашып йөргәннән соң янә әйләнеп кайтты. Кыз көлүеннән кинәт туктады да берике адым артка чигенде, ләкин имән төбендәге сәер кешенең йөзендә андый-мондый усаллык чаткылары күренмәгәч, тагы кыюлана төште.

— Нәрсә югалттыгыз дим бит инде, абый? Әллә, әллә соң чукракмы сез?

Хафизов, артына борылып, имәннең теге ягыннан кемнедер эзләгәндәй итте. Әмма тирә-юньдә чемченеп йөрүче җирән кашкадан башка җан иясе юк иде.

«Кайда, кайда гына ишеттем соң мин бу тавышны? Кайда, кайчан сөйләштем мин бу кыз белән? Юк, гомумән, кайдадыр күрдем бит инде мин бу кызыйны...»

Хафизов, әле яңгыраган тавышны хәтерләсә дә, каршысында, гаҗәпләнүенең чигенә чыгып, соры күзләрен тутырып карап торучы кызны, кызганычка каршы, беркайчан да, беркайда да күргәне юк иде. Ләкин тавышы... Кайчандыр нәкъ менә шушы имән төбендә ишетә иде түгелме соң?.. Ләкин бу кызый авызыннан түгел...

Тормышының кыен көннәрендә, госпиталь койкасында ятканда көн саен ике-өч мәртәбә үлемнең ачы бәбәкләренә карап та яшәүдән өметен өзмәгән, ләкин инде кичерелгәннәрдән чигә чәчләре буй-буй чалара башлаган кырык яшьлек ир менә бу минутта чарасыз калды. Әле генә җанын талкыган борчулы уйларын бер дә булмагандай онытты да җибәрде...

— Җир салкындыр бит, абый, суык тидерерсез. Әллә соң сез, чынлап та, чукракмы?..

— Юк, сеңелем, чукрак та, телсез дә түгел мин. Җирдән, сеңелем, суык тимәс... Җылы икән бит ул безнең җир. Менә тотып кара, сеңелем, җир җылысы бит ул...

Кыз, Хафизовтан битәр аптырап, үзенең нечкә бармаклары белән ярмалы кара туфракны тотып-тотып карады. Дөрестән дә, җылы иде туфрак.

Бәлки, туфракка Хафизов кулындагы җылы күчкән булгандыр...

— Җылы икән, абый. Әллә сез җир җылысын билгеләүче тылсым иясеме? Җан җылысы кирәк кешеләргә, абый.

— Дөрес, сеңелем, тик җан җылысы вакытлар үтү белән онытыла, диләр кайберәүләр. Ә менә туган җир җылысы онытылмый да, кимеми дә...

— Әй, сез, абый, әллә нинди серле сүзләр сөйлисез. Шагыйрь-фәләнме әллә сез?

Хафизов кызның кәкре атып туры тидерә язуыннан елмаеп куйды.

— Юк, сеңелем, мин шагыйрь түгел, ләкин моннан атна ун көн элек кенә журналист идем...

— Ә хәзер, хәзер кем соң сез, абый?..

— Хәзерме? Хәзер мин, сеңелем, әллә бәхетемә, әллә бәхетсезлегемә каршы, менә шушы җирләр өчен җаваплы кеше, «хуҗа» ди колхозчылар. Председатель иттеләр мине, сеңелем...

— Кайсы колхозга, абый?..

— Менә бу җирләр, сеңелем, мин туганнан бирле, «Дуслык» колхозыныкы... Аңа хәтле дә безнең бабайларныкы булган...

— Сез Яңавылныкымыни? Мин дә шунда кайтам бит әле.

— Күрәм инде.

— Мин быел гына кайттым бу якларга. Ләкин, ни хикмәттер, бу җирләр миңа бик якын тоела. Нигә икәнен үзем дә белмим.

— Шулаймы? Кем кызы буласың соң син (Хафизов аны чүт кенә «җен кызы» дип атамады), кемгә кайтасың?

— Әнием... әнием авылына кайттым мин, абый. Бик елады әнием. Гел шушы якларны сагынып яшәде. Мине дә гел шушы якларны сөйләп үстерде. Моннан да матуррак, мондагыдай да игелеклерәк, җанга якынрак җир бүтән беркайда да юк, диде әнием миңа. Менә бу имәнне алар яшь чакта «вокзал» дип атап йөрткәннәр. Дөрес әйткәнме икән ул, абый?.. Абау, абый, сез нишләдегез... нишләдегез дим, абый?..

Хафизов нәрсә булганны үзе дә аңлап өлгермәде. Аның төзәлеп бетсә дә, ара-тирә хәбәр биргәләргә маһир яралары, сызлау, михнәтләре — барысы да, барысы да берьюлы янәдән әйләнеп килгәннәр дә үлем базына таба өстериләр сыман тоелды аңа. Ләкин әлеге шаукымның беренче көчле дулкыны тиз үтеп китте. Җилкәсеннән кочаклап тоткан кулларны тойды Хафизов. Һич көтмәгәндә аны салкын рәхәтлек биләп алды. Тагын бер минуттан аның йөзеннән качкан кан кайтты, күзләренә нур иңде, ачык күрә башлады. Әмма колакларында шундый кискен вакытларда кабатлана торган чыңлау тавышы гына калды. Тик Хафизов аңа игътибар итмәде. Ул кызның йомшак, ләкин нык кулларына тотынды да башта бер аягына, аннары икенчесенә басты. Кызның күзләре шундый якын, шундый таныш, искиткеч таныш иде...

— Ни булды сезгә, абый? Әллә авырыйсызмы?

— Хәзер үтте инде, шайтан алгыры, кайчакта шулай сынатып куя. Ул тагын «сылу кызлар алдында» дип өстәмәкче иде дә, урынсыз шаярту булыр дип, дәшмәде.

Алар, шушы җирдә туып-үскән, шушы җирнең җылысын тоеп яшәгән Дамир Хафизов һәм әнисе туган җир җылысы тартып кайтарган исемсез кыз, шактый гына бер-берсенә текәлеп тордылар. Хафизов аягына баскач, әлеге кыз кулларын тартып алды да ике-өч адым артка чигенде, яулык астыннан чыгып, иреннәренә тиеп йөдәткән чәчләрен башта өреп карады, аннары, житез хәрәкәт белән яулык астына яшереп куйды...

Хафизов чемченә-чемченә шактый ерак китеп өлгергән җирән кашканы тотып килде, кызның таш төягәндәй авыр дипломатын кулына алды.

— Әйдә, сеңелем, кайтыйк, алайса, Яңавылга,— диде.

Алар Кәжинкә елгасын үтеп, Акбалчык басуы аша салынган кыр юлы белән авылга таба атладылар. Бераздан аста, инеш буенда сыенып утырган авылның борынгыдан калган мәчет манарасы күренде. Ачылып килгән офыкның яктысы күзләрне чагылдырды. Ничә көннәр инде вак яңгыр койган болытлар Мәрәҗән тавы ягыннан килеп, Шомыртлык борынына таба агылалар, алар артыннан күз йөзе чистара, яңгыр болытларыннан арына бара иде.

## 12

Бүген кибәннәргә өелгән игеннәрне, куәтле өрдергечләр белән киптерелгәннән соң, суктыра башларга булдылар.

Иртән иртүк Хафизов янына баш агроном Вәли Гомәрев килеп җитте. Соңгы берничә көн эчендә аның түгәрәк йөзе сузылыбрак кал-

ган, шуңадырмы, күзләре зурайган шикелле күренә иде. Әмма аңарда беренче тапкыр үткәргән идарә утырышындагы сүлпәнлекнең эзе дә юк, әйтерсең, кешенең бөтен характерын, сөйләшүен, фикерләвен атна-ун көн арасында алмаштырып була, дип уйлап алды Хафизов.

— Бүген эшне нәрсәдән башлыйбыз, иптәш Хафизов? Суктырырга керешмибезме? — диде ул кунакханә бүлмәсендәге өстәл янына килеп.

— Әйдә синеңчә ничек, Вәли абый, башларга мөмкинме?

Агроном, гадәтенчә, ашыкмыйча гына чәчсез түбәсен сыйпап алды, нәрсәгәдер «кесә бухгалтериясен» чыгарды, аны ачып та тормыйча янәдән урынына салды һәм:

— Минемчә, вентиляторлар ярыйсы гына җилләндерделәр, киптерделәр, башласак та ярый,— диде.

Хафизов аның белән килеште һәм алар бергәләшеп эш урынын карарга, рекогносцировка ясарга киттеләр.

Машина-трактор паркында аларга комбайннарын суктыруга куярга тиешле механизаторлар да кушылды. Озакламый бер төркем ир-ат ындыр табагы янындагы чирәмлектән калкып чыккан кибәннәр арасында туктаусыз эшләп торган җилләткечләр янына килеп бастылар.

Әмма киңәш-табышны башларга өлгерә алмадылар, идарә ягыннан бер атлы күренде. Партком секретаре Семенов атыннан төшә-төшешкә үк Хафизовка:

— Иптәш председатель, тагын ике сәгатьтән безгә өлкә комитеты вәкиле килә. Әле генә Гайнуллин шалтыратты. Сезне табарга, идарәдә көтәргә кушты,— диде, ашыгудан булса кирәк, чуваш һәм татар сүзләрен гадәттәгедән ныграк буташтырып.

Бу хәбәрне көтмәгән Хафизов бераз караңгыланыбрак алды, дәшмичә торды. Аннары Гомәревкә борылып:

— Син, Вәли абый, мондагы эшне оештырып җибәрерсең,— диде дә Семеновка «киттек» дип ымлады.

Сәгать ярым узмады, идарә каршына аллы-артлы ике «УАЗ» килеп туктады. Хафизов аларны каршы алырга дип урыныннан кузгала башлауга, ишек ачылып китте, һәм бусагада обком вәкиленең мәһабәт гәүдәсе күренде. Болай да әллә ни зур булмаган бүлмә, ул кергәч, тагын да кечерәеп, тараеп калган шикелле булды. Хафизов белән алар электән үк танышлар иде.

— Я, иптәш корреспондент, эшләр ничек бара? Сезне киң фронт белән һөҗүмгә күчкәнсез дип әйтәләр, шул дөресме?

Хафизов каушамады, хәрбиләрчә төз баскан килеш җавап кайтарды.

— Геземнәрдәге игеннәрне җыеп кибәннәргә өйдек. Бүген суктырырга керешәбез, Фәргат Әхмәтович. Әмма киң фронт белән һөҗүмгә күчүдән бик ерак әле без...

— Я, я, нәрсә җитми, әйтегез, иптәш Хафизов.

— Җитмәгән нәрсәләр күп, Фәргат Әхмәтович. Колхозга озакламый илле ел тула, кызганычка каршы, шушы тантананы уздырырга культура йортыбыз да юк...

— Булыр. Булыр, иптәш Хафизов. Без менә нәкъ шуның өчен килдек тә сезнең колхозга... Тик, сүзне башлаганчы, әйдәгез әле, сезнең фермаларны, терлекчелек биналарын карап кайтыйк. Аннары күз күрер...

Җәлпәк «УАЗ»лар пычрак ярып фермалар ягына таба кузгалдылар. Хафизов Фәргат Әхмәтовичның тикмәгә генә йөрмәсен белә иде. Шуңа күрә терлекчелек фермалары турында сүз чыгуга, эшнең нәрсәдә икәнлеген чамалагандай итте. Алар авылның кырый урамы аша уздылар да, бакчалар артындагы тугайны ярып, фермалар ягына киттеләр.

Хафизов савым сыерларының санын белешкән иде, әмма калганнары турында тулы мәгълүмат бирә алмады. Фәргат Әхмәтович баядан бирле үзләренә ияреп йөреп тә бер авыз сүз әйтмәгән партком секрета-

рена борылды да терлекчелектәге хәлләр турында сөйләвен үтенде. Теге ык-мык килде, юньле җавап бирә алмады. Аннары, терлекчелектәге эшләр өчен председатель җавап бирә иде, дип ычкындырды. Читтәрәк торган Сабир Гайнуллин аңа йодрык күрсәтте, сүзгә кушылырга омтылды. Әмма Фәргат Әхмәтович кинәт көлеп җибәрде. Райком секретареның Семеновны якларга маташуын сизгән иде ул. Гайнуллин әйтергә җыенган сүзен әйтмичә туктап калды.

— Менә нәрсә, иптәш Хафизов,— диде, ниһаять, Фәргат Әхмәтович.— Менә нәрсә... Сезгә мәгълүмдер дип уйлыйм, Акъяр районында дуңгыз симертү белән шөгыльләнүче комплекс-автомат бар. Әмма әлегә кадәр мөгезле эре терлекләрне симертү комплексы юк. Кыскасы, сезнең районда да бу эшне яңа алымнар, югары механизация нигезендә башларга вакыттыр бит, иптәшләр, ә? Сез, иптәш Хафизов, иптәш Гайнуллин, моңа ничек карыйсыз?

Хафизов моңа ни диярга дә белмәде. Дөрес, аның мал симертүче эре комплексларда булганы бар, карап йөргәне, хәтта андый фермалардан мәкаләләр дә язганы бар. Ә монда, әле күптән күнегелгән эшләрне дә җайга салмаган килеш... Меңләгән баш терлекне симертергә...

Гайнуллин озак көттермәде, Хафизовның дәшмәвен кирегә юрап булса кирәк:

— Бу — бик вакытлы киңәш. Безнең моңа җавабыбыз бер: керешергә кирәк бу эшкә,— диде. Беравыктан, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, өстәп куйды: — Билгеле, тиешле акчасы һәм кирәкле материаллары бирелгән очракта...

Фәргат Әхмәтович бөтен гәүдәсе белән берьюлы аңа таба борылып:

— Ә сез, иптәш Гайнуллин, «Дуслык» колхозының шундый олы эшкә көче җитәр дип уйлыйсызмы? Хәтерем ялгышмаса, алар дәүләткә миллион сумга якын бурычлы...

— Билгеле, бөтен район хуҗалыклары бергә тотынган очракта, кооперация юлы белән оешканда, минемчә, башкарып чыкмаслык эш түгелдер,— диде Хафизов көтмәгәндә дулкынлана башлап. Эре комплекс-ферма корган очракта аның янәшәсендә торак, культура йортлары булачак, һичшиксез, юлы да салыначак бит дигән уй-хыяллар аның күз алдыннан уздылар...

Хафизов, кунакларга юл күрсәтеп, алдан атлады. Озын-озын кибәннәрнең ике башында, аз-маз яңгыр сибәләп торуга да карамастан, тузан өере күтәрелә иде. Фәргат Әхмәтович якындагы комбайн янына килде. Аның күз алдында кайчандыр барлык авылларда булып та, соңгы унбиш-егерме ел арасында онытылган күренеш — игеннәрне урында суктыру күренеше пәйда булды. Комбайн хедеры алдында алты-җиде ир-ат кулларына яртылаш сындырылган ураклар тотканнар да кибәннән бирелгән көлтәләрнең бавын кисеп барабан авызына ташлыйлар. Югарыдан көлтә биреп торучыларның шаян сүзләре ишетелгәли иде.

Мондый күренеш аның күңеленә хуш килде бугай, ул, Гайнуллинга таба борылып, нәрсәдер әйтте, тегесе аның белән килешеп башын селкеп куйды, нәрсәдер сөйли башлады. Соңрак, җитәкчеләр идарәгә кайткач, обком вәкиле Хафизовны мактап, эшләрне искечә дә бик яңача оештырып була бит, диде.

Шулай итеп, «Дуслык» колхозында бөтен бер районның ит заданиесен үтәп барырлык комплекс — ферма кору турындагы мәсьәлә хәл ителде. Яңа елдан төзелешне башларга булдылар.

Шул ук көнне, кичке караңгылык төшеп килгәндә, Таһир Вәлиуллин кайтты. Ул комбайн көпчәкләренә кидерә торган биш пар резин башмак-гусеница алган, файдалану тәртибен дә белеп кайткан иде. Эшне ир-

тәгәгә калдырмаска, бүген үк җайланмаларны куярга, сынап карарга булдылар һәм көйләүчеләрне, комбайнчыларны чакырттылар.

Кешеләр җыелганчы, Хафизов силос салучылар янына китте. Караңгы төшүгә дә карамастан, бередә эш тукталмаган, яшел масса кайтаручы тракторлар берәм-берәм кыр ягына китеп баралар, озын-озын траншеялар өстенә терлекчеләр йорты түбәсенә куелган прожекторның көчле нурлары сибелә иде.

Траншеяларга барып җитәргә кырык-илле адым чамасы калгач та яшел масса таптатып торучы трактор ышыгыннан күләгә аерылып чыкты, Хафизов ягына таба атлый башлады.

Шул мәлдә, бөтен тирә-юньне караңгылыкка чумдырып, прожектор сүнде. Траншея өстендә аркылы торган трактор фараларының сүрән яктысында Хафизовның бөркетнеке кебек зирәк күзләре каршы килүчене абайлап кына түгел, танып та өлгерде.

Ризаевның авыш-тәвеш атлавыннан ук Хафизов аның яхшы ният белән килмәвен аңлап алды.

— Карале, карачкы дип торам, безнең Хафизов түгелме соң бу? — дигән булды Ризаев гөбедән чыккандай тавышы белән. Аннары сул кулындагы тимер чылбырны күтәрә-күтәрә: — Я, Хафизов, әйт иманыңны, әгәр дә андый нәрсә синдә була калса, канишне...

Хәрби вазифаларын үтәгәндә һәрвакыт уяу булырга күнеккән Хафизов баш өстенә таба күтәрелеп барган чылбыр бөҗраларның чыңын ишетте. Шул ук мизгелдә ул чыңга кискен халәттә колакларында яңгырый торган шау да кушылды. Хафизов капылт алга омтылды, уң кулын чылбырга каршы сузып, бар авырлыгын, бар көченең саллылыгын сул йодрыгына салып, яшен ташы сыман ялтыратып Ризаевның ияк астына бәрде. Башта «чык» дигән тавыш, аннары тешләр шыгырдаганы ишетелде... Әмма Хафизовның да уң кулы түзә алмаслык тупас авыртудан чыбыркы шикелле салынып төште, трактор фараларының тонык яктысы бер мәлгә югалып торды.

Прожектор сүнгәч тә, «ни булды» дип терлекчеләр йортыннан чыккан кешеләр тавыш килгән якка ыргылдылар. Ул арада меңле лампа кабынып китте, Хафизов, авырткан кулын күкрәгенә кысып тоткан килеш, җирдә хәрәкәтсез яткан Ризаев аша атлап чыгуга, партком секретаре Семенов белән күзгә-күз очрашты. Мизгелнең бер өлешендә булган бу бәрелеш Хафизовка бик күп нәрсә сөйләгәндәй булды, бәрелешнең серен ачып салгандай итте.

— Ни булды, ни булды Тамир Чәләевич?

Авырткан кулның сызлавы йөрәкне сава, колактагы шау ачы сызгыруга күчә, башны каядыр ашерәсе, җәһәннәмгә сикерәсе килә иде Хафизовның. Бер-берсенә ябышкан тешләрен көч-хәл белән ачып:

— З-з-зарррар юк... Аны карагыз,— диде председатель.

Семенов белән тракторчы, силос салуда эшләүче ике-өч ир-ат Ризаевны җирдән күтәреп торгыздылар. Аның белән бергә сул кулына ураган тимер чылбыр да күтәрелде. Барысы да аның кулына уралган чылбырына, аннары исләре китеп Хафизовка таба борылып карадылар. Председатель исә уң кулын күкрәгенә кысып тоткан килеш, берәүгә дә бер сүз дәшмичә борылды да караңгылыкка кереп югалды.

Бу вакытта машина-трактор паркында эш башланган, комбайнчыларның барысы да, хәтта ялкаулыгы белән даны чыккан Мотыйгулла да, көйләүче-слесарьлар арасында резин гусеницаларны кидереп маташалар иде.

Беренче сынауны Шиһабетдин комбайнына ясарга булганнар, һәркайсы шунда, кулына эш тимәгәнe киңәш-фәлән биреп булса да ярдәм итәргә тырыша. Ни әйтсәң дә, комбайн кадәр комбайнга мондый әкәмтөкәм гусеницаларын кидертүне моңарчы күргән-белгән кеше юк иде.

Озак та үтмәде, кунак егете сыман көязләнеп торган «Нива» һәр төше килешле, җыйнак кыр корабы, әллә ниткән карачкыга әверелде дә куйды. Мотыйгулла, күршесен чәнечкеләп алыйм әле дип:

— Карагыз әле, егетләр, карагыз... Шиһап абзагызның комбайны гражданнар сугышыннан кайткан инглиз танкысына әйләнде бит...— дигән булды, тәмәкедән саргайган тешләрен ыржайтып.

Мут Мотыйкның шаяртуы урынлы булса да, аңа иярүче булмады. Күн эшләпәсе астыннан сары чәчләре тузылып чыккан Таһир аңа: Буталма, пожалысты, Мотыйгулла абзый, аяк астында. Бар, әнә үз комбайныңны алып чыга башла,— диде. Беркөнге җыелыштан соң үзенең комбайны тирәсендә маташса да, суктырган процентлары аз булгач, минекен барыбер сүтеп таратырлар диебрәк йөргән Мотыйгулла, кичәле-бүгенле генә баш инженер итеп куелган Таһирга ышанмыйчарак карап торды. Тегесе кабат: — Бар, бар диләр бит сиңа, Мотыйгулла абзый, алып чыга башла комбайныңны,— дигәч кенә урыныннан кузгалды.

Шул чагында комбайн алдында уң кулын бинт белән урап, плащнакидка өстеннән муенына аскан Хафизов, аның артыннан баш агроном Гомәрев килеп чыктылар.

— Әйдә, Шиһабетдин абый, кабыз двигателеңне, атлатып карыйбыз... бу нәмәстәне...

Стартер гөжелди башлады, калын тонык тавыш белән двигатель эшләргә тотынды. Хафизовның төсе качкан, әмма карашы элеккегечә нык, тыныч, бары тик яңак сөякләре генә уйнаклап-уйнаклап ала иде.

Кабина күперчегеннән:

— Нишлибез, иптәш Хафизов, кузгалып карыйбызмы? — диде комбайнчы; Хафизов, бер читкәрәк атлый-атлый, «әйдә, кузгал, карап карыйк әле» дигән сыман исән кулын изәде.

Двигатель көчлерәк эшләргә кереште, резин гусеницалар тартылдылар-тартылдылар да тәгәрмәчләргә юл салып җиргә ята башладылар.

Җыелган ир-ат комбайн тирәсеннән атлады. Җылы ятагын калдырып килгән Закирҗан карт та шулар арасында. Капкадан чыгып иллеалтмыш метр киткәч, Шиһабетдин комбайнны туктатып җиргә төште, агрегаты тирәли ике тапкыр әйләнеп чыкты да, башын чайкап, елмаеп торды, аннары, гадәтенчә, салмак кына әйтте:

— Майлаган кебек бара, җир өстенә кергәч нишләр бит әле... камыл-саламны җыймасмы,— дип шик-шөбһә белдерде.

Монысын инде эшләтеп карамыйча белеп булмый иде. Шуңа күрә озын-озакка сузмыйча басуга таба кузгалдылар.

## 13

Салкынча иртә. Юл буендагы өянкеләр, таң атканда көчәя төшкән җилдә тирбәлә-тирбәлә, нәрсә турындадыр гәпләшәләр. Яңгыр туктаган, ләкин әле сүрән болытлар үз юллары белән каядыр һаман агылалар, күк йөзендәге йолдызлар сирәк-мирәк кенә күренгәлиләр дә тагын югалалар. Әкрен генә таң атып килә.

Резин гусеницалар кидерелгән кыр корабларын җайлап җибәрүнең мәшәкатьле яклары җитәрлек булды. Җир өстеннән ярыйсы гына шома барган гусеницалар камыллы-саламлы төшкә кергәч утыз-кырык метр узуга зурая башлыйлар, аннары авырлыкка чыдый алмыйча бер читкә шуып чыгалар, агрегатны туктатырга мәҗбүр итәләр иде. Тора-бара җаен таптылар, агрегатлар, акрын тизлек белән булса да, тамырда басып торган килеш каралып калган игеннәрне егып сала башладылар.

Менә, ичмасам, көн дисәң дә көн, дип уйлады машина-трактор паркы яныннан кунакханәгә таба барган Хафизов. Әгәр моннан берничә ел элек, госпитальдә яткан чакларда «син әле шундый-шундый киеренке көннәрне дә эһ итмичә кичерерсең» дисәләр, Хафизов аларга ышанмас иде. Ә хәзер...

Хәзер Хафизов үзенең кичәге төш вакытыннан бирле авызына бер валчык икмәк капмаганны уйлап алырга өлгермәде, колхоз ашханәсендә «ялт» итеп ут кабынды. Хафизовның чигәләрен кысып-авырттырып, йөрәгенең ерак бер түрен дөрләтеп Надирә искә төште. Әйе, ул хәзер ашханәдә булырга, механизаторларга иртәнге аш пешерергә тиеш. Борылыргамы, юкмы?

Котмагәндә калыккан бу сорауга җавап бирен өлгергәнче, Хафизов авыр итекләрен лаштыр-лоштыр китереп ашханә ягына таба атлый иде инде. Инде керәм дип болдырга күтәрелгәндә пәрдәсе яртылаш ачык тәрәзәдән Надирәнең шәүләсе күренде.

Керергәме, юкмы? Хафизовның калган берничә адымны атларга хакы бармы?

Хафизов баскан төшендә туктап калды, аптырап тирә-якка карады. Чынлап та: керергәме, юкмы?

Күпме еллар узды, күпме сулар акты, нинди юллар үтәргә туры килде бит аларга соңгы тапкыр икәүдән-икәү сөйләшкән-серләшкән карлы-буранлы март төненнән соң. Тормыш үзенекен иткәндер бәлки. Надирә аны күрергә, сөйләшергә дә теләмидер? Дамир да бит әнә, теләгән булса, табар, тапмый калмас иде, илдәге кеше бит, чит-ят илләрдән дә эзләп табалар.

Юк, Надирә аның йөрәгеннән беркайчан да чыкмады, югалмады. Димәк, икесенең дә бер-берсен онытмаулары бик ихтимал ич. Бер-берсен гомер буена яратып та шул кадәр еллар буе очрашмаганнар икән, аңлашмаганнар икән, димәк, кешеләрнең күпчелеге тарафыннан танылган кагыйдәләр яраксыз булып чыга. Хәер, тормыш бит ул язылган кагыйдәләргә караганда, язылмаганнарны күбрәк ярата, кешеләр алдына шуларны ешрак куя түгелме соң?

Надирәнең узган тормышын бөтенләй белми Хафизов, белми... Ләкин беркөнге очрашу, берәүгә дә әйтелмәгән кичерешләр аңа бик күп нәрсәләр турында сөйләде бугай...

Ун ел элек Хафизов офицерлар йортында эшләүче бер хатын белән мавыгып, хезмәттәшләре сыман тату гаилә кормакчы булып, тиз арада шуңа өйләнеп тә алган иде. Ләкин ел ярым тормадылар, гаиләне беректереп тотучы нигез ташы — мәхәббәт дигән нәрсәнең булмавы Хафизовның теләгән чәлпәрәмә китереп ташлады.

Хезмәт вазифаларын үтәгәндә каты яраланган Хафизовка тоташтан ел ярым госпитальдә ятарга туры килде. Хафизов җан газабын кичереп, үлем белән тартышып яткан минутларның берсендә, хәтта дәвалаучы врач та «летальный исход» сүзләрен ычкындырды. Хафизов ул сүзләрне аермачык ишетте. Ишетте дә: «Әһә, шулаймы? Мине исән килеш исәннәр исемлегеннән сызмакчы буласызмы?» дигән шикелле, икеләтә-өчләтә үҗәтләнеп, тормышка алып бара торган өмет мыскалларына ябышты.

Тагын көннәр, айлар үтте. Хафизов палатада, аннары коридорда, ниһаять, ишегалларында йөри башлады. Шул көннәрдә житкерделәр аңа: изге теләк белән кабызган гаилә учагын усал җилләр пыран-заран китереп, туздырып ташлаганнар иде...

Ул чакта:

— Выше, выше голову, капитан,— диде ул үз-үзенә.

Кыенлыкларны түземлелек белән кичерергә өйрәнгән йөрәге, озак-

ламый госпитальдән чыгасын ишеткәч тә, әллә нишләде, йомшарып китте, тамагына тыгыз төер килеп тыгылды. Ул күршесендәге капитанга:

— Кыенлыкларны кичерүе шатлыкларны ишетүгә караганда җиңелрәк бит. Болай булыр дип уйламаган идем,— диде, әлеге төерне йотарга тырышып.

Менә хәзер дә Хафизов шул күршесенең:

— Выше, выше голову, капитан! — дигән сүзләрен ишеткәндәй булды. Һәм үзен үсмер чагындагыдай җитез, чая итеп сизде. Ашханә тәрәзәсенә тагын бер карап алды да, сул кулын сузып ишекне тартты, «пычрак итекләрне салырга тукталсам, керә алмам», дигән уй белән эчкә атлады.

— Саумы, Надирә-Кара толым... иртәләгәнсең...

Надирә җавап бирмәде. Күкрәгеннән чыгам-чыгам дип типкән йөрәген тыярга тырышып тирән сулыш алды. Беравыктан: «Юк, Дамир, иртә түгел, соңгарак калмадым микән?» димәкче иде, булдыра алмады, күзләрен томан каплады. Дамирның арадагы бер-ике адымны атлыйсы да, Надирәне кочагына аласы килде. Чәчләреннән сыйпыйсы, юатасы иде аны, үткән еллар үкенечен бергә бүлешәсе иде. Шул вакыт Дамир өстәл янында утырган, беркөн урман буенда очраган кызны абайлап алды. Надирәгә ике тамчы су кебек охшаган, аның дәвамы... Хафизов бу кызның колхозга баш бухгалтер урынына рөхсәт алып килгәнен бераздан белер.

Яңавыл өстендә таң туды. Салынкы-сүрән болытлар Мәрәҗән тавы ягыннан килеп, Шомыртлык борынындагы ялгыз имән ботакларына тия язып агылып беткәннәр иде инде. Күк йөзе чип-чиста, анда яңа гына туган ай көн яктылыгына коена, җир йөзенә кояш нурлары карый башлаганны көтә иде.

## Камил Кәримов

# АЛДАВЫЧ КӨЗ

КЕЧКЕНӘ ПОВЕСТЬ



Әйтәм аны, тавышсыз-тынсыз гына чыгып шылганнар! Менә сиңа булышчылар, менә сиңа дуслар! Тапкан хәзинәләрен алып калырмын дип курыктылар микән? Кирәкми, хәрам килешми миңа, гомеремдә кеше малына кызыкмадым. Бары тик беләсем генә килә: нәрсә таптылар микән?— Нәгыймәттәй авыз эченнән сөйләнә-зарлана, авыл бетереп, малайларны эзли торгач, эңгер-меңгер төшкәнне дә сизми калды.— Кая гына олакканнар соң, авыл эчендә бер генә малай да калмаган?!.

Кайтырга ашыкмады Нәгыймәттәй. Эңгер-меңгер куерып, караңгы төнгә дә әверелде, күзгә күренә алырдай нәрсәләрнең барысын да яшереп куйгандай итте. Тик утны гына яшерә алмый ул. Әнә, дөм караңгылыкта ут куышы... Тагын инеш ярында. Тагын дип аерып әйтүнең мәгънәсе шунда: кичләрен — җәйнең куены салкыная башлагангамы, башка берәр хикмәте бармы— соңгы айны учак бик еш кабына әле монда.

Иренмәде Нәгыймәттәй, абынмаска-сөртенмәскә тырышып кына инеш ягына атлады. Кеше күзенә чалынса, каз бәбкәсен эзлим, дияргә була. Һич икеләнмәсләр, ышанырлар. Нәни «сары йомгакларың» инеш ярының җәелеп үскән чирәмендә каз булып үсеп җиткәч кенә малай-шалайларга ирек бир әле син... Ялгандырмы, чындырмы, алар каз-үрдәкне тотып, каурыйлары-ние белән әрләп балчыкка төрәләр дә утка ыргыталар имеш, бер сәгатьтән шакыраеп каткан балчыкны урталай ярсаң, парда пешерелгән кош итенең менә дигәне була икән... Сөйләнгән кадәресен дөрескә санасак та, халыкның куркырлыгы юк. Елларның әллә ник кенә кәефләре кырылды: узган ел җәй буе яңгыр койды, быел киресенчә, кырның язгы кар суларыннан гайре дым күргәне юк, корылык җәфалады. Еллар холыксыз килгәч, житәкчеләр дә кырысланды. Әлек җәй уртасыннан колхоз кырларында сый-хөрмәткә кинәнгән казларның картраклары да борчак-бодай басуларын төшләрендә генә күрәләрдер хәзер. Таза каз салмак була, аны канатлары күтәрә алмый. Ә быелгы казлар, кайчан карасаң да, авыл өстендә. Бер күтәрелгәч, өйләренә әйләнеп кайтмаучылары да бардыр, ахрысы, югалган һәр кошны учак куышлыгында җылыга сөенешеп утырган малайларга сылтап кына торалар.

Нәгыйматтәй, ут күбәләге кебек, учак янына тартылды. Тирән эчле кәлүшләрен лаштырдатмаска, кагылуга шартлап сынарга торган куралларга орынмаска тырышып кына гел малайларга якынайды. Кайнар ризык, йомшак урын-җирләрне дә оныттырырлык нинди генә уен таптылар икән соң?

Ә малайлар гамьсезләнеп карта уйныйлар. Бәхәсләшеп тә алалар. Вакыт-вакыт Нәгыйматтәйләргә һич кенә дә таныш булмаган килделе-киттеле сүзләр сөйлиләр: «Очко», «Перебор», «Ике туз», тагын әллә ниләр. Зәһәр кычыткан белән өтәләп, өйләренә җилдертәсе иде дә бит шушы селәгәйләрне, тик гайрәтен тыеп тора әле Нәгыйматтәй. Тыелмассың — әнә, ярдәм итәбез дип, тимурчылар исеме күтәреп йөргән укучылар бакчадагы алмагач чокырын ташлап чыгып качканнар да, каядыр посып, төн җиткәнне көтеп ятканнар. Инде уен аралаш акча саныйлар... Учак сүрелгәнне дә сизмиләр, акча бүләләр.

«Кассада илле сум! Мин тагын иллене өстим... Очко!»— һәм берсе кәгазь акчаларны янгарак этеп куйды. Колхоз пенсиясеннән гайре керем күрмәгән Нәгыйматтәй өчен исең-акылың китәрлек акчалар бит бу. «Ай-һай бай яши хәзерге балалар!»— дип сокланып куйды ул. Тик соклануның чиге булмады: малайлар аның саен акча санадылар: йөз, биш йөз, мең... Нәгыйматтәйнең йөрәге ярыла язды, колак алдаса да, күз шаһит... сүрелеп барган учак тирәсендәге кәгазь акчаларның игечиге юк! Түзмәде Нәгыйматтәй, зәһәрләнеп, малайларга җикеренде, ә үзе, тегеләр котлары очып югалышкач, учак тирәсендә өелеп калган акчалар өстенә ябырылды, чүп-чарлары белән бергә алъяпкычка төйнәде. Ул үзен кинәт кенә бик көчле кеше итеп тойды. Эз төшмәгән төбәктән кураларны ера-ера, чокырлар, ерганаклар аша турыдан гына өенә кайтып китте.

Өйгә керешли үк, юньләп бик күрмәгән капка, болдыр ишекләрен эчтән яхшылап бикләп куйды. Электр лампасын яндырырга да исәбе юк иде, чоланнан челпе алып чыкты. Бу минутта бөтен кеше дә аны гына күзәтеп торадыр төсле тоелды — җәһәт кенә пәрдәләрне дә корып куйды. Ниһаять, ул челпекнең саран яктысына иелде. Алдындагы акчаларны идәнгә бушаткач, өй эченә ислемай исе таралгандай булды. Баштарак ул аларны нишләтергә белмичә, тәртипләп җыярга теләде, аннары, нидер сизенеп, берсен ут яктысында уйнаткалап карады да кинәт ачуы чыгып атып та бәрде. Нәүмиз күңелен тынычландырыр өчен тагын берсен алып карады, хәтта иснәде дә. Кәгазь өеменнән күгәрек салам исе, балчык, авыр тирес исе дә килә иде бугай — иске акчалар ич, кайдадыр качып-посып яткан иллешәр сумлык иске акчалар. Нәгыйматтәй: «Шул кирәк сиңа, карт тилегә!» — дип, үзен-үзе битәрләп, мич капкачын ача башлаган иде, күңеленә юаткыч бер уй килде: «Тукта әле, белмәссең дөнья хәлен, хөкүмәт дигәнең иске заемнарны да сатып ала хәзер. Бәлки боларның да кирәге чыгар!..» Һәм Нәгыйматтәй акчаларны берничә кисәккә төрде дә көзге артына, тәрәзә саңагына, ишек өстенә кыстырып куйды. Ә араланып калган ак кәгазь кисәкләрен — дәфтәр битеннән ясалган карталарны күргәч, бөтен ачуын малай-шалайларга каплады: «Күр әле, миннән дә тилерәкләр бар икән! Мин хет наданның да наданы инде, ә алар соң, алар...»

*
* *

Мәктәп юлы өстендә генә булгач, малайлар укырга барышлый, кирәксә-кирәкмәсә дә кибеткә сугылып чыгар, чиратсыз-нисез генә үлчәү янына тыкшыныр. «Нәрсәгә генә өйрәтәләр соң сезне мәктәптә, кеше төсле чират та тора белмисез?!»— дип, җаннарын тынгысызлаучыларга җаваплары әллә кайчан әзер: «Дәрескә соңга калабыз». Бүген дә шул

ук хәл кабатланды. Дөрес, алар бу юлы өерләре белән түгел, берсе генә килеп керде. Башкалары урам ягында көлешә-көлешә көтеп калдылар.

Рәүф, иптәшләре өйрәткәнчә, туп-туры чират алдына килеп басты, зурларча эшлекле кыланып, сатучы кызга кулындагы зур кәгазь акчаны сузды:

— Шушыңа прәннек бир әле, Фәнилә апай...

Алтмышынчы еллар сатучылары әмма да сизгерләр иде... Кеше кулында ике төрле акча — искесе дә, яңасы да. Искесе әкренләп кими торды, ә яңасы күбәйгәннән-күбәйде. Болай, күрер күзгә әллә ни сизелерлек аермалары да юк югын,— төсләре дә шул ук; берлекләр сары, унлыклар кызгылт, тик яңалары бераз кечерәк кенә шунда. Ләкин хикмәт кәгазь алышынуда түгел, яңа акча элеккеге бәяне ун өлешкә кечерәйтеп куйды. Әгәр алтмышынчы елга кадәр бер кило шикәр ун сум чамасы дип йөртелгән булса, алтмыш беренче елдан ул бары бер сум дип кенә телгә керде. Вак акчалар да зурлыгы ягыннан искеләрдән аерып алгысыз, бары тик чыгарылган еллары гына укырга ятышлы икән — тегеләй карасаң да, болай карасаң да — 1961. Баштагы мәлләрдә яңа акча искесенә ияреп кенә йөрде. Колхоз кассасыннан хезмәт хакы өләшкәндә яңаларны әз-әзләп кенә кушып бирәләр иде. Юкса, ай саен кесә тутырып акча алып кайткан ирнең бер айлык эше уч төбенә дә сыя. 1961 елның гыйнварыннан, бөтенләй яңа акча көенә генә калгач, әкренләп ияләнде халык. Шулай да, карты-корысы акча берәмлеген әле һаман да үзенчә телгә алгалый. «Алтмыш кило шикәр алырлык эшкә күчкән... Йөз илле кило шикәрлек ит саткан... Самолет белән очсаң, утыз кило шикәр бәясенә төшә икән...»

Аның каравы сатучыларның эше җиңеләйде — санарга да җиңел, элеккеге ун тиен бәрабәренә торган яңа бер тиен дә сансызланды — санамый калсаң, искәрүче юк, төшеп китсә, иелеп алмыйлар...

Фәнилә ул чорларны каян белсен, акча алышынган елны туды гына бит әле ул. Рәүфнең кулында зур кәгазь акча күргәч тә искедер дип уйлап өлгермәде, я, кайсы җүләре икенче класс баласына шушындый байлыкны тоттырып чыгара инде, дип кенә гаҗәпләнде. Шулай да акчаны алгач, сәерсенеп ут яктысына китерде, иснәп карады, инде үзүзенә ышангач кына Рәүфкә җикеренде.

— Иске акча ич бу!

Рәүф акчаны тартып алып тиз генә чыгып шылырга ниятләгән иде дә, кая ул... Алырсың Фәнилә кулыннан — беренче елын гына эшләми инде ул сатучы булып. Нәселдән килгән гадәтләрен дә өстәсәң... Әнисе Әгъдияне гомерен сатучы эшендә үткәргән дип сөйлиләр.

Һәммәсеннән димәсәк тә, сатучыларның күбесеннән менә дигән артист чыгар иде... Әле генә җикеренгән Фәнилә кинәт кенә иң юаш кызга әверелде дә куйды.

— Тукта әле, Рәүф, әгәр дә бу акчаны кайдан алганыңны әйтсәң, уч тутырып прәннек бирермен.

Чираттагылар да тынып калдылар. Бер авылда яшәп, кемнең кайда нәрсә кыланганын белү кызык бит ул.

— Әвәле прәннек давай,— диде Рәүф батыраеп.— Аннан может әйтермен дә.

Фәнилә учына сыйганчы прәннек алып, Рәүфкә сузды, тик бирергә ашыкмады. Үзе кызарып, үзе кабарып пешкән прәннекләргә озак карап тора алмады Рәүф.

— Нәгыймәттәйләр бакчасыннан! Абыемнар аның бакчасына өшегән алмагач казып чыгарырга барганнарые, агач төбеннән тапканнар.

Фәнилә чираттагыларга кутәрелеп карамыйча гына түргәрәк үтте дә склад ягында җыештырып йөрүче кызга кычкырды:

— Идәннәр юылмыйча калса да ярар. Йозак кайда, кибетне бикләргә кирәк?!.

* * *

Өй эче караңгы булса да, кергән-чыккан кешеләргә йөзе якты Нәгыймәттәйнең. Фәниләгә дә түрдән урын бирде ул. Казан астында, ботак сынган тавышлар чыгарып, усак утыны пыскый, стенада герле сәгать саңгырау гына текелди.

— Нәгыймәттәй,— дип тынлыкны бүлде Фәнилә,— нумизматның кем икәнен беләсеңме син?

— Авыр туфрагы җиңел булсын, мәрхүм әниеңә охшагансың — хәл-әхвәл белешү юк, үз кирәгеңне сорый башлыйсың... Кемне беләсеңме дисең әле?

— Нумизматны.

— Исеме бигрәк кәмит, бер дә кабатлап әйтмәле түгел. Белмим мин андый кешене, безнең авылда яшәгәнме соң ул?

— Иске акчалар җыеп ята торган кешегә кушалар ул исемне.

— Сатучыларга туры килә икән. Искесен дә, яңасын да бик оста җыясыз.

— Сатучылар ише генә түгел, бөтен кеше дә котырып-котырып акча җыя хәзер.

— Әниең дә җыеп караган иде, теге дөньяга үзе белән алып китә алмаган.

— Әрләшергә дип кермәдем, Нәгыймәттәй.

— Каш өстендә сипкел кеби алты сатучыбызның берсе белән ызгышып торалар димени?! Тоз-шикәргә дә районга гына йөрисе кала бит аннары. Калада гына рәхәт иде ул: сатучының күзенә карап, әйтәсеңне әйтәсең дә икенче кибеткә кереп китәсең. Бик ачуыңны китерсәләр, жалу кенәгәсен сораган булып, котларын аласың.

— Бер киткәч, ник калмадыгыз соң анда?

— Үз иргем белән түгел, әнкәң [illegible]ткысына алданып кына киткән идем мин. Ә ул, нигеземнең иманын к[illegible]чырып, бакчама агач төбе саен акча күмеп яткан.

— Нәгыймәттәй, җыен юк-барны сөйләп, күңелеңне керләндермә, сиңа килешми ул, лутчы күрсәт шул акчаларны, бераз хыялланып алырмын ичмасам... Санап карыйсым килә. Синең бакчадан тапсалар да, әни өлеше бит инде...

Нәгыймәттәй, капылт кына торып, кулына йон бияләй киде дә яшерелгән төргәкләрне Фәниләгә сузды.

— Мә! Берүк өеңә алып кайтып кына сана. Монда тузанын да коясы түгел.— Һәм, Нәгыймәттәй, почмакка кереп, кулын кер сабыны белән юып чыкты.— Күптәннән бирле бер киңәш бирәсем килә үзеңә: ташла син кибетне, күч башка эшкә, акчалы урын төс түгел сиңа... Киңәшемнең ихласлыгына ышанмасаң, әтиеңнән сораш, үткәннәрне авыр әкият итеп сөйләп бирер.

— Анысы бер хәл, Нәгыймәттәй, гик бу кәгазьләр янына башка нәрсәләр күмелмәгән идеме икән? Сине, бу акчалар табылгач, бөтен алма бакчасын актарып ташлаган дип сөйлиләр.

— Бу хәтле җаһил да булырсың икән!..— Нәгыймәттәй, ярсуына буылып, шуннан да артыгын әйтә алмады.

* * *

Илленче елларда кибеткә дип бура күтәрделәр: мүкләделәр дә чутладылар, агачларны кызганмадылар, торыгы-торыгы белән генә сузып салдылар. Складын, киштәләрен, ял бүлмәләрен сыйдырырлык

йорт калыкты. Авылда бер кибет бар иде инде барын, тик анда чиратның өзеләсе юк, вак-төяккә генә килә калсаң да, ишектән башыңны тыгарлык түгел. Әгәр инде берәр юграк әйбер кайтса, чират кибет әйләнәсенә урала. Аннан соң, берәү генә булгач, хуҗалык өчен кирәкярагы да, азык-төлеге дә шунда. Ә менә яңа кибеттә азык-төлек кенә сатылачак икән, тимер-томыр — сатучысы белән иске кибеттә калачак, ди. Нигезен казып, почмакларына унышар тиен көмеш ташлаган минуттан яңа кибеткә сатучы эзли тордылар. Яңа морҗасыннан төтен чыкканчы, кеше тапмасалар, Питрәч райпосыннан бер марҗа кайтарасылар икән, дигән хәбәр таралып та өлгерде. Ашыгып-ашыгып сатучылык эшенә ярардай кеше эзләделәр. Соңыннан, авыл картлары җомгага җыелгач, өйлә намазы алдыннан ике мәчеттә дә җитди генә сөйләшү булды. Укыган намазлары, кылган догалары белән уртак фикердә яшәсәләр дә, һәр ике мәчетнең теге яки бу очракта үз фикере бар иде. Менә хәзер дә ике кешене сатучы итеп күрсәттеләр. Тик гелдәгечә, авылның зуррак ягына караган мәхәллә сүзе өстен чыкты: кече классларда арифметика укытып йөргән ярлы Әгъдияне сатучы итеп куярга дигән фикер җиңде.

Үгетләделәр Әгъдияне.

Баштарак ул кистереп кенә: «Шту сез, авызыгыз ни сөйләгәнне колагыгыз ишетәме? Арифметика дәресләре белән сатучылык эшен чагыштырырга ярыймы соң?! Дәрестә бит ул — кара тактага нәрсә язсаң да сыя, ялгышсаң, ошатмасаң, юеш чүпрәк белән сөртеп аласың да — эше бетте хатаның! Ә товар белән эш итү — ике яклы: ялгышсаң, гомерең буе кара тактадан исемең төшмәс!»— дия иде. Тагын үгетләделәр. Үзенә ялынасыларын белеп назландырып торуы түгел, бары тик кыл уртадан кайсы якка егылырга белмичә икеләнүе генә Әгъдиянең. Райпо председателе белән авыл советы рәисе икәүләшеп: «Элеккеге приказчиклардан ким яшәмәссең, һөнәрең нәселдән-нәселгә күчәр»,— дигәч кенә Әгъдиягә шайтан коткысы керде. Тагын бераз ялындырсам, башка берәүне табып куймагайлары, дигәндәй, житәкчеләрне уйларыннан кире түндермәс өчен ризалык белдерде: «Юньлерәк сатучы тапканчы эшләп торсам гына инде...— диде.— Тик сатып алучыларыгыз гына зарланмасын».

Бер атна чамасы эшләгәч, Әгъдия, яңа һөнәренең нәтиҗәсен күрергә теләгәндәй, курка-курка гына үз-үзенә ревизия ясап карады. Кирәге чыга калса дип, эштән китәргә алдан ук гаризасын да язып куйды.

Өстемнән чыкмагае дип, сдачаларны кызганыбрак биргәнгәме, әллә эше шундый төшемле — атна эчендә айлык получкага торырлык мәһәр җыелган. Ышанмады Әгъдия, артып калган акчаларны теге кирәксез гаризага төреп, читкә аерып куйды: аларны тотмаска кирәктер, берәрсе онытып кына калдырмады микән, сорап керсәләр, кайтарып бирергә туры килмәгәе...

Беренче «ревизия»дән соң Әгъдия сатып алучыларның йөзенә күтәрелеп карарга да оялды. Бөтен кеше дә аның яшереп куйган акчасы хакында беләдер төсле тоелды... Шөкер, әкренләп бу хәлгә күнегелде тагы. Йөзгә бәреп әйтү түгел, кыеклап кына да сүз атучы юк. Шулай итеп, яңа һөнәргә гыйшыгы керде аның. Айга дүрт атна, елга — илле, дигәндәй... Кило саен чеметем-чеметем генә коелып калса, аннан кешегә ни зыян? Алай хафаланырлык берни дә юк... Аннан соң Әгъдиянең сылтавы да бар бит:— «Ялынып сорагач кына ризалашкан идем, бер дә эшлисем килми...» Вак-төяк кимчелекләр табып, зарланырга ниятләүчеләрнең шелтә ишеттерергә дип ачылган авызын шушы сүз белән «шап!» иттереп яба да куя ул. Шикәр комы дымлырак тоелса, капчыклар янында чиләкле суның онытылып калганлыгын әйтеп тормады. Беренче сортлы он белән икенче сортлысы буталса да, акланмады, сдачаларның кайбер вак-төяге үлчәү тартмасында бүле-

неп калса да, исе китмәде... Инде аерып куйган акчаларын төрер өчен теге гариза кәгазе генә житми хәзер...

* *
*

Фәнилә кибетендә күкеле сәгать күреп кайтты Нәгыймәттәй. Кеше ник җыелды микән, дип узып барышлый гына кереп чыгасы иткән иде — баксаң яңа товарлар бар икән. Авыл җирендә урамга чыккан саен кесәгә куп итеп акча салып йөрү гадәткә кермәгән инде ул. Казан каласы түгел лә... Анда акчасыз бер адым да атлый алмыйсың. Ә авылда башкача. Кибеткә ниләр кайтканын күршеңә кереп белешәсең дә, сумкаңны тотып йөгерәсең.

Былбылга гыйшыгың төшсә, тал яныннан китмәссең, ди... Күкеле сәгать теләп, урмандагы күкегә дә әллә ничә кат алгысынды инде Нәгыймәттәй. Күптәннән кызыгып йөргән малы шул. Сәгатьләрнең төрлесе бар: кыңгыраулысы, чаңлысы, көйлесе, тавыш-тынсызы... Тик Нәгыймәттәйгә кирәкми алары. Каладан кайткан улына да әйтеп җибәрә инде, зинһар, эзләп тап, ди шул күкеле сәгатьне. Аптыраткач, йөдәткәч, улы әнисенең гозереннән алҗыды ахрысы, бер кайтуында әле бөгәрләнеп тә карамаган йөз сумлыкны тоттырды:

— Әни, андый нәмәрсәләр шәһәрдә күренми, кулдан тотылганын сатып алсаң гына инде, бик иске модель бит ул...

Нәгыймәттәй, йөзлекне бөтен килеш саклап, Фәнилә кибетенә күкеле сәгать кайтканны көтеп йөрде. Инде бүген кибеттә үз күзләре белән дә күргәч, күке тоткандай сөенеп күңеле үсте аның.

Башка авылларда сатучылар ничектер, Фәнилә иң әүвәл акчаны ала, аннан соң гына товар бирә. Бу гадәте аңа егерме ел буе кибеттә эшләгән әнисе Әгъдия мәрхүмәдән мирас булып калган, диләр. Яшьләр, бала-чагалар моны усал мәзәк итеп кенә тыңларлар. Тик Нәгыймәттәй кебекләр, ягъни Әгъдиянең яшьтәшләре, Фәниләдәге һәр холык-гадәтне дә танып торалар. Тамгалары таныш шул. Әгъдия, товар кыйммәткәрәк төшсә, тиз генә күзлегән алыштыра — бүтәнен, якынайтыбрак күрсәтә торганын кия торган иде. Фәниләсе дә шулай... Әгъдия кибетендә идән себерүчесе бертуган абыйсының кызы иде, Фәнилә кибетендә туганнан туган сеңелесе... Кибеткә кергән кеше: «Исәнмесез»,—дисә, Фәнилә, әнисе кебек итеп: «Нәрсә кирәк?»— дип кенә сәлам кайтара. Әгәр әнисе Фәнилә туган көнне үк якты дөнья белән хушлашмаган булса, моңарчы кызын әллә нинди серләргә өйрәтер иде әле.

Шыкырдап торган йөзлекне күкеле сәгатькә алыштыргач, Нәгыймәттәй сдачасын да санарга онытты. Хәер, Фәниләнең шикәрле-чәйле киштәләренә кулдан гына кергән товар диделәр аны, сатулашырлык мал түгел, вакытны кызганмыйча йөрсен дә төгәл саный белә торган күкелесе генә туры килсен. Кадалып китсен сдачасы, затлы малга чүп ябышмый...

Сәгатьне алып кайтып, алты стенаның иң тигезенә элеп куйгач, Нәгыймәттәй сәгать теленең келт-келт йөрешенә сөенә-сөенә күке чыкканны көтте. Ярты сәгать көтте, бер сәгать. Күке бозлы яңгырдан качып яткан кошчыктай тәрәзәдән баш чыгарырга ашыкмады. Нәгыймәттәй һаман көтте... Сәгать ярымнан соң, ниһаять, күке атылып чыкты: муенын сузып, нидер әйтергә теләде, тик тавыш-тыны чыкмады. Йолкынып-йолкынып та Нәгыймәттәйне тавышы белән сөендерә алмагач, күке хурлыгыннан оясына кереп качты һәм шуннан соң бүтән күренмәде.

Абау, бигрәк тә эче телле икән Фәнилә:

— Сәгате йөргәч, ярамаган тагы! Күкесен зиратка килеп тыңларсың,— дип тезеп китте ул.

Чираттагылар арасында Нәгыймәттәйне яклап сүз кушучылар

табылгач кына Фәнилә «күксез» сәгатьне прилавка астына алып куйды.

— Ничә сум сдача биргәнием әле мин сиңа?

— Йөз тәңкәдән кайтарганың менә шушылар,— дип, Нәгыймәттәй кулындагы акчаларны үлчәү тәлинкәсенә салды.

Фәнилә ялт кына санап чыгарды да акча өстәде. Тик Нәгыймәттәй генә аптырап калды.

— Йөз сумлык бөтенемне кая куйдың? Бер генә җыерчыгы да юк иде әле! Улым үз куллары белән биргән иде, тап, хәзер үк тап, юкса таптырам!..

— Мә, җылама! — диде Фәнилә һәм халат астындагы кесәсеннән йөзлекне алып, пычрак идәнгә ташлады.

Чираттагылар «аһ!» иттеләр.

— Инде бөкләп тә өлгергән!— Нәгыймәттәй йөзлекнең пычрагын сөртә-сөртә кибеттән чыгып китте. Алтмыш ел яшәп, алты кешедән дә ишетмәгән сүзләр генә артыннан яңгырап калды...

*
* *

Заманында Әгъдия укыта башлаган балалар инде мәктәпне тәмамлап, кайсы кая — зиһен баетырга таралыштылар. Сатучылар әзерли торганына да керүчеләр бар дип сөйләделәр.

Кешеләр үскәч, авыл да үсте: сөйгән ярлар, парлы булып, башка чыга тордылар — авыл читендәге чирәмлеккә күченеп, нигез корып үрчи дә башладылар... Алты урам алты якка җәелде. Кеше дигәнең тик тормый ул, үсеш-үзгәреше күзгә күренмәсә дә, берзаман үзен сиздерә башлый. Хәзер исә карты-корысы, картаерга өлгермәгәннәрен, яшьлектән олыгаюга таба авышкан барлык авылдашларны бергә җыйнап, чама белән классларга бүлеп, яңалифкә өйрәтә башладылар. Шулай итеп халык сабакка йөрде. Почта бүлегендә эшләүче ханым да: эш күбәйде, дип зарлана ди, хатлар-гәҗитләр бермә-бер артык килә икән. Шулай булмый ни! Каладан үзенә атап кәефенлекләр кайтарткан Һадия әбинең дә ачык тәрәзә каршысында гәҗит укып утырганын күргәннәр. Билем чатный дип, капка төбендәге урындыктан ары китә алмаган Мөхәммәтҗан бабай көн саен почтага килеп, күрше авылның бер карчыгыннан булырга тиешле «Лично в руки!» диелгән хат эзләштерә, ди... Грамотный халык кибеткә кергәч, әүвәлгечә: бу товарың ни хак дип йөдәтеп тормый, ярлыгына күз салып ала да тиешле акчасын алдан ук санап куя. Үлчәү тәлинкәләренең тигезләнгәнен көтеп торып, ашыкмыйча гына үлчәтәләр, тәлинкәләре әле бер, әле икенче якка уйнаклап «атына» башласалар, үрдәк борыны сыман бөгәлҗәле тимереннән тотып туктаталар — кайсы тәлинкәгә ни җитмәгәне күз алдында.

Базар көннәрендә генә күзгә чалынып, атналар буена калада торган көтеп ятучы «ки‥мешәкләр» дә коткы таратып китәләр: имеш, шәһәр кибетләрендә жалу кенәгәсе бар, теләгеңне-зарыңны язып куйсаң, сатучының тәр ибен райпо утырышында тикшерәләр икән... Кеше ул шундый, яхшы киңәшләргә исе китми, ә инде теләсә нинди усаллыкны отып калырга дигәндә, аларга куш... Андый коткыга бирелүчәннәр өчен Әгъдия кибет чоланында «запас» яшереп тотты. Цәйлүн чәе, хәлвә эчле конфетлар, кызыл прәннекләрне башта әзләп, соңыннан әрҗәләп саклады. Аннан соң телчән хатыннарның ирләре дә кибет тирәсендә бутала. Нишлисең бит, урыны шул — Мамадыш чыгарган аракыларның күбесе шушы кибеткә кайта торгандыр. Аракы көн дә бар, тик хезмәт көненә килгән акча гына — айга бер генә бирелә. Андыйларның да хәленә керде Әгъдия: бурычка өләште, «әҗәтләләр кенәгәсенә» исемнәрен, кушаматларын һәм шешә хисабын яза барды.

Әй сөенделәр ирләр... Хатыннарын да тыйдылар — Әгъдия турында гайбәт, авыр сүз әйттермәделәр. Әйтеп өлгерсәләр, күрше-күләннәргә ишетелерлек гауга чыгасын көт тә тор!

Бертуган абыйсының кызы дип тормады Әгъдия: кибет җыештыручы кызны складка керткәнче тышлыгы таушалып, чүпрәк белән ямалган коръән тоттырып ант иттерә иде. Үзенчә тәүбәгә китертә, гадел, ихлас булырга һәм, дөресен генә әйткәндә, урлашмаска куша. Кызның коръән җәзасыннан ни дәрәҗәдә куркуын кем белсен, шулай да кибет эчендә ул-бу хыянәте сизелмәгәч, Әгъдия тыныч иде. Көтмәгәндә генә җиде күк катына ясалма иярчен очырдылар. Алла, коръән, бисмилла, дигән тирән мәгънәле сүзләрнең ышандыру көче кимеде... Әгъдия инде кызның күңелен күрергә тырышты — һәр чәршәмбе, җомга көннәрендә аның сумкасына бушлай гына «күчтәнәчләр» тутырды. Бу күчтәнәчләр Әгъдия өчен пүчтәк кенә иде.

*

* *

Биек караватны төреп алырга җитәрлек олы юрганның бер читен генә ачып, тагын салкын урын-җиргә үрмәләп керде Әгъдия. Мондый чакларда, ни галәмәттер, ирләреннән зарланып йөргән хатыннар күз алдына килә дә тора, аның саен ачуы кабара башлый... Белмиләр ир кадерен. Берәр кичне генә ул назлы хатыннарны менә шушы салкын юрган астына куып кертәсе иде. Ул чагында алар ирләрен ерак урманга утынга да җибәрмәсләр, юлда кунып кала күрмәсеннәр тагы, дип, куркырлар иде. Хәер, беләләр алар ир кадерен, Әгъдия болай, көнләшүеннән генә әллә ниләр уйлап ташлады... Әнә ич, узган елда гына әле, Зөлфирә аны адәм көлкесенә калдыра язды...

Ерак урманнан тикле утын алып кайткач, шоферны сыйламыйча ач килеш өенә кайтарып җибәрмәссең бит инде?! Әгъдия дә Габдрахманны бер чүмеч салкын чишмә суы белән генә сугарып калмас. Кем әйтмешли, дөньясы арба көпчәге сыман бит аның, әйләнә дә бер баса. Утының ягылып беткәч, тагын шушы Габдрахманга ялынырга туры килә. Сыйланды Габдрахман. Машинасын гаражга илтәсе барын да онытып сыйланды.

Ире озак кайтмый торгач (әллә инде тол хатын янында утырганын сизенгәнгә күрә генә вакыты да шулай әкрен үтәме?) Зөлфирә түзми, Әгъдиянең капка төбенә килә. Килсә, куш тәрәзәгә корылган ак пәрдәдә пар күләгә биешә. Өй эчендәге ут яктысы Габдрахман белән Әгъдиянең һәр хәрәкәтен күләгәләп пәрдәгә төшереп тора — нәкъ кинодагы төсле. Күләгәләрнең бер-берсенә капланып тынсыз калган чакларын озак күзәтеп тора алмады Зөлфирә, ярсуын кая куярга белмәгәч, башындагы яулыгы белән йодрыгын урады да куш тәрәзәнең бер өлгесен чәлпәрәмә китерде. Шунда ук пәрдәне дә сөйрәп алды. Бактың исә, Габдрахман өстәл артында үзе генә, ә Әгъдия мич тирәсендә кайнаша. Өй эчендәге ике лампочка күләгәләрне икеләтеп бутап бетергән икән... Шул көннән бирле Әгъдия ике лампочканың берсен сүндереп куя торган булды. Юкса, ялгыз чагында да тәрәзәдә икешәр күләгә күренеп торгандыр, кемнең ирен ияләштерде икән бу, диярләр.

Ялгызлыкка күнегә алмый шул әле ул. Дөресрәге күнегергә теләми. Төн уртасында әйләнеп кайтасы ирен көткән гыйшыклы хатыннар төсле йокы алдыннан матур-матур эчке күлмәкләр дә кия, киң карават кимсенмәсен дигәндәй, икешәр ястык та сала, юрганы да ике кешедән бер балалык кына артып калырлык... Тик өй эчендә ул һаман бер үзе. Йокы килми дә килми. Ишегалдына карый торган ян тәрәзәнең пәрдәсе корылмаган. Өлгеләрне йөзе белән каплап, тулган ай карап тора, ялгыз картаерсың ахры, Әгъдия, ди микән?! Башына кергән

уйларның әле берсен, әле икенчесен уйлап карады. Еламады, көлмәде. «Һич югы кечкенә генә, исерек кенә булса да, бер ир бирсәң иде, ходай! Сугам дисә, тәнемне кызганмам, сүгенәм дисә, телен тыймам, эчеп егылган дисәләр, арба-чанага салып алып кайтырмын, зарланмам...» Ходае да «ишетте», ахрысы, әнә капканы дөбердәтә башладылар. Көзге салкынны шаккаттырып, ялангач кына йөгереп чыкты Әгъдия, башка вакыттагыча котыңны алырдай итеп: «Кем бар анда?!!»— дип тә сорап тормады, капка бигеп ачты: Буйдак Әхмәт иде бу... Йомышын ялт кына әйтеп бирергә өлгермәде, өйгә кереп керергә туры килде. Өйгә кергәч, оялчан малай сыманрак итеп башын түбән иде, бәлки ялангач Әгъдиядән оялып түгел, түшәмгә башы бәрелүдән сакланып кынадыр әле.

Буйдак Әхмәт пилорамда эшли. Пермь өлкәсендә урман егучы булып бәхет эзләп кайткач өйләнергә исәбе бар икән, дигән сүз таралган иде. Авылда тол хатыннар җитәрлек анысы. Тик Әхмәт, сугыш аркасында тол калган хатыннар каршысына басарга көчем җитми, дигән. Үзе дә башыннан ахырынача сугышта катнашкан кеше. Авылда аны бик тә хөрмәт итәләр. Пилорамда эшләгәч, һәркемнең гозере аңа төшә. Рәшәткә, идән-түшәмлек, коймага дип такта ярдырырга күпме тол хатын килде аның янына. Тик яман аты чыкмады, аракы сорап та интектерми, төнге тымызыкта, этләр өрдереп, тәрәзәләр дә шакып йөрми. Әгъдиянең дә урам ягына караган тәрәзәсен шакымады, ә менә ат арбасы сыярдай капкасын дөбердәтте. Шуңа күрә Әгъдия шикләнеп-тартынып калмады, өстәл яныннан урын бирде, ашыкмыйча гына халатын киде. Вакыт соң иде инде. Колхозның электр станциясе төнге ялга тукталган. Әгъдия унлы лампа кабызды. Аннан соң гына Әхмәткә текәлде.

— Әгъдия, алып кайтып куйганың юкмы? Шешәсенә кырык-илле таңкә сорасаң да, риза.

— Берәрсе котыртып керттеме?

— Кеше кубызына биеп йөрер чагыммыни?!

— Төн уртасында аракы эзләмиләр инде.

— Никтер йокы качты, бәлки файдасы тияр...

— Икебездә дә бер үк чир икән...

— Ышанмасаң, Әгъдия, менә күз алдыңда гурласыннан гына чөмерәм.

— Китче, шул хәтле... Кеше төсле генә эч.— Әгъдия тиз генә чоланнан тозлы кыяр алып керде. Идән астыннан сургычлап бөкеләнгән бер шешә аракы чыгарды.— Утын алып кайта калсак, кирәгер дип кенә тота идем, сиңа насыйп хәмер икән.

— Ничә сум бирим?

— Җарар, җарар, бушлай сыйлыйм. Бәлкем сиңа нярел кенә үзем дә күтәрермен. Ничә ел буе сатам зәхмәтне, ә шушыныңчы исен дә иснәгәнем юк.

Әгәр бик нык теләсәң, бер йотымы да исертә икән аның. Ашыкмады Әхмәт, Әгъдиянең «үзем дә» дигән сүзеннән ифрат та канәгать булып, урындыкның аркасына терәлебрәк утырды ул. Әгъдиянең тупырдап торган буй-сыны тирәсендәрәк бөтерелердәй сүзләр кулланып сөйләшәсе килде аның, тик нидән башларга гына белмәде.

— Караватыңның аягы биек синең,— дип әйтеп карады Әхмәт, шушы җөмләгә бик зур һәм чиксез тирән мәгънә салырга теләгәндәй.

Әгъдия кырт кистереп кенә җавап кайтарды.

— Биек дип, егылып төшкәнем юк әле.

Тәк, кисәк алдырдым, ахры, болай килеп җитәлмәссең, әле дә ярый орышып ташламады, дип уйлап куйды Әхмәт. Әгъдия дә аның уйларын ачык күкрәге белән тоеп тора бугай, төксе генә әйтелгән җөмләсен төзәтергә ашыкты.

— Аяк астындагы банкаларны алып ташласаң, чүгә эле ул,— һәм Әгъдия, Әхмәткә сүз бәйләп китәргә ярдәм итәргә теләгәндәй, әйтә куйды:— Ике кеше менеп ятсаң, сытыла торгандыр әле ул банкалар.

Әхмәтнең әкренләп каны сыегая баргандай тоелды, йөрәге дә әллә нинди ләззәтле ялкынга ымсынып тибә башлады, сулыш та җитми сыман, шуңа күрәдер инде еш-еш сулата. Юк, болар барысы да исерә башлаудан гына түгел... Менә хәзер Әгъдияне курчак күтәргәндәй генә, ачуың килмәгәе, урындыгы ние белән, элеп аласы иде дә әйтәсе иде: әйдә, сынап карыйк, банкалар түзәрләр микән?!. Юк шул, тол хатынга ялгыш орынсаң да, «Каравыл!» дигән тавышы чыгар.

— Әллә ник көрсендерә әле. Авыр суларга да куркып торам, лампаң сүнеп китәр дә, караңгыда минем белән генә калып котың очар дип.

— Төне караңгы түгел лә, лампа дигәнең ай яктысын да җиңә алмый.

— Миннән курыкмыйсыңмы соң, Әгъдия?

— Курыкмаска булдым әле. Куркып яши торгач, сазамыкландым инде. Кырык яшькә җитеп, ирләр куенына кырык секунд та сыенганым юк.

— И-их!— дип үзалдына сөенеп куйды Әхмәт, һәм комарлыгын сиздерүдән сагаеп, ялт кына читкә борылды. Ул йөзен Әгъдиядән яшереп кенә әллә ялварып, әллә ышанып, ә бәлки өметләнеп кенә әйтеп салды,— и-их, янында каласы иде...

Әхмәт лампа тынлыгында Әгъдиянең җавабын көтте. Әгъдия дәшми дә дәшми. Ул әнә шулай, ай нурына ләззәтләнеп, янындагы ир кешенең ихтыярына буйсынып, аның теләгенә сүзсез генә җавап та бирде бугай...

Әхмәт дөрләп утырган лампаны кысып та тормыйча бер сулыштан сүндерде. Тулган ай ян тәрәзәдән йөзен алган иде инде...

Икенче көнне кичкырын буйдак Әхмәтнең вак-төякләре төялгән кул арбасы Әгъдия капкасыннан кереп китте.

Әгъдиянең кибете өч көн буе ачылмады.

Әхмәткә яңа кушамат эзләделәр...

*
* *

Монетный дворга әллә кайчан хат язасы иде Әгъдия, тик адресын гына белми. Нүжәли алар үзләре ясаган акчаларны кызык өчен генә кисәләренә тутырып карамыйлар икән? Бигрәк зур бит бу кәгазьләр: бер кило шикәр алучыдан да дәфтәр бите кадәр ун берлек кирә!.. Бу хәтле акчаны кайда гына саклап бетерергә дә ничек кенә санап өлгерергә? Кечерәк кәгазьдән генә бастырсалар ярамаган микәнни?

Әгъдия хәләлен дә, хәрамен дә бергә кушып, бары иллелекләр генә җыя башлады. Атна саен акча салганыңны күреп, халык ни әйтер. Болай да инде тынып торганнары юк, иллелеккә ияреп кергән вак-төяк кебек кенә гайбәт ирешеп тора. Акчаны табуына караганда саклавы кыенрак икән... Подвал казытыр идең, тагын: «Тапканы-табылганы өенә сыймый»,— диярләр. Бәлки Әхмәт белән киңәшсә, җаен табар иде, тик шикләнде Әгъдия. Йортка кергән кешегә ышанып җитмәде ул. Дөрес, Әхмәтнең бу нигездә чын-чынлап төпләнеп калырга бугай исәбе. Сүз җае чыккан саен, яңа йорт салу турында бәхәс куптара. Тик хакмы, хак түгелме, барыбер Әгъдия фикере өскә чыга: буралык агач артыннан йөрүгә караганда әзер йорт сатып алу арзангарак төшә! Әнә, Нәгыймәнең йорты елның елында буш тора. Җәй җитте исә, ул каладагы малае яныннан кайтып, каз-үрдәк кенә үстереп

ала да, беренче карлар күренүгә, тагын китеп бара. Ә нәрсә, үгетләп карарга кирәк үзен?! Егерме биш мең дип колагына тукып торсаң, ризалашыр әле. Малае да куаныр. «Победа» машинасы сатып алыр.

• • •

Кодрәтеннән килгәнчә карышып маташты Нәгыймә: кая ул, авылны сатып китү! Тик Әгъдия — әйткән сүзеннән чигенүчеләрдән түгел: оялчан кызны күзләп йөргән егет сыман әле уңнан, әле сулдан Нәгыймә янына килеп басты, әле алдына төште, әле артыннан ияреп йөрде. Хәлвә кебек татлы, цәйлүн чәедәй шифалы сүзләр сөйләде, җанга рәхәт вәгъдәләр бирде. Нәгыймәнең күңеле иләсләнеп, теле икеләнә башлагач кына иң соңгы коралын эшкә җикте: «Өегезгә күз-колак булырдай кеше юк, кыш көне дә пожарлар чыга, ходай сакласын. Егерме биш меңнең көле генә өелеп калыр. Сатып китсәң, җаның тыныч. Теләгән чакта, үз өем дип, кунакка кайтасың...»

Агымсу кире кайтмый, диләр... Ай-һай... Әгъдия үгетләсә, үргә каршы да агар иде ул... Ризалашты Нәгыймә: шушы җәйне генә торам да ачкычны синә тоттырам, диде.

Егерме биш мең сум ссуда биреп торуларын сорап, колхоз идарәсе исеменә гариза язды Әгъдия. Әхмәтем исән-сау эшләп торганда, биш елдан да калмыйча түләп бетерербез, диде. Йорт сатып алырлык акча җыйган икән, дип сөйләмәсеннәр өчен ничарадан бичара гына уйлап чыгарылган бер чара түгел иде бу. Әйдә, чишмә авызына чиләк элгән саен тик тәкелдәсеннәр шунда...

Колхоз җыелышының өченче көн тәртибенә күчеп, Әгъдиянең гаризасы укылгач, залдагылар, Фәйзи Йосыповның мәзәген тыңлагандай, тыела алмыйча көлешергә тотындылар. Мәгәр нык торды Әгъдия, җыелышны ташлап чыгып качмады. Тавышка куйгач та халык мәзәк өчен генә кул күтәргән иде — карар да кабул итеп куйдылар.

Әгъдия колхоз кассирының өенә барып килде. Аңа банктан бары тик илле сумлыклар гына алып кайтырга кушты.

Икенче көнне өйләдән соң Әгъдия колхоз кассасыннан биш төргәк иллелек тотып чыкты. Аны, яңа кайралган балтасын бил каешына кыстырып, Әхмәте каршы алырга килгән иде.

• • •

Әгъдия килеп кергәндә, Нәгыймә инкубатордан алып кайткан чебиләр белән чүкердәшеп йөри иде. Әгъдиянең карарлыгы калмаган: чәчебашы тузгыган, күз төпләре кара янган. Төн генә кунып чыгыйм әле, ди. Гомер бакый яшәп тә үз башыннан кичергән хәл түгел бу Нәгыймәнең, шулай да ир белән хатын арасындагы гыйбрәтләрне ишетеп-күреп туйган. Кал, диде ул, Әгъдиягә, төн узганчы Әхмәтең сагынсын үзеңне.

Иртән торып бит югач, Әгъдияне күз төпләрендәге кара янган эзләре матураеп калды. Ул көндез, Әхмәт эшкә киткәч дигән булып кына өеннән төенчекләрен ташып торды. Кибеткә дә Нәгыймәдән генә китә, эштән туры монда кайта. Зур гауга куптарып аерылышканнар диярсең, Әхмәтнең эзе дә юк. Шулай да, атна чамасы узгач, килде Әхмәт. Әгъдияне ишегалдына чакырып чыгарды да нәрсә турындадыр бик озак пышылдаштылар... Аннан соң Әгъдиясе акырды һәм Әхмәт, козырегы урталай сынган кепкасын учына кысып, ярсып чыгып китте. Ә Әгъдия хуҗаларча нык басып, өйалды ишекләрен шартлатып ябып керде дә Нәгыймә каршысына килеп басты. Аның зәһәрле күз кара-

шыннан Нәгыймә кулындагы орчык та бөтерелүеннән туктап калды. Бу минутта Нәгыймә үзен фатирга кергән кеше кебек, алай гына да түгел — оясыннан бизгән ана каз кебек хис итте.

— Нәрсә әйтәсеңне беләм инде. Ярар, иртәгә сәвиткә барырбыз, килешербез.

— Бәясен бүген үк, хәзер үк килешеп куйыйк,— диде Әгъдия сабырсызланып.

— Соң җегерме биш мең ссуды алгансың ич, миңа бирергәдер инде, шул җитәр.

Шушы минутта Нәгыймәне үбеп алырга риза иде, тик тыелып кына калды, шатланганын сиздермәскә тырышты. Я тагын: «Чамасыз арзанга бирдем, ахры»,— дип, бер ун меңне өстәп куймасын...

Икенче көнне килешү язып, аңа авыл советы мөһере дә сугылгач, Әгъдия шаһитләрнең күз алдында өстәлгә егерме биш мең тәңкә акча чыгарып салды. Авыл җирендә мондый тамаша бик сирәк була, идарәдә исәп-хисап эшендә эшләүче барлык хатын-кызлар җыелды. Кассир да килде. Төргәк-төргәк таушалган өчлек, бишлек, унлыкларны күргәч, бераз аптырап калды ул. «Үз кулларым белән биргән иллелекләрне кая куйды икән бу?!»

*
* *

Атна уртасында Әгъдияне райпога чакыртып алдылар. Алай итми торганнар иде. Ни ай, ни ел ахыры түгел, отчетлар тапшырыр чак та җитмәгән.

Авылдан килеп җиткәнен көтә-көтә алҗыганнардырмы, әллә үзе шундый чытык йөзле — райпо председателе бик исе китмичә генә каршы алды аны. Кара савытына шешәдән ашыкмыйча гына кара салды, каләмен манып язып та карады. Шуннан соң, бик зур эш эшләгәндәй тынычланып, каләмен куйды. Сүз башларга кыймыйча торуы Әгъдияне бераз сагайтты.

— Укырга диләр...

— Миңамы?

Райпо председателе үзен бер сүздән үк аңларлар дип бик нык ышанган иде ахры,— тиз генә җавап таба алмады.

— Мин үземнекен укып кайттым инде. Ә менә сезгә укырга кушалар.

— Әллә башкалардан ким эшлимме? Ун ел стажым бар...

— Кибетеңдә өлкән сатучы булып калыйм дисәң, укырга туры килер. Ике сменалы эшкә күчәрсез. Ял көннәрендә дә эшләр өчен. Укыйсың килмәсә...

— Я, я?!— диде Әгъдия, председательнең сүзен тартып алырдай булып.

— Яшьләр укый хәзер... Син курыкма, тыныч бул, эш урының саклана, окладың бара...

Нишләмәк кирәк, ризалашырга туры килде.

*
* *

— Бу дөньяда һәр яңалыкны да яхшыга гына юрарга кирәк,— диделәр яңа үлчәүдәшләре, Әгъдиянең моң-зарын тыңлап бетергәч.— Укытабыз дигән булып, безне тагын нәрсәгә генә өйрәтергә җыеналардыр, белмим...

Казан тирәсендәге авыллардан кырыклап сатучы җыелган иде. Курсларга дип алып килүләре дә әнә шул таушалган акчалардан гай-

ре кәгазь күрмәгән ханымнарны гәҗит-фәлән укырга, үлчәү янында үзләрен әдәплерәк тотарга, каешланган телләрен «йомшарту» һәм шуның өше гади, әмма бик тә кирәкле гадәтләргә күнектерү өчен икән. Авыл кибете белән өй эчендәге вакыйгаларны гына белгән сатучыларга мәдәниятка, халыкара хәлгә кагылышлы дәресләр бик кызыклы тоелды. Ниндидер «Эйзенхауэр доктринасы» хакында да аңлатып маташтылар. Кукуруздан мул уңыш җыюның серләренә дә төшендерделәр. Тиздән, бик тиздән ракетага кеше утыртып та очырачаклар, ди. Бер бизмәнгә салып кына әйткәндә, заманалар үзгәргәндә, сату-алу эшләре аеруча үзгәрергә тиеш икән.

Дәресләрдән бигрәк кичләрен кызык. Аларның кырыгын да бер тулай торакка урнаштырдылар. Караңгы төште исә, урамга чыгып йөрүләр юк. Авыл җире түгел, шәһәрдә юньләп йөри белмәгәч, адашып, бәла-казага юлыгасыңны көт тә тор... Кызыл почмакка җыелалар да телевизор дигән әкәмәт кино карыйлар — ни дисәң дә, авылда юк нәрсә бит әле. Агач сандык сыман нәрсәнең илле сумлык хәтле генә тәрәзәсе бар. Шул тәрәзәдәге сурәтләрне зурайтып күрсәтсен өчен алдына ярымшар кебегрәк зур пыяла куелган — линза диләр бугай. Телевизор сүнгәч тә, йокларга ашыкмыйлар. Баштагы мәлне авылдагы йорт эшләреннән алҗып килгән хатыннар, буш вакыт табылды исә, бераз черем итеп алыйк, дип, тынып кала торганнар иде. Җае килгән саен, шулай черем итә торгач, өч-дүрт көннән бөтенләй йокылары качты. Инде хәзер төннәрен дә йоклый алмыйлар, торып утыралар да теләсә нинди юк-бар сөйләшергә керешәләр, тәҗрибә дә уртаклашалар.

— Яшереп-нитеп маташмыйк, монда гел үзебез ишеләр генә. Я, әйтегез, таңкәләрне кем ничегрәк сава?

— Йөз моржалы авылның кайсы төшеннән савасың ди инде?!

— Аның каравы бер үзең хуҗа,— дип кушылды Әгъдия.— Менә безнең авыл зурлыкка зур да, тагын ике кибет салдылар. Мин монда симереп ятам, ә анда, калган ике кибет, кинәнәләр генә... Чагыштырып карасаң, бездә дә бизмән башына йөзәр генә морҗа туры килә ул.

— Причем монда морҗа? Әзрәк үлчәп, күбрәк каера белергә кирәк!

— Юньлерәк товар кайтса, вак-төяк белән чуалган булып, вакытны сузарга, чиратны күбрәк җыярга кирәк. Андый чакта кеше, кулына күпме сдача тоттырганны санап тормый, этешү-төртешү белән мавыга ул.

— Алайга калса, мин махсус табак тотам. Ырмавына пластилин сылыйм да аңа ядрәләр батырам. Табакка 320 грамм дип язылган, ә үлчәп карасаң, ярты кило булыр. Чуртым да сизелми. Үлчәгән саен йөз илле граммны «ык!» та итмисең. Бер көн шулай хөрмә кайтардылар. Ураза вакыты. Халык ишә генә тегене алып... Бер-ике сәгать эчендә, ышанасызмы, юкмы...

— Ул хәтле акчаны кая куеп бетерергә кирәк? Кассага салам дисәң, почтага якынаер хәл юк — күргән бере бурга караган кебек шикәеп текәлә.

— Каракның бүреге яна димәсләрие.

— Анысы бер хәл. Өйдә кәгазь саклау тагын әллә ничек, утыдыркүзедер, дигәндәй...

— Илле сумлык бөтен кәгазьгә әйләндереп җыйсаң, әллә ни күп күренми ул,— дип, тагын сүзгә кушылды Әгъдия. Аның бу минутта тыңлап торучыларны гаҗәпләндерерлек бирәр киңәш бирәсе килә иде.— Җыясың да өч литрлы пыяла банкага тутырып, алмагач төбенә күмеп куясың. Хөкүмәт банкларыннан бер дә ким түгел.

— Авыл кибетенә каян керсен ди ул иллелекләр?

— Колхоз кассиры белән дус булырга кирәк,— дип үзенекен итте Әгъдия.— Мин үзем, берәүнең өен сатып алган атлы кыланып, колхоздан ссуда сорадым. Кассир гел иллелекләрне генә алып кайтып

бирде. Йорт — менә дигән товар ул, акча кирәксә, теләсә кайчан сатып җибәрә алам.

— Да, кызлар, акчалар күбәйде хәзер. Бераз кечерәк итеп чыгарсалар... Исәп-хисап алыйм дисәң, вак акчаларны санап та торган юк. Үлчәү белән генә үлчибез — бакыр-бокырның килосы ун тәңкә! Яңа төрле акчалар кирәк!

— Кечкенә булсалар, яңаларының да бәрәкәте бетәр шул...

* * *

Курслардан белем алып кайтып, иске кибеттә яңача эшкә керешкәч кенә Әгъдия тормышына һич көтмәгән яктан үзгәреш килеп керде. Көтмәгән дип инде, ирдәге кешенең балага узуы гадәти хәл, әлбәттә. Тик кырык бишкә җиткән хатынның: «Йөгемне югалтырга булыш»,— дип, им-том белән көн күрүче Суфия карчык янына килүе чынлап та көтелмәгән хәл иде.

Иренмәделәр, курыкмадылар, төрлечә сөйләделәр: «Имеш, калада кысыр хатыннарның күңелен күрә белүче бер ир бар, Әгъдиянең укырга дигән хәйлә белән китеп баруы шуңа икән... Казанның хатын-кызлар җаны буенча данлыклы врачында дәваланган диләр, юкса ничә ел ир куенында яшәп, бала китерә белмәде... Бала түгел, эченә чир үскәндер әле, хәрам килешмәгән...»

Суфия карчык үзен халык табибы дип саный, шуңа күрә дә кеше сүзенә колак салучан бәндә. Әгъдиянең эченә кул тидергәнче җентекләп сорау ала башлады.

— Әхмәтең алдында хыянәтең бармы?

— Тәүбә диген, Суфия түти.

— Җилдән түгелдер ич?!

— Әхмәттән, билләһи, Әхмәттән! Ике ай курсларда йөреп, ял итеп кайткач, сагынылган күрәсең... Кайтасымны алдан белеп, сакалмыегын кырып ташлаган, хушбуйлар сибенгән... Кавышкан көнебездә дә алай яратмаган идем үзен.

— Ачуланма, Әгъдия, бала гомере белән шаярган кешегә закон бик каты. Аннан, ни, бераз соңгарак та калгансың.

— Җук, җук, Суфия түткәй, шушы яшемдә тапсам, кайчан үстереп өлгерермен мин аны.

— Әхмәтең ни дияр?

— Ии-и! Аның ни диясе билгеле инде: югалтсаң, өйгә кайтып керәсе түгел, ди. Икебезгә ике өй, аерым яшәрбез.

— Игезәк булмагае...

— Ходаем. Телгәләмә бәгыремне. Кулыңнан килмәслек эш түгел. Сора, күпме кирәк?!

— Товар синеке, син сора,— диде Суфия, Әгъдияне өметләндереп.

— Бер иллелек җитәме?

— Кул пычратып торалар, ди.

— Ике?!

— Тәвәккәлләп тотынган хакы да юк.

— Биш?!

— Алты... Өч йөз сум, килештек. Түлке кулым белән кагыласым юк, тәүбәмнән яза алмыйм. Үзеңне генә өйрәтеп җибәрәм...

* * *

Күк гөмбәзендә кояш берүзе.

Тупыл-таллар, җәйге чилләләрдән алҗысалар да, көннәр көзгә таба авышкач, кояшны үзләренә сеңдереп, нурланып торалар. Яфрак-

лар авырайганнар — җил, аларны тибрәндермәкче булып, күпме генә тырышмасын, алар инде тибрәнеп тормыйча, алтын тәңкәләр булып өзелеп кенә төшәләр, төшәләр дә, агач төбеннән ерак китмичә, саргаймый калган чирәмне көз күзеннән яшерәләр.

Бөтен җирдә көз хәстәрлеге. Буш арба, буш кул күрмәссең. Урманкырлардагы бар байлык авылга күчә.

Коргаксыган күпер бүрәнәләрен дер селкетеп, кала юлыннан сельпо машинасы кайтып керде. Кузовны олы брезент белән бәйләп куйсалар да, әллә кайдан беленеп тора — карбыз тәягәннәр. Моны күреп калган һәр кеше куркытылган кырмыскалар төсле, эшен-шөгылен ташлап, өйләренә ашыктылар. Чыпчыклар базары кебек чыркылдашып кайтып килүче мәктәп балалары брезент астыннан бүлтәеп торган баш чаклы түмгәкләрнең ни икәнен тиз генә абайлап, шул арада таралышып та беттеләр: «Карбыз кайтты!» — дигән хәбәр авылның икенче башына барып җитте. Биш-ун минут эчендә карбызлы машинаны халык сырып алды. Шундый көчле чират иде бу — кул тормозына куелган йөкле машина урыныннан этелер төсле.

Әгъдиянең иртәдән бирле кәефе юк. Суфия түткәй киңәшләрен тыңлап, ярамаган эшкә тотынган иде, никтер касык турысыннан чәнчү чыга. Әгъдиянең сөмсере коелып йөрүе дә шуннан гына. Хәлен сорашып, аның күңелен күрергә тырышучыларга да ярты-йорты гына җавап кайтарды... Карбызлы машинаны күргәч кенә хәле җиңеләеп киткәндәй тоелды, хәтта елмаеп та куйды. Күз ачып йомган арада гына халатын алыштырып киде дә машина тартмасына менеп киттте. Төркем өстеннән кулдан-кулга күчереп кенә үлчәүне дә менгерделәр. Булышып торыр дип, Әхмәтне дә чакырасылар иде, тик Әгъдия каршы төште.

Иске көмеш тәңкә кебек шомарып, таушалган берлек төсле төссезләнгән, бәгыре каткан димәгез, Әгъдия дулкынлана да белә. Карбызлар өстендәге брезентны ачып җибәргәч, зур табыш майтарырдай һөҗүмгә әзерләнгән арысландай хис итте ул үзен. Яраткан эш — җан азыгы шул. Кызык инде, менә тиктомалдан гына Әгъдиянең күз алдында заем уены чагылып үтте: илле мең, егерме биш мең, ун мең... дип тезелгән таблицаны алдыңа китереп салалар, ә син шул саннар арасыннан үз меңеңне эзләп, оеп каласың: маңгаеңнан тибеп чыгар өчен тир бөртекләре көтеп тора, күзләрең саннарны буташтыра, йөрәгең күкрәгеңнең әле уң, әле сул почмагына күченгәндәй була. Акча уенының бөтен халәте дә шундый инде...

Әчтерханның соңгы карбызлары шул бу, чамасыз олылар, ачуың килмәгәе, һәркайсын икешәр кеше күтәрмәле. Авырлыклары бер хәл, шәм сылаган төсле, кулдан таялар үзләре. Кысыбрак тотмасаң, шуып төшеп, утыз-кырык сумыңның аяк астында чәлпәрәмә килгәнен көт тә тор! Шуның өстенә тагын бер җайсызлык — халык кулында яңа акчалар да бар, аныс ын яңача санарга кирәк, искесен — искечә, абайламыйчарак калсаң, зыян киләсе, ичмасам, акчаларны җентекләп карыйм дип, озак маташа торган чак түгел...

Май чүлмәгенең генә тышыннан билгеле, диләр. Карбызны белә алмыйлар әле. Әнә, Һәдия әби шушы яшенә җитеп, ак белән караны аерырга өйрәнсә дә, яшел белән яшелне чагыштырып карый алмады. Куана-куана күтәреп, ярты потлы карбызны үлчәп карады. Бизмәне дөрес, герләре җитәрлек. Үлчи торгач, Һәдия әби җан ачуын аклардай күренешкә бот чабып куйды: карбыз ким икән! Алдаган Әгъдия, товарына нәкъ өч кадак авырлык җитми!

Ике кисәкне ике кулына тотып, янә кибет янына ашыкты Һәдия әби. Юлда очраган кеше саен туктап зарланып алды! «Менә, ярты пот дигәнне, үлчәп карасам, өч кадагы җитми!»

Өзлекте Әгъдия, билдән түбән өлешендә эче ут яна, тәненә бер бозлы су, бер кайнар бөркелеп киткән кебек, сыны калтырый. Кулына тоткан карбызлары да әле зураеп, әле кечерәеп күренә башладылар. Өстәвенә изелгән карбызлардан машина тартмасының идәне җебегән. Әгъдия таеп та китте, гөрселдәп ауды да... Яңадан аягына баса алмады, алай да үрмәләп барып, карбыз сатудан җыелган акчалы капчыкның авызын бәйләп өлгерде... Башкасын хәтерләми... Һәдия әбинең зәһәрләнеп кычкырганы, каргый-каргый нәләтләр укып, ходай исемен телгә алуы да ничектер, төштә күргән кебек кенә яңгырап ишетелде аңа.

Машина, күпернең коргаксыган бүрәнәләрен дер селкетеп, район больницасына китеп барды.

Быелгы көз коры килгәч, коелар саекты, чишмәләр дә бик саран ага: суга килүчеләрнең чираты хәйран зур. Район больницасына күрешергә баручылар сөйләделәр, ялганласалар, ояты аларга булсын. Имеш, Әгъдия, бала табарга теләмичә, йөге белән шаярган икән, каурый кулланган, диләр. Ике якның берсе — я баласы, я үзе исән калачак, ди.

*
* *

Әхмәт, сыңар чиләк тотып, чишмәгә килде. Чираттагыларның үзенә таба борылып пышым-пышым серләшүләрен, сүз ара: мескен, уңмады, үз башына икән, ире дә бәхетсез инде, дигән җан әрнеткеч җәрәхәтле сүзләр ишеттерүен күтәрә алмады Әхмәт. Баш врачның күзгә кереп әйтә алмый торган шомлы хәбәре менә монда, чишмә улагына килеп җиткән.

Чиләген чиратта онытып калдырды Әхмәт. Кайтты да, кызулыгы белән бил каешына үткен балтасын кыстырып, урамга чыкты. Пилорам тыкрыгына җитәрәк кенә исенә төште — кич ләбаса, әле эштән кайтканына сәгать тә үтмәгән. Ул ни өчен урамга чыкканын исенә төшерде... Менә бу сукмак олы юлга, ә олы юл район больницасына алып бара. Атсыз арбалар, арбасыз атлар, аңа бәрелүдән куркып, читкә өркеп юл биреп калалар. Ә җәяүлеләр сыный карасалар, Әхмәтне танымаслар да иде. Көннәр буе ботак юнудан маңгай тирләре агып ерганакланган йөзе көн сүрәнлегенә карамый янып пешкән; бәрәңге алмасы кебек бүлтәеп торган бәбәкләре шиңеп, күзләре зуррак ачылган, балта чабарга җайлашып бөгелеп калган гәүдәсе, тураймакчы булып, сизелерлек язылган иде. Салмыш чагы түгел, эчми ул хәзер. Стаканны күрсә дә, саруы кайный башлый, чәйне дә чүмечкә салып эчсә эчәр, мәгәр стаканга салмас. Эчүдән генә түгел, ашаудан, яшәүдән калырлык хәл бит бу. Бөтенесенең дә хатыннары «ир бирмәк — җан бирмәк!» дип өзгәләнеп яши. Әхмәтнекенә генә кибет җене кагылган, сатып алынган йорттан куып та чыгарыр хәл юк. Мичкә генә ягам дип кереп китә дә шунда кунып кала, ирем югалткандыр дип пошынып та карамый. Әгәр эзләп керсәң, сдача сорап кергән агайга җикеренгән кук тавыш куптара. Калада курсларда йөреп кайткач, Әхмәт куенында берәр атна чамасы йоклады бугай. Аптырагач инде Әхмәт ул йортның тәрәзәләрен такта белән кадаклап та карады. Юк, барыбер кибеттән кайтышлый ук керә дә бикләнә шунда. Больницадан кайткач кына үзгәрмәсә...

Район ягына баручылар күренми. Каян килсен ди инде алар? Кич җитте исә, һәр машиналы, үзенә кушылган нәрәтне үтәп, авылга ашыга.

Әхмәт уң кулының чамасыз нык авырайганын тойды. Бактың исә — балтасын калдырмаган икән. Хәер, ир кеше өчен бик зур иптәш ул

үткен балта. Әхмәт аның чәерле сабын ныграк кысты. Көче артты, әйтерсең лә иң ышанычлы дусты белән кулга-кул тотынып бара!

Сатучы Әгъдиягә йортка кергәннән бирле кулак малаена караган кебек үчегәләр Әхмәткә. Узган кышны гына, торфлыкка чыршы кисәргә менгән җирдән артыннан ат белән куа чыкканнар иде. Әхмәт, караңгылыкта югалырга тырышып, урман эченә качты. Өчесе өч яктан чолгап алып туктаттылар да Питрәч урыслары булып кыланалар. Татарчаны ватып, урыс теле ясап сорау алмакчылар.

«Хатының җыйган акчаны кая яшердегез? Әйт, юкса... беттең-киттең!»

«Чабып өзәм» дип үкерде Әхмәт. Әгәр балта сабы юкадән генә юнылса, шул хәтле кысып тотуга өзелеп чыгар иде. Әхмәт җан ачуы белән каршыдагы каен кәүсәсенә шундый итеп кизәнеп сукты — сырлы бәләк юанлыгы агач, очкын очырып, коелып кына төште, төште дә тегеләрнең берсенә таба ава башлады. Анысы чигенгән арада Әхмәт аларның икенчесенә таба атлады. Качтылар. Әхмәт тә куа китте. Үзе йөгерде, үзе күңеленнән: «Куып җитмәсәм генә ярар иде, куып җитмәсәм генә ярар иде»,— дип кабатлады.

Исән-сау котылдылар тегеләр.

Авыру кешене чир җитәкли шул. Әгәр чир дигәне артык зыян китермәсә, авыру кеше медпунктка кереп чыккач та савыга. Ә Әгъдияне район больницасыннан каланыкына озатканнар.

Әхмәт аны төнге йокы сәгате җиткәндә генә эзләп тапты. Шулай да, ни хикмәттер, каршы килеп маташмадылар. Дежур торучы туташ, Әхмәтнең тышкы киемнәре белән балтасын калдыртты да, халат бөркәп, Әгъдия яткан бер кешелек палатага озатып куйды.

— Хәлем яхшыра шикелле.— Әгъдия, үз сүзләренә ышандырырга теләгәндәй, мендәреннән күтәрелде.— Монда һәрбер чирнең бер профессоры бар, ди, озак ятарга ирек бирмәсләр. Ник соң төн уртасында эзләп чыктың, сагындың мәллә?

Әхмәтнең Әгъдияне шундый ягымлы итеп беркайчан да күргәне юк иде әле. Әгәр ул, урын җәеп, һәр төнне каршы алыр алдыннан Әхмәткә карата мизгел хисабына гына шушылай назлы итеп караса икән... ул чагында бәлки бүген иске генә булса да үз куышында кабарып торган ике ястыкның берсендә Әхмәте килеп ятканны көтеп торган чак булыр иде... булыр иде...

— Нәгыймә тагын кайтты. Йортымнан-җиремнән, авылымнан ятим итмәгез, кире үземә сатыгыз, ди.

— Мин терелеп чыккачны гына түзсен, хәл итәрмен.

— Сузарга ярамый бит.

— Нишләгән тагын?

— Сату-алуны шушы ике айда хәл итәргә кирәк. Яңа елдан соң акчалар бөтенләй алышынасы, ди. Гәҗиттә язып чыкканнар: кулдагы зур акчаны яңасына алыштырып бетерергә кушканнар, кассага салсаң да ярый, ди.

Әгъдия, көтелмәгән бу хәбәрдән хәлсезләнеп, мендәренә ауды.

— Әллә санитарка чакырыйммы?— диде Әхмәт, куркуга төшеп.

— Җук, җук! Бер җирем дә авыртмый, алҗыдым гына... ирем, җанашым, алып кайт син мине моннан! Өйдә тизрәк терелермен.

— Врач рөхсәтеннән башка сине кем чыгарсын?!

— Кайтасым килә... Беләсеңме, Әхмәтҗаным, савыгып чыксам, кибет эшенә якын да бармасыем.

— Ие шул, Әгъдия. Кеше әйтә... кеше әйтә, Әгъдиянең җыелган иллелекләре нишләр икән, ди.

Дәшмәде Әгъдия, иреннәрен генә кыймылдатып куйды.

— Карчык, нәрсәдер әйттең ахры?

— Кеше сүзенә ышанма.

— Тагын нәрсәдер әйтәсең бар бугай?
— Кешене тыңлама.
— Юк, карчык, барыбер нәрсәнедер әйтмичә яшереп калдырасың.
— Үләргә җыенмыйм, васыять көтмә.
— Хуш, алайса!..
— Ишетсен колагың, мин кайтканчы Нәгыймәне өйгә кертәсе түгел!
Кимсенде Әхмәт, һай кимсенде...

* * *

Тән сызлауларын онытты Әгъдия. Иртәнге обход вакытында врачка ничек ялваруларын берәр кеше күреп, я ишетеп торса, түзмәс, Әгъдиягә кушылып, үзе дә врачны үгетли башлар иде. Кайтармадылар. Больница законнары ирекле тормышныкына караганда кырысрак шул. Әгәр врачлар һәр авыру кешенең аһ-зарына буйсынып торсалар — ул чагында кешеләр больницага алып килгән хасталарга каршы түгел; ә күбрәк авыру кешенең холкына, чирле таләпләренә каршы көрәшергә туры килер иде.

Кайтармадылар Әгъдияне.

Ул төне буе керфек какмады... Акча алыштыру турындагы хәбәр күптән йөри иде инде. Искеләренең кадере бетүе микәнни? Бәлки алышыну дигән нәрсә, әнә шул, яшерелгән җирдәгеләрен чыгару өчен уйланылгандыр. Бик-бик күп хезмәт иттеләр инде алар — нихәтле алышбирешкә, шатлыкка-кайгыга, югалтуга-табышка сәбәп булдылар. Димәк, кеше кулыннан җыеп алып, бөтенләйгә күздән югалтырга вакыт җиткән үзләрен. Тик ашыгасылары калмаган, бераз гына сабыр итәсе, мин терелеп чыкканны көтәсе иде. Бу теләкне бер мин генә теләмимдер әле, шәт... Әгәр тиз генә аякка баса алмасам, соңга калуым бар. Ул чагында инде Нәгыймә алмагачы төбенә күмелгән акчалар кирәксез кәгазьләргә әверелерләр. Әлегә алар көчлеләр, һай көчлеләр! Һәм минә шушы көчне саклап калыр өчен бу «зинданнан» кичекмичә чыгарга, һичшиксез чыгарга».

Ул урыныннан торып басты да, аякларының ныклыгына ышангач, тәрәзә янына килде. Тышта бөтен дөнья ап-ак кар эчендә. Тупыл-каеннар манылган сары төс уңган. Җәй буе саркып җыелган алтын көз беренче кардан ук күгәреп калган... Урам яңа кыш сафлыгыннан тантана итә.

Каршы яктагы урамда, бер-берсенә сыенып, кибетләр тезелешкәннәр. Никадәр күп алар! Ә сатучылары тагын да күбрәктер! Әгъдия язмышын кабатлаучылар бармы? Күпләрме?

Коридорны үтеп, ванна ягына керүгә, Әгъдия күзенә чалынган нәрсә пальто булды: няняларның берәрсе чишенгәндер инде. Ул кача-поса гына киенде дә тынлыктан курка-курка гына баскычка юнәлде. Баскыч аны урамга алып чыгарга тиеш... Берсенә басты, икенчесенә, өченчесенә... шулчак, инсезрәк басылдымы, үкчәсе идән ташына тиюгә, кинәт Әгъдиянең эчендә нәрсәдер өзелгәндәй итте. Һәм ул гөрселдәп ауды... Ә бераздан, яңа туган кыз бала аваз бирде.

* * *

Искиткеч салкын кыш иде ул.

Аннан соң инде тагын өч ел үтте. Халык әле һаман җылына алмый бугай. Бу алмагачларның нәни үсентедән башлап, карт агач исеме күтәрердәй гомер кичереп тә, андый суыкны күтәргәннәре юк иде...

Туңардай нәрсәләр туңып бетте. Өй җылысын тотар өчен мичләр сүрелмәде. Мал-туар, кош-кортларның күбесе өйгә керде. Авыл суынды. Тәрәзә канатына кызык өчен генә кагылган термометрларның шушы суыкны күрсәтерлек көче җитмәде.

Әгәр дә мәгәр, яңадан үз нигеземә кайтып, кешечә гомер итә башласам, бакчадагы алмаларымны ел саен балаларга өләшермен дип, нәзер әйткән иде Нәгыйматтәй. Алмагачлары, өч тапкыр майның унбишләрен җиткерсәләр дә, чәчәк атмадылар, яшәрмәделәр...

Өйләдән соң малайлар җыелгач, Нәгыйматтәй аларны бакчага алып керде. Шул корыган алмагачлар урынына яңаларын утыртырга кушты.

Өшеп корыган алмагачларны ничек кирәк алай кисеп ташладылар. Төбе-тамырын актарганда гына бик озак азапландылар. Нәгыйматтәй кызганды үзләрен, балакайларның тир түккәнен күзем күрмәсен дип, өйгә кереп китте, чәй әзерли торды.

Малайлар һәр тамырга аерым-аерым ябыштылар. Көрәкләр белән төрткәли торгач, тамыр астында ниндидер пыяла ватылган сыман тоелды. Мәктәп китапханәсендәге маҗаралы китапларны ятлап барган малайларның күзләре майланды. Көрәкләрен атып бәреп, тамыр астындагы балчыкны куллары белән актара башладылар...

Нәгыйматтәй бакчага чыкса: «Аһ» итте. Алмагач төбе авыз ачып калган. Эшне җиренә җиткереп, һәр нәрсәне урынына куеп китә торганнар иде. Ә бүген нәрсә булган соң аларга?! Сау бул, дип тә әйтмәделәр, чәй эчүне дә онытканнар.

Күңелгә шик килә дә тора бит ул. Шикләнебрәк карый торгач, тамыр төбендә кул белән тырналган чокырны да күреп алды Нәгыйматтәй... И ходаем, хәзинә тапканнар ахры болар, дип көнләшеп тә куйды. Һәм ул ясаган чәен дә эчәргә онытып, малайларны эзләп чыгып китте.

## Мансур Вәлиев

# ИКЕНЧЕ КАТТАГЫ БҮЛМӘ

НОВЕЛЛА



Архитектор Самат Гәрәевич Кадыйргулов, мөгаен, бик күп яктан, сезнең белән минем кебек үк, гадәти бер кеше булгандыр. Әмма соңгы елларда холкында торган саен ачыграк сизелә барган сәер сыйфат аны бүтәннәрдән нык кына аерып куя башлады. Танышлары, дус-ишләре әйтмешли: әлеге сыйфат безнең заман кешесенә һич тә хас түгел, ә Самат Гәрәевич кебек хөрмәтле интеллигентка инде бөтенләй дә бармый, «просто килешми» иде.

Бу сүзләрнең мәгънәсен, дусларының тел төбен ачыклый төшсәк — Самат Гәрәевич соңгы вакытларда үз-үзе белән генә калуны яратарак бирә, ялгызлыкны дөньяның бик күп рәхәтлекләреннән өстенрәк куя. Чамасыз ыгы-зыгылы эш көннәре һәм тулысынча диярлек гаилә өчен үткән кичләре, ял вакытлары — ялгызлыкны аңа күптән күрелмәгән, бик тансык, бик кадерле итеп бетергәннәр иде инде. Ул, мөмкинлек туып, әз генә җай чыккан саен, дус-ишләреннән һәм иптәшләреннән аерылып, бик күбәеп киткән мәҗлесләрдән читләшеп, үзе генә калырга тырыша. Башкаларга сәер булып тоелган әнә шул бәхетне Самат Гәрәевич торган саен көчлерәк тели бара.

Үзе нык кына ышанган бер фикер дә йөри Самат Гәрәевичның күңел төбендә. Яшәү дигән хикмәтнең иң мәгънәле өлеше ялгызың калгач башлана, дип уйлый Самат Гәрәевич. Әнә шул вакытта — төрле ясалмалыклардан, бүтәннәр көенә җайлашудан, кыланулардан арынгач — кешенең иң чын гомер итүе башлана. Шул чагында кеше үзенең тирәнәйгән күңел халәтен, рухының иң ихлас, риясыз рәвешен кичерә.

Иң кадерле хисләр, өр-яңа һәм олы фикерләр аңа әнә шунда килә. Кешенең беркайчан һәм беркем тарафыннан кабатланмаячак шәхес булуы да әнә шуннан башлана...

Соңгы елларда үзе канәгать булырлык бер генә яңа проект та тәмамлап тапшыра алмавы, күрәсең, аның ялгызлык хакындагы бу уйларын көчәйтеп җибәргәннәрдер. Инде менә ничә ел бит Самат Гәрәевич гел агымдагы вак эшләр белән мәшгуль, гел шулар шаукымында яши. Аның үз-үзеннән: «Әй синеке генә сапалырдай, син чын-чынлап горурлана алырдай эш кая соң?» — дип борчылып сораган чаклары торган саен ешрак кабатлана...

Үзен бирегә, Н. шәһәренә командировкага җибәрүләрен дә ул бик теләп кабул итте. Моннан унбиш еллар элек Самат Гәрәевич күпмедер гомер кичергән бу район шәһәрчеге хәзер заманча матур итеп яңадан

төзелә башлаган икән. Аның бер өлешен — якындагы елга ярына барып терәләчәк иркен массивны исә — бераз үзләренчәрәк, бүтән шәһәрләрне кабатламыйчарак салдырмакчы булалар. Әнә шуның генераль планын төзетү өчен район җитәкчеләре Казаннан үзләренә танышрак, бу якны белгәнрәк архитекторны, ягъни Самат Гәрәевичны чакырганнар да инде...

Менә хәзер безнең Самат Гәрәевич Кадыйргуловыбыз Н. шәһәре үзәгендәге ике катлы кунакханәдә, район җире өчен иң яхшы саналган бүлмәдә яшәп ята.

Көндезләре эш белән үтә, ул йортлар салыначак урынны — ландшафтны өйрәнә, нечкәләп күзәтә, һәрбер кечкенә үзенчәлегенә хәтле хәтеренә сеңдерергә тырыша. Кайчагында куен дәфтәренә җиңелчә генә сызгалап та куя. Алары бирсдә урнашачак торак йортларның, төрле корылмаларның беренче чалымнары була инде. Тора-тора, кульман артында шактый көннәр тир агызып утырганнан соң, исәпсез күп сызу-бозуларның, тегеләй дә, болай да уйлап карауларның бер нәтиҗәсе булып, әлегә җиңелчә ясалган рәсемнәр матур гына йортларга әйләнеп китәләр. Аларның иң уңышлы дигәннәре — табигать үзе озак еллар дәвамында һәм стихияле рәвештә төзегән сыман — урынга бик ятышып та, аңа өстәмә ямь дә биреп торачаклар.

Самат Гәрәевичның яшьлегеннән бирле килгән зур хыялы да — табигатьнең үзенеке ише биналар, сарайлар салу иде. Укыганда да аларны шундый матур максат өчен әзерләделәр. Әмма, институтны бетереп, эшкә тотынгач, күбесен вак заказлар, бәләкәй эшләр мәшәкате басып китте. Заказчы оешмаларның үтенече буенча алар инде күптәннән үткән чорныкы дип саналган проектларга өлешчә үзгәртүләр ясадылар, берөзлексез шулар ихтыяҗын үтәделәр. Институттан алып килгән зур планнар, хыяллар әкренләп артка, ерак киләчәккә күчә торды. Вакыт шулай үтте.

Билгеле, Самат Гәрәевич сыман танылган кешенең үз проектлары да булмый калмый. Иң башта, институт бетереп, берничә ел эшләүгә үк, өлкән архитектор Хәкимҗан абый зур спорт корылмасы проектлауга чакырды аны. Алар икесе дә бик дәртләнеп, яратып эшләгәннәр иде. Хәзер ул бина, аулаграк урында булса да, шәһәрне бизәп, урамга үзенчә ямь биреп тора. Аннары Самат Гәрәевичка мөстәкыйль проект та бирделәр. Инде хәзер, саный китсәң, андыйлар да дистәгә якын җыела бугай... Әмма күбесе, бигрәк тә соңгы еллардагылары, ашыгычрак, элек иләнгәнчәрәк — тирән уйланмыйча һәм матур хыяллар-сыз гына башкарыла башлады шул. Эш арасында гына дигәндәй, бик кысан вакыт эчендә генә... Ә ашыгу сәнгатьтә сизелмичә каламы соң ул? Соңгы эшләргә югары сәнгатьлелек дигән бөек бер нәрсә житмәгәне һаман ныграк, ачыграк күренә бара иде. Самат Гәрәевичның шушы күңелсез хакыйкатьне аңлавы да тирәнәя, шул ук вакытта аны төзәтү өчен булган мөмкинлеге дә, гомер үтү белән, һаман азая, һаман кысыла сыман.

Бирегә килгәч тә ул күп эшләде. Хәтта Казандагыга караганда да нәтиҗәлерәк, күзгә күренерлегрәк эшләде. Чөнки райбашкарма бинасыннан бирелгән аерым бүлмәдә — ул көн буе берүзе. Җитәкчеләр аңа эш өчен бик әйбәт шарт тудырганнар — Самат Гәрәевич үтә дә канәгать иде.

Ә кичләрен ул үзе күптән теләгәнчә — ялгыз гына. Рәхәтләнеп укырга дип, моңарчы хыялланган китаплары белән генә. Ул аларны өендә дә, эшендә дә кешегә күрсәтергә кыенсына, уңайсызлана. Чөнки китапларның күбесе, танышлары уйлаганча, архитектура яки төзелеш буенча түгел, ә матур әдәбият әсәрләре иде. Матур әдәбиятның да иңдие генә әле — иң нечкәсе дипкме: русчадан Иван Бунин, Сергей Никитин хикәяләре дә татарчадан Әмирхан Еникиның калын гына бер

китабы. Тагын икесе, югарараклары — шигырьләр... Килгәндә, аның зур портфелендә әллә ни күп урын алмадылар алар, ә,менә хәзер бүлмәне нииндидер, җан өчен шифалы һава белән тутырып, кадерле, олы әйбер кебек торалар. Самат Гәрәевич, әлеге югары сәнгать әсәрләрен укыганда, дөнья чуалчыклыгында югалта башлаган үзен табып алгандай була. Яшьрәк чакның матур, канатлы яшәеше кире кайткан сыман тоела аның күңеленә. Җирдәге кабатланмас үз урыныңны да ныграк тоясың, сизәсең шикелле андый чакларда...

Әнә шул кичләрен ул бернәрсәгә дә, беркемгә дә алыштырмаячак иде. Алар, ул кадерле минутлар, үзенә бирелгән бердәнбер гомер дәрәҗәсендә, шуның кебек үк газиз иде аңа. Алар гына Самат Гәрәевичне үзе теләгән Самат итәләр, аңа ул теләгән яшәүне — гомеренең ул көткән чынын, ныклысын бирәләр иде.

Әлбәттә, монда аның эше дә Казандагы сыман кичке бишкә хәтле калмый. Өч-дүрт тирәләрендә Самат Гәрәевич инде үзенең икенче каттагы бүлмәсендә була. Юынып, сөртенеп — черем итеп алырга әзерләнеп йөри. Шулай, бераз йоклап алгач, ул бер тәүлектән ике көн ясаган кебек хис итә. Торгач үзенең башы сафлыкка, күңеле көрлеккә сөенеп йөри. Үзендә көч, дәрт сизә.

Ә инде биредәге шимбә, якшәмбе көннәре аның өчен чын бәйрәм кебек тоела. Ул бит ике көн буена үз иркендә! Ашыкмый гына елга буенда йөрисеңме, яисә аның теге ягындагы, күңелне ымсындырып торган урманына әкрен генә чыгып керәсеңме, әллә шәһәрнең кырыйдагы аулак, тыныч урамнарында ялгызың гына сәяхәт кыласыңмы — һәммәсе үз кулыңда, үз иркеңдә!.. Ике көн! Никадәр вакыт, нихәтле мөмкинлек бит бу!

Бүген шимбә көн иде.

Иртәнге якта Самат Гәрәевич бик озак, бик тәмләп-ләззәтләнеп йөреп кайтты. Күңеле булганчы, аяклары тәмам арыганчы, онытылып атлады ул урманлы яр буеның бормалы, матур сукмакларыннан. Көньякта ял иткәндә дә һәм бүтән җирләрдә булганда да күзенә ташланмаган гаять үзенчәлекле, күңеленә искиткеч якын урыннар очратты. Ул урыннарның берсе дә синс тиз генә җибәрми, күпме булсаң да, әле һаман нәрсәнедер әйтеп, биреп бетермәгән сыман, үз янында тота, кешенең эченә әнә шул хасиятне бер дә кабаланмый гына, иплән кенә — әйтерсең, агач яфраклары лепердәгән көй белән генә — сала, бөтен барлыгыңа әкрен-әкрен тутыра иде. Самат Гәрәевичка бары тик мондый мөмкинлекне моңарчы таба алмаганга үкенергә генә һәм үз эченә табигать җанының, табигать рухының нинди рәхәтлек биреп агып керүен тын килеш тыңлап торырга гына кала иде...

Ул сихри сәяхәттән кайткач, Самат Гәрәевич ял итеп тә алды. Ә хәзер аның нияте йомшак кәнәфигә чуму, онытылып әдәбият дөньясына китү иде. Матур башланган көнен тагын да әйбәтрәк итәсе, күңел сахрасында тәмам хушланасы, ләззәтләнәсе килә иде Самат Гәрәевичның. Ул үзенең күптән түгел очраклы рәвештә ачкан язучысы Сергей Никитинның китабын алып утырды. Кечерәк кенә күләмле хикәяләр иде анда. Әмма ул кечкенә хикәяләр шуның хәтле тирән һәм шундый да хисле, тәэсирле иделәр — әйтерсең, андагы һәрбер хәрефкә кешелек миллион еллар дәвамында кичергән бөтен нәрсә сыйган да, хәзер менә шулар, хәрәкәткә килеп, синең эчке дөньяңа күчәләр. Юк, күрәсең, әлеге байлык ул хәрефләргә сеңмәгәндер. Ул язган кешенең күңелендә шулай бихисап күп, мул булгандыр. Шуңа күрә аның һәр язган әсәре җан хәрәкәтен, йөрәк тибешен, рух дулкынлануын чагылдырадыр, шуларны белгертәдер. Бер кеше эчендәге олы һәм сихри дөнья шушы хикәяләр аша әкрен генә икенче кеше күңеленә күчәдер... Самат Гәрәевич өчен бу күренеш гаҗәеп ләззәтле иде. Һәм, иң мөһиме, бу аның бөтен барлыгына бик тансык иде. Ул, нык сусаган кеше кинәт кенә

суга тап булгандай, бер туктамыйча эчәргә, озаклап һәм тын да алмыйча, шуның рәхәтен тоярга әзер иде.

Кунакханәдә кичке ыгы-зыгы купканчы була торган үзенчә бер ипле, сабыр тынлык урнашкан. Ишекләр ачылып-ябылу да юк, беркем йөрми дә. Тып-тыныч. Әйтерсең, төнге илаһи тынлык.

Бу исә Самат Гәрәевич бүлмәсендәге халәтне тагын да көчәйтә. Ул вакыт-вакыт күцеле белән генә түгел, ә менә шушы икенче каттагы бөтен бүлмәсе белән үк, җир тормышыннан аерылып, каядыр бик ерак-ка киткән, бүтәннәр аңлый да, таба да алмаслык ниндидер серлелеккә күчкән кебек тоя үзен. Әйтерсең, ул хәзер шунда яшәп ята...

Самат Гәрәевичның бу рәхәт халәтне кичерә башлавына күп үтмәгән иде әле. Мөгаен, ярты сәгатьтән дә артмагандыр. Астан, беренче каттан ишетелгән көчле һәм шактый ямьсез тавыш аның игътибарын үзенә тартты. Ниндидер хатын-кыз (җыештыручы булса кирәк — бу вакытта ул үз эченнән нәрсәдер сөйләнгәли-сөйләнгәли коридор идәннәрен юып, сөрткәләп йөри торган иде) усал, кискен итеп кемгәдер кычкыра иде. Аның сүзләре Самат Гәрәевичка аермачык ишетелде:

— Кая! Кая барасың, дим! Төш тизрәк — менә шуның белән битеңә чәпегәнче!

Аңа каршы бер ир-ат тавышы басынкы гына, юаш кына итеп нәрсәдер әйтте... Бусын Самат Гәрәевич ишетә алмады. Аның каравы тегесенең, җыештыручының авазы икеләтә көчәеп, тагын да властьлырак булып, бөтен кунакханәне яңгыратты:

— Кертмим булгач, кертмим! Юк ул! Йоклый! Ял итә! Аптыратмаска куштылар аны. Ә синнән туйган инде! Көн дә исерек, әшәке!

Самат Гәрәевич: «Кемне шулай оятсыз итеп, шул хәтле түбәнсетеп сүгә бу хатын?» — дип, аптырап китте. Аңа, үзе яшәгән югары дөньядан әле аерылып җитә алмаган кешегә, түбәннән килгән авазлар үтә тупас һәм бик ачу китерә торган булып тоелды. «Нинди явыз хатын, ә! Ничек инде тып-тыныч кына йөргән җирдән шулай каты кычкыра алырга мөмкин?! Беркемнән оялмый, кыенсынмый, ничек шулай явыз итеп кычкырырга!.. Моның өчен, мөгаен, эчендә бик озак еллар буена җыелган чиксез күп явызлык булу кирәктер... Нормаль кеше болай гына, шушы кыска гына арада бу хәтле авыр сүзләр табып, әйтеп өлгерә алмас иде...»

Ә бераздан, инде үзенең югары дөньясыннан аерылып җиргәрәк якынайгач һәм тагын берникадәр вакыттан соң тәмам үз бүлмәсенә кайтып ук утыргач, аның башына: «Ә кемгә шулай җикеренде икән ул?— дигән уй килде.— Шул хәтле тартынмыйча кемне сүкте икән ул хатын?»

Тукта, «ял итә» диде бит! Әллә сүз минем хактамы? Безнең катта бүтән кеше бик калмый кебек иде бу вакытта... Ул үзе генә юынып йөри иде йоклап алгач... Ә кем килергә мөмкин соң әле? Кем?..

«Неужели — ул?..— Самат Гәрәевич ниндидер йокыдан уяна бара кебек иде.— Чынлап та... ул микән әллә...»

Әйе, килүченең ул булуы бик мөмкин иде.

Самат Гәрәевич уйлаган саен моңа ныграк ышана барды. «Шулай бит, бөтен рәвеше дә аңа туры килә бит...»

Самат Гәрәевичның «ул» дигәне — аның Н. шәһәрендә яшәгән чагындагы иң якын дусты Хәмәт иде.

Юк, дусты гына түгел иде аның Хәмәт! «Дус» дигән бер кыска гына сүз аларның бер-берсе өчен кем булганлыгын әйтеп, белдереп бетерә алмы соң?!

Аларның исемнәре генә — Самат белән Хәмәт — охшаш түгел, ә холык-фигыльләре дә бер төрлерәк, берчәрәк иде. Шуңа күрәдерме, ничектер, очрашу белән бер-берсен үз итеп, якын итеп алдылар. Ул чагында алар Н. шәһәренең әллә ни күзгә ташланып тормаган гади

генә оешмасында эшләп йөрүче басынкы гына егетләр иделәр. Ә юк... Шулай да басынкылык күбрәк Саматка хас булгандыр. Хәмәт исә Самат характерының шәһәрчәрәк варианты иде бугай. Анда шәһәрчәлек, иркенлек, кыюлык күбрәк иде. Чөнки ул тумышы белән үк шушы Н. шәһәреннән — шунда үскән, шунда укыган. Бу тормыш аңа бик тә үз, таныш иде.

Иң мөһиме—Хәмәт бик талантлы егет иде. Ул, барысын да шаккатырып, баянда уйный. Җаны теләгәндә баянына кушылып җырлап җибәрергә матур моңлы тавыш та биргән аңа табигать. Төрле уңай белән стена газетасы өчен шаян шигырьләр дә яздырып алалар Хәмәттән... Кыскасы, күпкырлы талант, бәхетле егет иде Хәмәт.

Эштә бүтәннәр бик мөһим дип санаган нәрсәләргә исе дә китми иде аның. Хәмәт үзенең бәйсезлеге, ниндидер бер эчке кыюлыгы белән гел диярлек аерылып торды. Башкалар директорга ошау өчен, аның кәефен күрү өчен кулыннан килгәннең бөтенесен эшләргә әзер торса һәм шуны ныклы кагыйдә итеп санаса, һич тайпылмый шуны үтәргә тырышса — Хәмәт, яшь кенә булуына да карамастан, ничектер үзен аның белән тигез тота төсле иде. Һәрхәлдә бүтәннәрдә бик өстә яткан буйсыну, баш ию дигән нәрсәләр Хәмәт холкына якын да килми иде. Ул яшьтән, кечкенәдән үк иреккә күнеккән. Аңа табигать тарафыннан бирелгән әлеге сәләтләр дә әнә шул бәйсезлекне, ирек сөюне көчәйтәләр төсле иде. Ул еш кына хыялда гына була алган ниндидер алдагы чор тормышыннан безнең көннәргә ялгышып килеп төшкән бер кош баласы кебек тәэсир калдыра иде.

Ләкин аның Саматны борчыган бер йомшаграк ягы да бар иде. Ул үз язмышына ничектер үтә битараф, китапча әйткәндә, җавапсыз карый. Самат моны бигрәк тә үзе белән чагыштырып уйлаганда нык сизә. Саматта — авыл егетендә — тырышлык, даимилек, эш-планнарда тотрыклылык көчле. Ул үзенең киләчәге, тормышының алдагысы хакында артык тирәнгә кереп уйлый алмаса да, күңеле белән сизенеп диикме, ниндидер интуитив тою көче аркасындамы — дөресрәк юлны табып ала да, шул юлдан тайпылмыйча, бүтән нәрсә белән бик мавыкмыйча, акрын гына бара бирә. Ә Хәмәт андый бер генә юлны җаны-тәне белән азсына, тарсына төсле иде... Акылы белән төшенмәстән, үзеннән-үзе шулай килеп чыга кебек иде бу аның. Ул гомере буена шулай киң һәм иркен яшәү алып барачагына нык ышанган кеше кебек иде...

Әмма тормыш күп чакта без көтмәгәнчәрәк, үзенчәрәк китереп чыгара шул. Самат та, Н. шәһәреннән Казанга күчеп киткәч, Хәмәт турында пошаманга төшерердәй сүзләр ишетә башлады.

Башта аны хатынынннан аерылган диделәр. Хәзер бигрәк тә еш сала икән дип сөйләделәр. Аннары ничектер: «Хәмәт хатыны янына кайткан икән» дигән сүз дә килеп эләккән иде Саматның колагына. Тик бераздан ул хәбәр нәкъ киресе булып ишетелде. Хәмәтнең аерым фатир алып, үзе генә торуы беленде.

Ләкин, ничек кенә йөрсә дә, Хәмәт эшен ташламый, ниндидер ныклы бер бирелгәнлек белән һаман шунда эшли һәм, күпләр әйтүенчә, аны теләсә кемнән шәбрәк итеп башкара икән. Әмма Хәмәтнең торабара бөтен Н. шәһәренә таралып өлгергән даны инде бу яхшы якны да күмеп килә икән. Кешеләр Хәмәтнең макталырга лаеклы әнә шул әйбәт сыйфатын да начар итеп: «Һаман шунда ята инде...» — дип, ошатмыйча сөйлиләр иде...

Самат үзенең иң якын дусты турындагы бу сүзләрне Казанга килгән танышлары аркылы ишеткәләп торды. Хәер, күчеп киткән беренче елларны, Самат Н. шәһәренә кайткалап йөргәндә, алар шактый еш очраштылар. Гадәттә, берәр аулаграк ашханәгә яисә биредәге бердәнбер ресторанга кереп, озак итеп, тәмләп сөйләшеп утыралар иде алар. Менә шул сөйләшү Саматка бик ошый иде. Хәмәт аның алдында буасын

ерып киткән ташкын төсле ургыла-ургыла — бер дә туктамас һәм басылмас агым сыман иде. Менә шушы сөйләшеп утыруларга бик сусаган була иде ул. Сүз арасында гына әллә нинди зур эшләр хакында да әйтеп ала. Шулай бер мәртәбә ул Саматны зур картина ясавын әйтеп шаккатырды. Билгеле, ул аны очраклы бер заказ буенча, вокзал бинасына кую өчен эшләгән. Ләкин хикмәт андамыни! Самат дустының мондый сәләтен бөтенләй белми дә иде бит әле! Иң кызыгы тагы шул — картинаны тимер юлчылар бик ошатканнар. Мәскәүдән килгән җитәкчеләре хәтта Хәмәтнең үзен дә чакырып сөйләшкән. Самат бу сүзләрне авызын ачып тыңлады. Ә Хәмәт исә, кечкенә һәм артык әһәмияткә ия булмаган бер фактны искә төшергәндәй, йөтертеп кенә узды да эшендәге хәлләргә кереп чумды. Бүтән чагында болай тыныч кына, ипле, сабыр гына йөргән Хәмәтне, әзрәк салса, эше борчый, тынгысызлый башлый иде. Аның әллә нинди зур мәсьәләләрне үзенчә чишү вариантлары була, һәм алар бик кызыклы да, дөрес тә сыман тоелалар иде.

Хәмәтнең табигый талантына, күңел көченә, җан байлыгына чынчыннан исе китә иде аның! Бер яшүсмер кебек ихлас соклана, шакката иде Самат! Юк, болар исереклек йомшавы гына түгел иде. Икенче көнне, тәмам айнык хәлдә, салкын акыл белән уйлап карагач та нәкъ шул фикердә кала иде Самат.

Һәм шундый сөйләшүләрдән соң: «Зур максатлы эшкә тартылмаган, шуның ихтыярына җигелмәгән нихәтле талант буш йөри бит бездә!— дип уйлый иде ул, эченнән бик нык сызланып.— Тормыш өчен үтә дә кирәкле нихәтле рухи байлык тиешенчә файдаланылмый! Пычранып йөри-йөри, әкренләп күпме талант югала... Эх, аларны күтәрергә, һәммәсен үз урынына куярга иде! Балкытырга иде аларның барысын да!»

Ләкин, мондый сызланулы һәм сокланулы уйлардан соң да тормышлары — Саматның үзенеке, Хәмәтнең үзенеке булып, аерым-аерым акты. Берәр сүз ишеткән чакларда яисә нинди дә булса очрак уңаеннан искә төшкәндә генә уйлый башлады Самат элеккеге дусты турында. Бик каршылыклы һәм үзеннән тиз генә ычкындырмый торган искә төшерүләр иде алар.

Ә соңга таба, бер-ике ел эчендә, Хәмәт хакындагы хәбәрләрнең күңелсезләре күбәйде, бик нык күбәйде. Самат вакыт-вакыт хәтта менә-менә җан өшеткеч сүз ишетермен дип куркып та куя иде. Хәмәтнекенә охшаш кайбер язмышлар турысында аның кайдадыр — шул ук сәнгать кешеләре хакында укыгандамы икән — ишеткәне бар иде...

Озак кына кайтмый торганнан соң, бу килүендә инде менә икенче атнасын яши безнең кадерле Кадыйргуловыбыз Н. шәһәрендә.

Ирешкән бәхете — ялгызлыгы белән, күптән тимәгән шул рәхәтлек белән хозурланып үткәрде Самат Гәрәевич бу вакытны. Хәмәт янына барып карау теләге аның башына да килмәде. Чөнки аның үзенең нәрсәләндер котылу, нигәдер ирешү сөенече бик зур иде. Самат Гәрәевичны тулысы белән әнә шул бәхет йоткан иде!

Мондагылар, аны күреп белүчеләр өчен дә Самат Гәрәевич — Казаннан килгән зур архитектор, данлы, хөрмәтле кеше иде. Шуңа күрә ул кешенең биредәге бер эчкече белән дус булуы — һич тә башка сыярлык нәрсә түгел! Әгәр дә инде андый очрашу — ике дусның элеккечә ихлас сөйләшеп утыруы килеп чыга калса,— бу очракта әлеге факт Н. шәһәре кешеләре тарафыннан һичшиксез үзләрен мыскыл итү, аларның фикерләрен санга сукмау һәм, әле алай гына да түгел, шәһәрнең аларча күзалланган абруен аяк астына салып таптау дип кабул ителәчәк иде...

Самат Гәрәевич боларны белепме, әллә барысын белеп тә бетермичәме — Н. шәһәре кешеләренең ихтыярына каршы килә алмады.

...Ул үз уйлары белән мавыккан арада аста җыештыручы хатын тагын нәрсәләрдер кычкырды, нидер боерды. Монда үзен тулысынча хуҗа итеп сизә иде ул. Килүче кеше, әйтерсең, бер зур байның өенә мәрхәмәт сорап, рәхим-шәфкать өмет итеп аяк атлаган да шуңа күрә, әйтерсең, хуҗабикә үзен бик эре тота, бик усал сөйләшә...

Бераздан ул тавышлар басыла төште. Тышкы ишек шап итеп бер ябылды да, кунакханә яңадан үзенең элеккеге тормышы белән яши башлады...

Яңадан барысы да үз урынына кайтты. Тынлык та яңадан кайтты кебек кунакханәгә һәм аның икенче каттагы иң яхшы, иң тыныч бүлмәсенә.

Тик Самат Гәрәевичның күңеленә генә тиз кайта алмады ул тынычлык. Аңа берсеннән-берсе тынгысызрак сораулар ябырылды. Ул шулар арасында күмелеп калды. «...Нишләп аның каршысына йөгереп төшмәдем соң әле мин?.. Нишләп әле минем дустымны ниндидер бер тупас җыештыручы хатын куып җибәрде? Ни хакы бар аның Хәмәтне куарга?!. Ә син... Ә син үзең ни уйлап утырдың? Барысын да тыңлап, ишетеп тордың бит!.. Икенче каттагы бүлмәңдә... «Илаһи» яшәү ләззәтен татудан аерыла алмыйча... Нәрсә тотты сине, йөгереп төшеп, аны үз бүлмәңә алып керүдән? Ә? Нәрсә каршы төште, ни туктатты сине?»

Әйе, көтмәгәндә, уйламаганда нәрсәдер кисәк кенә үзгәргән иде...

Ул икенче катның иң яхшы бүлмәсендәге үзе өчен бик рәхәт һәм уңайлы дөньядан гына аерылмаган, ә тагын ниндидер — тел белән әйтеп булмастай бер биеклектән дә төшкән, түбәнәйгән сыман иде...

Ә нинди биеклектән?

Анысына Самат Гәрәевичның башы җитмәде...

## Булат Сөләйман

# АБУ БАБА

хикәя



Себердә күпчелек авыллар елга һәм күл буйларыннан үзләренә җайлы урын сайлап алганнар да, шунда мәңгегә төпләнеп, тамырланып калганнар.

Елга буйларыннан әз генә эчкәрәк аяк бастыңмы, иксез-чиксез тайга да сазлык хакимлегенә барып керәсең. Көннәр, атналар барырга мөмкин, ләкин тип-тигез сазлык эчендә кеше йөзендәге сипкелләр шикелле бер-берсенә охшаш игезәк утраулардан башка берни очратмассың. Бары бөтен гомерен тайгада үткәргән кеше генә, игезәк балаларын аера алган ана шикелле, ул утрауларның берберсенә охшамаганлыгын таный алачак. Менә шуңа күрә дә бу якларны Себердә «саз яклары» дип атап йөртәләр. Ә галимнәр исә күлләрнең, кечкенә инешләрнең, гомумән, суның күплегенә карап булса кирәк, бу якларны мәшһүр Венеция белән чагыштыралар, «саз ягы Венециясе» дип атыйлар.

Иртыш елгасының тәбәнәк, сул як ярына оялаган Козоклы авылы да зур түгел, бары тик йөзләп хуҗалык. Өйләре дә рәт-рәт урам булып түгел, бүредән коты алынган сарык көтүе шикелле ничек килде шулай бер җиргә укмашканнар. Бары тик авылның көнчыгыш һәм көнбатыш ягында гына, бүрек колакчыны кебек тырпаеп, берничә өй тезелешеп утырган. Козоклы дигәч тә, Козоклы авылы берәү генә түгел, икәү ул. Иртышның каршы, текә яр башында Урыс Козоклысы да бар.

Колхоз фермасы авылның көнчыгыш колакчынында иң кырыйда урнашкан. Кыш көне Себердә төннәр бик озын, көннәр бик кыска булганлыктан, сәгать өчләрдә караңгы төшкән була инде. Ләкин, караңгы төшүгә дә карамастан, фермада эш тукталып тормый. Кичке унберләргә кадәр дәвам итә. Ике ел рәттән инде Абу баба шушы фермада ат караучы булып эшли. Ә бит сугышка хәтле атаклы аучы исемен күтәреп йөри иде түгелме соң? Аны мактап газета битләрендә телгә алдылар, мәкалә, очерклар яздылар. Бөтен районга, хәтта өлкәгә Абу мәргән исеме таралды. Ә хәзер кем соң ул? — Гап-гади ат караучы. Кайберәүләрнең Абу баба турында шөһрәткә, данга кызыга икән дип ялгыш уйлаулары бар. Ләкин эш анда түгел. Бөтен гомерен тайгада, ауда йөреп үткәргән Абу баба сәгать саен, минут саен хәзерге язмышын каргый иде. Сөекле эшеннән, тайгадан аерылуына һич кенә дә күнегә алмады ул. Тайгага бүтән чыгып йөри алмас микәнни инде. Шушы хәсрәт көн-төн Абу бабаның йөрәк маен суыра иде.

Бәла дигәнең кешене адым саен сагалап йөри дә көтмәгәндә килеп чыга икән ул. Абу бабага да ул нәкъ шулай килеп чыкты. Яше алтмыштан узганда, ул үзен кешедән ким-хур итеп санамый иде. Тазалыгына гомерендә зарланганы, бер тапкыр да врачларга күренгәне булмады. 1941 елны, сугышның беренче айларында ук, ике улының берсеннән — Хәсәннән «кара кәгазь» килгәннән соң әллә ни булды Абу бабага. Болай үзе сау-таза кебек булса да, эчтән сыза башлады. Шул елны тайгага ауга күрше авылның Нәби белән чыгып киттеләр. Нәби, Абу бабага караганда бер ун яшькә кече булса да, танылган аучы иде инде. Сугышка да алмадылар үзен, бронь биреп калдырдылар. Бәла дигәнең Абу бабаны нәкъ әнә шунда көтеп торган икән. Баштарак эшләре бик әйбәт, майланган арба шикелле тәгәрәп кенә барды. Капкын, мылтык ярдәмендә шактый гына төрле җәнлек тиреләре булдырдылар. Болай барса, быел планны шактый арттырып үтәячәкбез дип шатланып кына йөргәндә, Абу бабаның күзләре начарлана башлады. Мылтыгын корып, җәнлеккә төзи башлавы була, әллә каян керфекләре яшьләнеп, күз аллары томанланып китә. Бу турыда Нәбигә бер сүз әйтмәде. Үтәр, бетәр дип өметләнде. Күзләрен сөртергә кулъяулык та алып йөреп карады, ярдәме булмады. Тирене бозмас өчен яхшы аучы җәнлекнең башына гына атарга тиеш. Ә аның үткән атнада бер тирене бозуы җитмәгән, менә бүген тагын берсенең башына тидерә алмады. Димәк, сезон беткәнче тагын күпме тирене бозачак ул. «Болай ярамый, миңа чик куярга кирәк»,— диде Абу баба үз-үзенә. Урман өенә караңгы төшкәндә генә кайтып керде. Нәби аш пешереп куйган, Абу бабаның кайтуын көтеп утыра иде. Аш ашап, чәй эчеп, тамак туйдырып алгач, каңсаларны[1] кабызып җибәрделәр. Аннан Абу баба Нәбигә болай диде:

— Нәби энем, җыелышта райком секретареның нәрсә сөйләгәнен хәтерлисеңме?

Нәби аптырап калды. Нигә шундый сорау бирә эле бу? Ни әйтергә тели? Начарлык эшләмәдем бугай. Әйе, ул райком секретареның әйткән сүзләрен яхшы хәтерли. Алар баш миенә кадак шикелле кереп утырганнар. «Иптәшләр, быел без сезгә планны икеләтә арттырып бирәбез. Илдә канкойгыч сугыш бара. Ә затлы тиреләр чит илләргә алтын бәһасына сатыла. Шуңа күрә бирелгән планны сез берсүзсез үтәргә һәм бер тирене дә брак бирмәскә тиешсез. Менә ни өчен без сезне фронтка җибәрми алып калабыз».

— Хәтерлим, Абу баба, бик яхшы хәтерлим.

— Хәтерләсәң, менә шул.— Ул ашыкмыйча гына капчыгыннан бүген атып кайткан тиресен өстерәп чыгарды да тиредәге пуля тишкән урынга бармагы белән төртеп:

— Күрәсеңме менә моны? — диде.

— Күрәм.

— Күрәсең. Ни дигән сүз бу?

Нәби дәшмәде. Үзеннән олы кешенең хәтерен калдырасы килмәде.

— Брак, брак дигән сүз бу, Нәби энем. Димәк, иртәгәдән башлап син мылтык белән генә ауга йөрерсең. Ә мин капкыннар белән генә ауларммын. Килештекме?

Нәби, ризалыгын белдереп, баш какты.

Абу баба күзенең начарлана башлавы турында Нәбигә бер сүз әйтмәде, ләкин Нәби эшнең нәрсәдә икәнен күптән инде сизенеп йөри иде.

Шул сезоннан Абу баба аучылык эшен ташларга мәҗбүр булды.

Иртышка атларны сугарырга төшкәндә, буран әле яңа баш күтәрә генә башлаган иде. Чирек сәгать үткәндерме, җил инде, карларны пыр туздырып, күккә чөя, чокыр-чакырларны, юлларны күмә, карны карал-

[1] Каңса (себер тат.) — чәләм.

ты-кураларга, өйләргә сылап йөри иде. Кич тагын да караңгыланды. Абу баба атларга тиз генә кичке печәнне салып алды да ферма йортына таба ашыкты. Атлар абзарыннан егерме биш-утыз метрда гына торган ферма йортын ул, күпме текәлеп караса да, тапмады. Тик әллә кайдан, төпсез караңгылык эченнән генә бүре күзе шикелле бер ут күренә иде. Шушы караңгылык эчендәге ялгыз ут Абу бабаның уйларын әллә кайларга алып китте. Гүя ул колхоз фермасында түгел, иксез-чиксез тайга уртасында басып тора. Котырып буран дулый, агачлар шаулый. Абу бабаның иңендә сәнәк түгел — карабин, билендә бау түгел — патронташлы каеш иде. Ферма йортының ялгыз уты да нәкъ тайгада аучылар ята торган өй утына охшаган. Абу баба үзе дә сизмәстән, куллары белән төнне ярып, утка каршы атлады.

Ферма йортында каравылчы Ариф бабадан башка беркем дә юк иде. Сыер савучылар, терлек караучылар, эшләрен бетереп, өйләренә кайтып киткән булып чыкты. Абу баба шуны көткән иде дә. Ул хатыннар арасында кара карга булып бер ялгызы утырырга яратмый. Эш яшь хатыннарның Абу бабага төрле төртке сүзләр әйтеп шаяруларында түгел иде. Канлы сугыш барган вакытта ир башың белән тол хатыннар арасында йөрү авыр иде аңа.

— И-и-и, һаман карт сөягеңне җылытып мич янында ятасыңмы,— диде Абу баба, ишектән үзе белән бер өер кар бураны алып кереп.

— Мин синең шикелле хатын-кызлардан куркып качып йөрмим бит.

— Кара син аны, үзеннән өлкәннәр белән ничек сөйләшә башлаган. Чебеш.

Ариф баба Абу бабадан нибары бер-ике яшькә генә кечерәк иде. Яшьтәшләр дисәң дә ярый.

— Ялгышасың, Абу, бик нык ялгышасың. Гөнаһ... минем хакта алай дип әйтү. Хатыннар янында мин әле этәч. Ә менә син — чебешнең дә чебеше.— Ариф баба үз сүзләреннән үзе канәгать булып, яңа йомырка салып чыккан тавык шикелле кеткелдәп алды.

— Ярар, телеңә күп салынма. Телеңә телчә чыгар. Лутче самосадыңнан бер төтәтеп җибәрик,— дип Абу баба Ариф бабаның янына барып утырды.

Ишектән кергәч тә уң кулда дүрт аяклы тимер мич басып тора. Эчендә саргылт ялкын телләре уйный. Тимер мичнең озын, нечкә торбасы, түшәм аркылы үтеп, туп-туры һавага чыга. Ике ятак арасында калын такталардан эшләнгән өстәл. Аның өстендә пыяласы корымланган фонарь. Бер почмакта буш флягалар өеме. Стенада каравылчы Ариф бабаның бүреләрне куркыта торган мылтыгы һәм колхоз председателенең сбруйлары эленеп тора. Фонарьдан керосин исе, эленеп торган сбруйлардан ат тире исе, флягалардан әчкелтем сөт исе һәм Ариф бабаның каңсасыннан чыккан зәң [1] исе — барысы бергә кушылып, йорт эчендә әллә нинди үзенә бер төрле ис барлыкка китергән иде. Бигрәк тә урамнан кергән кешегә шушы ис аеруча нык тәэсир итә. Абу баба каңсасын Ариф бабаның самосады белән тутырып, бер-ике тапкыр әчкә суыргач кына ул исләрне әзрәк тоймый башлаган кебек булды. Ариф бабаның тәмәкесе һәрвакыттагыча бик куәтле. Абу бабаның кипкән тамак төпләрен куырып алды, башын әйләндерде, гүя кырлы стакан белән шәрап эчтемени. Абу бабаның хәлен сизгән кебек, Ариф баба әйтеп куйды:

— Потлап-потлап төтен йотарга — бу сиңа махорка түгел, тәмен белеп кенә суыр.

— Әйе, бигрәк тәмле шул тәмәкең — кәнфит шикелле,— диде Абу баба көлемсерәп.

[1] Зәң (себер тат.) — трубка эчендә утырган тәмәке сумаласы.

Тимер мичнең гүләве белән тыштагы буранның улавын исәпкә алмаганда, бер мәлгә өй эчендә тирән тынлык урнашты. Каңсалардан елан теле хәтле генә ике соры төтен, ирекка чыгарга теләп, түшәмгә үрелә. Абу баба үзен тагын тайгадагы өйдә итеп хис итте. Гүя аның белән бергә Ариф карт түгел, аучы Нәби дусты утыра иде.

— Ишетмәдеңме, суд булды микән Закирның хатынына?

Тынлыкны бозган бу сорауга Абу баба аптырап алды.

— Нәрсә? — диде ул. Ариф картның ни сораганын аңламады.

— Закир хатыны Мөслимәгә суд булды микән дим. Ишетмәдеңме?

— Биш ел биргәннәр, ди.

— Кем әйтте.

— Предколхоз Камил белән фермәч Шакир шаһит булып барганнар. Бүген районнан кайттылар. Алар әйтте.

— Менә син миңа грамутный кеше. Гәзитләрне дә күп укыган. Әйт әле син миңа. Кар астыннан казып, биш килограмм башак җыйган өчен биш елга төрмәгә ябып кую дөрес эшме бу? Бармы андый закун?

— Белмим.

— Беләсең. Курыкма, мин синең өстеңнән жалу язып бирмәм.

Ариф баба бу сүзләрне әйтергә теләмәгән иде. Ялгыш Абу дустының иң авырткан җиренә кагылды. Уйламыйчарак кызып китеп әйтеп җибәрде.

Абу бабаның йөрәгенә кайнар дулкын килеп бәрелде. Ариф картка тозлап-борычлап бер-ике сүз әйтергә теләгән иде дә, ничектер салкын акыл сабырлыгы коткарып калды. Хәзер талашып утырудан ни файда. Инде онытыла да башлаган иде кебек. Ләкин Ариф аны нигә кузгатты икән? Тыныч кына йоклый бирсен иде. Эх, бу кешенең теле.

Бәла бер ялгызы гына йөрми дип бик дөрес әйткәннәр икән. Шул кырык беренче елны Абу бабаның үзенә генә дә берсеннән-берсе авыр әллә ничә бәла килде. Башта өлкән улының үлгән хәбәрен китерделәр. Аннан күзләре күрми башлады, сөекле эшеннән аерылды.

— Я, нигә дәшмисең? Телеңне йоттыңмы әллә?

— Эш анда түгел.

— Алай булгач әйт, нәрсәдә? Кемдә гаеп? Ул бит аны урламаган. Ире Закир ил өчен башын сугышта югалтты. Камил шикелле, тәмәке суы эчеп, фронттан качып калмады.

Абу баба түзмәде.

— Син нигә миңа бәйләндең әле, ә? Бар да әнә предколхозның үзеннән сорау ал.

— Хет балаларын кызганырлар иде. Ул сабыйларның ни гаебе бар. Кемгә кала инде алар,— дип сөйләнде Ариф, йончыган тавыш белән.

Абу баба да тавышын акрынайтты.

— Ике малаен да детдомга җибәрергә булдылар. Анда аларны ашаталар, киендерәләр, укыталар. Бар да түләүсез. Хөкүмәт өстеннән.

— И-и Абу, син үзең беләсең бит. Ата-анасыз үсүләрне алла күрсәтмәсен.

Әйе, Абу баба ятимлекнең нәрсә икәнен үз җилкәсендә татыды. Өч яшендә ул әтисез калды. Әтисе Хәлиулла Эрбет ярминкәсенә ашлык сатарга киткән җиреннән әйләнеп кайтмаган. Акчасын талап, юлда юлбасарлар үтереп киткән диган хәбәре генә әйләнеп кайткан. Тикшереп, эзләтеп йөрүче дә булмаган. Бер-ике елдан соң әнисе Гөлҗамал, биш яшьлек Абуны әбисенә калдырып, каядыр кияүгә чыгып киткән. Абу башта әбисендә тәрбияләнгән, ул үлгәч, җәйләрен көтү көтеп, кышын кешегә сепарат аертып тамагын туйдырган. Сабый күңеле кешенең бер ягымлы сүзенә, елмайган күз карашына зар булып үсте. Исеме дә Абитулладан Абу булып кына калды.

— Димәк, Камил белән Шакирның эше бу,— дип сүзен дәвам итте Ариф карт.— Әйтәм, сыер саварга килгән саен Шакир Мөслимәгә гел

бәйләнә иде. Просто худ бирми иде. Беркөн ничектер соңгарак калып килдем. Килеп керсәм, ни күрим: Шакир Мөслимәне сәкегә егып салган да талап маташа. Фермадагылар барысы да кайтып киткән, ә Мөслимәне ул ниндидер сәбәп табып алып калган. «Синңа күптән теге дөньяга вакыт, кешегә мешать итеп йөрисең шунда, уләксә»,— дип сүгеп чыгып китте үземне. Ул киткәч, Мөслимә үксеп-үксеп елады. «Кулсыз, аяксыз булса да, Закирым исән кайткан булса, мондый адәм актыклары бәйләнеп йөрмәсләр иде, ди. Төннәрен исерек килеш ишек шакып, балаларымны куркыталар, ди. Бөтен авыл белә, кешегә күренер әмәлем калмады инде, ди».

— Чибәр, яшь хатын кемгә ошамас. Кайчагында әле мин дә карт башым белән, эх тагын бер егерме яшькә яшьрәк булсам иде, дип уйлап куйгалыйм аңа карап. Ә ул горур хатын, үзен үзе белә. Менә шуңа үч иткәннәр инде, кабәхәтләр. Ярар, сугыш кына бетсен. Ирләр кайткач, барысы өчен җавап бирерләр әле,— диде Абу баба, инде күптән сүнгән каңсасын авызыннан алып.

Аннан торып киенә башлады.

Ариф карт башта аны тышка чыгып кына керә торгандыр дип уйлады. Аңа да бер чыгып, ферманы әйләнеп карап керергә кирәк. Кураларда бүре керерлек тишек-мазар булмаса да, кем белсен ул ерткычны, бер дә уйламаган-көтмәгән җирдән керергә тишек таба бит.

— Син кая, тышка чыгып керәсеңме әллә? Тукта, бергә чыгарбыз,— диде Ариф карт.

— Миңа өйгә кайтырга кирәк. Болай да озак утырдым.

— Бу буранда рәтле кеше этен дә урамга чыгармый. Монда кун да кал. Өеңдә бер ялгызың нишлисең,— дип Абу бабаны ул ниятеннән айнытырга тырышып карады.

— Мин бит хәзер ялгыз түгел.

Ариф карт, ялгыш ишетмәдем микән, дип авызын ачып, Абу картка сораулы караш ташлады. Абу баба дәшмәде. Ул нәрсәдер уйлый иде. Ариф карт моны үзенчә аңлады. Кара син аны, әллә карт көнендә юләрләнә башлаган инде. Хәер, аның бабасы да, җитмеш яшендә яшь хатынга өйләнеп, оныклары белән яшьтәш ике малай үстергән диләр. Әгәр бу да бабасына охшаган булса... Ариф картка бу бик кызык булып тоелды. Ул инде ерылган авызын тыярлык хәлдә түгел иде. Кеткелдәп көлә-көлә Абу бабага:

— Өйләндеңме әллә? Кемнең кызына? Түлке алдан ук килешеп куйыйк. Хәлеңнән килмәсә, мине ярдәмгә чакырырсың.

Абу баба башта аңлатырга дип, авыз ачып караган иде. Кая инде ул. Ариф карт тыңларлык хәлдә түгел иде. Күзләрен кул сырты белән сөртә-сөртә көлә. Шунда гына Арифның яшьләр түгеп көлүенең серенә төшенде һәм үзенә дә кызык булып китте. «Вәт юләр. Кара син аны нәрсә турында уйлап утыра икән». Абу баба таудан аккан шарлавык шикелле күкрәктән чыккан тавышы белән шаркылдап көлеп җибәрде.

Шушы буранлы төндә ярым караңгы ферма йортында яшен яшәгән, ашын ашаган ике карт бер-берсеннән рәхәтләнеп, язгы ташкын кебек иркенәеп, җәелеп көлешәләр. Гүя илгә килгән афәт тә, ачлык-ялангачлык, кайгы-сагышлар да юк иде бу минутта.

— Юләр,— диде Абу баба,— вәт юләр. Кызлар турында уйлап утыра икән.

— Нигә, карт сыер каймак бирә диләр бит.— Ариф баба әле һаман сүзне көлкегә борырга тырыша иде.

— Кызлар өндә түгел, төшкә дә кермиләр хәзер. Беләсең бит теге ятим Усман малаен. Вәлишне.

— Янсуфин Усманныкын әйтәсеңме,— диде Ариф баба тынычланып.

— Әйе.

— Нигә белмәскә. Әллә берәр нәрсә булганмы аңа?

— Исән-сау, берни булмаган. Тик менә соңгы вакытны җиңгәсе бер дә карамый башлады малайны.

— Үз баласы булмагач, аңа нәрсә. Ирләрне йокларга кертә, бергәләп аракы эчә. Хатын-кыз аракы эчә башладымы, ул инде үз баласы турында да уйлап тормый. Югыйсә, ире дә исән бит әле. Ире кайтса, ничек күзенә күренер ул аның. Әнә Мөслимәне алып карыйк. Көтәсе ире дә юк. Шулай да бозык юлга кереп китмәде.

— Үзе белә торгандыр инде. Тик менә мин Вәлишнең ач-ялангач йөргәнен күреп артык түзеп тора алмадым. Бүген иртә белән Корбанбикә киленгә кереп:

— Я малайны рәтләп кеше кебек карыйсың, я мин аны үземә алып кайтам,— дип кистереп әйттем.

— Нәрсә диде соң?

— Синең ни эшең бар! Нигә кеше эшенә тыгылып йөрисең, ди. Ирләр белән аракы эчеп, гулять итәсең икән, ирең кайткач, ни дип җавап бирерсең, дип тә карадым. «Сугыш әле бетмәгән. Әллә кайта, әллә юк. Мин аны көтеп яшьлегемне үткәримме? Картайгач кемгә кирәгем бар минем»,— дип җавап бирде. Минем әйткән сүзләремә исе дә китмәде. Вәлишне бирде, анысына каршы килмәде.

— Котылганына сөенгәндер әле.

— Ә син, өйләндеңме әллә дисең.

— Аны башта ук шулай диләр,— диде Ариф баба, гафу үтенгән сыман.

— Ярар, миңа кайтырга кирәк.

Абу баба тагын бер тапкыр саубуллашып чыгып китте.

Урамда Абу бабага бер тере җан иясе дә очрамады. Караңгыда кар күмеп киткән юлны сукыр кеше кебек аяк белән капшап атлавы бик кыен. Юлдан читкә дә төшеп киткәли. Бата-чума тагын юлга чыга. Әз генә җил тынып торган арада төпсез караңгылык дөньясыннан ач бүреләрнең улаган тавышлары ап-ачык булып ишетелеп кала. Алар якында, авыл читендә генә. Ярты авылның диярлек тәрәзәләрендә ут юк. Әллә ятып йоклаганнар, әллә керосиннары юк инде. Калган өйләрдән тоныкъ яктылык урамга сибелә. Бәлки шушы ярым караңгылык эчендә яшь киленнәр, хатыннар күңел җылыларын, күз нурларын кушып, фронтка я йон бияләй, я йон оекбаш бәйлиләрдер, бәлки буй җиткән япь-яшь кызлар я кулъяулыкка, я тәмәке янчыгына үзләренең исемнәре белән бергә өметләрен дә чигә торганнардыр. Бәлки үсмер малай я кыз үзенең әтисенә яки абыйсына тырыша-тырыша сагынычлы сәлам хатлары юллыйдыр. Аннан Абу бабаның уйлары тагын бүреләргә әйләнеп кайтты. Сугышка хәтле бүреләр бик сирәк очрый торганнар иде. Бу чаклы котырган да түгел иделәр. Ә хәзер ялгызың беркая чыгып булмый, көпә-көндез авыл тирәсендә сагалап йөриләр. Ялгыш урамда кунып калган этләрне алып китәләр, шушы сугыш афәтеннән качып, әллә бөтен Европаның бүреләре Себергә җыелганнар инде.

Абу бабаның өе авылның икенче як колакчынында иң кырыйдан беренче. Нәкъ зират янында, дүрт почмаклы кечерәк кенә бер өй. Барлы-юклы ике тәрәзәсенең берсе ишегалдына караса, икенчесе зиратка текәлгән, тышкы ишекне җил-яңгырдан, кар-бураннан ышыклый торган кечкенә генә араны да бар. Өй түбәсе, ямала-ямала, корамʼа юрганга охшап калган.

Абу баба аран ишеген көч-хәл белән генә ачып керде. Ишегалдына калын итеп кар өеп куйган иде. Бәхетсезлеккә каршы, кар көри торган агач көрәге дә аран эчендә калган булып чыкты. Башка көннәрдә көрттә чәнчүле тора торган иде. Нишләп кертеп куйгандыр, үзе дә белми. Аннан тәрәзәдә ут юклыгын күреп, тагын шиккә төште. Ышанмыйча тәрәзәдән өй эченә текәлеп карады, ләкин боз сарган пыяла аша берни күрмәде. Әллә мине көтә-көтә берүзе утырырга куркып, күршеләргә

кереп киткән инде. Абу баба ишек төбен аягы белән көри-көри тирләп бетте. Бераз ачылырлык булгач, көчкә кысылып, эчкә үтте. Көрәген алып чыгып ишек алдын көрәп, чистартып куйды. Әгәр төне буе болай котырынса, иртәгә хәтле кар бөтенләй күмеп китәчәк, өйдән чыга алмый утырырсың, дип уйлады.

Өй ишеге эчтән бикле булып чыкты. Шуннан соң гына Абу бабаның күңеленә җылы йөгерде, иңеннән авыр йөк төшкән кебек булды. Өйдә, димәк, беркая чыгып китмәгән. Бәлки йоклый торгандыр. Абу баба йодрыгы белән ишекне берничә тапкыр төйде дә тынып калды. Озак та үтмәде, өй эченнән:

— Кем,— дигән нәзек кенә тавыш ишетелде.

— Бу мин, балам, мин. Ач тизрәк,— дип кычкырды Абу баба. Гүя аның артыннан куып килүчеләр бар иде. Аннан ишек келәсенең челт итеп ачылганы ишетелде. Абу баба ишектән керү белән:

— Нигә караңгыда утырасың, керәсин беткәнме әллә, балам? — диде.

— Кәрәсине бераз бар әле.

Абу баба тәрәзә буенда утырган өстәлгә барып төртелде һәм, кулы белән капшап, җиделе сукыр лампаны эзләп тапты. Чалбар кесәсеннән сирәңкә[1] алып лампаны кабызды. Абу баба сирәңкәне кадерләп кенә тота, бик кирәк очракларда гына куллана. Күпчелек вакыт ут кабызырга аның чакма ташы бар.

— Өй дә суына башлаган икән энә. Болай туңып утырырга ярамый, балам, салкын тидерүең бар.

— Мин мич башына менеп ятып кына торган идем, йоклап киткәнмен. Хәзер ут ягып җибәрәм, әле күмере сүнмәгән.

— Үзем ягармын, балам. Кара, яланаяк, күлмәкчән генә торасың бит. Бар, тизрәк мич башына менеп ят. Өй җылынгач, төшәрсең.

Биш минуттан ян-яклары тишелеп челтәрләнеп беткән тимер мич паровоз топкасы шикелле гүләп яна иде инде. Әнә мич калаенда яңа күтәрелеп килгән таң кебек алсулык та хасил булды. Абу баба, тимер чәйнеккә чәй куеп, идән астындагы чокырдан бәрәңге алып чыгып, кабыгы белән бәрәңге пешерергә утыртты. Өй бик тиз җылына башлады. Өйгә җылы таралгач, беренче булып мичкә каршы тәрәзәнең бозлары эреп, тулган ай кебек түгәрәкләр барлыкка килде. Тәрәзә төбеннән идәнгә тамчылар акты. Чәй кайнап, бәрәңге пешеп чыкканчы әзрәк ятып торса да ярар иде. Абу баба каңсасына тәмәке тутырып кабызды да ишек төбендәге агач караватка менеп ятты.

Ята торгач Абу бабаның күзләре ярым караңгылыкка да ияләшеп бетте. Ул хәзер өй эчендәге бөтен әйберне аерым-ачык күрә иде. Әнә сәкенең бер башында тимер кыршаулы зур агач сандык тора. Аның өстенә каз йоны тутырылган түшәк, корама юрган, ястыклар өелгән. Кеше эшсез һәм ялгыз калса, аның күңелен үткәннәр билэп ала, Абу баба да шушы сандык өстендәге түшәк, юрган, ястыкларга карап ята торгач, гомеренең иң бәхетле елларында ятып калган үткәннәре белән күзгә-күз очрашкандай булды.

Яшьтәшләре өйләнешеп, үз семьяларын корган чакта, Абу баба өйләнә алмый йөрде. Абуга кызлар карамады түгел, карады. Аның өчен янып йөрүчеләр дә шактый иде. Ул зифа буйлы, дулкынланып торган чем-кара чәчле, коңгырт-зәңгәрсу күзле, борынгы грекларныкы сыман туры, нечкә борынлы егет иде. Нинди генә эшкә тотынмасын, бар да кулыннан килә. Өстәвенә авылда, юк авылда гына түгел, бөтен якынтирәдә иң оста биюче. Дөресен генә әйткәндә, килешмәгән җире юк иде. Бары бер генә кимчелеге бар иде аның. Ул да булса, атасыз-анасыз ятим, ярлы егет иде ул. Яшьтәшләре өйләнешкән чакта Абуның

[1] Сирәңкә (себер тат.) — шырпы

сөйгән кызына өйләнә алмавына шул сәбәпче булды да инде. Ул үзенең өзелеп яраткан кызы (ул да Абуны ярата иде) Зәйнәбенең кулын сорап, атасы Кәлимуллага әллә ничә тапкыр яучылар җибәреп карады. Абуның йөзенә ярып әйтмәсәләр дә, төрле сәбәп табып, сузып килделәр. Калымын да, юри Абуның хәленнән килмәслек итеп сорадылар. Югыйсә, үзләре дә бай яшәмиләр иде. Атасы Кәлимулла әйткән имеш, алма кебек кызымны Абу шикелле бер ыштансызга бирергә, мин әле үз акылымда, дигән имеш. Абуны яратып йөргән барлык кызлар яратмаган егетләренә кияүгә чыгып беттеләр. Абуның Зәйнәбен дә, кызы каршы килгәч, атасы көчләп кияү чанасына төяп җибәрде.

Беренче бөтендөнья сугышына Зәйнәпнең ире дә, Абу да эләкте. Шушы үлем кырыннан Абуны революция коткарды, ә Зәйнәпнең ире мәңгегә Пруссия җирендә ятып калды. Бу әллә ничек, Абу теләгәнчә килеп чыкты кебек. Юк. Абу Зәйнәбенең иренә үлем теләмәде, ләкин Зәйнәпнең ялгыз калуын тели иде. Бары Октябрь революциясеннән соң гына Абу яраткан Зәйнәбе белән кушылды. Ләкин озак та үтмәде, гражданнар сугышы башланып китте. Революциядән соң, коммунист буларак, Абуны комбед председателе итеп сайлаганнар иде. Акгвардиячеләр килгәч, Абу үзенең иптәшләре белән тайгага китеп өлгерде. Соңга калганнарны Иртышка алып төшеп, терелә́й бәкегә батырып үтерделәр. Абу Колчак отрядын Себердән куганчы, тайгада партизан отрядында булды. Авыл халкы теленә Абу әнә шуның өчен «Кызыл Абу» булып кереп калды, әнә шушы сандык өстендә өелеп торган түшәк, юрган-ястыкларның барысын да Зәйнәп үз кулы белән текте. Ләкин, кызганычка каршы, гомере кыска булды. Абуга ике бала үстереп бирде дә кисәк кенә үлеп китте.

Көтмәгәндә кемдер тәрәзә шакыган кебек тоелды. Абу баба, татлы уйларыннан бүленеп, тавыш ишетелгән ян тәрәзәгә колак салды. Ялгыш ишетмәдеме? Бәлки җил кага торгандыр? Мондый буранлы төндә бүреләрдән курыкмыйча кем йөрер икән, дип уйларга өлгермәде, яңадан, бу юлы инде аерымачык итеп, тәрәзә шакыган тавыш ишетелде. Әллә фермада берәр нәрсә булды микән? Атлар абзарына бүреләрнең керүләре дә бик мөмкин. Нигә дисәң, абзар түбәсе салам белән генә ябылган. Элек тә бүреләрнең, салам түбәне тишеп, абзарга кергәннәре булгалаган иде. Абу баба тиз генә караватыннан төшеп, тәрәзәнең коймак хәтле генә эрегән җиреннән урамга текәлүе булды, таныш булмаган бер адәм белән йөзгә-йөз очрашты. Ул да тәрәзәдән өй эченә ябырылып карап тора иде. Абу баба бер мизгелгә ни эшләргә белмичә аптырап калды. Алай йөзгә-йөз очрашырмын дип уйламаган иде ул. Ләкин теге кеше бер дә каушап калмады. Абу бабаны күрү белән ук тагын тәрәзәгә чиртеп, кунарга кертүен үтенде.

Себер татарлары борын-борыннан киң күңелле, кунакчыл халык. Әгәр дә төнлә берәр юлаучы яки узгынчы килеп, ишек шакый икән, аның кем булуына карамастан өенә кертер, ашатыр, эчертер һәм түрдән йокларга урын җәеп бирер. Бу — борынгыдан килгән гадәт. Абу бабаның ишек ачарга чыгып киткәнен Вәлиш карап калды.

Алар берәү генә түгел, икәү булып чыктылар. Чаңгыларын, мылтыкларын һәм азык-төлекләрен аранга кертеп куйдылар да өйгә керделәр. Алар икесе дә уртачадан калкурак, таза ирләр иде. Берсе илле яшьләр тирәсендә булыр, битен төк баскан, икенчесе егерме яшьләр тирәсендәге кара күзле чибәр егет иде.

— Ох, җиле эче, каһәр суккыры. Прямо битне ялап ала,— дип сөйләнде сакалбай.

— Нишләп басып торасыз. Чишенегез. Үз өегездәге кебек булыгыз, тартынып тормагыз. Өй җылы. Кирәк булса, тагын мичкә өстәрмен,— диде Абу баба.

Алар икесе дә өс киемнәрен салып, ишек төбендәге кадак чөйләргә элеп куйгач, эскәмиягә утырдылар.

Абу баба мичкә тагын бер-ике каен ярка өстәп җибәрде. Аннан кунаклардан:

— Сезгә бүреләр очрамадымы? — дип сорады.

— Очрады,— диде сакалбай,— ләкин бу караңгыда ничә бүре икәнен белеп булмады. Куркытыр өчен мылтыктан берне аттым. Шуннан соң гына күздән югалган кебек булдылар.

Аннан урыныннан торып, Абу бабага килде.

— Әз-мәз эчкә җылы керде, инде танышырга да була,— дип кулын сузды.— Мин Һарун Баймурзин булам. Ә бу, — ул яшь егеткә кулы белән күрсәтте,— минем улым Зөфәр була.

— Абу. Миңа шулай дип эндәшерсез.

Абу бабаның үзен Абу дип таныштыруы булды, Һарун Баймурзин шатлыгыннан кычкырып җибәрде.

— Абу, атаклы аучы Абумы?

— Әйе, аучы Абу мин үзем булам.

— Ә без сезне эзләп килгән идек. Туп-туры үзегезгә керербез дип кем уйлаган. Менә бит, ә.

— Ә сез кемнәр буласыз соң?

— Без күрше Яулы Тора районыннан. Аучылар. Бәлки сез безне белми дә торгансыздыр, Абу баба. Минем аучылык белән шөгыльләнгәнемә күп түгел, биш-алты ел гына әле.

Абу баба күпме генә хәтерен актарып караса да, Баймурзин фамилияле аучыны исенә төшерә алмады. Югыйсә, күрше-тирәдәге барлык аучыларны яхшы белә. Алар бармак белән генә санарлык иде. Үзе әйтмешли, күптән түгел генә аучылык эше белән шөгыльләнгәнгә шулайдыр, дип уйлады Абу баба.

— Ә мин сезне өйдә туры китерә алмам, тайгага чыгып киткәнсездер дип курыккан идем. Аллага шөкер, безнең бәхеткә, өйдә икәнсез әле.

— Юк, киткән юк минем,— дип кенә җавап бирде Абу баба. Нигә тайгага чыгып китмәгәнлеген аңлатып торасы килмәде. Юлдан килгән кеше һәрвакыт ач була. Башта кунакларны ашатырга кирәк иде. Ә сөйләшергә әле өлгерәчәкләр, төн озын, тик керосин гына җитсә ярар иде.

Ул арада бәрәңге дә пешеп чыкты. Ә чәй инде күптән кайнап утыра иде. Абу баба чуенны мич өстеннән алып бәрәңгенең суын саркытты. Аннан чуенны-ние белән өстәлгә китереп утыртты.

— Әйдәгез, өстәлгә якынрак утырышыгыз. Юлда ачыккан булырсыз,— дип, кунакларны табынга утырырга кыстый башлады Абу баба.

Кунакларның карыннары чынлап та ач иде. Сусауны басар өчен капкан карны исәпкә алмаганда, көне буе аларның авызларына бернинди ризык кергәне юк. Югыйсә, капчыкларында бер икмәк кенә түгел, башка төрле ризыклар да бар. Ләкин таш кебек туңган ипине ничек итеп ашарга кирәк. Козоклыга килеп җиткәнче түзәргә туры килде.

— Әйдә, улым, төш, бәрәңге ашарга.

Вәлиш өлкәннәр арасында, бигрәк тә ят кешеләр янында утырырга уңайсызланды. Корбанбикә җиңгәсе кеше килгәндә бервакытта да Вәлишне табынга бергә утыртмады, онытылып, ялгыш утырса, өстәл артыннан куып җибәрә иде. Ничә тапкыр ул шулай ач йокларга мәҗбүр булды.

— Баба, миңа монда гына салып бирсәң икән. Анда төшеп торасым килми,— диде ул куркып кына.

Ул әле Абу бабага ияләшеп өлгермәгән, бабасы ничек кенә яхшы булмасын, Вәлиш шушы өйдә әле беренче көнен генә яши иде.

Абу баба табакка берничә бәрәңге, бер телем ипи салып Вәлишкә бирде. Аннан соң бер кружка чәй китерде. Кайнар бәрәңгенең исе бо-

рын яфракларын кытыклап, сулышы белән эченә үтте Вәлишнең. Шунда аның хәтеренә әнисенең исән чагы килеп керде. Әнисе бервакытта да бәрәңгенең үзен генә ашатмады. Ул аны гел катык белән бергә бирә торган иде. Катык белән кайнар бәрәңге. Аннан да тәмле ризык юк кебек иде бу дөньяда. Ул чаклар кая китте икән? Тагын күреп булырмы, әнисе кире кайтмаган кебек, ул чаклар да кире кайтмас инде ахры.

Ашарга утырыр алдыннан Баймурзин малаена нәрсәдер әйтеп ым какты. Зөфәр аранга чыгып китте һәм аннан бер төргәк алып кереп өстәлгә салды. Ул чучка мае булып чыкты. Аннан кунак Абу бабадан:

— Сез сало ашыйсызмы? — дип сорады.

— Кеше ашаган ризыкны мин дә ашыйм. Тормыш барысына да өйрәтә ул.

— Аракы эчкәндә салодан да әйбәт закуска юк. Кара нинди закуска бит, әй,— диде телен шартлатып.

Шунда Абу бабаның идән астындагы бер шешә аракысы исенә төште. Улларын фронтка озатканнан калган ие. Абу баба үзе аракыны ул хәтле яратмаганлыктан, инде онытылган да булган икән.

— Мин хәзер киләм. Әйдәгез, бәрәңге суынганчы ашый торыгыз,— дип урыныннан торды. Аннан идән астына төшеп, караңгыда кармалана торгач (ул шешәне кая куйганын да онытkан иде инде), бер әрҗә эченнән тапты. Сургыч башлы аракыны өстәлгә китереп утырткач, Баймурзин гаҗәпләнүле тавыш белән:

— Абу баба, сез нәрсә?! Әллә мине аракы сорый дип уйладыгызмы? — Аннан җәелеп елмайды.— Чыннан да аракы сораган кебек килеп чыкты бу. Гафу итегез.

— Улларымны фронтка озатканда алган идем. Сезнең бәхеткә утырган икән,— дип, Абу баба ашыкмыйча гына шешәнең авызына суккалады, сургычын ватып, бөкесен ачты. Аннан йөзәр грамм сыешлы өч стаканга аракы бүлеп чыкты. Борыннан килгән гадәт буенча исәнлек-саулык, эшендә уңышлыклар теләп тост күтәрде. Аракы Абу бабаның бөтен кан тамырлары буйлап йөгерде, хәтта аяк бармакларының очына хәтле барып җитте. Бит алмалары эсселәнеп, алсуланып китте. Гүя Абу бабаның иңнәреннән картлык йөген алып ташладылар. Кунакның да күзләре ялтырап, күңеле күтәрелеп китте. Әйтерсең, ару-талулар бер дә булмаган. Бары Зөфәрнең генә ашаганнан соң үтереп йокысы килә башлады. Күз кабакларын күтәреп утырырлык та хәле калмаган иде.

Зөфәрне йокларга яткырганнан соң Абу баба белән Баймурзин икесе генә утырып калдылар.

— Мин балачактан ук аучы булырга хыяллана идем. Ләкин, кызганычка каршы, безнең районда сезнең яклардагы кебек иксез-чиксез кара урманнар юк. Калын урманнары булмагач, билгеле инде, бер Николай Фомичны исәпкә алмаганда, чын аучы исемен йөртерлек кешеләр дә юк. Үрдәк, куян аулаучылар муеннан. Башта мин дә үрдәк, куян аулап йөрдем. Әгәр Николай Фомич очрамаса, бала чактагы хыялымны әле дә исә тормышка ашыра алмас идем.

Абу баба, Николай Фомич исемен ишеткәч, Баймурзинның сөйләп бетерүен көтеп тора алмады.

— Сез Николай Фомич Кутафин турында әйтәсезме? — дип аның сүзен бүлдерде.

— Әйе. Ул минем остазым иде.

— Үлгән дип ишеткән идем мин аны.

— Үлде шул. Бик кызганыч үлде. Үләр алдыннан миңа: «Син, Һарун, аучылык һөнәреңне ташлама. Мин сине Туртаз якларына, зур тайгага алып чыкмакчы булган идем. Туры килмәс ахры инде. Ләкин мин сиңа иң якын дустымның, Абу мәргәннең адресын бирәм. Ул сине аучы-

лыкның бөтен серләренә өйрәтер. Ничек булса да эзләп тап син аны,— диде.

Абу бабаның күңеле йомшарып китте. Николай Фомич белән очрашмаганнарына биш-алты еллар бардыр инде. Ләкин шактый вакыт үтүгә карамастан, Николай Фомич үзенең шаян, шук холкы белән Абу бабаның күз алдына килеп басты.

— Ул минем иң якын дусларымның берсе иде. Үз гомеремдә нинди генә кешеләрне очратмадым. Төрлесе булды. Ләкин Николай Фомич таң йолдызы шикелле нур сибеп калдырды минем күңелемдә. Киң күңелле, бик тә кешелекле кеше иде. Шатлыгың булса, ул синең белән бергә шатланыр, үзенеке кебек чын йөрәктән кабул итәр. Нәкъ сабый бала шикелле. Кайгың булса, ул аны уртаклашып кына калмас, ничек булса да синең кайгыңны җиңеләйтергә тырышыр иде. Мин үз гомеремдә дуслыкның кадерен аның шикелле белүчене хәтерләмим. Аның белән хет дөнья читенә чыгып китсәң дә, куркыныч түгел иде. Ул ничә тапкыр мине тайгада бәладән коткарып калды. Ә менә үзен бәладән коткаручы булмаган.

Баймурзин, олы кешенең сүзен бүлдермичә, ихтирам белән, әдәп саклап тыңлап утырды. Югыйсә, кәефе кырылуы бар. Аннан тайгага чыгарга ярдәм итәр дип уйлама да. Бүген аның һәм улының язмышы хәл ителәчәк, ә ул язмыш Абу баба кулында.

— Һарун, әйдәгез Николай Фомич истәлегенә күтәрик әле. Авыр туфрагы җиңел булсын, мәрхүмнең,— дип Абу баба стаканнарга шешәдә калган аракыны бүлде.— Нигә соң яхшы кешеләр тиз китә икән бу дөньядан, ә?

— Әйе, әйе,— дип кенә куйды Баймурзин. Әллә аракыдан, әллә башка сәбәптән ул уйланып утыра иде.

Алар, стаканнарын чәкештереп, сүзсез генә эчтеләр. Аннан икмәк һәм дуңгыз маеннан бутерброд ясап капкалап алдылар.

— Шулай, аю тырнагыннан үлде Николай Фомич,— дип башлады Баймурзин.— Быел көзен безнең якта әллә каян шатун[1] барлыкка килде. Игеннәр урылып беткән, җиргә кар яумаган иде әле. Көннәрдән бер көнне, көпә-көндез, бер сыерны алды бу. Көтүче күреп торган, ләкин берни эшләтә алмаган. Чыбыркы белән генә аюга каршы барып булмый шул. Үзенең коты ярылып, көтүен ташлап качкан. Башта аның сүзенә ышанмаганнар, юкны сөйлисең дигәннәр. Хәзер нишләп йөрсен ди аю. Барып карагач кына ышанганнар. Менә шуны атып бирүен үтенеп, Николай Фомичны чакырганнар. Үзегез беләсез, Николай Фомич кешегә ярдәм итмичә калмый инде. Мин Николай Фомичка килгәндә, ул инде ике этен ияртеп, бер үзе генә шатунны атарга чыгып киткән. Аны шатун өзгәләп ташлаган булыр иде, ярый әле этләр ирек бирмәгәннәр. Мин килеп атып алдым шатунны.

— Ә нишләп Николай Фомич атмаган соң?

— Нигә атмасын, аткан. Соңыннан ул үзе миңа болай дип әйтте. Шатун этләргә игътибар итмичә, арт аякларына басып, Фомичка каршы килә башлаган. Фомич, гадәте буенча, аюны якын ук китереп күкрәгенә төзәп диярлек атарга ярата иде. Бу юлы да аюның якын килүен көтеп торган. Һәм күкрәгенә төзәп атыйм дигәндә генә мылтыгы отказ биргән. Икенчегә корырга өлгерми кала, шатун басып китә Фомичны. Өйгә алып кайткач, ике-өч сәгать кенә яшәде.

— Бары бер генә осечка һәм гомерең юк дигән сүз,— Абу баба авыр сулап, уйга талды. Аннан мич өстендә утырган чәйнекне алып килеп, икесенә дә чәй ясады. Ул бүген чәйне элекке көннәргә караганда куерак ясады. Бар да кунаклар хөрмәтенә иде. «Чай кирпичный, вода Иртышный»,— дип мактап та алды.

---

[1] Шатун — кышкы йокысына ятмаган аю.

һәр сүзнең җаен туры китереп әйтсәң генә ул сүз кешегә тәэсир итә. Менә хәзер шундый момент килеп җитте, дип уйлады Баймурзин. Абу баба минем кем икәнлекне хәзер инде белде. Хәтта үзенә ошадым да бугай әле. Якын дустының соңгы амәнәтен кире какмас инде. Аучыларда андый гадәт юк. Димәк, ярдәм итәргә тиеш, тәвәккәлләргә кирәк. Әнә шуларның барысын да күңеленнән кичергәннән соң гына ни йомыш белән килеп чыгуын әйтергә булды.

— Абу баба,— дип сүзен башлады ул, йомшак, ягымлы тавыш белән. Аннан пауза ясап алды. Ул ничек тә Абу бабаның күңеленә тәэсир итәргә тырыша иде.— Мин сезгә бер бик зур үтенеч белән килгән ием.— Сүзен әйтеп бетермичә тагын пауза ясады.

— Я, я, тыңлыйм. Әйт, улым, йомышыңны.

Абу баба «улым» дип әйтеп җибәрүен үзе дә сизми калды. Авылда һәркемгә «улым» дип эндәшү гадәткә кергән иде.

Абу бабаның үзенә «улым» дип әйтүен үзенчә аңлады кунак. Димәк, болай булса, эш уңачак. Ләкин шатланырга әле иртәрәк иде. Ул йомшак, ягымлы тавыш белән ашыкмыйча сүзен дәвам итте:

— Абу баба, үзегез беләсез, безнең якларда иксез-чиксез тайга урманнары юк. Шуңа күрә затлы җәнлекләр дә юк диярлек. Аучы кеше ауга йөрмичә яши алмый. Фомич мине сезнең якларга яки сезнең кышлауга алып чыкмакчы иде. Хәзер ул да юк инде. һәм аның соңгы амәнәтен үтәү теләге белән мин менә, улымны алып, сезгә килдем. Хәзер инде бар өмет сездә генә, Абу баба.

Абу баба аның нәрсә турында сүз алып барачагын күптән сизеп алган иде инде. Нигә дисәң, Абу бабадан башка ул якларны белүче кеше калмаган иде, Фомичның укучысына ул һәрвакыт ярдәм итәчәк. Ләкин ул Баймурзинга алай дип әйтергә ашыкмады.

— Мин ауга йөрүне күптән ташладым бит инде, һарун улым. Хәзер мин колхозда ат караучы булып эшлим.

— Ничек алай? Берни аңламыйм.

— Хәзер аңлатып бирәм үзеңә.

һәм Абу баба нигә ауга йөрмәгәнен түкми-чәчми сөйләп бирде. Азактан:

— Хәзер мин ауга чыксам, авыл тирәсендә куян атарга гына чыгам. Менә шулай минем эшләр, улым.

— Бәлки сез безне озатып кына куярсыз үзегезнең кышлауга хәтле?

— Атларны кем карар минем өчен?

Баймурзин чынлап торып куркуга төште. Болай булса, барлык өметләре, корган планнары челпәрәмә киләчәк бит.

— Сездән башка тагын берәр кеше бармы сезнең кышлауны белүче.

— Безнең кышлауны бары өч кенә кеше белә иде. Аларның берсе мин, икенчесе Нәби, өченчесе Кутафин иде. Кутафин юк. Нәби фронтта. Бүтән безнең кышлауга юлны белүче кеше юк.

— Безгә нишләргә соң инде алай булгач? — диде Баймурзин. Аның борчылуы йөзенә чыккан иде.

— Ярар, иртәгә предколхоздан бер-ике кичкә ял бирүен сорап карармын. Сазга хәтле озатып куйсам, калганын минем сызымнан үзегез дә табарсыз.

— Рәхмәт, Абу баба.

— Рәхмәт әйтергә ашыкмагыз әле. Иртәгә предколхоз ни дияр бит. Әле үземнең урынга калып торырга кеше дә табасы бар. Ярар, вакыт соң, йокларга кирәк. Иртәгә күз күрер,— диде Абу баба.— Әнә, малаең янына ятарсың. Хәерле йокы.

Аннан Абу баба, каңсасын кабызып, ишек янындагы агач караватка, үзенең яраткан урынына барып ятты. Ятказ та әле тиз генә йоклап китә алмады. Николай Фомич турында уйланды. Югыйсә, Абу бабага караганда шактый яшь иде бит әле, әнә ничек бит ул гомер дигәнең.

Кайчан, ничек үләсеңне белмисең. Бер осечка башына җиткән бит. Күпме тапкыр аюга бер ялгызы йөреп, күпме аю атып, нинди генә кыен хәлләрдән исән-сау котылып, уйламаганда гомерең өзелә дә куя. Һарун да болай әйбәт кешегә охшый. Николай Фомич начар кешене тәкъдим итмәс. Тик менә Абу бабаны шикләндергән бер әйбер бар. Сорарга уңайсыз. Кем соң этсез тайгага ауга чыга инде.

Кичен озак утырсалар да, Абу баба гадәте буенча иртән уянды. Стенадагы сәгать нәкъ алтыны күрсәтеп тора иде. Ул, кунакларны уятмаска тырышып, сукыр утны кабызды, мичкә ягарга тотынды. Өй эче төнлә суынган иде. Аннан тәрәзәгә ябырылып урамга текәлде, ләкин берни күрмәде. Кичен эрегән тәрәзәләр яңадан боз белән капланганнар. Шулай да урамда буран басылганга охшый иде, җил улаган тавыш та ишетелми. Ничек кенә уятмаска тырышып караса да, барып чыкмады. Баймурзин торып утырды. Абу баба гафу үтенгән сыман әйтеп салды:

— Сезгә йокы бирмәдем ахры.

— Юк, мин үзем уяндым.

— Йоклагыз. Әле бик иртә бит.

— Бер уянгач, кабат йоклый алмыйм мин.

Аннан бергәләп тәмәке кабыздылар.

— Мин озак тормам, берәр сәгатьтән кайтырмын,— дип киенеп урамга чыкты Абу баба.

Абу бабаның өе иң кырыйда булганлыктан, бу якка үтүче кеше эзләре юк иде. Буран тынган, тып-тын. Кайбер өйләрнең тәрәзәләреннән яктылык сибелә. Авылга кергәнче Абу бабага тез тиңеннән кар ерып барырга туры килде. Авыл эченә кергәч кенә кеше үткән эзләр күренгәли башлады. Монда кар да юкарак иде. Эзләрнең барысы да ферма ягына таба киткән. Димәк, бүген Абу бабадан алданрак торучылар да бар икән. Абу бабаның башында бары бер генә уй иде. Каравылчы Ариф карт өенә кайтып китмәгән булса гына ярар иде. Абу баба ферма йортына килеп кергәндә, Ариф карт өенә кайтырга җыенып ята иде. Ул исәнләшеп-нитеп тормастан сүзгә күчте:

— Әз генә сабыр итеп тор әле, Ариф, сөйләшәсе сүзем бар иде.

— Нәрсә булды соң?

— Берни булмады. Минем урынга бер-ике көнгә калып тора алмассың микән. Атларны Вәлиш улым сугарыр. Син печән салырга гына ярдәм итәрсең.

— Ә син кая китәсең?

— Күрше районнан аучылар килгән иде. Тайгага юлны белмиләр. Аларны сазга хәтле озатып куярга кирәк иде. Я, карап торырга ризамы син? Риза булсаң, мин предколхозга әйтермен.

— Ярар. Түлке озак йөрмә, яме. Тизрәк кайтырга тырыш. Ике көнгә генә риза булам,— диде.

Абу бабага артык кирәк тә түгел иде. Беренче көнне үк алар сазга барып җитәчәкләр, һәм Абу баба ул көнне Үзенлеккә [1] кайтып куначак. Икенче көнне фермага кичке печәнне салырга өлгерәчәк.

Абу баба чыгып китү белән үк Баймурзин малае Зөфәрне уятты. Бер үк вакытны мич түбәсендә йоклап яткан Вәлиш тә уянды. Ул мич түбәсеннән, йоклаган булып, тегеләрне күзәтеп кенә ятты. Әз-мәз курка да иде.

Баймурзин белән малае Зөфәр торып ашыга-ашыга киенделәр дә, әле берсе, әле икенчесе тышка чыгып кергәләделәр — тынычсызланалар иде. Атасы малаена гел нәрсәдер пышылдый. Әллә ачулана, белмәссең.

Байтак вакыт үткәннән соң гына Абу баба кайтып керде. Кунаклар, бигрәк тә Баймурзин, тынгысыз карашларын аңа текәделәр. Ни әйтер Абу баба кунакларны тынычландырырга ашыкты.

— Булды. Ике көнгә рөхсәт иттеләр. Борчылмагыз, бар да әйбәт

[1] Үзенлек — авыл исеме.

булыр. Хәзер чәй эчеп алабыз да юлга кузгалабыз,— дип, чәй ясый башлады. Аннан Вәлишне уятырга дип, мич түбәсенә үрелгән иде, аның уяу икәнен күргәч:

— Уяндыңдамыни, балам. Әйдә, ашарга төш. Аннан без китәбез. Мин менә бу кунакларны сазга хәтле озатып киләм. Берсекөнгә генә кайтачакмын. Ә син, үзең өйдә кунарга курыксаң, Ариф бабаң янында кунарсың, яме. Атларны сугарырга булышырсың.

— Ярар, бабай. Тик атларны сугарырга төшкәндә кара айгырга менәргә ярыймы?

— Курыкмасаң, менәрсең.

— Курыкмыйм!.

Вәлишнең шатлыгы эченә сыймады. Кара айгырга мену үзе бер бәхет. Авылда малайлардан кемнең кара айгырга атланып йөргәне бар. Предколхоздан башка беркемнең дә юк. Эх, кара айгырда, авыл малайларын көнләштереп, урам буйлап бер чаптырып үтәсе иде!..

Чәй эчеп алганнан соң юлга җыена башладылар. Абу баба бер бит кәгазь алып, сазга төшкәннән соң кая, ничек барасын күрсәтеп, сызым сызарга утырды. Юл дип, кышлауга барасы бернинди юл юк иде. Бары тик кайсы утраудан кайсы утрауга һәм анда нинди тамгалар булуын гына күрсәтеп бирергә кирәк. Ансыз, тайгада йөреп, нинди генә шомарган булсаң да, таба алмаячаксың. Юл планын сызып бетергәннән соң Баймурзинга аңлатып тормады Абу баба. Сызым сазга төшкәч кенә кирәк булачак, һәм шунда җиткәч аңлатыр ул аны.

Баймурзин малае белән күптән киенеп алганнар һәм түземсезлек белән Абу бабаны көтеп торалар иде.

Абу баба аягына бүре тиресеннән тегелгән унтысын, өстенә куй тиресеннән тегелгән тунын, башына бүре тиресеннән тегелгән бүреген киде. Биленә патронташлы каешын бәйләде һәм, стенадан уналтынчы калибрлы мылтыгын алып, урамга чыкты. Мондый юлга мылтыксыз чыгу үлем белән бер. Бүреләргә юлыгуың бар. Барганда ярар, алар өчәү, ә кайтканда Абу баба бер ялгызы булачак бит. Дөресен генә әйткәндә, Абу баба мылтыксыз беркая да чыкмый иде.

Вәлиш тә, өс-башын киенеп, аларны озатырга урамга чыкты. Урамда исә караңгы тынлык иде. Бары ак кар гына аз-маз агарып күренә. Ишек алдына биек көрт өелеп куйган.

Абу баба табаны болан тиресе белән капланган җиңел, ауга йөри торган киң чаңгысын киде, планын Баймурзинга аңлатып бирде:

— Сазга хәтле моннан унөч чакрым,— диде.— Урыс Козоклысына хәтле өч чакрым, аннан Үзенлеккә биш чакрым. Үзенлектән сазга хәтле биш чакрым. Әгәр сәгатенә уртача өч чакрым барсак, примерно сәгать уникеләрдә сазда булабыз. Һәм мин сезне озатам да кире Үзенлеккә кайтып кунам. Иртәгә авылга кайтып керәм.

Абу баба бу сүзләрне аучыларга түгел, үз-үзенә сөйли иде кебек.

— Әйдәгез, аллага тапшырып, кузгалыйк. Юл кешесенең юлда булуы хәерле,— дип, Абу баба кунакларны кар сырып, күмеп киткән юл белән түгел, туп-туры авыл читеннән үк Иртышка алып төшеп китте. Иртыш белән Урыс Козоклысы күренеп тора, туп-туры. Аннан Иртышта кар да юка, барырга да җиңел иде. Юлда сүзсез, тавыш-тынсыз гына бардылар. Урыс Козоклысын үтеп, Үзенлеккә килеп җиткәндә генә көнчыгышта офык яктыра башлады. Соңгы елларда Абу бабаның ерак юлга чыгып йөргәне булмаганга Үзенлеккә килеп җиткәнче шактый арыды, тамак төпләре кипте. Үзенлектә бераз ял итеп, берәр стакан кайнар чәй эчеп үтмичә, хәл кермәячәк иде.

— Һарун, монда минем Нәби энемнең хатыны яши. Хәтерегездәме, аучы Нәби турында сөйләгән идем. Хәзер ул фронтта. Үзе теләп, добровольно китте. Бронь биреп калдырганнар иде югыйсә.

— Әйе, хәтерлим, Абу баба.

— Хатыны өйдә булса, әзрәк ял итеп, чәй эчеп алсак начар булмас иде, дим. Картлык җитте ахры миңа да. Арыдым.

— Ярар, Абу баба. Тик озак утырмасак ярар иде,— дип кенә әйтә алды Баймурзин. Аның туктап һич кенә дә вакыт үткәрәсе килми иде. Ләкин Абу бабаның сүзенә буйсынмыйча чарасы да юк иде.

Үзенлек авылы Қозоклыга караганда кечкенәрәк булып чыкты. Күп булса егерме биш, утыз хуҗалык бардыр.

Нәби аучының ишегалдына килеп кергәндә, хатыны Гөлмәрьям курадан сыер савып чыгып килә иде. Абу бабаны күрү белән үк танып алды. Ят кешеләр бар дип тартынып-нитеп тормады. «Абу баба, исәнме, нинди җилләр ташлады безнең якларга?» — дип кочаклашып күреште, калганнары белән болай гына исәнләште дә өйгә керергә кыстый башлады.

— Әйдәгез, хуш килдегез. Хәзер мин чәй куеп җибәрәм. Ачыккансыздыр,— дип чиләкле сөтен күтәреп, өенә кереп китте.

Абу баба юлдашлары белән өйгә кергәндә, тимер мич өстендәге чәйниктә чәй кайнап утыра иде инде, өй эче пөхтә, җылы. Гөлмәрьям чәчәкле ситсы күлмәктән, башында шулай ук чәчәкле яулык, өстәлгә табын хәзерләп йөри. Иң кечкенә малае (Абу баба аның исемен дә белми иде) урындыкта ашыклар[1] белән уйнап утыра. Ят кешеләр килеп кергәч, ашыкларын күлмәк итәгенә җыеп, тын-тын гына карап утыра башлады.

— Бу өченчегез буламы? — дип сорады Абу баба, малайга күрсәтеп.

— Әйе. Сугыш алдыннан туган улым.

— Өлкәннәр кая соң, күренмиләр?

— Мәктәптә. Кызым Алсу өченче класста, улым Алим быел беренчегә керде.

Аннан барысы бергә чәй эчәргә утырдылар. Өстәл өстенә куелган ашамлыклар сугыш вакытына карата бик сирәк кешедә була торган үзе бер байлык иде. Яңа савып кергән сөт дисеңме, сары атлан май дисеңме, катык, бәрәңге, тагын әлләниләр бар иде өстәл өстендә.

— Ярыйсы гына яшисез икән, килен,— диде Абу баба, өстәл өстендәге ризыкларга күрсәтеп.

— Әлегә ярыйсы гына. Нәбинең калдырып киткән запасы булмаса, авырга туры килер иде. Икмәк ул хәтле мул булмаса да, сөт белән бәрәңгедән өзелгәнебез юк.

— Хат киләме соң үзеннән? Ниләр яза?

— Исән-сау дип яза, снайпер икән. Үзең ауга йөрисеңме соң?

— И-и килен, кая инде миңа тайгага йөрү. Монда хәтле дә көч-хәл белән килеп җиттем әле. Менә болар булмаса,— ул юлдашларына ымлады,— эшемне ташлап, беркая кузгалмый идем.

Баймурзин белән малае, чәй эчеп беткәнче, бер сүз эндәшмәделәр.

Чәй эчеп алгач, Гөлмәрьямгә рәхмәтләр әйтеп, киенә башладылар. Абу бабаның әле тагын бик күп сөйләшәсе сүзләре бар иде, юлдашлары киенә башлагач, ул да өстәл артыннан торырга мәҗбүр булды.

— Утырыгыз тагын әзрәк кенә, кая болай ашыгасыз, Абу баба,— диде Гөлмәрьям аптырап.

— Мин, килен, бүген сезгә кунарга килермен. Бу иптәшләр күрше Яулы Тора районыннан. Аучылар. Безнең дус Кутафинның танышлары икән. Миңа ярдәм сорап килгәннәр. Мин аларны үзебезнең кышлауга озатырга булдым. Барыбер хәзер анда беркем юк. Сазга хәтле озатып куям да кире борылам. Караңгы төшкәнче кайтып җитәрмен.

Гөлмәрьям бакча башында басып торган килеш карап калды. Сугышка хәтле Гөлмәрьям елның елында Абу баба белән ире Нәбинең, нартага этләр җигеп, тайгага чыгып китүләрен шулай карап кала торган иде.

Көн аяз, салкын. Кояш офыктан аз гына югары күтәрелгән, ике-өч сәгатьтән кире тәгәрәп китәчәк. Ял итеп, чәй эчеп алгач, Абу бабага

[1] Ашык (себер тат.) — сарыкның тез сөяге.

хәл кереп, күңеле күтәрелеп китте. Ләкин сазга хәтле әле биш чакрым барырга, тагын биш чакрым кире кайтырга кирәк. Барлыгы ун чакрым. Бу, әлбәттә, Абу баба өчен аз ара түгел.

Үзенлектән чыгу белән, Абу баба Зөфәрне алга куйды.

— Әйдә, Зөфәр улым, син безгә караганда яшь тә, көчең дә күбрәк, чык алга. Юл ярып барырсың безгә.

— Мин юлны белмим бит, Абу баба,— дип әйтеп салды Зөфәр үзенең беркатлылыгы белән.

— Уңгамы, сулгамы, кая икәнен мин сина әйтеп барырмын.

Алар, бер-бер артлы тезелешеп, урман эченә кереп киттеләр. Иң алдан Зөфәр, аннан атасы, арттан Абу баба бара. Әзер юлдан барып, Абу баба Егаер елга башына барып җиткәннәрен сизми дә калды. Үзе әллә ни арымады да кебек. Егаер елгасы саздан агып чыга, саздан башланып китә иде. Сазга төшкәч, урман бетеп, вак агачлар башланды. Тагын ике йөз метрлап барганнан соң, вак агачлар да бетте. Кая карама, тип-тигез кар болыны җәйрәп ята. Арырак күгәреп утраулар күренә. Ерактан караганда алар барысы бергә тоташ бер урман кебек күренәләр иде.

— Менә килеп тә җиттек. Хәзер инде юлны минем сызым буенча үзегез дә таба аласыз. Сез, Һарун, тайгада беренче көнегез түгел, адашмассыз дип уйлыйм. Иң беренче әнә теге утрауга, туп-туры барыгыз. Анда уңдарак егылган коры нарат агачы булырга тиеш. Ул тим алгыч[1] дип атала. Аннан ары, сызымда күрсәткән буенча, уң кулдарак зур бер утрау булыр. Аңа бер дүрт чакрымлап бар. Анда кечкенә генә бер избушка тора. Шунда кунарсыз. Ә иртәгә кышлауга барып җитәрсез.

— Ярар, Абу баба, бик зур рәхмәт сезгә,— дип, Баймурзин аңа кулын бирде. Аннан улы Зөфәр килеп саубуллашты.

— Хәерле юл сезгә, Һарун улым. Уңышлар телим. Язын кайтышлый миңа керми үтмәгез, яме. Ату үпкәләрмен,— диде Абу баба елмаеп.

Инде саубуллашса да, Абу баба кайтып китәргә ашыкмады. Бер сүз дәшми генә офык буйлап сузылган кара-күксел тайгага карап торды. Менә аның каршысында гына җәйрәп ята бит ул! Кире өйгә кайтмыйча, туп-туры кер дә кит. Яшьлектә сөйгән ярың кебек үзенә чакырып тора. Гомереңнең иң бәхетле минутлары миндә үтте дия кебек. Әллә онытыңмы? Килгәнсең икән, кире борылма, кил, кер минем кочагыма, дип чакыра шикелле.

Абу бабаның күңеле томанланды, күзләре яшьләнде, бөтен гәүдәсе буйлап хәлсезлек йөгереп үтте. Гүя ул гомер юлдашы белән мәңгегә саубуллаша. Әйе, тайга гомер буе Абу бабаның юлдашы булды. Әгәр дә арттан Баймурзинның тамак кырганы ишетелмәсә, әнә шулай, балбалга табынган кебек, ул әле тайгага карап тагын күпме басып торган булыр иде, кем белсен. Туган иленнән, сөйгән ярыннан аерылу кешегә ничек кыен булса, Абу бабага да тайгадан аерылу кыен иде. Бүтән килмәячәгенне, бу күрүең инде иң соңгысы булуын белеп аерылу авыр иде. Аннан Абу баба кайтыр юлга борылды. Хәзер инде тапталган юлдан Үзенлеккә бик тиз кайтып җитәчәк. Гөлмәрьям килен дә көтә торгандыр, дип уйлады.

Абу баба, кайтыр юлга борылып, ун метрлап киттеме, юкмы, арттан гөрселдәп мылтык шартлады. Абу бабаның сул як кулбашыннан аскарак нәкъ йөрәгенә кургаш кисәге үтеп керде. Бу аюга дип корылган кургаш иде. Абу баба шундук егылмады, артына борылып карарга көче җитте. Баймурзин мылтыгын кулында тоткан килеш Абу бабага карап тора иде. Абу баба нәрсәдер әйтергә теләгән иде дә, тавышы чыкмады һәм ул, аңын югалтып, кәфен сыман җәелеп яткан ап-ак карга ауды.

Абу баба аларның сугыштан качып йөрүче дезертирлар икәнен белми үлде.

---

[1] Тим алгыч (себер тат.) — сазда, тайгада ял итеп ала торган урын.

# СЕРГЕЙ МИХАЛКОВКА 70 ЯШЬ



*Күренекле рус совет язучысы — балаларның сөекле шагыйре, мәсәлче, драматург һәм публицист. Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе Сергей Владимирович Михалковка 70 яшь тулды. С. Михалков әдәбият сөючеләргә «Степа абый» кебек бик күп шигырьләре, «Фитиль»дәге үткен сатира әсәрләре, пьесалары, ялкынлы мәкаләләре аша яхшы таныш. Күп санлы журнал укучыларыбыз исеменнән әдипне зур юбилее белән кайнар котлап, бу санда без аның иҗатыннан кайбер үрнәкләр — балалар өчен шигырьләр һәм мәсәлләрен тәкъдим итәбез.*

## Сергей Михалков

### Тынычлык

Җыела өйгә кунаклар:
Женяның туган көне.
Женяның зур юбилее —
Сигез яшь тулган көне!

Алып килгәннәр бүләккә
Пистолет һәм автомат,
Кылыч, мылтык һәм пулемет —
Теләгәнчә ат та ат!

Көтә дә малай бүлмәдән
Кунакларның чыкканын,
Ыргыта сүтеп, ботарлап
Бөтен уенчыкларын.

Ә кунаклар кала телсез,
Йөзләрендә — сызлану.
Женя көлә: «Борчылмагыз!
Бу бит — коралсызлану!»

## Кызылтүш

Мәктәптән соң мин бүген
Соңгарак калып кайттым.
Мин кошлар базарыннан
Кызылтүш алып кайттым!

Кызылтүш — шундый матур,
Тавышы — шундый көчле:
Сайрап җибәрде кошым
Нәкъ урмандагы төсле!

Сайрар әле кызылтүш
Күзләрен-кышларын да.
Сайраганын күрергә
Килделәр дусларым да.

Туйдырды ла кызылтүш
Ике атна дигәндә.
Тыңлыйм хәзер мин аны
Бары вакыт тигәндә.

Ә бервакыт шәһәрдән
Китеп тордым өч көнгә.
Ялгызына калырга
Туры килде мескенгә.

Мин югында кызылтүш
Чак-чак кына үлмәгән:
Ашарына беткәчтен,
Ни ашарга белмәгән.

Сыйладым бөртек белән,
Сыйладым җим биреп тә.
Туйганчы су эчердем
Һәм очырдым иреккә!

Өйдә миңа: «Син безнең
Төпчек балабыз! — диләр.—
Синең туган көнеңә
Көчек алабыз!» — диләр.

Ә мин әйтәм: «Алыгыз!
Тик әле хәзер түгел!
...Аны тәрбияләргә
Мин әле әзер түгел!»

## Булдыксыз

«Бик булдыклы булалар
Тик талантлы балалар:
Концертта катнашалар,
Җырлый-бии алалар.

Әгәр дә матур сурәт
Ясасалар балалар,
Журналда бастыралар,
Күргәзмәгә алалар.

Турнирга, конкурска
Чит илләргә баралар,
Күпме бүләк алалар
Тик талантлы балалар.

Лисичкина Наташа
Җиңүче — һәр ярышта!
Гарик исә — лауреат!
Җиңелми бит ялгыш та.

Булдыксызларга гына
Бөтен юллар ябылган...»
Шундый сүзләр сибелә
Миңа әни ягыннан.

Каршы килмим, сөйләшмим,
Иң әйбәте — эндәшмим.
Бу күңелсез темага
Мин бер дә бәхәсләшмим.

Әйдә, башка балалар
Түгәрәккә йөрсеннәр,
Рәсемнәр төшерсеннәр,
Хәтта җырлый белсеннәр.

Скрипка уйнасыннар,
Кинода уйнасыннар,
Үзләрен бик талантлы
Кеше дип уйласыннар.

Мин беләм кем булырга!
Мин югалмам кайда да:
Үсеп җиткәч бер көнне
Китәчәкмен тайгага.

Әле дусларымны да
Тайгага алачакмын.
Алар белән бергәләп
Тимер юл салачакмын.

Рельс буйлап поездлар
Кош кебек очар әле.
Мин төзегән тимер юл
Әнигә ошар әле!

Мине бик оялтса да,
Әнидә — әйбәт теләк.
Тик төзүче җырчыдан
Барыбер кирәклерәк!

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәләре.

## Арыслан һәм ярлык

мәсәл

Иртән торган да Арыслан, җене чыгып,
Тотынган ди үкерергә, җикерергә:
«Бу ярлыкны койрыкка кем тагып киткән? —
Табарга һәм тотып бире китерергә!
һе... Ярлыкка: «Ишәк» — диеп язганнар бит,
Имзасы бар, мөһере бар, датасы бар! —
Өзеп кенә атар идең бу нәләтне,
Документ бит — соңра җавап тотасы бар...
Бу хурлыктан закон мине коткарсын!» — дип,
Ул җәнлекләр җыенына килде кызып:
«Мин — кем? — ди ул.— Арысланмы, түгелме?» — ди.
Әйтте Шакал: «Әйе, эһем, кызык, кызык...
Син Арыслан инде болай бер карасаң,
Ә юридик яктан килсәк — гади ишәк!»
«Ни сөйлисең? Синең кайчан күргәнең бар
Торганымны салам, печән ашап... Хәшәп!
Көңгерәдән сорыйк әнә, әйтсен иптәш,
Яхшы белергә тиеш ул кемлегемне!»
«Арыслан да кебек инде...— ди Көңгерә.—
Нәрсә генә әйтергә дә белмим инде...»
Тәмам ярсып китте шулчак Арысланбай:
«Ә син нәрсә, су каптыңмы, Ишәк тәре?!
Хәтерләтәм мени соң мин абзарларга
Кереп йоклый торган хәсис ишәкләрне?!»
Башын иеп уйга калды шулчак Ишәк
һәм әйтте ул әллә нигә күңле тулып:
«Син Арыслан түгел инде... Әмма ләкин
Җитмәгәнсең әле син чын ишәк булып!»
Ялынды да, ялварды да Арысланбай,
Җәнлекләрнең һәммәсен дә кузгатты ул,
Аңлатты да, янады да, елады да,
Бүре белән Шакалга да сүз катты ул.
Кызгандылар аны хәтта кәҗәләр дә,
Уфтандылар хәтта мескен сарыклар да.
Тик Арыслан — ник Арыслан булсын икән
Койрыгында «Ишәк» дигән ярлык барда?!
Арысланның төсе китте, сызды-кипте...

Сөйләделәр: инде тәмам ычкынган, ди:
Бүген иртән, өннән башын тыгып кына,
Нәкъ Ишәкчә: «И-а-а!» диеп кычкырган, ди.

Бу мәсәлдән чыга бары
Тик бер вәгазь:
Арысланнарны да бөгә
Кайбер кәгазь!

## Нәзберек Мияубикә

мәсәл

Чибәр кызый
Мияубикә
Мырлый-мырлый
Кияүгә кияү кетә.
Күп эзләде, гаҗиз булды, башы катты —
Тапмады ул кияүлеккә кандидатны.
Ничек кенә бармак кирәк шул ЗАГСка:
Берсе — юан, берсе — пеләш, берсе — кыска.
Берсе — тычкан ашаганны гаеп итә,
Берсе — күселәрне күрсә качып китә.
Бу мыеклы чибәреннән куркып торам —
Яман көнче диеп сөйли бөтен урам.
Ә тегесе — аты чыккан ялкау икән,
Көне-төне мич башында ята икән!
Мияубикә:
«Мияу!» — ди,
«Мияу!» — дими —
«Кияү!» — ди.
Ары чапты Мияубикә, бире чапты.
Һәм беркөнне ул... берничә бәби тапты.

...Ул көн шактый Мырауҗаннар,
Качып-посып,
Өйдә генә утырганнар
Койрык кысып...

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәләре.

## Нурия Измайлова

### Сүз

Яши миндә таудай зур сүз —
Телгә салып ничек әйтим?
Яши миндә бик авыр сүз —
Селтәп кенә ничек атыйм?
Ул шулкадәр газаплы сүз —
«Әйт!» дип җан сызлата торган.
Ул шулкадәр җаваплы сүз —
Әйтсәң, кире кайта торган.
Ул — тешле һәм тырнаклы сүз,
Тисә, каты яралар күк.
Ә шулай да кирәкле сүз —
Аңлардайлар аңларлар күк.

Аңлардайлар аңлар кебек,
Күрердәйләр күрер кебек
Үрә карап йөргәннәрне
Күзгә салкын пәрдә корып,
Янгынны да читләп узып,
Кычкырмыйча «әдәп саклап»,
Үтеп китә алганнарны
Төп-төз атлап, намус таптап.
Калын пәрдә аша да мин
Ул күзләрдә коллык күрәм —
Коллар гына карый алыр
Шундый битарафлык белән!

Әй табигать! Синдә ни юк?
Юк синдә тик битарафлык.
Күкнең — җиргә, җирнең — безгә
Карашында — наз һәм шатлык.
Сүнмәс мәхәббәтең белән
Үлемсез син, яшь һәм көчле!

Битарафлык — ул көчсезлек,
Ул — картлык, үлем билгесе.

Кодрәтеңнән бир бер тамчы,
Мин ялварам сиңа, Кояш!
Ач син безгә боздан эрү,
Гел яшь булу серләрен ач!
Боз эресә күзләрендә,
Битарафлар күрә белер,
Җәлләп адәм балаларын,
Шәфкатьле яшь түгә белер.
Кул җылытыр өчен генә
Утлар төртмәс инде алар,
Җыеп кеше балаларын,
Утка кертмәс инде алар.
Уйлый белер җиргә туган
Һәм туачак балаларны,
Безгә тигән байлыкларда
Аларның да хакы барны.

О, ул кадәр якты уйдан
Балкып торыр бар Җир шары!
Тик, уйлана белсен өчен,
Нишләтергә тираннарны?!
Битарафның уе нурсыз...
Коллар да бар, тираннар да —
Туңам җирдә алар барга...
Нәфрәтле һәм ачы сүзем
Гомер буе шушы хакта.
Әйтәлдемме меңнән берсен
Кояшка ялварган чакта?..

### Юл — тик алга

Үз өеңдә үз күзләрең
Ишек тапмый йөри.
Киләчәккә киткән уйлар
Кайта — юлны белми.

Яңа ишек тишәр идең —
Эшең төшә кулдан.
Өр-яңадан юл башларга
Теләк тә юк сыман...

Бу вакытлы фаҗиганы
Кемнәр кичермәгән!
...Бәхетленең үткәннәргә
Юлы киселмәгән.
Анда аның эчәр суы,
Ашар икмәге бар.
Сагыныр кеннәр, сыеныр куллар,
Аһ! дип көткәне бар.
Зарын онытып, ул бәхетле
Хыял көймәсендә
Үткәннәргә кайтып егылыр
Йөзеп күз яшендә.
Мин бәхетсез: үткәннәрдә
Сыеныр почмагым юк.
Кире тартып кайтарырлык
Сулар эчкәнем юк.
Юл тик алга! Юл башларга —
Сагынып искә алырлык,
Үзең үткән адымнарга
Үзең сокланырлык!

## Чүл генә белә...

Син һаман минем төшләрнең
Иң татлысында.
Гел ләззәт кенә ул төшләр,
Гел шатлык кына.
Гел дулкынланулар гына,
Гел оялулар.
Киләм диеп килми калып,
Күрми калулар.
Аннан соң эзләп йөрүләр
Таңнарга чаклы.
Тик мәңгегә югалту юк!
(Уянгач ансы...)
Ә уянгач — буш күңелдән
Сине табалмау.
Назлы сагыну диңгезендә
Дулкынланалмау.
Уй белән дә, хис белән дә
Үткәнгә кайтмау.
Ә күңелдә чүлдәй чиксез
Зур бушлык саклау.
Кибә күңелем коры чүлдә!
Нишләргә икән?!
Күңел тулып ташып чыга,
Төшләргә керсәң!
Төштә диңгез була күңел,
Көн туса — кибә...
Диңгезгә әйләнгән чүлләр
Бар микән җирдә?
...Диңгез, диңгез, ешрак кер син
Чүл төшләренә.
Диңгезле төшләр кадерен
Чүл генә белә...

●

Күпме йөртелде хыялда,
Күпме көтелде!
Килде шаулап, килде купшы,
Ләкин соң килде —
Яңа ел үткәч бизәлгән
Чыршы шикелле...
Ах, бу бәхет!

## Энҗе Мөэминова

### Язмышлар

●

Еллар аша киләчәккә карап,
Үткәннәргә барлау үткәрдем:
Киләчәктә — оныкларым бәхете,
Үз бәхетем минем — үткәнем.

### Ике язмыш

Табынымда муллык ташып тора!
Муллык бөтен тирә-ягымда.
Мин шатланып бетә алмыйм шуңа...
Үткәннәргә борылып карыйм да
Уйга калам... Экрандагы кебек,
Күз алдыма килә үткәннәр.
Аннан кабат бүгенгегә кайтам —
Озак калып булмый үткәндә!
Чагыштырып карыйм — ике чорның
Үтә таныш ике язмышын.
Колак салып тыңлыйм ике чорның
Үтә таныш ике тавышын.

Беренче тавыш:

«Минем әче язмыш күчә сине,
Бәхетсезем минем, кыз бала!—
Сан юк, балам, сиңа дөньяда...
Ир хатыны, кол һәм курчак булу —
Синең котылгысыз язмышың.
Ә язмыштан узмыш бармы соң?!»

Икенче тавыш:

«Алло, алло, Җир! Җир! Тыңла мине!
Мин космоста бүген! Космоста!!!
Алло, алло! Ватан! Кабул ит син:
Сәлам юллый кызың космостан!»

Колак салып тыңлыйм, чагыштырам
Ике чорчың ике тавышын:
Колны кеше иткән Көрәш юлын
Дәлилләүче ике язмыш бу!

## Балалар

Балаларны яуланасы үрләр көтте:
Чирәм җирләр, Космос,
КамАЗ, БАМнар,
Себер нефте...

## Тарих кайтавазын ишетәм

Таң алдыннан, шаулап, гөр килешеп,
Яшьләр үтте олы урамнан.
Кайтавазлар булып җавап бирде
Болын-кырлар, яшел урманнар.
Бу — аларның бергә урам буйлап
Узулары — соңгы кабаттыр:
Аттестатлы яшьлек хыяллары
Төрле якка тиздән таратыр.
Алар өчен әле тарих үзе —
«Үткән заман» дигән төшенчә.
Ә мин һәр ел менә шушы көнне
Тарих кайтавазын ишетәм:
— Кырык беренче ел. Июнь. Егерме ике...
Онытмадыгызмы кешеләр?
Онытмадыгызмы?!—
Шушы сүзләр яңгырагандай була
Алсуланган офык читеннән.
Һәр ел саен шулай... һәм бүген дә
Яшьләр үтте, чишмә ашкынгандай,
Кушылырга олы инешкә.
Мин үткәнгә киттем...
Алар әле бары киләчәкнең
Чакыру авазларын ишетә.

## Хакы бар шул

— Чаллыгамы?
— Әйе.
— Без дә шунда. Утырыгыз әйдә. Барабыз.
Үз машинам. Кунакка дип чыктык.
Улыбыз шунда. Төпчек балабыз.
Биш балабыз иде. Таралдылар.
Бүген менә калдык икебез.

Пенсиядә. Тормышыбыз җитеш.
Яшәп була шартын китереп.
Оҗмахтагы кебек. Барсы да бар.
Кадерен генә белеп яшисе.
Дөрес бит, әй! Әллә су каптыңмы?
Ник дәшмисең әле, әнисе?!.
— Мактанырга дисәң, ясап куйган!
Тыңлар кешең булса әгәр дә,
Көне буе сөйләп торыр идең...
— Сөйләсәм ни!
Кунак булып барабыз бит, карчык,
Герой улыбыз төзегән шәһәргә!
Орден, медальләрне әллә бүген
Юкка тактыммы мин, күрсеннәр!
Улы атасыннан өзелеп төшкән,
Шуңа батыр булган дисеннәр.
Мактанырга, карчык, чутым бар.
Берлиннәрдән җиңеп алып кайткан
Орденнарны тактым мин шуңар!
Алтын йолдыз таккан улың бүген
Чыгып бассын әле каршыңа!—
Синең белән мине каршылап.
Аңлыйсыңмы шуны, карчыгым?
...Мактанырга, әйе, хакы бар шул
Ап-ак чәчле авыл картының!

# Асия Минһаҗева

## Биогамма

Кем геннары тынгы бирми миңа,
Кем хисләре көйләп эндәшә?
Дулкын тота күңел локаторы,
Биотоклар нидер сөйләшә.

Ультракыска тирбәнештә килә
Миңа дигән күңел сагышы...
Бик аз ялга рөхсәт алса хыял,
Өнсез ялгызлыкка сабышам.

Бер яналар, бер сүнәләр утлар —
Инфракызыл, яшел, миләүшә.
Төсле музыкадай алчак җаным
Гүя дөнья белән киңәшә.

...Җир — тумыштан бер формасыз гына
Гади күзәнәкле башмакчык.
Булдыралсаң, челпәрәмә китер,
Чиксезлекнең чиген атлап чык!

Без килмәгән булсак табигатькә,
Кеше калыбына салынып —
Кайтыр идекмени үткәннәрдән
Җирнең тарту көчен сагынып.

...Кем күзләре тынгы бирми миңа,
Ныклап сынап карый, күзәтә...
Шуңа гына тәңгәл килермен күк —
Кем йөрәген җыеп сүз әйтә...

## Бармакларың

Сиңа язган шундый язмыш: бармакларың
йөз сызыкларын сыйпамый да
тоярга тиеш.
Күрергә тиеш бары бармакларың.
Югалтмаска тиеш күңел тармакларын.
Ишетергә тиеш бармакларың гына:
көйнең дә җитезен түгел, салмакларын гына:
үткәрергә тиеш аралап;
Җаның бары шуның белән яралап,

өзгәләнгән күңелеңне
уздырырга тиешсең син
бармакларың аша.
Хисең түгел, бармакларың шаша!
Ахры, саташа...
Газапларың тамып бармак очларыннан
әверелә сылу кызга,
җыерчыклы гаҗиз йөзгә;
әверелә көйгә,
сабыр, тыныч гаиләле өйгә...
Син бармакларың белән коясың
бөек Яралышны!
Тудырасың мәңге җанга сусап
яшәячәк кешеләрне!
Сикереп төшеп рәхмәт әйтәлмәс,
узалмас өнсезлек чиген
шуларның берсе!
Озайтасың безнең өлешкә
саран тигән Яшәешне,
Син — игелекле, изге хисле...
Шуның өчен — әле икебез дә исән чакта,
әле икебез дә әверелмәгәндә
салкын ташка,
бирче, үз вакытында
Баш куйыйм кулларыңа:
исәнлекләренә сәҗдә кылып,
берәм-берәм тидерим иренемне
тере ун бармагыңа!

## Вакыт

Яшәү мәңге булыр иде,
Вакыт кына туктата.
Күз йоммыйча йөрер идең,
Вакыт тотып йоклата.

Мең елны гасыр итәрлек
Сәбәпләрне тапканнар,
Кешелеккә, вакыт бүлеп,
Сәгатьләрне такканнар.

«Шундый вакыт килер!» —
диеп,
Өметләнеп көткәннәр.
Вакыт җиткәч, әллә кемнәр,
Әллә кемнәр киткәннәр...

Вакыт — талант. Әлләниләр
Тудырырга сәләтле,
Булса да тик безнең өчен
Егерме дүрт сәгатьле!

Кайчакларда җитмәгәнгә,
Туктатырга теләсәк...
Туктар да вакыт... Тик ансыз
Ни эшләр соң киләчәк?

Шуңа әнә катып калып
Искәртергә теләгән
Хиросима бомбасыннан —
Күпердәге күләгә...

## Кирәкми!

Бу болытлар болыт түгел инде,
Сугыш җиле илләр иңләп йөри.
Болыт түгел, атом яңгыры бу,
Явар җирләр эзләп иңрәп йөри.

Өерелеп, кайнап ага болыт,
Ил өстеннән җир өстенә күчеп.
Басуларга түгел, җанга явып,
Ул сынарга әзерләнә көчен.

Юк, шифалы җылы яңгыр түгел,
Тамчы-тамчы үлем кояр кебек!
Җирнең җыерчыклы, арган йөзен
Инде соң мәртәбә юар кебек...

...Ни гаебе бар бу болытларның? —
Әйләнәләр һаман судан парга.
Тик мин хәзер нәни Садакодай[1]
Карый алмыйм кургаш болытларга...

●

Ишегеңә киләм.
Юк, мәхәббәт түгел,
Аның белән көлгәчә янган...
Рыялансаң — рыя гомер буе,
Алдый алсаң — үлгәнче ялган.

Барьер кебек тора ак ишегең
Күңелләрне бүлеп, аерып.
Тик ярату була алмый хәзер
Башкалардан үзгә, аерым.

Тик бер адым. Анда синең дөнья...
Түгелергә иде, керергә!
...Еллар итеп санап баскычыңны,
Тып-тын гына төшәм кирегә...

●

Сизмим дә мин, тавышыма
Кай арада моң тула.
Җырым белән тизрәк аны
Коткарырга омтылам.

Даладагы курай кебек
Моңлана да моңлана!

Җаныңа тынычлык табыйм
Дисәң, мине тыңлама...

...Үземне качып баручы
Бер дәрвишкә охшатам...
Сиңа — җыр... Мин —
Чайпалып торган
Җан газабын бушатам.

---

[1] Садако — нурланыш авыруыннан үлгән япон кызы.



*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

## Эльмира Шәрифуллина

### Кыл уртада басып тора ана

Сагыш җиле кай тарафтан исә —
кайсы илдән, кайсы кыйтгадан?
И, Кешелек! Уйла үткәнеңне —
Хәтереңме әллә йоклаган?

Бу дөньяның кайсы төбәгендә
золым чәчеп, афәт уралар? —
Тынычлыкның күзләренә кереп,
бәбәкләрен терәп торалар.

«Рәхәтенә чыдый алмый кеше»,—
дия сыман әнкәй авазы.
Кайтып-кайтып сөйли сагышланып,
кырык бишнең моңлы ул язын.

Хәтер сорый, акыл сыный, уйлый:
ни җилкетә адәм баласын?
Дәрес булды, сабак булды, күрде
сугышлардан нәрсә аласын.—
Ни җилкетә адәм баласын?

Сагыш җиле исә кай тарафтан,
кай яклардан иңрәп зың килә?
Кемнәр елый ятып, җирне тырнап,
акылыннан шашып, кем көлә?..

Кузгатмагыз, зинһар, җир уллары,
әниләрнең татлы сагышын.
Үлем чакырып бөек кешелеккә,
алмагыз ла ана каргышын...

Газиз ана басып тора сыман
Җир шарында — урта бер җирдә:
сугыш чире йоккан вандалларны
тудырмаска кирәк иде дә...

Тудырмаска кирәк булгандыр шул
үзәк өзеп, кырык кыл өзеп.
Актарыла ана хәтерләре,
Кыйтгаларны йөри ул гизеп...

Сакта ана: бүген таңда туган
оныгына җил өрмәсен лә.
...Кыл уртада басып тора ана —
тора уйлар өермәсендә!..

## Оя кордык

*Фаилгә*

Синең белән оя кордык.
Бер-бер артлы кызлар туды,
моңлы булдык, җырлы булдык.

Синең белән оя кордык.
Җил тимәсен җимешләргә —
уяу тордык, уйда булдык.

Синең белән оя кордык.
Хәсрәт килсә, шатлык килсә —
күкрәкләргә башны куйдык.

Синең белән оя кордык,
оябызга мая куйдык.

## Яшьле яңгыр

Яңа кабер туфрагына
тамчылары коела,
Яшенле түгел, бу яңгыр
Яшьле булып тоела.

Җилләр җиргә ятып елый,
җилләр дә җирсиләрдер.
Җаны яралы анага
кушылып үксиләрдер.

Табигать шуңа кайгылы —
Югалткан бер баласын.

Аңа да газиз булгандыр
яңа туган нарасый.

Җитәр, җилләр, җирсемәгез,
син дә, болыт, түкмә яшь.
Чык, кояш, юат ананы,
чык, хәсрәтен уртаклаш.

«Нишлисең? Тукта!!!» — дип хәзер
язмышларга дәшимме? —
Керфекләремне көйдерә —
яшемме бу, яшенме?

●

Үзәкләрне өзә бер моң,
өзә, үтмәле түгел!
Уйный да, уйлый да икән
торгынлык кичкән күңел.

Яңгырлардан, җилләрдән соң,
гомер күзендә шулай
сискәнеп куямы күңел
әбиләр чуагыдай?

●

Иртән торып, суга барам,
чайкала чиләкләрем.
Комлы юлда: шыгырт-шыгырт
сөйләшә чүәкләрем.

Әнкәемә су кайтарам —
чишмә сулары, чәйгә...
Тәпи йөреп китәр инде
Нәни кызым да җәйгә.

Үсепләр буйга җитәр дә
чишмә юлыннан китәр.
Тәүфигы артсын иде лә
буй-сыннарыннан битәр...

Уйга чумып, суга барам
чайкала чиләкләрем.
Кабул булсын су алганда
теләгән теләкләрем.

## Дәва җыям

Аланда балан өлгергән,
баланның дәвасы бар.
Кайтам баланлы аланга —
күңелнең ярасы бар.

Күңелемнең ярасы бар...
Их, дәваласы иде.
Дөрләп янасы иде дә —
исән каласы иде.

Һаман әрнетә күңелне,
бер яра бирми тынгы...

Киләләр ятлар яныма,
тартып карарга кылны.

Чиртәләр күңел кылларын
төрлечә, төрле яктан.
...Күңелемә дәва эзлим,
туган җир, туган яктан:

туган җирдә, туган илдә
үскән әче баланнан.
Тәлгәш-тәлгәш дәва җыям
шул баланлы аланнан,
шул баланлы аланнан.

## Хыялымда кайтып килдем

Озын-озак көн булды бу:
иртәдән төнгә кадәр
хыялда җәяүләп кайттым
Иделдән Сөнгә кадәр.

Сөн буйларына кайттым да
утырып уйлар уйладым.
Үзәкне өзгән моңымны
җырга салдым, җырладым.

Кушылды куш каеннарым
сагышлы хисләремә.
Күзләремә яшь төелде,
төштең дә исләремә...
Озын-озак көн булды бу —
Иртәдән төнгә кадәр,
хыялымда кайтып килдем
Иделдән Сөнгә кадәр.

●

Үлеп тереләсе иде
әкияти җаннар кебек.
Их, сөеләсе иде бер
кочакка сеңеп, сеңеп.

Сөеп, сөеләсе иде:
бар микән андый ярлар?

...Кичтән генә ап-ак иде,
каралган икән карлар.

Тапталган икән шул карлар
без килеп эз салганчы...
...үлеп тереләсе иде
үкенечтә калганчы...

●

Йөрәк турың кайда икән,
Җир-ана?
Йөзкәеңдә меңләгән җөй,
мең яра...

Парә-парә теленгән һәр
төбәгең.
Бу газапка ничек түзгән
йөрәгең?
Ярый әле, кешеләр бар —
терәгең.

Синең өчен утка кергән
Кешеләр,
сине, мине яклый белгән
Кешеләр!
Алар барлык үлемнән дә
көчлеләр.

...Уйлы юллар, утлы еллар,
киң дала,
йөрәк турың кайда икән,
Җир-ана?
Йөрәк турың кайда икән,
Җир-ана?!

*1981—1982.*

*Рафаил Газизов — Мамадыш районының Кече Кирмән авылында туып үскән егет. Ул хәзер авылында урта мәктәп директоры булып эшли. Шигырьләрендә дә туган яклары, табигать һәм кеше матурлыгы, тормышның нәниләр дөньясы белән бергә үрелгән кызыклы яклары турында уйланырга ярата, укытучы-тәрбияче буларак, җитди нәтиҗәләргә омтыла...*

*Татарстан Язучылар союзының яшьләр белән эшләү бүлеге аның шигырьләренә багышланган махсус семинарны да яшь шагыйрьнең туган авылында үткәрде: И. Юзеев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Гатауллин һәм «Агымсу» әдәби берләшмәсе членнары катнашында узган бу утырышта Р. Газизов иҗатына җентекле анализ ясалды, уңышлы дип табылган шигырьләре вакытлы матбугатка — шул исәптән журналыбызга да — тәкъдим ителде.*

# Рафаил Газизов

## Кычытканнар

Кем кычыткан үскән җирне таба,
Ул тук иде авыр елларда —
Һәм шул егәр белән басу сөрдек,
Берәр потлы орлык биштәрләрен
Без күтәреп йөрдек юлларда.

Ил алдында бурычыбыз йөртте,
Намусыбыз авыр елларда.
...Кабаланып үтеп барган чакта,
Онытылган якын дус шикелле,
Кычытканнар очрый юлларда...

## Чит җирдә

Кемем бар минем монда?
Агачтан төшкән яфрак,
Юлаучы җил канатына
Ияреп килгән туфрак...

Ни калган миңа монда?
Күңел канатым сынды,
Гөлләрем чәчәк койды.
Сайрар кошларым тынды.

Төшемә керә инеш,
Таң җиленең назлары,
Йөрәкне урталай ярып,
Йөзә авыл казлары.

## Үкенеч

Синең эзләр яңа яуган карга
Шигырь язып китте.
Урамнардан, яшьлек нуры булып,
Зифа буең үтте.

Күз карашым шигырь юлларыңны
Җирдән үрелеп алды.
Күңелемнең офыкларын нурлап,
Синең кояш янды.
Өзгәләнә йөрәк синең белән
Бергә китмәгәнгә,
Акылымны хис яшене суга
Күкләр күкрәгәндә.

## Каенлыкта

Таныш сукмаклардан атлау белән
Кочагына ала каенлык,
Язгы томанмыни, эреп бетә
Хисләр дәрьясында сабырлык.

Каен бураннары иркәлиләр
Күз карашын, җанны, фикерне.
Ап-ак бураннарга салып чайкыйм
Күңелемне сөлге шикелле.

## Әни

Үз өлешен ашамады әни,
Безгә имезлеккә чәйнәде.
Бар гомерен без киеп йөрисе
Оекбашлар итеп бәйләде.

Кара төннәремне яктырталар
Әниемнең ап-ак чәчләре.
Гаиләбезнең гөл бәйләмендә
Әни — нурлы кояш чәчәге.

## Циркта

Искитәрлек номер! Юлбарыслар —
Йорт мәчесе сыман тыңлаучан,
Ләкин алар күзендәге сагыш
Җанны тетрәтерлек, уйласаң.

## Этюд

Сузып-сузып шаян җил сызгыра,
Гүләп тора өйләр, буралар,
Җилнең бөдрәләрен тарый
Тарак теше кебек коймалар.

Тәрәзәдә — кышның кульязмасы,
Каеннарда — чыпчык чылбыры,
Төлке кергән, ахры, морҗабызга
Никтер сыймый калган койрыгы.

Җил искәндә койрык, шарф булып,
Каеннарга килеп урала,
Аннан, шуып төшеп, кар кызының
Кочагында эреп югала.

## Кыш

Серле бүген дөнья, гаҗәп серле:
Тирә-ягым актан уралган,
Каен сабыйлары, әкият тыңлап,
Селкенергә куркып тын калган.
Серле бүген дөнья, гаҗәп серле:
Вакыт-вакыт карыйм тукталып.
Шук җилләр дә исми, минем кебек
Торалармы әллә сокланып?!

## Телефон чыбыклары

Бу чыбыклар — күңел җепселләре,
Кунган чыпчыклары — төеннәр,
Кайсыбызның җан өшеткеч сүзе
Бәс челтәре булып эленгән?

Кем тавышы чыңлый чыбыклардан,
Кем язмышы җилдә тирбәлә,
Кем ядкаре җир-күк арасына
Йомры чыпчык булып төйнәлгән?




# Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ЕЛНЫҢ БЕР КӨНЕ

ОЧЕРК

Райком секретаре Хәким Нәбиевич Гатиятуллин тәмам сабырсызлана башлады: юл салучыларның эшләрен төгәлләүләре турында хәбәр юк та юк. Ниһаять, олы юл Оренбург өлкәсе чигенә барып җитәргә тиеш иде. Ике-өч көннән уракка төшәчәкләр. Урак өстендә, бөтен көч, оештыру сәләте уңышлы җыеп алуга һәм дәүләткә мөмкин кадәр күбрәк ашлык сатуга юнәлдереләчәк. Хәер, юллар әйбәт булмаса, хәтта җыйган уңышны да түкми-чәчми элеваторга озату мөмкин түгел. Шуңа күрә җир ачылуга һәм юл салучылар эшкә керешүгә үк, секретарь бер минутка да тынычланмады. Хәзер дә, көтеп-көтеп тә хәбәр килмәгәч, төзүчеләр янына ул үзе чыгып китте.

Юл төзүчеләрнең эшен кабул итү комиссиясе тикшерә иде. Шунда секретарь яшь кенә бер төзүчегә игътибар итте. Тар гына козырекле күн кепка кигән бу егетне прораб мактады. «Шушы кеше булмаса, бу участок бүген өлгерми иде әле»,— диде.

Прораб шулай диюгә, яшь егет уңайсызланып калды, әмма күзләрен читкә алмады.

— Мин булмасам, башка берәү табылыр иде,— дигән булды.

— Калмадылар бит, барысы да киттеләр дә бардылар, син калгач кына, сиңа карап кына башкалар да эшли башлады...

Прораб шулай диде дә комиссия членнары янына таба китте.

Чәченә чал керә башлаган прораб шат иде: аның коллективы планны срогында үтәде, асфальт юл күрше өлкә чигенә кадәр китереп җиткерелде.

Хәким Нәбиевич та, прораб сүзләре тәэсиренә бирелеп, әлеге егетнең кулын кысты, рәхмәт әйтте, аннары прораб артыннан иярде.

— Нигә шул хәтле мактадыгыз егетне? — дип кызыксынды.— Кызарынып чыкты хәтта!

— Мактарлыгы бар,— диде прораб.— Шундый егетләр күбрәк булсамы минем... Яллары белән хисаплашмыйча, ике көн, ике төн эшләде ул. Үзегез беләсез: иртәгә участокны тапшырырга дигән көнне асфальтны күп китерәләр, җәеп кенә өлгер. Вакытында җәймәсәң, асфальт суына — ташка әйләнә. Машина-машина асфальт килә, тын алырга вакыт юк. Җиңел эш түгел асфальт җәю, кән азагына таба җеп өзәрлек хәл калмый, кәчкә аякка басып торасың. Ә ул егет үз бригадасы белән төнгә дә калырга булды. Һәм менә — участок әзер...

Комиссия участокны кабул итте, автоинспекция вәкиле генә актка кул куймады, һәм ул хаклы иде. Авылга кергәндә, юл кисәк сулга борыла, шул төшкә борылыш тамгасы куелырга тиеш икән, ә юлчылар моны истән чыгарганнар. Юл һәйбәт, шоферның, очып килеп, читтәге чокырга төшеп китүе бар. Менә сиңа — бәхетсезлек.

Автоинспекция вәкиле нәкъ шулай диде: «Бәхетсезлек чыгуы ихтимал, бүген кичтән үк тамга куелган булсын! Әлегә юлны ябарга!»

Кон кичкә авыша башлагач, прораб янә эшчеләрне җыйды. «Егетләр, комиссия актка кул куйды, әмма авылга кергәндә, сулга борылыш знагы куелырга тиеш, бүген үк, хәзер үк!..»

Хәким Нәбиевич авылга, колхоз председателе янына да кереп чыгарга булды. Авылга җитәрәк ул машинасыннан төшеп калды. Хәким Нәбиевич кыр юлында ялгыз гына йөрергә ярата: үткәне турында уйлана, хәзергесен күрә, киләчәкне күзаллый. Ул яңа гына салынган асфальт юлдан авылга таба атлый. Киң офык алсуланган, кояш баешка таба тәгәри. Яңа утыртылган чакрым баганаларында шәфәкъ нурлары уйный. Асфальт исе борынны яра, тамакны кытыклый. Юлда машина-фәлән күренми, ябык әле ул. Төзүчеләр эшләрен яңа гына бетерделәр. Комиссия юлны хәзер генә кабул итте.

Менә күпер. Хәким Нәбиевич туктарга ниятләде, елга агышының шавын тыңлыйсы килеп китте, әмма туктамады.

Күперне чыккач, Хәким Нәбиевич юл читенә утырган бер кешене күреп алды.

— Исәнмесез!— дип, үтеп барышлый сәлам бирде.

— Исәнмесез!

— Нишләп утырасыз?

— Машина көтәм,— диде егет.

— Бүген бу юлдан машина үтмәс, әлегә юл ябык, иртәгә ачыла.

— Үтәргә тиеш, үтми хәле юк.

— Ай-һай,— дигән булды Хәким Нәбиевич, әмма икенче мәлдә үзе дә киресен уйлап куйды: «Яңа асфальт юлдан нинди шофер үтми түзәр икән?»

Еллар буе көтеп алынган юл бит бу. Аны сузу, әнә ул күперне салулар һич кенә дә җиңел булмады! Кайчак район үзәгенә әчәр-дүртәр көн кайтмый ята иде Хәким Нәбиевич, әйтерсең, юлчы булып эшкә кергән! Иртәгә көзгедәй шушы юлдан узучы шоферлар аның ни бәрабәренә төшүе турында уйланырлар микән, аны салучыларга рәхмәт укырлар микән, ичмасам?.. Юк, мөгаен, уйланып та тормаслар: юл шома, машина оча гына — шул бик җиткән, ә юл төзүчеләрне шоферның гомер буена да күрмәве мөмкин.

Хәким Нәбиевич кисәк кенә юл салучылар хезмәтенең ифрат җаваплы, авыр икәнлеген уйлый башлады. Әле менә бүген генә кабул итеп алынган юлны салуда да кешеләрдән күпме фидакарьлек таләп ителгән... «Чү, юл буендагы егет шул үзе түгел идеме? Әйе, әйе, үзе, шул егет! Тагын ул калды микәнни? — дип уйлады Хәким Нәбиевич.— Борылыш тамгасын куярга да ул алынды микәнни? Ул, әлбәттә». Янә күз алдына китерде Хәким Нәбиевич юл буенда күргән егетне. «Шул инде,— диде ул үзалдына сөйләнеп.— Шул егет ич! Комиссия членнары янында чакта да аның күзләре кызарган, күз кабаклары шешенкерәгән, иреннәре яргаланган иде. Шулай да ул елмайды, прораб абыйсы мактаганга ул хәтта уңайсызланды, янәсе, мактарлык нәрсә эшләде соң әле, ул калмаса, башка берәү табылган булыр иде. Ә бит калмаганнар, вахта автобусы килүгә, төялгәннәр дә кайтып киткәннәр.

Хәзер әнә тагын соңга калган ул, машина көтә. Кайтыр ара шактый. Мин аңа үз машинамны бирәм. Кайтсын!»

Хәким Нәбиевич кире борылды, әмма шул мәлдә кечке эңгерне ертып, күпер яклап, үзбушаткыч килеп чыкты, юл буендагы кеше кул күтәрде. Шапылдап ишек ябылды, һәм берничә секундтан, Хәким Нәбиевичка әче төтен бөркеп, машина узып та китте. Кабинада, шофер белән янәшәдә тар козыреклы кун кепка кигән егет утыра иде. Яшь бригадир. Комсомол. Районның юллар төзү идарәсенә менә кемне начальник итеп куярга! Тик хәзергә районда андый идарә юк һәм, шунысы кызганыч, аның кайчан буласы да билгеле түгел әле...

Хәким Нәбиевич борылышка җитте. Автоинспектор таләп иткән тамга тиешле урынына куелган иде.

«Шулай,— дип үзалдына сөйләнде Хәким Нәбиевич.— Шулай үсә кадрлар. Ә без аларны кайчак күрми торабыз. Кайчак хезмәтен намус белән башкарган эшче читтәрәк кала, ә күп сөйләүчеләр алга чыга. КПСС Үзәк Комитетының май (1982) Пленумы карарларында ил алдына куелган проблемаларны хәл иткәндә исә бөтен өмет — эшлекле кешеләрдә. Планны үтәү дә, тәрбия эше дә урта звено җитәкчеләренә бәйле. Ул күрсәтә эшчегә үрнәк, үзе эшләп күрсәтә, үзенә ияртә, тәрбияли һәм аларны коллектив алдында олы бурычларны үтәргә әйди».

Асфальт юлда авыл кызларының биек үкчәле туфлиләре тыпырдавы ишетелә башлады — яшьләр Культура сараена бара, ерак та түгел, елганың аръягында гармун тартып җибәрделәр, якындагы бер өй янында берәү гитара кылларын чиртеп алды.

Хәким Нәбиевич идарәгә юл тотты, анда аны колхоз председателе көтә. Председатель белән сөйләшү җитди булачак. Әңгәмәне кайсы яктан башларга? Бүгенге сүз озакка барачак. Сүзен сүз итәргә гадәтләнгән, шактый тәкәббер һәм мин-минлек белән чирле башлаган кеше янына бара ул бүген. Председатель яшьләрне дә яратып бетерми, туры сүзне дә өнәми икән. Кеше аңа дәресен әйтә, ә дәреслек ул дага түгел, бөкләп кесәгә тыгып кына котылып булмый. Дәреслек өчен көрәшәләр. Берсендә Хәким Нәбиевич КПССның Татарстан өлкә комитетыннан: «Яхшы хуҗадан яшьләр китми»,— дигән гыйбрәтле бер сүз ишетеп кайткан иде.

Хәзер дә аның исенә шул хак сүз килеп төште. Чыннан да, җитәкче яхшы икән, колхозчы аннан ник китсен?! Туган җирдән дә якын җир юк лабаса! Димәк, кадрларны саклауда җитәкченең роле гаять зур икән.

Бу авылдан да яшьләрнең китү сәбәбен ачыкларга кирәк булыр. Культура сарае салдылар, район үзәгеннән ике сәгать саен автобус йөреп тора, театр коллективлары, танылган җырчылар килә. Ниһаять, менә күптән көткән асфальт юл файдалануга тапшырылды. Бу да үзгәреш кертмәсә авылга? Яшьләр һаман китә торсалар? Сәбәбе нидән булыр? Эш урыннарында шартлар начармы? Алай дисәң, терлекчелектә дә, игенчелектә дә эшнең яртысыннан күбрәге механикалаштырылган. Китүләрнең төп сәбәбе җитәкчеләрнең яшьләргә салкын мөнәсәбәтендә булуы бик ихтимал. Нинди-дер аңлашылмаучылык туган икән, секретарь председательгә ярдәм итәргә тиеш булачак. Әйбәтләп сөйләшергә кирәк, тыныч кына, һәр ягын үлчәп, бизмәнгә салып. Кадрлар белән эшләүдә вак мәсьәләләр юк. Тели икән, егет кеше өйләнә икән — рәхим итсен, йорт-җир бирергә, өйдә, каралтыны да үзе ничек тели шулай салсын, колхоз һәр яклап булышсын!

Кайда гына аны очратмасын, әлегә кадәр председатель күпер, юл турында сүз кузгата иде. «Күпер кирәк безгә, шушы Кандыз елгасы аша күпер кирәк! — дип, райком секретаренең үзәгенә үтте.— Ярты авыл бер якта, яртысы елганың икенче ярында. Күпер булмау аркасында ничәмә гаилә колхоздан китте инде».

Ул да хаклы булгандыр, бәлкем. Ләкин колхозчыларның авылдан китүен юлга яки күпергә генә сылтау дөрес булырмы икән? — дип уйлады Хәким Нәбиевич, идарәгә якынлашканда.

Әйе, колхозчылардан да, председательдән дә ишетте ул юл, күпер турында, үпкә сүзләрне күп ишетте ул. Һәм менә, ниһаять, күпер дә салынды, асфальт юл да күрше Оренбург өлкәсенең чигенә үк илтеп җиткерелде. Хәким Нәбиевич халыкка биргән вәгъдәсен үтәде. Кечкенә, әмма яз саен шашынып ташучан Кандыз елгасы аша, кызлар билен буып куйган путадай сузылып күпер ятты. Язгы чәчүләрдә, шушы күпер булмаганга, зур эшләр өзелеп тора иде. Колхозның барлык производство мастерскойлары, терлек фермалары — елганың уң ягында, ә авылның зур өлеше сул якка урнашкан.

Бу юл турында тарих язарлык. Ничәмә карар гына чыгарылды, кемнәр генә тотынып карамады күпер салырга, юл сузарга. Агымдагы ремонтны ясаганда гына да бу урыннарга меңнәрчә тонна ком-таш китерелде, меңнәрчә сум акча түгелде, яз җитүгә, янәдән юлсыз калалар иде. Язгы сулар, көчле яңгырлар ташылган комын да, ташын да әллә кая алып китеп бетерә торды.

Хәким Нәбиевич бервакыт кызыксынып исәпләп чыгарды: соңгы ун ел эчендә генә дә бу юлга салынган ком-таш, әгәр үз урынында торса, юл тасмасын тугыз метр биеклеккә күтәрергә тиеш булган икән. Тугыз метрга! Юк, асфальтсыз рәтле юл салам димә. Асфальт юл — заман таләбе, киләчәк юлы, коммунизм юлы, безнең буын юлы, ниһаять!

Асфальт-бетон беләнябылмыйча, бары тик ком-таш өеп кенә ясалган юл районга меңнәрчә сум зыян китерде. Колхоз һәм совхозларны, район үзәгендәге предприятиеләрне, төрле оешмаларны бөлдерде. Йөрергә рәтле юл да булмады. Хәким Нәбиевич яхшы белә: бүген асфальт-бетоннан салынган автомобиль юллары колхоз һәм совхозларның экономикасын күтәрүдә бердәнбер чара булып тора. Асфальт юлдан меңләгән тонна ашлык ташылачак, төрле йөкләр кучереләчәк, халыкка медицина хезмәте күрсәтү яхшырачак, автобусларның яңа рейсларын ачарга мөмкинлек туачак, колхозчыларга көнкүреш хезмәтен күрсәтү дә җиңеләячәк. Кыскасы, район үзәгеннән колхоз-совхозларга асфальт-бетон юллар уздырылса, хуҗалыкларга әлегә исәпләп бетерүе дә мөмкин булмаган бихисап зур файда киләчәк. Хәтта яшьләрнең авылларда күбрәк калуына да асфальт юллар ярдәм итәчәк.

Бусы — хакыйкать, моңа берәү дә каршы төшми, тик менә шушы теләк-уйларны ничек тормышка ашырырга?

Шушы көнгә кадәр районда гына түгел, хәтта республикада да авылларны яхшы юллар белән тәэмин итү мәсьәләсе бердәм хәл итеlә алмый әле. Бу хәтта бер безнең республикага гына да кагылмый. Бүген юл төзү белән уннарча оешмалар шөгыльләнә, аларның һәркайсы аерым министрлыкларга буйсына. Ә нык кына куллы төп бер хуҗа юк. Шуңа карамастан, соңгы ун елда гына да Баулы районы авылларында 40 километр асфальт-бетон юл салынды. Ун ел элек кенә районда фәкать өч километр һәйбәт юл бар иде. Күренә ки, үсеш бар, әмма барыбер әле җитәрлек түгел, колхозчылар ризасызлык белдерәләр: «Әнә шәһәрләрдә, диләр, хәтта ишегалларына хәтле асфальт җәйгәннәр, без шәһәр кешеләреннән киммени?! Юк. Шулай булгач, нигә бездә дә, авылда да...»

Борынгыларча әйтсәк, аякны юрганыңа карабрак сузарга туры килә — һаман да шул бер балык башы — уннарча оешма башкара юл төзү эшен. Район җитәкчеләре кайсына барып ишек кагарга да белмиләр. Алай да йоклап яту юк, шакыйлар, кирәләр, таләп итәләр, җаен-көен табалар. Соңгы елларда авылларда күренгән һәйбәт юллар фәкать шуннан — район җитәкчеләренең кайгыртуы нәтиҗәсендә булдырылды.

Юл салу мәсьәләсендә Мәскәүгә кадәр барып җитүчеләр бар. Моны да белә Хәким Нәбиевич. Шул ук вакытта, алма пеш — авызыма төш, дип, көтеп яткан, гамьсезләр дә җитәрлек. Алар һаман шулай юлсыз интегәләр, ә менә ул эшләгән Баулыда шактый эшләр башкарылды. Шул темп белән барганда, бу бишьеллыкта район үзәгеннән һәр хуҗалыкка диярлек асфальт-бетон юллар сузылачак, нык юллар, ышанычлы юллар.

Ә бүгенгә райондагы егерме колхоздан унсигезе район үзәгенә асфальт-бетон юл белән тоташтырылды. Иң шатландырганы шул: юлы яхшы колхозлардан яшьләр китми башлады. Дөрес, моның сәбәбе бер һәйбәт юлда гына түгелдер.

Янә бер яңалык: Баулы хәзер Башкортстан автономия республикасы, Оренбург, Куйбышев өлкәләренә китүче олы юлга тоташты. Ютазы, Урыссу һәм Бөгелмә якларына да ел тәүлегенең теләсә кайсы мизгелендә чыгып китеп була. Бер Баулы районында гына да соңгы ун ел эчендә юлларның иңкүле төшләренә — 115 тимербетон торба һәм 17 капиталь күпер салынды һәм... Менә ер-яңа унсигезенче күпердән Хәким Нәбиевич үзе чыгып бара.

Колхоз председателе белән бик тә очрашасы килә Хәким Нәбиевичның. Ул аны яхшы белә: бу кеше — үз урынында, Бөек Ватан сугышында катнашкан, эшен гөрләтеп алып бара, колхоз үргә менә, үсеш бар. Сайланган көннән үк ул кадрлар турында кайгырта башлады. Бик күп яшьләрне колхоз исәбенә югары уку йортларына, техникумнарга җибәрде, читтән торып укуларына да ярдәм итә, тегеләр диплом тотып әйләнеп кайткач, һәммәсенә диярлек, үзләре теләгән эшен таба. Кыскасы, үз кешеләре турында аталарча кайгырта ул. Әгәр дә мәгәр яшь белгеч аның ышанычын акламый икән, шулай ук аталарча кыздыра, җыелышларда телгә ала, оялта: колхоз сиңа белем бирү өчен биш ел буена акча түкте, ә син ничек җавап кайтарасың?..

Хәким Нәбиевич күреп йөри: районның һәр авылында матур ярыш бара. Бу үзенчәлек җир-ана туфракта да, киң колачлап салынган өйләрдә дә, киңәйтелеп сузылган урамнарда да, чүп үләнсез кырларда да, урманнарда, елга-күлләрдә дә бар. Туган җиргә, туган авылга, туган туфракка, елга-күлләргә, әрәмә-урманнарга һәр авыл үзенчә карый. Бер авыл, әйтик, Ык елгасы буендагы әрәмәләрне кисеп, болын ясады, әмма уңмады, шәрәләндерелгән җирнең иң ашлы катламын язгы кар һәм ташу сулары алып китте, шуннан бу болыннарны әрекмән, шайтан таягы басты, сайрар кошлар китте, ә менә шул ук Ык ылгасы буендагы башка авыллар әрәмәлеккә кагылмадылар, сакладылар, бүген анда карлыган, шомырт, балан үсә, кошлар сайрый, бал кортлары бал җыя. Язларын күккүкләр кычкыра. Ул гынамы, авыл халкы ел саен шушы әрәмәлекләрдән йөзләгән тонна печән чабып ала. Әле генә Хәким Нәбиевич килеп бара торган авыл да әрәмәлеккә тимәде. Димәк, өметле халык яши бу авылда, арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит дип, бүгенге белән генә тормыш итмиләр, киләчәк өчен кайгырталар. Авылның басулары: урманы-әрәмәлеге, күле-елгасы — ул шул халыкның йөзе, намусы, вөҗданы булып тора. Туган туфракка, туган авылга, туган илгә булган мәхәббәт тә шуннан башлана: туган авылдан, аның әнә шул әрәмәлекләреннән, тау битеннән тибеп чыккан чишмәләреннән.

Әмма соңгы елларда бу авылның колхоз председателе шактый үзгәрде. Колхозчылар белән эреләнеброк сөйләшә, кирәксә-кирәкмәсә кычкыра, тавыш күтәрә. Шул хәлдән соң, баш алып, авылдан китеп баручылар ишәйде. Җиткерә торалар Хәким Нәбиевичка, хәбәре җитә тора, бар, андый күңелсез хәбәрне җиткерергә ашкынучы кешеләр дә бар.

Авылда, шәһәр өйләрендәге бөтен шартлар булдырылсын, әмма каралты-куралары да, бакчасы да булсын. Газы, салкын һәм җылы суы килеп торсын. Шунда гына, фәкать шунда гына, ихтимал, яшьләр шәһәргә кызыкмый башларлар...

Юл буендагы егет Хәким Нәбиевичның һаман күз алдыннан китмәде. Ул аның исем-фамилиясен дә белми калды. Егет — эштәге үҗәтлеге, хезмәтенең нәтиҗәсе, үйтеләкләре, омтылышлары белән күпләргә үрнәк булырлык эшче. Аның хәтта эчкерсезлеге, карусызлыгы да җитәкчеләрне кисәтә сыман — хезмәт кешесенә карата гадел, игътибарлы булыгыз, башкарылган эшкә дөрес бәя бирә белегез, аңа ышаныгыз, кирәк чакта яклап чыгыгыз һәм аларны вакытында күреп алып, үстерегез! — ди сыман...

Бу — КПССның Баулы райкомы беренче секретаре Хәким Нәбиевич Гатиятуллинның, елдагы өч йөз алтмыш көненнән бары берсе, җәйге бер көне иде. Әмма бу көндә дә аның эше бетмәгән әле, Хәким Нәбиевичның колхоз председателе белән кадрлар турында ныклап сөйләшәсе бар.

## АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕН ХАЛЫК ЭШЕ

## Кояш Тимбикова

# МӘСҮФӘНЕКЕЛӘР ҺӘМ ПИВНИК

ОЧЕРК

Юлдан кайтып кереп, ял итәргә ниятләп утыра идем, телефон шалтырады. Трубкадан: «Беләсеңме, Пивник Казанда бит,— дигән хәбәр ишеттем.— Буби Пивник — Казанда!»

Берничә минуттан без Казанның Яшьләр үзәгендәге кунак йортында, Пивник каршына килеп баскан идек инде. Ул безне: «Тукта, тукта, әйтмәгез, мин үзем танырга тиеш!»— дип каршы алды. Шактый вакыт текәлеп торганнан соң ул миңа апам исемен атады, аннары кисәк кенә: «Юк, юк,— дип, үзен-үзе төзәтергә ашыкты.— Син — Закир абыйның төпчек кызы булырга тиеш,— диде. Исемемне әйтте.— Кечесе, кечкенәсе, әлбәттә,— дип кабатлады.— Утыз сигез ел вакыт үткән бит инде»...

Бер-беребезгә карашып сүзсез калдык. Шул ук төз, озын буй, какча йөз, кылыч борын, тирәнгә баткан, моңлы, зур коңгырт күзләр, шома чәч. Күе зәңгәр төстәге костюмы, саргылт кызыл күлмәге, буйлы галстугы гына аны тәмам олы, эшлекле кеше кыяфәтенә керткән сыман.

— Син бөтенләй үзгәрмәгәнсең, Буби,— дим. Артыгын әйтә алмыйм, үткәндә кичергәннәр бары берьюлы күңелгә кереп тулган да, төен булып, тын юлын каплаган. Авыз ачсаң да, күзгә яшь тулар кебек.— Син үзгәрмәгәнсең, Буби!..

Мин бу сүзләрне юри кабатламыйм: Буби, чыннан да, 1943 нче елның салкын яңгырлы көзге кичендә, Чистай районының без яшәгән Иске Роман авылына аяк баскан кичтә дә шундый ук иде кебек. Һәрхәлдә, аның кыяфәте минем күңелдә гел шундый булып саклана. Алар безнең авылга Эстониянең башкаласы Таллин шәһәреннән килеп төштеләр. Туган йортларының немец фашистлары кулында калуына сагышланып, тормышның мең кыенлыгын авыл халкы белән бергәләп җиңә-җиңә, алар бездә шактый гомер яшәделәр. Әнисе, Фаня Гиршевна Пивник, немец теле укыта башлады, Бубины мәктәпнең атын карарга алдылар. Әниләребез бергә эшләгәнгә, без дә гел бергә идек. Буби безгә эстоннар турында сөйли, аларның җырларын көйләп күрсәтә, аннары бездән татарча сүзләр өйрәнә, авыл халкыча сөйләшергә теләвен аңлата иде. Эстон мәктәбендә өзелеп калган укуын һичничек дәвам иттерү мөмкин булмаганлыктан, аның буш вакыты күп. Ул атын чистартып, ашатып-эчертеп, эшен түгәрәкләп куя да китаплар, газета-журналлар дөньясына күчә. Тик ул еллардагы татар авылында аның зәвыгын канәгатьләндерерлек, аңлаешлы китаплары да аз булгандыр, мөгаен. Шуңа күрә Бубиның телне өйрәнергә ашкынуы табигый. Ул үзенең бу теләгенә шактый тиз иреште. Кышкы озын кичләрдә авыл яшьләренең аулак өй мәҗлесләрендә, «Йөзек салыш» уйнаганда иң оста итеп ул җырлый торган булып китте. Авыл кызлары Бубиның ягымлы баритон тавышын яраталар, җырны ул башлаганны көтеп торалар иде. Буби исә моңа бик шат, ул кыстатмый, тамагын кыргалап, кызлар ягына елмаюлы карашын ташлап ала да йөзек салучыны биетерлек иттереп такмаклый:

...Китте йөзек, китте йөзек куллардан,
Барыйм әле, барыйм мин шул юллардан...

Аңа башкалар да кушыла. Тәбәнәк, караңгы өй яктырып киткәндәй була. Без, кечкенәләр, я киң сәкенең түр почмагына, я мич башына, я сәндерәгә үк чөмәшкән килеш зурларның уенын күзәтәбез. Йөзек кем кулыннан табылыр, ул кешегә нинди «җәза» бирелер дә, «гаебен» ул ничек җиңеләйтер: җырлармы, биерме, башка берәр тамаша күрсәтерме?

Җанга капылт ябырылган истәлекләр тәэсиреннән айный алмый утыруның озаккарак сузылуын чамалап, тел очында торган беренче соравымны бирәм.

— Безнең якларны онытып бетергәнсеңдер инде, Буби?

Ул үпкәле карашын бик тиз читкә борды, креслосында чайкала-чайкала, үзалдына гына сөйләнгәндәй итеп, саф татарча:

— Ул елларны онытсаң, җир йотар,— диде.— Ярыймы соң, мөмкинме?!

Соравыма сорау белән җавап бирүе генә түгел, теленә кинәттән безнең авыл кешеләре еш куллана торган «җир йотар» кебек сүзләр килеп керүе дә Бубиның бернәрсәне дә истән чыгармавына көчле дәлил иде.

Бер-беребезне бүлә-бүлә шул чактагы хәлләрне, бер караганда, көлке, икенчеләй исәпләсәң, үзегеңне өзәрдәй вакыйгаларны сөйли башладык.

— Фаня Гиршевна Октябрь бәйрәме көнне безнең мичтә бәрәңгедән шундый тәмле бер ризык пешергән иде. Тәме әле дә авызда. Исемен сорарга гына оныткanмын.

— Син кечкенә идең бит әле, кая анда аш исемнәрен сорап тору! Минем ат күтәрәмгә калгач, сезгә йөгереп барып кердем, әйдә — син генә. «Әйдә, дим, аркан очын тотып кына торсаң да ярар». Икәүләшеп абзарга кердек. Тотып кына торырга кушсам да син тартып азапланасың икән. Бер заман карасам, үзең лыпылдап җиргә утыргансың, аркан да ычкынган...

Көләбез. Күзләребезгә ихтыярсыздан тулган яшьне бер-беребездән яшерер өчен читкә борыла-борыла көләбез. Бүлмәне тутырган көлү авазлары яшьлектә, балачакта без кичергән яман еллар күләгәсен читкә, еракка куа, күңелләребездә әллә кайчан бөреләнгән карусыз дуслык бәхетен меңмиллион мәртәбә арттыра кебек.

Буби «ат караучы озын эстон малае» хәленнән җаваплы постка күтәрелгән, Бениамин Моисеевич Пивник хәзер Таллиндагы кием-салым тегү берләшмәсенең генераль директоры икән. Сүзебез бер эзгә төшкәч, ул, уңайсызланып: «Ни гомер үткән, ә Чистайга кайтып килергә җай чыгара алганым юк,— дип куйды.— Инде бу юлы бер генә көнгә булса да барырмын диган идем, киңәшмә озакка сузылды. Казанны да беренче күрүем бит — гаҗәеп шәһәр икән!.. Чистайга эләгеп булмады».

— Әйдә, Буби, иртәгә таңнан чыгып китәбез!— дим.

— Командировкам бетте. Самолетка билетлар алынган. Сез инде миңа сөйләгез генә: әйдә, авылның беренче йортыннан башлыйбыз, ерак чишмә юлына чыгып җиткәнче, бөтен кешеләр турында! — Буби, үтенеченең чынбарлыктан шактый ерак икәнлеген сизеп, төзәтергә ашыкты. Сәгатенә күз салды.— Анысына да вакыт җитми икән,— диде.— Өч йөзләп йорт бит анда, без аларның исемнәрен генә әйтеп чыгарга да өлгермибез, самолет өчтә оча, хәзер — уникe...

Без Бубига аеруча якын кешеләр турында сөйләшергә тотындык. Ул сорый, без ни белгәнебезне түкми-чәчми аңа җиткерәбез. Кайберләрен ул белә дә икән әле.

— Фатир хуҗабыз үлгән инде,— диде Буби.— Шәйдулла абый да, әби дә юк инде.— Шул сүзенә ялгап, ул яңа сорау китереп чыгарды.— Мәсуфәнекеләр нишләде икән, сез беләсезме? Ул апа берүзе алты бала үстерә иде. Андый семья авылда бер генә, безнең очта, безгә якын гына торалар иде. Аларны күргән саен аптырый идем: мин әнием белән берәү генә, әле үзем дә эшлим, акча алам, алай да җитми, Мәсүфә апаның ялгызына — алтау!!! Ни ашатты икән ул аларга? Киендерергә ниләр тапты икән? Әле аңардагы шәфкатьлелекне белсәң! Берсендә ул әниемә түшкәсе белән каз биргән иде! Ул балаларның кайсы исән калды икән, нишлиләр икән алар, кайларга таралыштылар икән?..

Кызганычка каршы, ул кичтә Бубиның бу сорауларына тәгәл җавап бирерлек мәгълүматым юк иде. Бер-ике сүздән соң җавабым өзелеп калды. Туган үскән яклар Таллин кадәрле үк ераклыкта булмаса да, сирәгрәк кайтыла шул: җәснә бер әлексә, әләгә, әлекмәсә — юк. Инде чираттагы кайтуда, авыл капкасыннан үткәч үк, колак

төбендә Бубиның соравы кабаттан яңгырады кебек: «Мәсүфәнекеләр нишләде икән?..» Бу юлы мин Пивник соравына тәп-төгәл җавап алырга тиеш идем.

Без яшәгән чорда алты бригадалы җыйнак кына бер колхозны тәшкил итүче Иске Роман авылы хәзер «Степной» исемле совхозга әйләндерелде. Дирекция урнашкан ике катлы кирпеч йорт буп-буш. Кемнең кайдалыгын сорагач, болдыр баскычында утыручы малай (ул әнисе урынына килгән булып чыкты) бик горур кыяфәттә:

— Әллә күктән төштегезме?— дип, йөзен читкә үк борды.— Бүген кем конторда утырсын инде? Безнекеләр генә түгел, Чистайдан килгәннәр дә кырда ята, кичкә бәйрәм була бит!

Малайның артык сөйләшергә теләге юк иде, турыдан-туры Мәсүфә апа Мортазиналарның үзләренә китүдән башка чара калмады. Аларны табу исә бик җиңел булып чыкты: Түбән очтагы инешкә тоташкан аркылы рәт тоташы белән аларныкы икән. Балалар, киленнәр, кияүләр, кодагыйлар — бары да бер тирәдә. Мәсүфә апа яши торган ак ташпулат башкалардан аерылып тора, ул башка йортларга караганда зуррак та, биегрәк тә, мәһабәтрәк тә. Дөрес, йортларның башкаларына да тел-теш тидерерлек түгел, барысы да төзек, җыйнак, аларында да авыл тормышының хикмәтләрен яхшы белүче, нык хуҗалыклы, уңган кешеләр яшәве әллә каян сизелә.

Зәп-зәңгәр мөлдерәмә күзләре, елмаеп, бер генә сирпелде, Мәсүфә апа, безне танып, өйгә чакырды.

— Узыгыз, уз! — диде. Үзе газ плитәсендәге казаннарга ишарәләде.— Ике табынлык аш пешерәм. Берсе осталарга, чуаш ягыннан килгән ике оста мунча өлгертә. Икенчесе — балаларга. Хәзер кайтып керергә тиешләр. Әйдә, узыгыз, әйдә!..

Өйнең күп тәрәзәле, өч яклап көзге кояшның алтынсу салкынча нуры белән ертелгән җәйлек өчен ясалган өлешеннән эчкә үтәбез. Залны, кунак бүлмәләрен, кече якны күргәч, йөзебезгә чыккан гаҗәпләнү галәмәтләрен чамалап, Мәсүфә апа аңлатырга ашыкты.

— Илдусым: «Йөз квадрат метр булсын!»— диде дә кырт кисте. «Ниемә бу кыр хәтле өй?» — димен. «Кунак-төшем килгәндә, туйлар уздырганда җайлы була ул, әнәй»,— дилар.— Ана шунда ук балалары кылган эшнең яманларлык түгеллеген дә искәрә.— Соңыннан аларныкы дөрескә чыкты,— ди.— Безнең нәсел зур бит. Ел саен ике-өч туй уздырабыз, гадәт кушканча, бишәр-алтышар пар кодалар китертеп, аларны өчәр-дүртәр кич кундырып ясыйбыз туйларны! Әле генә Рафика кызымның Рәсимәсен бирдек, аннан алда Иргемнең Ландышы чыккан иде. «Әһ» итәргә дә өлгермисең, оныклар үсеп җитә: Рәисе, Рамиле, Чәчәк, Энҗе... Инде оныкларның балалары аякка басты, яшь тулмас борын дөнья җимертеп йөрергә тотыналар. Ул арада бер ишесе мәктәбенә кергән була, армиясенә китеп бара. «Карт әбием, әйдә, туй ашлары пешерешергә син кирәк!» — дип чакырырга да килерләр. Барысы да рәт-рәт тезелгән: Радигы, Мараты, Алинәсе, Русланы...

— Шулаен шулайдыр инде ул, Мәсүфә апа, тик бу безнең урмансыз якта, бөтен авыл сыярдай мондый йортны нәрсә ягып җылытырсыз?

— И-и, канатым, син һаман теге еллар аршины белән үлчисең икән әле. Хәзер бөтенләй башкачага әйләнде бит эшләр: су өйләргә керде, электры, газы... Утын дигән нәрсәне дә кызык иттеләр аны, гел кирәге калмады дисәң дә була: пар казаны ясаталар да мичене соскычлап ташкүмер генә өсти торалар...

Капка тавышы ишетелеп, сүз өзелде. Мәсүфә апаның кече улы Илдус кайтты. Аңа иярәп, өйгә авылның бар мәшәкате, шатлыгы, борчулары да кергән кебек иде. Ул ым кагып кына исәнләште дә, ашыгып, түргә атлады, телефон трубкасына ябышты.

— Әй, диспетчер, карале, ну, ничек анда? Эһе! Алайса, бәйрәм була!..

«Бу нинди хәл соң: бөтен авылларда халык җан-фәрманга эшләп ята, Романда бәйрәм уйлап чыгарганнар?»— дигән аптыраулы уй туды. Илдус исә, телефонда сөйләшеп туктауга, шикләнүемне сизгән диярсең, аңлатырга тотынды.

— Шәп вакытка туры килдегез әле!— ди.— Бүген бездә уракны бетерәләр. Тагын бер-ике сәгатьтән бөтен комбайннар авылга кайта. Бер айлар элек, зур митинглар ясап, басуга озатып калган идек үзләрен, хәзер каршы алырга кирәк инде. Әни, синең эшләр ничек соң, өлгерәсеңме?

Мәсүфә апага бу тантана турыдан-туры кагыла, чөнки аның Сәгыйдулла кияве белән Фәүзия кызының улы Рамил-онык бер комбайнда эшләгән. Алар ай буе күзгә-башка да күренмәгән, төнге уникеләргә генә өйгә кайтып, баш тертеп алалар икән дә, таң беленер-беленмәстән, басу ягында тагын комбайннар гөрелтесе ишетелә башлый икән. Көндезге ашау-эчүләре, ял итеп алулар — барысы да кырда көйләнгән.

Бүген инде, ниһаять, бөтенесе бергә җыелып, сыйлана-сыйлана, сөйләшә-сөйләшә кич утырырлар. Әнисенең «барыгыз бергә» дигән сүзе еш кабатлана башлагач, Илдус кисәтергә кирәк тапты.

— Барыбыз да кайтып бетә алмабыз, әни,— диде.— Миңа хәзер җәйге лагерьга, кичке савымга китәргә кирәк. Рафика апаның да яңа туган егермеләп бозавы бар, соң гына кайтыр, Рәшит абый — төнге көтүдә...

Ана кеше, беләм инде, дигән кебек, башын игәләп, кулын селтәнгәләп кенә торды. Аның өчен әллә нинди яңалык юк, һөнәрең терлекче булгач, барың бергә җыелып утырулар эләгәмени ул?! Башкасын әйткән дә юк, Мәсүфәнекеләр туй мәҗлесендә дә ферманы онытып тормыйлар, табынга чиратлашып кына утыралар. Хатыннары савымга киткән арада, терлекче ирләр кунак сыйлый, маллар карарга вакыт җиткәч, азык әзерләү җиһазларын, абзар чистарткыч транспортерларны эшләтергә фермага ирләре китеп бара. Кунаклары кайберләренең күзгә-башка чалынмый торуын сизми дә калалар. Кайсы баласының кай сәгатьтә кайда икәнлеген Мәсүфә апа гына белә. Ул әле кайберләренең исенә төшергәли: «Бар, кызым!», «Ярар, килен, калганын үзем эшләрмен, фермаңа йөгер!», «Улым, әйдә, ашык!», «Кияү, бар, канатым, әйләнеп кайт, күз-колак булмый ярамас!..»

Балалары да, рәхмәт яугырлары, анага каршы килеп тору дигәнне белмиләр. Ул әйткән икән — димәк, шулай кирәк. Бу — ихтыярсыздан коры буйсыну гына түгел. Тормышның бөтен җаваплылыгын хәзер үз иңнәрендә тотучы балалар әниләренең терлекчелектә иң нечкә серләрне дә белүен, киңәш биргәндә, бары тик файдалысын гына әйтүен яхшы аңлыйлар. Мәсүфә апа да кыз-улларының, килен-кияүләренең эшләрен пошырырлык итеп, гел күрсәтмә биреп кенә утырмый. Үтмәстән генә, әйтми калсаң, үкенеч булырын гына телгә ала. Белә ана: бүгенге терлекчелек кешеләр алдына, ул эшләгән чордагы белән чагыштырганда, күп мәртәбә зуррак мәсьәләләр китереп куя. Бурычы да, аны чишү әмәлләре дә гаять катлаулы. Кем белә, Мәсүфә апа бүгенгесендә, бәлки, әллә ни майтара да алмас иде әле. Әмма үз чорында аңа тиңнәр булмаган, шунныктан әниләренә зур хөрмәт китергән шул һөнәр балалар өчен дә яшәү максатына әйләнгән. Аларның үсеп җиткән һәрбере терлекчелеккә килә торган. Хәзергесе көндә «Степной» совхозының сыер-бозау фермасында Мәсүфә апаның ун баласы эшли. «Чү!»— диярсез.— Аның балалары алтау гына иде бит әле? Буби Пивник та: «...Ялгыз башына — алтау! Тамакларын ни белән туйдыра алды икән?»— дигән иде.

Кыяр-кыймас кына Мәсүфә апага ул ерак еллар хакында сүзләр әйткәли башлыйм, Пивникларны искә төшерәм. Елмая ул, үтә күренердәй зәңгәр күзләр дымлана.

— Алтау иде шул,— ди.— Ул елларда әле алтау гына иде. Хәзер бит алар барысы да башлы-күзле булды инде. Оныкларымны да, тагын аларының балаларын да кушып исәпләргә тотынсам, сан-исәпләрен бутый башлыйм. Үзләре, шөкер, әллә ни еракка таралышмадылар. Менә бит, Нәфисә кызым белән Зәйнулла кияүне әйтмәгәндә, барысы да — үз янымда. Нәфисәм күрше авылга, Каргалыга килен булып төште...

— Андагы киявегез нииндирәк кеше соң?— дим,— нәселегезгә тиңме?

Ана җитдиләнде. Сорауның ни сәбәптән бирелүенә төшенмәкче булып, берәзгә тукталып, уйланып алды. Аннары, кисәктән, әздереп әйтте:

— Бик уңдым мин! Киленнәрдән дә, кияүләрдән дә уңдым. Күз тидерә күрмә!

Табигатьтә һәрьяктан мөкәммәл кеше бөтенләй диярлек очрамый. Сирәк кенә буладыр, бәлки, тик гадәтиләргә барыбер нидер җитеп бетми. Халык әйтмешли, ябе килсә, сабы килми. Мәсүфә апаныкылар да гап-гадиләр, һәр кешегә хас сыйфатлар аларда да бар. Мәсүфә апа үзе үк балаларына да, килен-кияүгә дә кисәтүләр ясап кына тора. Шунсыз гына авыл кадәр булып үрчегән нәселен бер үзәккә туплап

кала алыр идемени ул?! Әмма ләкин балалары турында бирелгән сорауга ана, теш агартып, бер генә зарлану сүзе дә кыстырмыйча җавап бирде. Мишәр хатынына табигатьнең үзе тарафыннан иңдерелгән түземлек, горурлык, имәндәй ирләреңне дә сыгып кына төшерә торган хәсрәт килгәндә дә сер бирмәүчәнлек бер бөтен булып калыкты. Мәсүфә апа, әле ишеттеңме-юкмы, дигәндәй:

— Минекеләр яхшы!— дип кабатлады.— Балаларым да игелекле булып үстеләр, килен-кияүләрнең дә, чүпләп җыйган кебек, иң яхшылары миңа туры килде!— Ул күңелләрдә һичнинди шикләнүләргә урын калдырмас өчен сабыр гына, берәм-берәм дәлилләр китерә башлады.— Яшем җитмештән ашты, бер генә баламның да сүземне аяк астына салганы юк. Әтиләре сугышка киткәндә, олы улым Рәшит кенә бераз кул арасына керә башлаган иде әле. Төпчегебезне әле үзем дә белмим, узып кына азапланам, аңа алты атналык йөгем генә бар иде. Вагыйз фронттан җибәргән беренче хатларында аңа «исеме билгесез балама» дип сәлам яза иде...

МТСлар оештырылгач, районда тракторчылар бригадиры булып эшләгән Вагыйз Мортазин сугышка киткән дә бер-ике генә хат салып өлгергән. Мәсүфә апа болай сөйли:

— Тормыш итүләре авырая башлагач, колхоз председателенә бардым. «Миңлегәрәй-канатым, дидем. Бир әле миңа авыррак эш! Балаларны кеше итәргә кирәк бит».— «Кулыңнан килсә, бер эшем бар-барын, ди, сезнең очта яңа ферма салабыз, утыртма баганалар чокырын казырга кеше таба алмыйм»...

Төзелешләр бетеп, яңа фермага сыерлар кереп тулгач, Мәсүфә апа шунда эшкә калган. Аннары янына берәм-берәм балалары да җыела башлаган: кызлар, киленнәр әниләре кебек савымчы булалар, ир-атлар терлекчелекнең авыррак эшләренә алыналар.

Иске Роман фермасында Мәсүфә апа Мортазина гаиләсе эшләгән барлык вакытны исәпләсәң, алар бу фермага 225 еллык хезмәт куйган булып чыга. Дәрья-дәрья сөт, көтү-көтү тана-бозау, олау-олау ит, май биргәннәр алар. Мәктәптә укыганда:

**...Безнең ике казыбыз бар,**<br>**Аны бер оя итәбез!**<br>**Ник, дисезме, белмисезме!**<br>**Әти кайтуын көтәбез...**

— дип шигырь сөйләп, өлкән яшьтәгеләрне елатып, үз сүзләренә сабый беркатлылыгы белән ихластан ышанып, әтисен күрәчәгенә өметләнеп яшәгән Рафика сыерларның уңынчы яңа буынын үстереп тапшырган инде. Аның ире Сәгыйдулла Ислямов — кирәксә, тракторына, бульдозерына, теләсә нинди маркалы машинасына, комбайнына утырып, һичнинди чик-чаманы белмичә эшли торган, укымышлы, универсаль механизатор. Җайге-көзге кыр эшләре, ремонты-фәләне беткәч, ул да үз туганнары янына фермага килә, абзар чистарткыч, азык әзерләгеч механизмнарны көйли. Аңа да әбисе Мәсүфә башлаган эш — изге. Уңган бу механизаторның терлекчелекне дә үз итүен сизеп, дирекция аңа ферма мөдирлеген дә тапшырып караган. Өч ел эшләгән Сәгыйдулла. Тик кырлар киңлегендәге җанга сихәт бирүчән машина гөрелтеләре чакыруыннан котыла алмаган. Үтенечен тотып, дирекциягә килгән: «Машиналардан башка булмый икән, бирегез миңа иң иске бер тракторны, үзем көйләп, эшләтермен!» — дигән.

Сәгыйдулланың фермадагы урынына Мәсүфә апаның кече улы — коммунист Илдусны куялар. Җиңелме аңа хәзер, авырмы? Кул астындагы эшчеләренең яртысына якыны — үзенең туган-тумачасы.

— Эштә үзеңнекеме-түгелме, анысы исәпкә алынмый,— ди ул.— Бездә барысы да төп-төгәл исәп-хисапка корылган. Җәй башында иң күп сөтне Зөлфия сауды, минем хатын. Күз алдында битон-битон сөт алып тора икән, аны кая куясың?! Фәузия әнә, минем иң яраткан сеңел, ул да сава, аныкы азрак чыга икән, ул ягын аерып алып мактап булмый...

Сүзебезне тыңлап торган Мәсүфә апа, бер җаен табып, әңгәмәгә кушылып китте.

— Зөлфия сөтне мулрак сава икән, аның, улым, башка чарасы да юк. Аңла: хатыны ялкау мөдирне кем тыңлар иде? Ул бит синең абруй өчен дә тырышырга

тиеш. Артка калса, оятыннан, кеше күзенә ничек күренер? Фәүзия дә тырышмый түгел, тырыша. Бәлки, карт сыерлары артыбрак киткәндер. Болай гына калышмас ул, уналты яшеннән фермага барып кергән балам ул минем! Сигез классны бетерде дә инәлә-ялвара үземә ияреп йөри башлады. Авылда урта мәктәп юк. «Әнәй-канатым, янынңнан китмим, шунда гына эшләт мине! Йөзеңне кызартмам, яман сүз ишеттермәм!»— ди. Егерме дүрт ел үтте, вәгъдәсен бозганы юк.

Картлыгы аркасында башка кызы белән бутады, дип уйлыйм.

— Аңа нинди егерме дүрт еллык эш әле?! Кызларга алыштыргысыз!

— Алыштырмасаң, алыштырма!— ди Илдус, көлә.— Фәүзиянең улы Рамил үзе кызлар күзен кыздыра инде. Унны бетерде, бүген-иртәгә армиягә китәм, дип, әллә кем булып йөри. Җае чыккан саен, фермада эшләде, җәйгелеккә генә Сәгыйдулла җизни комбайнына китеп торды.

Фәүзия гаиләсенең дә бөтен тормышы, нәкъ әнисенеке кебек үк, фермага бәйле. Шунда ул булачак ире Рәшит белән дуслашкан. Инде егерме бер ел фермада эшләүче Рәшит-кияү Мәсүфә апаның олы улы, адаш-кайнагасы белән парлашып, терлекләр карый. Терлекләрне җәйге лагерьга чыгаргач, аларга эш бигрәк тә арта, тәүлек буе көтү көтәләр. Ирләренең терлекләрне ничек туендыруы хатыннарның сөт чиләкләре тулу-тулмауга килеп тоташканлыктан, дилбегәне бушатырга һич ярамый. Хезмәт хаклары сөтнең күләменә дә, куелыгына да, бозауларның көрлегенә дә бәйле. Ялкаулыгыңның соңгы нәтиҗәсе «шап» иттереп гаиләң кесәсенә, туганнарыңның көнкүрешенә китереп суга. Шөкер, көтүчеләрнең әлегә кадәр әрхур ишеткәннәре юк, маллар ашаудан өзелеп тормый, сөтнең куелыгы 4,2 белән бара. Май заводы куелыгы 3,6 булган сөтне стандарт итеп саный. Роман сөтенең күрсәткечтән арткан куелыгы савымчыларга өстәмә дип языла.

Хакыйкате шулаен шулай. Әмма ләкин алсу алма битле Фәүзиянең, әле ул өздереп җырлап та җибәрсә, шул терлек-туар арасында чирек гасырга якын эшләп йөрүенә ышануы авыр. Мәсүфә апаның гына исе китми.

— Аптырама, канатым,— ди.— Анысына әле ярый сигез классны бетерү тиде. Рәшит улым тугыз яшендә үгез җигеп, фермага салам ташый иде инде. Дүрт классны тутырып чыккач, ныгытып торып фермада эшли башлады.

Терлекче Рәшит Мортазинның фермадагы хезмәт стажы 36 елдан артып китә. Аның механизатор улы Ринат та, кышкы айлар керү белән, фермага килә, әти-әнисенә булыша. Әнисе, дигәннән... Ринатның әнисе, Кяфия килен Мәсүфә апаның фермадан китеп баруына сәбәпче икән. Юк, көтелмәгән күңелсезлек торгызмаган ул, барысы да бик табигый. Рәшит Кяфиягә өйләнгәч, бергә-бергә яши башлаганнар. Көннәрнең берендә Ринат-онык туган. Ул чагында совхозның хәзерге кебек балалар бакчасы, яслесе юк икән әле. Фермадагы эш тә бүгенге кебек тигәл сменалы, айга бишәр көн ял бирерлек итеп көйләнмәгән булган. Рәшит белән Кяфия шикләнә-шикләнә генә анага сүз кушалар.

— Әнәй, синә җитәр инде, ял итеп, хуҗа булып, өйдә генә утыр!— диләр.— Ялгызлыктан курыкма, көндезләрен Ринат белән икәү булырсыз...

Мәсүфә апаны аңлаешсыз уйлар биләп ала. «Ни бу? Шәфкатьсез картлыкның аваз салуымы? Барысы да җайланды дигәндә генә, эш көннәре күңелле бер тантанага әйләнә башлаганда, ятимлек, толлык кимсетелүләре инде онытылыр чигенә җиткәндә... кешеләр арасыннан китеп барыргамы?..» Бераздан ул тормышның бу закончалыгы ул кадәр үк начар түгеллегенә ышана: сабыйлар үстерү, эштән кайткан балаларны ачык йөз, кайнар аш белән каршылап тору — һәр чорның үз матурлыгын тоя белергә генә кирәк икән! Акыллылар гомеренең тәкә борылышларын да сөртенеп егылмый үтә беләләр.

Мәсүфә апа киткәннән соң, авыл фермасының һәр тармагына элекке еллар терлекчесенең зиһенен чуалтырлык үзгәрешләр килә. Кайтып сөйләгән сүзләрен генә тыңлап торсаң да, баш чатный башлый. Хәзер сыерлары да йөзәрләп тә меңәрләп кенә исәпләнә. Ул яңа биналар, ул терлек азыгы, ул терлекчеләр өчен ял өйләре, ул хезмәт хаклары — Мәсүфә апа эшләгәндә төшкә дә керми иде. Ана шулай да егылып китәрлек хәйран калмый: «Ала-ай! — дип кенә сузa.— Булыр, булыр, шулай да булмагач, селкенеп йөрергә дә түгел».

Соңгы елларда Илдус, «аһ-ваһ» килеп, электрик саву аппаратлары көйләтеп йөрде. Гасырлар буе хатын-кыз кулы башкарып килгән үзе вак, үзе бөтен буыннарның хәлен суыра торган хезмәт электрга йөкләтелде. Әй, рәхәтләнде савымчылар, әй котылды ул куллар! Егерме биш-утыз сыерны сөгать ярым эчендә савып бетерәләр. Шулай да «УДС-3» маркалы ул аппаратураны мактый башлаганчы, шактый четерекле хәлләр кичерергә туры килгән. Аппаратура, заводтан фермадагы бөтен сыерларның сөтен, гомуми бер көпшә аша үткәреп, олы бер цистернага җыю исулына көйләп чыгарылган. Савымчы үз сыерларының җиленен генә тоташтырып тора, сөтен күрми дә кала. Гомер-гомердән аргта сөйрәлүчеләр өчен җайлы да була ул: «Әйдә, ярар,— диләр алар,— алдынгылар-фәләннәр бетәр, бөтенебез тигез хәзер, җыелган сөтне сыерлар санына бүләбез дә кумәкләшеп урталыкта йөзәбез...»

Зөлфия килен ул көннәрдә ятьмәгә эләккән кош кебек бәргәләнә. Мәсүфә апа аны тынычландырырга тырыша: «Ашыкма! — ди.— Барлык кешедән алда син офтанма, күрерләр, аңларлар, бер җаен табарлар».

Хәзерге савымчылар ул көннәрне елмаеп кына искә төшерәләр. Эшләрен карап торсаң, бигрәк тә элекке фермаларның хәлен күргән дә булсаң, исең-акылың китәр. Мәсүфә апа сөйли: «Язлар җитсә, сыерларның азыгы бетүдән кот алынып тора иде, әкренләп түбә саламын сыдырып төшерә башлыйбыз. Анда нинди сөт тә, күпме май инде, җан саклау турында гына баш вату...»

— Буби Пивник та сезнең шулай җәфаланган көннәрегезне хәтерли икән,— дим.

— Кара син аны-ы! — Мәсүфә апаның йөзен ихлас гаҗәпләнү галәмәте каплады.— Ул да шул хакта уйлана белгән икән, ә! Мин үзем аларны жәлләп өзгәләнә идем. Без бит, ни әйтсәң дә, үз җиребездә, үз туган-тумачаң, авылдашлар, үз колхозың, бары — бергә, югы — уртак. Ул Пивниклар, бичаракайлар, башта безнеңчә сөйләшә дә белмиләр иде бит. Менә хәзерге кебек күз каршымда тора: беркөнне безнең капкадан килеп керде бу, Фанияне әйтәм инде, ул Фаня Гиршевнаны без икенче көнне үк үзебезчә, Фания, дип йөртергә тотындык бит, шул килеп керде. Кулында — бармак буе гына пыяла көпшә. Шуны миңа суза. «Нәмәстә соң бу?» димен. «Градусник, ди, бичарам. Синең, ди, балаларың күп, көне буе яланаяк чабалар, температураларын үлчәмичә, йокларга салма! ди. Минем Буби зур инде, аныкын үлчәмәсәң дә була...» Авызымны ачтым да калдым. Жар үлчәү дигән нәрсәне безнең белгән дә юк бит аны! Әз-мәз кызарынып китсәләр, мин аларны, мунчага алып кереп, кычкыртып-кычкыртып чаба идем дә мич башына, аталарыннан калган кайры тун өстенә салып, томалап йоклата идем... Чәй эчәргә чакырдым. Бәрәңгем пешеп кенә чыккан иде. Кишер, кабак телемнәрен көйдереп, аңа җиләк яфраклары кушып ясап куйган чәем дә бар чак. Бу бичара укытучы бер мәртәбә кайнар чәй эчеп, тамагын туйдырып чыкса да, дөньясы яктырыбрак китәр кебек. Чакырам, керми, аягын да атламый. Чамалап алдым: өендә ач баласы утырган кайсы ананың тамагыннан аш үтәр соң! «Тукта, мәйтәм, бер генә минут көтеп тор!» Иске савыт алып чыктым да аңа бәрәңге тутырдым, аннары чалырга вакыты җитсә дә, кызганыч булганга, әле һаман ишегалдында сукранып яшәүче аксак бәпкәм бар иде — күзем шуңа төште. Күтәреп алдым да аңа суздым. «Ал, Фания, ал!»— дим. Ул татарча белгән бөтен матур сүзләрен әйтеп бетерде. Әле урамнан да: «Рахмат! Сынок! Жаркой!..»— дигән сүзләре ишетелде.

Мин Әминә килененең саву кабинасы янында торам. Бестужев токымлы куекызыл сыер, чайкала-чайкала, үз урынына кереп бара. Аның артына тагын егермеутыз сыер, су буеннан тезелешеп кайткан казлар кебек, чиратка басканнар. Бу хайваннарда адәм акыллары бар микән әллә: үз савымчысын тапкан, үз аппаратын таныган, ишләре арасындагы тәртип санын да чамалаган — чираты җитүен тыныч кына көтеп ала белә. Хәзер һәр савымчы сыерларының хәзинәсен үзе җыя, үзе хисапчы кызга тапшыра. Әминә килен савымчылар арасында гадәтиләр рәтендә атлый. Хәрәкәтләре җитез аның, әмма каударлануның әсәре дә сизелми. Ул үзендәге салмаклык белән дә беренчелеккә чыгарына ышана шикелле.

Мин аңа башка килендәшләренең күбрәк савуын искәреп куйдым — ярышуга мөнәсәбәтен беләсем килә.

— Зөлфиянең сыерлары сөтне күп бирә икән, ә?! — дигән булам.— Былтыр һәрберсеннән 3700 килограмм алган...

«Син ник калышасың?» дип сорарга тел әйләнми, Әминәнең йөзен балкытып торучы елмаюы сүнәр, сыерларына әйтә торган ягымлы сүзләре тынып калыр кебек. Юк, кисәтү ясарга кыюлыгым җитми минем. Ферманың уңганнарын гына исенә төшерәм: «Фидания Сәхәбетдинованың сыерлары бүген унберәр литр сөт биргән,— дим.— Фәния Сөләйманова да күп сава икән...»

Әминә, мин сөйләгәндә, җырын акрынайта төште. Ул гел үзалдына гына көйләп-җырлап йөри. Күңелгә сәер фикер килә: «Моның сыерлары, мөгаен, шул җыр тавышына җыелалардыр?!» Әминәнең сәгатьләр буе өзлексез көйләнеп торган җырлары — барысы да сандугачлар хакында.

**...Сандугач сайрый сабырсыз, баскан талы тамырсыз.**
**Булмагыз, кызлар, сабырсыз, кадерсезгә калырсыз!..**

Ферманың телдән-телгә макталучы уңганнары турындагы фикерне ишетеп алгач, ул өнә шул җырны җырлады. Мин инде Әминә сорауларны җавапсыз калдырыр микәнни дип шикләнә дә башлаган идем. Җыр кинәт тынды. Әминә, эчкерсез кешеләрдә була торган сирәк тезелгән энҗедәй вак тешләрен ялтыратып, көлеп җибәрде.

— Яшьләр тырышсыннар, кыз, тырышсыннар! — диде.— Мин аларга бераз юл биреп торырга булдым. Сыерларым бозаулый башласа, күп сөтнең нинди икәнен тагын да күрсәтеп алам әле мин аларга! Хәзергә монысы да ярап торыр, кыз. Яшьләрнең ачуын китерергә ярамый.

Әминә, сүзе беткәнне аңлатып, тагын җыр сузды.

**...Сандугачлар басып сайрый безнең читәнебезгә.**
**Сандугачы китеп бара, кала читәне безгә...**

Әминә белән яшьтәшләр без. Нигә ул үзен яшьләрдән шул кадәр ераклыкка аерып куя соң әле?! Җанны билгән сорауларны ачыктан-ачык бары тик киң күңелле Мәсүфә апага гына бирә алдым.

— Әминә киленең фермада күптән эшлиме соң әле, Мәсүфә апа? — дим.— Ул анда үзен губернатор кебек тота.

— Әминәмә, үзен ничек тотса да, килешә! Ул бит, канатым, беренче башлап фермага килгәндә, сыерларның боты кадәре генә иде.— Мәсүфә апа әле көрсенеп куя, әле көлеп-көлеп җибәрә.— Ерактан гына күзәтеп йөрим тегене. Эчемнән уйлыйм: «Хатирәнең бу кызы озакка чыдамас, димен, үзе чисталыкны да бик ярата: һәр көнне аклы ситсы күлмәк киеп килә. Кырда үскән ак чәчәк кебек. Көнө буе тездән тирескә батып эшли дә арып-талып кайтып китә. «Ай үттө, елларга китте, терсәк буе кыз бала, күзгә күренеп, тернәкләнә барды.— Ананың тавышы акрыная төште.— Ул арада минем уртанчы улым Ирек үсеп җитте. Беркөнне, абзар чистартырга булышырсың, әйдәле, дип, мин моны фермабызга алып килдем. Әминә-канатым, миңа кадәр үк килеп, әллә кайчан сыерлары арасында йөри башлаган. Үзебезнең эш беткәч, Ирегемә әйтәм, бар, димен, әнә шул балага да булыш, улым, бик яшь әле ул, арыгандыр... Башка көннәрдә минем әйтүемнең кирәге калмаган иде инде. Ирегем, миңа булышканчы ук, иң әүвәл Әминәнең хәлен белә торган булып китте. Инде минем кызлары Ландышны кияүгә дә бирделәр. Алинә оныкларым тугач, Әминә килен әллә ферманы ташлар микән дип тә торган идем дә — сизелми әле. Китәм, дисә, берәү дә аңа каршы сүз әйтә алмас, аның фермада эшли башлавына утыз ел дисәң дә була...

Төүлек сәгате: «Җитәр инде, кешеләр, иртәгә дә көн бар, бүгенгесен түгәрәкләп, бераз ял итегез!» дип, күк пәрдәсен эңгер белән каплаганда, Мәсүфәнекеләр

өйләренә җыела башлады. Ана, алдан хәстәрен күреп, аларны каршы алып торды: Рафика кызы соңрак кайтасы булганга, аның йортындагы терлекләрне көтүдән каршылады, Кяфия киленнең мунчасын томалап кайтты, Фәүзияләренә бармаска да була — аның каенанасы өйдә. Төп йортта ике казан аш әзер. Табынны Зөлфия килен үзе тезәчәк, моңа аның кулы ята төшә.

Тик, әле Зөлфия кайткач та, түгәрәк табын тезелгәч тә, барысы да бик арыган булса да, өстәл тирәсенә килергә ашыкмадылар. Бары да көн тантанасының бу гаиләдәге төп каһарманнары — комбайнчы Сәгыйдулла белән аның ярдәмчесе Рамил оныкны көтә иде.

Рафика да кайтты. Ул, өй мәшәкатьләрен читкә куеп торып, совхозның кырчылык диспетчерына шалтыратты, җәмәгате Сәгыйдулланың хәлен сорашты. Калганнар Рафиканың күзенә генә карап тора. Трубкадан шактый күңелле хәбәр килде, күрәсең, Рафиканың нәкъ әнисенеке кебек зәп-зәңгәр, зур күзләренә сөенеч нуры тулды. Ишеткәннәренең рәхәтен җанына иңдереп, шактый ара эндәшми торды ул. Аннары туганнарына да аңлатып бирде.

— Сәгыйдуллага соңгы тезмәне суктыруны биргәннәр. Имеш, яхшы комбайнчы инде, шуңа күрә. Диспетчер әйтә, Сәгыйдулла абый суктырган ашлык алты мең центнерга тарта, ди. Эшләре беткәч, бөтен игенчеләрне кичке чәйгә җыялар, сез аны көтеп тормагыз, ди...

Ул тәүлектә Мәсүфәнекеләр төннең таңга ялгануын сизми дә калдылар. Яшьрәкләре авылның клубына, игенчеләр җыңүе уңаеннан оештырылган бәйрәм кичәсенә китеп барды. Өлкәнрәкләр арасындагы сүз тагын ерак елларга, Мәсүфә апа өчен аеруча кадерле чорларга килеп тоташты. Мин Пивникларны искә төшерү ягында идем. Бер җаен китереп:

— Буби сезнең балаларның исән-имин үсеп җитүләрен белергә бик телэгэн иде,— дидем.— Тагын бер очрашсак, барын да мактармын инде.

— Ашыкма, канатым!— диде ана.— Башта минекенә җиткерсеннәр әле!

Табын тирәли утырган балалары, килен-кияүләре: «Әнәй дөресен сөйли»,— дигән шикелле, башларын аска иеп кенә торалар. Аптырый калдым: бер уч черегән саламга шөкер итеп яшәгән ферма савымчысының бүгенге терлекчеләргә нинди дәгъвасы булырга мөмкин?

Зөлфия килен башлап җибәрмәсә, бәлки, Мәсүфә апа артыгын әйтмәгән дә булыр иде.

— Безнең әнәй бит ул ВДНХга барган!— диде Зөлфия.— Балаларының анда ук җиткәне юк әле.

Әллә кинәт үзенең җиңүчеләр сафына баскан көннәре исенә төшү шулай нык тәэсир итте, әллә килененең капылт кына бөтен серне чишеп ташлавыннан оялып куйды — ананың йөзе комачтай кызарды.

— Ни инде, ул елларда исәп-хисап алып барулары да башкача иде бит аның,— дип, үзе ирешкәннәрне мөмкин кадәр гадиләштереп сөйләп китте.— Көннәрнең берендә фермага комиссия килеп төште. Иртәдән алып кичкә кадәр безнең кайсы сыерның күпме сөт бирүен тикшерәчәкләр икән болар. Без савабыз, тегеләр һәр сыерның сөтен аерып үлчи бара. Мин башта уртачарак сыерларымны саудым, кайсы унике литр бирә, кайсы — унөч. Ахырдан өч-дүрт сыерым чиләк арты чиләк тутырдылар. «Унбиштән дә ким булмаска тиеш боларның сөте»,— дип чамалыйм. Бер чиләк тутырып илтәм, икенчесен, өченчесен... Ахырдан сорадым: «Күпмегә чыгардыгыз?» дим. «Унтугыз литр, апа! — диләр. Күзләре маңгайларына менгән.— Бу кадәр сөтне кеше үз абзарындагы сыердан да ала алмый!»

Соңыннан барыбызны бергә җыйдылар да әйттеләр: «Иң күп сөт бирүче сыерларны Мәсүфә Мортазина тәрбияли икән!»— диделәр. Аннары тагын тикшерделәр әле. Миннән: «Үзең карый торган сыерлардан ничә бозауны үстереп җиткерә алдың?»— дип сорадылар. «Унҗиде сыердан — унсигез бозау»,— дип җавап бирәм. Көләләр. «Әй апа, фермада эшләмәсәк тә, без бит аңгыралар түгел, бер сыерның елга бер генә бозау китерүен беләбез, әле анысын да аякка бастыруы кыен, азык юк, күбесе тууга кырыла бара, син шаяртма безне!»— диләр. Мин бүтәнчә дәшмәдем, ферма мөдире генә сөйләде. Әй, кызык та сөйли иде инде. «Иптәшләр!— ди,—

Мәсуфә Мортазинаның, ызначытсы, бер сыеры игез бозау тапты. Шуңа күрә, ызначытсы, иптәш Мортазина унҗиде сыердан унсигез бозау үстерүгә ирешә. Бүгенгесе көндә, ызначытсы, беренчелеккә ул чыкты...»

Әнисенең сүзен бүлеп, Илдус көлеп җибәрде.

— Әнинең ул көнне эштән кайтып кергәнен бүгенге кебек күз алдында тотам мин. Ишектән керде дә бусагага утырды. Шунда ук мөдире булып сөйләп күрсәтергә тотынды. Үзенең беренчелекне алуын да, ВДНХга җибәрергә карар чыгаруларын да, бүләккә бер бозау бирүләрен дә соңыннан гына әйтте. Һаман мөдир сүзләреннән көлә. «Тел төбенең мине мактап кыймылдавын да тоям,— ди,— ну, бер сүзен һич аңламыйм: «ызначытсы» — нәрсә соң ул?» ди...

— Заманасына күрә булган инде, юк кына нәрсәләрдән юаныч табып, көлке чыгарып яшәгәнбез.— Мәсуфә апа моңсу да, горур да кебек.— Кунагына күрә — өйрәсе, диләр, менә шул инде ул.

Ана: «...минекенә җиткерсеннәр әле!»нең ни икәнлегенә төшендеңме? — дигән кебек миңа карый. Аңламаган кая?! Алты ятим белән ач калган хатынның колхоз файдасына кылган эше Мәскәүләргә барып җиткән икән, баштин-аяк механикалаштырылган хезмәттә дә гадәтиләрдән генә саналучы бүгенгеләр хакында тел әйләндереп уңай сүз әйтү, бәлки, урынсыздыр, димәкче була ул, балаларының даны бөтен илне шаулатмаганына моңсулана кебек. Шул ук вакытта аның горур кыяфәтен дә аңларга була: бүгенге көннең иң гадәти хезмәте дә илгә күпме муллык китерүен ана бик яхшы белә.

— И-и-и, ул еллардагы хәлләрне сөйләсәң, хәзергеләр ышанмас та! — ди ул.— Көннең көн буена оланнар белән бергәләп кыр буенда йөри идек, колхоз амбарына алып кайтып тапшырган байлыгыбыз бер чиләк башак була. Хәзер бит меңәрләп кенә исәплиләр!..

— Мең генә түгел шул, әби!— Әңгәмәбезгә аз сүзле Сәгыйдулла кияү кушылды.— Быелгысы елда безнең Чистай районының дәүләткә сатканы гына да Татарстанда иң күп ашлык булып чыкты. Беләсеңме күпме — бер миллион йөз дә илле мең центнер! Аны потларга әйләндерсәң, зиһенеңне таратырлык зурлык килеп чыга, әби,— алты миллион тугыз йөз мең пот була ул, белдеңме?!

Сәгыйдулланың сүзен Мәсуфә апаның шофер улы Ирек куәтли.

— Бер башлагач, әйтеп бетер инде син, җизни!— ди.— Шул ашлыкның утыз алты мең потын мин суктырдым диген! Ташый-ташый да хәлдән тайдык.

Сәгыйдулла, Ирек кайнише кушканча, мактанырга ашыкмый ашыгуын, шулай да аның өзлексез елмаеп торуыннан да, эшләү өчен, мөмкинлеген тудырып торган табигатькә рәхмәт белдергәндәй, куш кулын әледән-әле күккә күтәреп: «Их! Алдан килгән булсагыз, мин сезгә быелгы әпәйнең бункердан ничек акканын күрсәтер идем. Бетердек бит! Коп-коры чакта, зыян-зарарсыз бетердек уракны!»— дип куюыннан да шул ук тойгыны, ул көнәрдә Мәсуфәнекеләрнең һәммәсе кичергән горурлык хисен сиземләргә мөмкин иде...

Буби Пивникка Иске Роман авылының шушы бер көнен генә тасвирлап язсаң да, Чистай районының бүгенге куанычлы тормышы аңлашылыр кебек. Калганнары турында, я ул безгә кайткач, я Таллинда очрашкач, энәсеннән-җебенә кадәр тәмләп бер сөйләшербез әле.

Фәүзия Бәйрәмова

# ТЕГЕРМӘНЧЕ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Дөньяның тегермәннәре күп төрле...

Бар җил көченнән дә зырылдап әйләнә торганнары, бар су агымы килеп бәрелгәч кенә шаулап эшли башлаганнары. Ягулык ягып, электр куәте белән хәрәкәтләнгәннәре дә бар. Нинди генә көчләргә җайлашмасыннар, кеше аңының, фәннең нинди генә мөмкинлекләреннән чыгып камилләшмәсеннәр — тегермәннәр бер үк вазифаны үтәгән, алар гомер буе он тарткан! Гасырлар буе кешегә ипи ашаткан.

Кешелек дөньясында башка төрле тегермәннәр дә бар икән...

Он әзерләүче тегермәннәрнең ипиен ашап үскән кешеләр беркөнне бөтен тегермәннәр уйлап таба башлаган. Ул тегермәннең ташлары астында калып илләр көлкүмергә әйләнгән, улаклары буйлап он түгел, кан аккан...

Җир шары әйләнгән дә әйләнгән...

1934 нче елда, Советлар иленең Югары Тегермәнлек авылы тегермәнендә Миңлешаһ Мөхәммәтша улы Мөхәммәтшин эшли башлый. Яңа оешып килгән колхозларны ныгытыр өчен, аякка басып килүче халыкка иминлек, туклык бирер өчен...

Ул еллар — фашистик Германиядә башка тегермән, үлем тегермәненең котырынып әйләнә башлаган чагы. Тегермәнчесе дә башка, максаты да — бөтен дөньяны шул үлем тегермәне аша уздыру, юк итү, көл итү.

Җир шары әйләнә дә әйләнә...

Югары Тегермәнлек авылында беренче колхоз төзелә. Тегермәнче Миңлешаһ белән колхоз ударнигы Миңсылуның берсеннән-берсе тере, берсеннән-берсе матур балалары үсеп килә. Тегермән улагыннан ап-ак, җылы он ага. Бәхет ага. Тегермән бер көйгә гөрләп кенә әйләнә дә әйләнә.

Дөньяның башка бер тарафында, башка бер тегермәннәрнең тимер ташлары астына чәчәктәй илләрне салып әйләндерәләр. Ашлык тегермәннәренең күңелле гөрелтесе аларга ошамый, алар нәкъ әнә шул тегермәннәргә каршы, кешелеккә, яшәешкә, тынычлыкка каршы үлем тегермәнен көйләп җибәрәләр. Каршы тора алырсыңмы, Советлар иленең Югары Тегермәнлек авылы тегермәнчесе Миңлешаһ Мохәммәтшин?! Җырың ярты юлда өзелмәсме, мәңгегә тукталып калмасмы Сула суы буендагы бу кечкенә генә колхоз тегермәне?..

Миңлешаһ тегермәне исән-сау.

Кешелек тарафыннан кискен-кискен сораулар куелганга да инде кырык ел вакыт үткән. Үлем тегермәне көйләүчеләрнең инде үз сөякләре тузанга әйләнгәндер. Советлар иленә нәфрәт белән караучы дәүләтләрнең яңа үлем тегермәннәре янына инде ничәмә сугыш чукмары басып карагандыр. Дөньяга яңа хәвеф, шом салып, күпме президентлар килеп киткәндер. Ә Югары Тегермәнлек авылы тегермәне һаман шул урынында тора. Янында ап-ак сакаллы, ап-ак чәчле татар карты Миңлешаһ... Әйтерсең лә, безнең мондый тегермәннәр мәңгелеккә дип салынганнар! Советлар иленең үзе кебек. Яңарып, үсеп, камилләшеп, киләчәктә дә тынычлык сагында тору өчен, кешеләргә иминлек, бәхет китерү өчен!.. Тегермәнче Миңлешаһ карт та үткәннәрдән киләчәккә күчеп бара.

Совет кешеләренең рухи ныклыгына, Ленин күрсәткән юлдан тайпылмыйча һаман алга баруларына чит илләрдә торып-торып гаҗәпләнәләр. Әйе, аларга безнең яшәү рәвешебез ят, максатларыбыз аңлаешсыз, алар без ирешкән азат тормышка шикләнеп, киләчәк планнарыбызга ышанмыйчарак карыйлар. Чөнки алар бу илнең Миңлешаһ Мөхәммәтшин кебек миллионлаган хезмәт ияләре барлыгын, тормышның шундый нык кешеләр җилкәсендә торганлыгын аңлый да, кабул итә дә алмыйлар. Совет чынбарлыгын бозып, безнең илебез, аның кешеләре турында төрле уйдырмалар тараталар, ялган, нигезсез фәлсәфәгә бирeләләр. Ә чынбарлык бер генә — ул менә шул миллионнарның берсе булган Миңлешаһ Мөхәммәтшинның тормыш юлы, яшәү

рәвеше. Аны тагын бер тапкыр күздән кичерик, хезмәт кешесенең батырлыгына тагы бер тапкыр сокланып, хәтерләребездә аңарга һәйкәл салыйк...

...Бу авылның болыннары — болынча, урманнары — урманча, кырлары кырча сакланган. Балык бистәсе районында, гомумән, табигать үз матурлыгын югалтмаган, һәр авылда, һәр колхозда зур төзелешләр, үзгәртеп корулар алып барылса да, алар табигатькә зыян китермичә башкарылган. Быел Югары Тегермәнлек авылы кергән Тукай исемендәге колхозда меңләгән башка исәпләнгән дуңгызчылык комплексын төзү тәмамланып килә. Авылның үз урта мәктәбе, больницасы бар, балалар бакчасы өчен дә бик матур бина салынган. Шунысы иң куандырганы: хуҗалыкның һәр тармагындагы кадрлар — колхозның үз кешеләре. Врачы да, укытучысы да, төзүче-прорабләры да, игенче-терлекчеләре дә шушы авылда туып үскән, шушы авылда яшәп калган, шушы авылда, шушы җирдә гөрләп торган тормыш алып баручы кешеләр алар. Миңлешаһ карт — шуларның берсе, гомер буе авыл халкын онлы, ипиле иткән, гомер буе халыкның рәхмәтен ишетеп яшәгән мөхтәрәм ил карты.

Аңа инде 80 яшь тулып килә. Ул гомер буе тегермәндә эшләде, сыңар кулы белән ярты гасырдан артык бәрәкәт, иминлек сагында торды. Аның тормыш юлы хезмәткә мәңгелек һәйкәл сыман, Советлар илендә хезмәт кешесенең дәрәҗәсен, хөрмәтен сурәтләүче һәйкәл сыман.

Кеше үзен хезмәттә күрсәтә, хезмәтендә ачыла, зур мәртәбәләргә ирешә. Җирдә кешеләре эшкә, хезмәткә тилмереп йөрүче илләр дә бар бит. Буржуаз дөньядагы эшсезләр саны миллионлап санала. Яшьләрне мәктәп эскәмиясеннән эшсезлеккә, кимсетелүләргә озатып калалар. Картлыкларында да аларны Миңлешаһ бабайга күрсәтелә торган кадер-хөрмәт көтми. Капитал дөньясының иң бай дип саналган илләрендә дә тәрбиячесез картлар ачлыктан, хәерчелектән газап чигә. Тормышларында һичнинди өмет яктылыгын күрә алмыйча, үз-үзләренә кул салучылар да очрый. Шул рәвешле алар үз илләрендә яшәп килгән законнарга, рәхимсезлеккә, битарафлыкка протест белдерәләр.

Совет иле кешеләренә мондый язмыш ят. Алар үзләренең картлыкларын кадерхөрмәт эчендә, хөкүмәтнең зур кайгыртучанлыгын, игътибарын тоеп, якыннарының, балаларының түрләрендә каршылыйлар. Алар — зур тормыш юлы үткән, искиткеч тәҗрибә туплаган зирәк аксакаллар. Халык бүген дә киңәш сорап алар янына, шул Миңлешаһ картларга бара икән, зур эшләргә ниятләгәндә, фатихасын алардан ала икән — бу да советча яшәү рәвешенең матур бер чагылышы.

Бүген Миңлешаһ картның янында — биш улы. Алар үзләре бер урам төзеп, авылдашларын сокландырып, бер диген итеп яшиләр. Аталарының йорты — урамның башында, гомерләренең башында. Аталарының тормышы — алар өчен иң якты үрнәк, аталарының сүзе — биш малай өчен дә закон.

Бердәнбер балаларыннан кадер-хөрмәт күрә алмаган ата-аналар өчен дә гыйбрәтле язмыш бу. Балаларын туган җирдә, үз яннарында калдыра алмаучыларга да, бәлки, бу гаилә тормышына күз салырга, өйрәнергә кирәктер? Бәлки Миңлешаһ бабайның үзеннән сорарбыз: бу кадәр бердәмлекнең, бу кадәр хөрмәтнең сере нәрсәдә икән?

— Серме? Сере — тегермәндә, олаң, хезмәттә.

Миңлешаһ бабай сыңар кулы белән түбәтәен иплебрәк куя. Мин ирексездән берсе-берсе ничәшәр центнер торган авыр тегермән ташларын, әле ашлык, әле он белән тулган потлы капчыкларны күз алдына китердем. Аларны урыныннан кузгатуы бер куллы түгел, ике куллы кешегә дә авырдыр. Тегермәнче аена ике тапкыр ул ташларны күтәртеп куеп, төшергә-үткерләргә тиеш бит! Ул капчыкларны урыннан-урынга күпме күчереп йөртергә туры килмәгәндер?! Тегермәндәге күпме хезмәт шул сыңар кул белән башкарылган! Тегермәнче Миңлешаһ бу ташларны кулы белән генә түгел, йөрәге, җаны белән дә күтәргәндер.

— Янымда һәрвакыт балаларым булды. Олы кызым Гөлчирә дә, биш малай да тегермәндә, үз янымда үстеләр. Минем уң кулым — балаларым ул. Ә йортны, хуҗалыкны һәрвакыт карап, барлап алып баручы әниләре булды. Тату гомер иттек без...

Миңлешаһ бабай бүген дә хатынын зурлап, яратып тора, аңа «анасы» дип кенә эндәшә, ә Миңсылу әби картын йомшак кына, тыныч кына «бабасы», «наный» дип йөртә. Үзе бер моң кебек гомер бит бу, үзе бер җыр кебек!

Малайларына да әтиләренең иң күркәм гадәтләре күчкән. Бу гаиләдә хатын аеру, ир ташлау — ят нәрсә. Эчү, тавыш чыгару, яманат белән халык теленә керү юк. Аларның данын таратkan, исемнәрен шаулаткан нәрсә — ул эш. Хезмәт. Ифрат та күңел биреп, ифрат та эчкерсезлек, осталык белән башкарылган намуслы эш.

Олы улы Бәдамшаның инде үзенә илле яшь, гомер буе техника белән «җенләнгән», хәзер амбарда механизатор булып эшли. Авылдашлары Бәдамша турында: «Ул машиналар телен инженерлар белән бер дәрәҗәдә белә»,— дип сөйлиләр.

Бәдамша абыйның инде үзенең дә биш баласы үсеп буйга җиткән. Тик шулай да ул гаиләсендә бер генә җитди эшне дә әтисе белән киңәшләшми эшләми.

— Әти ул безнең командир кебек,— ди Бәдамша абый.— Ул һәр көнне барыбызны да бер әйләнеп чыга. Аның сүзеннән узып, берни эшләмибез.

Икенче малай Хәйдәр — тракторчы. Мин аны кара тиргә, майга батып, трактор ремонтлап яткан вакытында очраттым.

— Әтиме?— Май арасыннан Хәйдәрнең ап-ак тешләре генә ялтырап күренә.— Әти мировой кеше ул безнең. Ул — безнең генә түгел, бөтен авылның киңәшчесе.

Шул чагында Хәйдәр, эшеннән аерылмый гына, сугыш елларында әтисе белән булып узган бер вакыйганы сөйләде. Миңлешаһ бабай үзе телгә алмаган иде. Ул, гомумән, үзе турында күп сөйләргә яратмый.

— Эшләдек, олан. Шулай эшләргә кирәк иде,— ди дә, тегермәне ягына карап уйга бата. Соңгы вакытта Миңлешаһ бабай тегермәндә эшләми инде. Алай да тегермән буйларын көн дә бер әйләнеп кайта. 53 ел таптаган сукмактан, әкрен генә, үз җаена гына Сула суы буендагы тегермәненә төшеп менә.

— Кодрәтеннән килсә, бүген төшеп, яңадан эшли башлар иде шул тегермәненә.— Монысын Миңсылу әби әйтә. Ул да күп сөйләшми, сүзгә сирәк катнаша. Татар хатын-кызларына хас булганча, күбрәк ир-ат сөйләгәнне тыңлый, аның киңәшен тота. Сөйләгәннәре дә, күбрәк, кеше алдында, балалары алдында Миңлешаһ бабайның абруен күтәрү өчен була.

Теге вакыйганы Миңлешаһ бабайның хәтеренә төшерергә тырышам. Күбрәк мин сөйлим, ул тыңлый гына, ахры. Әллә миңа гына шулай тоеламы? Әнә бит зәңгәр күзләре бер яктыралар, бер кырысланып, уйчанланып китәләр. Бабай ул елларда күргәннәрен тагын бер тапкыр җаны аша үткәрәдер кебек...

1942 елның көзендә була бу хәл. Игеннәр сугылмаган, ир-ат — фронтта, кырда — хатын-кыз, карт-коры, бала-чага. Берәм-сәрәм калган ир-атларның кайсы аяксыз, кайсы кулсыз... Җыелган игенне тизрәк суктырырга, дәүләткә тапшырырга, чәчүлек орлыкка салып куярга кирәк. Ә молотилканы эшләтерлек куәт юк, ни булган техника да фронтка җибәрелгән. Нишләргә? Авыл халкы җыелып, чарасызланып, тегермәнче Миңлешаһ янына килә.

Икенче көнне, көзге сүрән таң беленеп кенә килгәндә, Миңлешаһ абзый, сыерын җитәкләп, Чистай ягына чыгып китә. Берничә көн югалып торганнан соң, сыерын бер двигательгә алыштырып, халыкны шаккатырып, арып-ватылып Югары Тегермәнлеккә кайтып егыла. Шул көнне үк, үгез җигеп, двигательне арбага салып, кырга чыгып китәләр, молотилканы көйләп җибәрәләр, көне-төне ашлык суктыралар. Үз кырларында игенне суктырып бетергәч, күрше авылларга да булышалар...

Сугыш елларында, өч баланың ризыгын өзеп, карап торган сыердан колак кагарга һәркемнең тәвәккәллеге җитми. Әле хәтта хәзер, тыныч елларда да, әнә сонә кадәр ябышып ятучы кешеләр азмы?

— Шулай кирәк иде, олан. Заманы шундый иде.— Миңлешаһ бабай ул турыда күп сөйләргә яратмый. Һәм мин ышанам, әгәр кирәк икән, ул бүген дә, сөйләминитми генә, ил өчен барысын да эшләячәк. Ил үзе дә нәкъ менә шундый кешеләрне хөрмәтли, шундыйлар белән көчле дә ул.

Кабат бүгенге Югары Тегермәнлекнең киң урамнарына чыгыйк әле! Менә бу шыңгырдап торган сап-сары нарат бүрәнәләрдән салынган йорт — Миңлешаһ бабайның өченче улы Ханнанныкы. Ул да механизатор булып эшли. Йортын биш

туган бергә җыелышып салганнар. Малайлар өйләнгәч, башта төп йортта торалар икән, аннан туганнар бергә җыелып, яшь гаиләгә йорт салып бирәләр. Эш башында — әтиләре. Киңәше, мәгънәле сүзе белән, тәҗрибәсе, зирәк акылы белән ярдәм итә.

Дүртенче малай Мәүлә төп йортта калган. Анысы шофер. Ул өйдә бик сирәк күренә. Аз сүзле, тыныч, эшчән ир. Төп нигезне дәвам итәргә лаеклы кеше.

Төп йортта әле малайлар хезмәт иткән частьлардан килгән мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары һаман саклана. Алар төрле-төрле җирдә — Мәскәүдә дә, Урта Азиядә дә, хәтта ерак Монголия далаларында да хезмәт иткәннәр. Ләкин шаулап торган Мәскәүдән дә, әкияттәгедәй гүзәл Ташкент якларыннан да, Монголия сопкалары арасыннан да юл бары тик бер генә якка — Югары Тегермәнлеккә алып кайткан. Дөньяның нинди генә урыннарында булсалар да, Миңлешаһ абзый балалары үз авылларын ташламыйлар, дөньяның нинди генә кешеләре белән аралашсалар да, туган йортның җылысы, ата-ана киңәшләре аларны бергә тарта, монда калдыра.

Менә, килә-килә, төпчек малай Ибраһим йортына да килеп җиттек. Ибраһим күршедә, берничә йорт аша гына яши. Ул да механизатор, тракторда эшли. Яшьләрнең тормышлары матур, хуҗалыклары нык. Биш йортны бер итеп уйнап йөрүче сабыйлары бар. Ә иң зур байлыклары — һәрвакыт киңәш биреп, ярдәм итеп торучы ата-анасы, өлкән туганнары. Ибраһим — туган җирендә үсеп, тамырларын шактый тирәнгә җибәргән зур агачның бер тармагы кебек.

Шулай итеп, әтиләре тарттырган оннан пешкән күмәчне ашап үскән биш егет хәзер Югары Тегермәнлектә үзләре иген үстерәләр, кешеләргә икмәк ашаталар, балаларын тәрбиялиләр. Һәм аларның да балалары шушы җирдә калырлар, шушы кырларга хуҗа булырлар. Югары Тегермәнлек авылында Миңлешаһ бабай нәселенең яңадан-яңа буыннары үсеп чыгар, аларның урамы тагы да зураер, әнә ул кырларгача дәвам итәр.

Җир шары әйләнә дә әйләнә...

Югары Тегермәнлек авылы кырларында шаулап иген үсә, тегермән улагыннан ап-ак, җылы он ага...

Ә дөньяның башка бер почмагында иген үсәргә тиешле мәйданнар үлем полигоннарына әйләндерелә. Тегермәннәре — он тарттырмый, кешелек язмышы, илләр язмышы белән көч сынаша. Тынычлык тегермәннәре белән үлем тегермәннәре бүген дә ярышта.

Безнең илебез, бөтен дөнья иминлегенә өчен борчылып, Тынычлык программасы кабул итте. Без ашкынып кораллануны туктатырга, атом-төш коралын җитештерүне тыярга чакырып, бөтен кешелеккә мөрәҗәгать белән чыктык.

Рейганнар дөньясы исә үлем коралларын күбрәк таратырга, ил белән ил сугышуын тыныч кына читтән карап торырга тырышалар.

Тегермәннәр дуэльдә...

Кайсы җиңәр? Кайсысының җиңүгә хакы зуррак? Без беләбез: Җир шарын үлем тегермәненә салып әйләндерергә берәүнең дә хакы юк. Дөнья иминлеге өчен, кирәк икән, Миңлешаһ картның өрлектәй уллары күтәрелер, Югары Тегермәнлек калкыр, Совет иленең бөтен халкы бер булып чыгар!

Җир шары һаман әйләнә дә әйләнә. Ул үз өстендә Югары Тегермәнлек авылын да, аның ондай ак чәчле мөхтәрәм Миңлешаһ картларын да, кара капитал дөньясының өмете киселгән адәмнәрен дә әйләндерә. Әйләнә генә күрсен! Без аның бәхет ягына, матур тормыш ягына, хаклык, тынычлык ягына әйләнүенә нык ышанып яшибез.

## Ләбибә Ихсанова

# ЮЛ КЕШЕСЕ — ЮЛДА

Поезд шәһәргә якыная башлагач, һәркемнең күзе тышта булды. Менә Займище тукталышына җитеп киләбез, тиздән Казан да күренер. Уң якта — футбол кырыдай тигез, якты Идел, җиргә чүккән Ослан таулары, сулда кара-яшел чыршы урманы, карга чумган дача өйләре, юл читендәге челтәрле тимер баганаларның берәм-берәм артка шуышулары күренә. Тукталышны узгач, тимер-бетон корылмаларга җитәрәк, урыннарыбыздан кубып, тәрәзәгә капландык. Идел аша салыначак яңа олы юл күперенең субайларын барыбызның да күрәсе килә иде. Бигрәк тә командировкага килүче юлдашыбыз кызыксынып, гаҗәпләнгән сыман әйтеп куйды:

— Сала да башлаганнар икән инде!

Эшләнгән эш ул гынамы соң, дигәндәй, тәрәзә янында утырган ханым:

— Иделдә күпме ком юдырганнарын күрсәгез икән! — диде.

Купедагы дүртенче юлдашыбыз аңлатып бирде.

— Суның тирән урынына җиткәнче, ком өйдерәләр бит, күпер шуннан гына башлана,— дияргә ашыкты ул.

— Ә бусы нинди баганалар соң?

— Путепровод булачак ул. Өстеннән машиналар чаба, астан — поездлар.

Булачак юл үткәргеч астыннан поезд, күп булса, бер-ике минут узып киткәндер, ә шул турыдагы сүз Юдино станциясенә килеп җиткәнче сузылды. Мин шушы төзелештә эшләүче Факия ханым Хәбированы белә идем. Юлдашларыма аның турында да сөйләргә теләдем, ләкин вакыт аз калды. Аннан соң кайтып җитү, төшәргә җыену ыгы-зыгысында сүзнең кадерен дә җибәрәсем килмәде. Аның тормышы аерым утырып сөйләшерлек, кызык та, гыйбрәтле дә, шуның белән бергә, һәрбер совет кешесенә хас булганча, гадәти дә.

Һәрбер чор үзенең проблемаларын, яңалыгын, темпын алып килә. Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорны гына искә төшерик. Кешеләрнең ул вакыттагы омтылышын аңлау кыен түгел. Шундый зур афәтне кичергән халкыбыз тормышны аеруча бер нечкә хис белән кадерли белә иде. Тыныч тормышка сусаган кешеләр аерым бер дәрт белән үҗәтләнеп, илебезне аякка бастырырга керештеләр. Илленче еллар башында Бөек Идел каскадын төзү башланды. Аның бер өлеше — Казан шәһәрен судан саклау корылмалары булып, бишьеллыкның төп бурычларыннан санала иде. Казан шәһәре биш диңгез порты дип аталды. Казанка елгасының яңа юлы, бетонга төрелгән яр буйлары, яңа порт корылмалары турында радио һәм газеталар гел сөйләп, язып тордылар. Яшьләрне бөек төзелешләргә өндәгән очерклар, яңа җырлар, хикәяләр иҗат ителде.

Менә шушы күтәренкелек Актаныш районы «Игенче» колхозы кызы Факияне дә Казанга алып килде. Эшен ул бик гадидән, җир казудан башлады. Казанка елгасының булачак яңа ярыннан шәһәр тирәли биек вал өелергә тиеш иде. Күбесенчә үзе кебек авыллардан килгән кызлар белән бергә Факияне шунда җибәрделәр. Иптәшләре аның чаялыгын, өлгергәнлеген, ярдәмчеллеген бик тиз күреп алдылар. Аның белән дус булырга теләүчеләрнең тагын бер сәбәбе бар иде — Факия җырларга ярата, тавышы моңлы, матур. Тальян гармун — яннарында. Гармунчы да ялындырып тормый, ял итәргә утырдылармы, туган ягының моңы-сагышы тулы күңеле белән Факия җыр башлап җибәрә.

Озакламый Казанга Мәскәү трестының алтынчы күпер төзүчеләр отряды килеп төшә. Дамбалар, насос станцияләре кебек инженерлык корылмалары белән бергә Казанка елгасында күперләр дә салырга кирәк була. Җитмәсә, шәһәр үзәген Ленин районы белән тоташтыручы Кремль янындагы күперне иң кыска срокта 1956 елның беренче маена салып бетерү бурычы куелган. Отрядка эшчеләр туплаганда, күпер төзү эшенә шәһәрне судан саклау оешмаларыннан да кешеләр җибәрәләр. Егерме кешелек бетончылар бригадасы оештырып, Факия дә шунда килә.

Ул вакыттагы техниканы күз алдына китерсәк, шактый авыр һәм зур күләмдәге эш була бу. Үзебезнең көндәлек мәшәкатьләребез белән без хәзер бу күперне хәтта күрмибез дә кебек. Аңар күпме көч куелганын уйлаганыбыз, карлы бураннарда, кышкы әчы салкыннарда эшләгән кешеләрне бер генә тапкыр булса да күз алдына китергәнебез дә юктыр. Алар бит — хөкүмәтебез куйган бурычны намус белән үтәп, ничәмә-ничә буынга җитәрлек мәңгә дигән истәлек калдырган кешеләр.

Моннан байтак еллар элек, Рига шәһәренә беренче баруымда, балалар журналы «Берниба»ның әдәби хезмәткәре Юлия ханым Авексис мине истәлекле урыннар белән таныштырып йөргән идә. Менә бу — Петр I утырткан агач. Ул йортны фәләненче йөздә фәлән архитектор эшләткән, Туганнар каберлегендәге яшь иманнар латыш халкының көч-куәтенә ишарә дип сөйли-сөйли, борынгы шәһәр буйлап ул мине бик озак йөртте. Шул чагында Рига турында кызык кына бер легенда да сөйләгән иде: Даугава елгасындагы бер утрауда Дәү Кристя дигән кеше яшәгән, имеш. Бер төнне бала елаган тавышка уянып киткән бу. Чыгып караса, ишеге төбендә яшь бала ташлап калдырганнар. Кристя, баланы кызганып, җылы урынына кертеп салган, озакламый үзе дә йоклап киткән. Иртән торса... бала урынында бер өем алтын ятканын күргән, ди. Кристя шул алтынга Даугаваның диңгезгә койган җирендә шәһәр салдыра башлаган, ләкин салдырып бетерә алмаган, үлеп киткән. Менә шуннан башлап, ел саен килә дә икән ул, шәһәрне салып бетердегезме әле, дип сорый икән. Аңар, юк, дип җавап бирәләр ди. Әгәр шәһәр салынып бетсә, Кристя аны су төбенә алып төшәчәк, имеш.

Легенда легенда инде ул. Тик аның чынлыкка туры килгән ягы да бар. Чөнки шәһәр елдан-ел яңара, зурая, чыннан да аны салынып бетте инде бу, дип берничек тә әйтеп булмый. Тик бер генә нәрсә үзгәрми — ригалыларның шәһәрләрен ярату хисе һәм аны чиста итеп тоту гадәте.

— Без үзебезнең шәһәребезне бик яратабыз. Аның турындагы кечкенә генә истәлекне дә кадерләп саклыйбыз. Ял көннәрендә мин улым белән шәһәргә чыгам да, менә сезнең белән йөргән кебек, аңар барын да сөйлим. Кечкенә чагымда мине әтием шулай йөртә иде — дигән иде Авексис ханым.

Яратуын без дә үзебезнең Казаныбызны яратабыз, тик менә ригалылар кебек кадерләп тоту гына җитми кебек. Без дә урамнарыбызның, андагы йортларның тарихын балаларыбызга, оныкларыбызга күбрәк сөйләсәк, шәһәребездә пычрак ишегаллары, каерылган рәшәткәләр, лампочкалары ватылган электр баганалары булмас иде, мөгаен.

Шулай да сүзебез Факия һәм күперләр турында бит әле.

Казанка күперен салган вакытта алтынчы мостотрядка килеп кушылган Факия, 1979 елда туган ягына яңадан әйләнеп кайтканчы, гомеренең иң күп өлешен шушы коллектив белән үткәрә. Шунда ул һөнәргә өйрәнә, чын дусларын шунда таба, олы бәхетнең ни икәнен шунда белә. Соңыннан, шактый еллар үткәч, трестның 25 еллыгына чыгарылган кечкенә брошюрада аның турында менә мондый юллар бар: «...бу вакытта мостотрядның төрле милләттән торган дус гаиләсенә татарлардан да зур коллектив килеп кушылды. Алар соңыннан Рыбинск һәм Ярославль күперләрен салганда да бәя биреп бетермәслек зур хезмәт күрсәттеләр... Аларның бер өлеше соңыннан башка төзелешләргә китте. Яхшы күңелле кеше, арматура эшләренең менә дигән остасы, дистәдән артык арматурачыларның укытучысы, ничәмә-ничә тонна арматура корычыннан катлаулы конструкцияләр ясаучы, РСФСРның атказанган төзүчесе Факия Исламгалиевна Хәбирова исә алтынчы мостотряд коллективыннан аерылып китмәде».

Ул вакытлар турында сөйләшеп утырганда, Факиянең: «Кадерле генә булып йөрдем шул үзем дә»,— дип әйткәне бар. Тик менә шундый кадер-хөрмәткә ирешкәнче, Факия Исламгалиевнага эштә үзен күрсәтергә, берничә төрле һөнәрне, кешеләр бе-

лән эшләү осталыгын үзләштерергә кирәк була. Аның йөргән юлларына карап кына да илебез үзгәренең географиясен өйрәнергә мөмкин булыр иде: Казан, Рыбинск, Ярославль, Кострома, Кимры, Рязань...

Ул үткән юлларда челтәрле күперләр, бетонга төрелгән яр буйлары, киң дамбалар, нык буалар, юл үткәргечләр төзелеп калган.

Факиянең әтисе Исламгали солдат, фронттан кайткач, казылып-актарылып яткан иген кырлары, кое сиртмәләре генә тырпаеп утырган өйсез авыл урыннары, җимерелгән шәһәрләр, шартлатылган күперләр турында әрнеп сөйли торган булган. Сугышларда йөреп алҗыган карт солдат бу җирләрнең озакламый аякка басуына, кеше яшәрлек хәлгә килүенә шикләнеп тә караган. Ата ул чагында кызының зур төзелешләрдә эшләячәген күз алдына да китерә алмаган. Чөнки әле ул еллар — Факиянең колхозларында печән чабып, иген үстереп, урман кисеп йөргән чагы. Кызның илгизәрлеге әтисенең әнә шул кайгылы хикәятләрен тыңлаган елларда тугандыр, бәлки.

— Бер җирдә эшне түгәрәкли башлауга, яңа урынга барасы килеп, атлыгып тора идем,— дип сөйли ул.

Юл төзүче, күпер салучы, электр манараларын монтажлаучы, нефть бораулаучы, геолог кебек һөнәр ияләренең холкын аңлау шактый кыен. Уртак тормышта җайлы гына эш таба алмаслык кешеләрмени?! Юк бит, олыгаеп чәчләре агара башлаганда да романтик җанлы булып калган, үз эшләренә фанатикларча бирелгән кешеләр алар. Коллективлык, дуслык көче аларда аеруча зур.

Факиянең инде оныклары үсеп килә. Шулай да бергә гомер иткән коллективы белән араны өзми, гел хәбәрләшеп, күрешеп тора. Шулай бер көнне, бөтенләй башка нәрсәләр турында сөйләшеп утырганда, кинәт исенә төшерде, ахры, иреннән:

— Иртәгә билеткә барасыңны онытмадыңмы? — дип сорап куйды.

— Сәфәргә җыенасыңмы әллә?— дим.

— Котдусның елы башлана. Ярославльгә барып кайтырга кирәк, дустыбыз авырып киткән.

Факиянең «кадер» сүзенә салынган мәгънәне дә үзенчә аңларга кирәк. Элек-электән иң җаваплы эшне тапшырсалар, ул аңа хөрмәт итү дип караган. Бердәнбер кызлары Флүсә Казанда урнашып, гаиләсе ишәеп киткәч, яшьләргә булышмыйча ярамый, эшләгәндә балалар үстерү җиңел түгел дип, әти белән әни кеше туган якка кайтып төпләнәләр. Ә бит Факияне Мәскәүнең үзенә чакырып торган чаклары да булган.

Башкалабызны күрмәгән һәм аның метроларында йөрмәгән кешеләр аздыр. «Спортивная» станциясен үтеп, Ленин тауларына барганда, җир астыннан килгән поезд кинәт кенә якты дөньяга атылып чыга да күз алдына бик матур панорама ачылып китә. Мәскәү елгасының бер ягында Лужники спорт комплексын, каршы ярда мәскәүлеләрнең яратып ял итә торган җире — Измайлово паркын күреп каласың.

Менә шушы метро күперен Бөтенсоюз удар төзелеше дип игълан итеп 1958 елда сала башлыйлар. Илебезнең төрле җирләреннән күпләп-күпләп эшче көчләр килә башлый. Иң яхшы һәм тәҗрибәле эшче буларак, Факия Хәбированы да Рыбинскидан, вакытлыча, әнә шул төзелешкә җибәрәләр. Төзелеш башлауның беренче көенлыклары бирелә дә булмый калмый, әлбәттә, аңлашылмаулар да чыгып куя. Килгәненә ничә көн инде, Факиянең эшкә тотынганы юк әле. Алтындай кадерле вакытның әрәмгә үтүе кызның эчен пошыра. Гомерендә бер генә сәгать тик утыруны да белмәгән бишенче разрядлы арматурчы эшсезлектән җанын кая куярга белмичә, җитәкчеләр янына керә.

— Я миңа эш бирегез, я кайтарып җибәрегез. Тик торганга эш хакы алып ятасым килми,— ди ул.

Кызның кулына сызым тоттыралар, ярдәмгә өч кеше бирәләр дә тротуар блоклары ясарга җибәрәләр. Хәзер инде ул бик гади эш санала, элек кыен булган. Тәҗрибәле Факиянең исә куллары җитез йөргән. Иптәшләрен өйрәткән, ә үзе, алар берне ясаганчы, өч арматура бәйләп куярга өлгерә икән. Бурычны алар бик яхшы итеп үтәп чыгалар. Смена ахырында прораб — бригадирын алып килеп:

— Менә кара, конструкцияләрне ничек ясарга кирәклеген алардан өйрән,— дип күрсәтмә биргән.

Озакламый Хәбированы бригадир итеп куялар. Утыз кешелек бригаданың күбесе — ирләр. Утызында — утыз төрле холык. Шулай да чибәр һәм гадәттән тыш инсафлы, уңган һәм таләпчән кызның иркенә алар бик теләп буйсыналар. Факиянең ул чактагы рәсемен күрсәм, Такташның «үзе усал, үзе сөйкемле» Алсуын искә төшерәм.

Әгәр күз карашы сөйкемле булмаса, ихтыяр көчен күрсәтеп торучы нык кысылган иреннәр, чокырлы ияк аны шактый кырыс итәр иде. Түгәрәк нәфис йөзенә җылы нур бөркүче шомырт кара күзләр шул кырыслыкны җуя да куя. Кызның туры сүзен дә, гаделлегенә күрә, җиңел үткәреп җибәрәләр. Бәхәсләшеп тору да юк, ни кушса, шуңа ризалар.

Нәкъ шул көннәрдә утыртма баганаларга аркылы ныгытмалар кую башлана. Моны җиңел эштән санамыйлар, акча да аз төшә. Шушы бурыч тапшырылган бригада аннан баш тарта. Операцияне Факия бригадасына тәкъдим итәләр.

— Барабызмы?— ди бригадир, эш шартларын яшермичә.

— Барабыз,— диләр егетләр.— Кемгә дә булса эшләргә кирәктер бит инде аны.

Бригаданы каршы алган участок начальнигы:

— Кайсыгыз бригадир?— дип сорый.

Егетләр дәшми генә Факиягә карыйлар.

— Бригадирыгыз килмәдемени?— дип кабатлый начальник.

Шуннан соң Хәбирова җавап бирә.

— Мин бригадир.

Әзмәвердәй егетләр арасыннан каршысына какча гәүдәле яшь кыз чыгып баскач, начальник аптырап кала:

— Мондый эштә хатыннар да эшлимени?

— Ничек кенә әле,— диләр егетләр, бригадирларының дәрәҗәсен яклап.

Шул елны оештыру сәләте зур булган бригадирны, башкалабызның үзәгендә яхшы квартира тәкъдим итеп, эшкә калырга өндиләр. Мәскәүдә яшәргә кем генә кызыкмас икән. Аның һәр мәйданы, урамы, һәйкәлләре, йортлары — гомерең буе укып туймаслык кызыклы тарихи китап кебек. Ул театрлар, ул музейлар! Киноларның иң яңалары башлап Мәскәүдә күрсәтелә, үзебезнекеләр генә түгел, дөньяның атаклы җырчыларын шунда тыңларга мөмкин. Ә рәсем күргәзмәләре, бакчалар, парклар... Әмма Факия, башкала тормышы никадәр мавыктырса да, иптәшләрен сагынып, бирелгәч эше төгәлләнгәч, Рыбинскига кире кайта.

Шулай да ул метро күперен салган егетләр белән очраша әле. 1972 елда Мәскәү трестының алтынчы отрядын 25 еллык намуслы хезмәте һәм күпер салуда күп яңалыклар кулланганы өчен Почет билгесе ордены белән бүләклиләр. Юбилярны котлау өчен башкаланың Вахтангов театрына трестның барлык отрядларыннан киләләр. Фойеда киенгән-ясанган, күкрәкләренә орден-медальләр таккан чал чәчле төзүчеләр танышбелешләрен очратып, кочаклашып күрешәләр, хәл-әхвәл сорашып, салмак кына сөйләшеп йөриләр. Заманча киенгән шау-шулы яшьләр үзләре төркем-төркем булып оешканнар. Факияне белгән кешеләр бер-берсеннән сорашалар.

— Хәбированы күрмәдегезме?

— Фая Исламгалиевна килмәде микәнни?

— Мондый җирләрдән бер дә калмый иде бит...

Бу минутларда Факия Хәбирова, үзенә бер тыныч урын табып, тантанада сөйләячәк чыгышын кабатлый. Нәкъ шушы сәгатьләрдә Ярославльдә вакытыннан алда салынып беткән күперне файдалануга тапшыру тантанасы барганын да белә ул. «Ал тасманы кисеп җибәргәннәрдер инде. Иптәшләре утырган автобуслар, машиналар оркестр һәм җыр белән үзләренең яңа күперләреннән үткәннәрдер...» Күңелең белән әнә шунда булганда, ничек итеп тыныч кына сөйләргә мөмкин?! Җитмәсә, гади чыгыш кынамы әле. Әнә шул олы уңыш турында иптәшләре исеменнән бөтен трест алдында рапорт биргән кебек бит ул.

Факиягә өченче кеше итеп сүз бирәләр. Күкрәгенә РСФСРның атказанган төзүчесе һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан Хезмәттәге батырлык өчен медален кадаган яшь, чая хатын трибунага чыгып басуга, зал шаулатып кул чаба.

Андый бәхетле минутлары күп Хәбированың. Шулай бер көнне Факия ханымның дистәдән артык мактау грамоталарын, Коммунистик хезмәт бригадасы членлыгына һәм

Ярославль шәһәр советы депутатлыгына карата, Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә катнашуы уңаеннан бирелгән, хезмәт ветераны булуын раслаган таныклыкларын, транспорт төзелеше министрлыгы коллегиясе һәм тимер юл транспорты эшчеләренең профсоюзлар Үзәк Комитеты тарафыннан 1970 елда бирелгән «РСФСРның атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исемнең дипломын, 1973, 1977 елларда «Социалистик ярышта җиңүче» билгеләрен һәм башка истәлекле бүләкләрне карап утырдым. Болар — бер үк эштә бөтен көчен, тәҗрибәсен, тырышлыгын, белемен биреп эшләү нәтиҗәсе. Белем дигәннән, зирәк хатынның практик эштә алган тәҗрибәсе генә җитми инде хәзер. Төзелешләр туктаусыз катлаулана. Моннан егерме-егерме биш ел элек күзгә дә күренмәгән, колак ишетмәгән ысуллар ачылды. Алтынчы мостотряд үзе генә дә бөтендөнья белгечләре үрнәк алырлык әллә никадәр яңалыклар уйлап табып, эштә куллана башлады. Моннан унбиш еллар элек күпернең аерым өлешләрен электр белән эретеп беркетәләр иде. Хәзер бу эш махсус җилем ярдәмендә башкарыла. Ярославль һәм Кострома күперләре — нәкъ шулай «ябыштырып» салынган күперләр. Совет инженерлык практикасының соңгы еллардагы казанышларын файдаланып салынган Рыбинск күперенең рәсемен чит илләрдә басыла торган техник әдәбиятта да чыгардылар. Арматура сызымнарын аңлау өчен генә дә хәзер, ким дигәндә, урта техник белем сорала. Факия ханым да заман таләбеннән читтә калмый. Берничә тапкыр Мәскәүдә бригадирларның, мастерларның белемен күтәрү, квалификацияләрен камилләштерү курсларында укый.

1979 елда Хәбировлар гаиләсе Казанга күчеп килә. Факия яңа җиргә күчү мәшәкатьләренең беткәнен дә көтми, Саратов трестына караган өченче отрядка эшкә керә. Беренче елларында ул Хөсәен Ямашев проспектындагы һәм Оренбург трактындагы юл үткәргечләрне салуда катнаша. Унберенче бишьеллык корылмаларының берсеннән саналучы Идел күперен төзү башлангач, шунда күчә.

Өченче отряд начальнигы Анатолий Павлович Курилов Хәбированы электән үк белә иде инде. Ул аны шатланып каршы ала һәм иң җаваплы участокка, тимер-бетон конструкцияләр хәзерләү цехына мастер итеп билгели. Хәзер Факия ханым балта осталары, бетончылар һәм арматурачылар бригадаларыннан торган 30—40 кешелек коллективның эше өчен җаваплы.

План буенча бирелгән бурыч, әлбәттә, җиңел булмый. Аларның базасы елга 350 кубометр тимер-бетон конструкцияләр эшләргә тиеш. Детальләрнең төрләре кайчагында утыздан да артып китә. Конвейерга салынган автоматик эш түгел, һәркайсына игътибар белән уйлану кирәк. Факия Хәбирова бирегә дә тату, эшчән коллектив оештыра. Балта осталары бригадиры Виктор Алексеевич Дунин, арматурачылар бригадиры Валентина Георгиевна Акстина — аның иң зур ярдәмчеләре. Мастер үзе 1980 елдагы эш нәтиҗәләре өчен КПССның Казан шәһәре Мәскәү район комитеты һәм хезмәтчеләр депутатларының район башкарма комитеты тарафыннан «Районның иң яхшы мастеры» дигән мактаулы исемгә лаек дип табыла.

Йөзе җилдә, кояшта янып, көньякта ял итеп кайткан кешенекедәй каралган җиңел гәүдәле мастерның иртәнге эше цехларны карап йөрүдән башлана. Иң элек ул ап-ак болытка күмелгән парландыру камерасына кагыла. Мондагы эш тимер-бетон конструкцияләрнең ныклыгын хәл итә. Лаборантларның хәле ничек икән? Аннан ерак түгел — арматура цехы. Чуен чылбырлы күперләр өчен конструкцияләр ясау ифрат катлаулы. Бер күзен төшерсәң, челтәр дә сүтелеп китүчән, күпер салуда да шулай. Балта осталары яныннан да әйләнә мастер. Һәркайсына җылы сүз әйтә, туктап, киңәшләшеп тора. Кайчагында үзләрен аналарча әрләп тә алырга туры килә.

Бер көнне ял итеп утырганда эшчеләрдән берәү:

— Эшлисең, эшлисең, һаман акча җиткереп булмый,— дип зарланырга тотынды.

— Сиңа нәрсә җитми?— дип, иптәшләре аны кыздырып җибәрделәр.

— Машинага язылган идем лә...

Январына килеп туктаган мастер да егетнең сүзләрен тыңлап тора. Ул:

— Акчаны аны биргәнең булса гына аласың, энем,— дип куйды.

— Ничек инде... биргәнең булса?

— Син укыдыңмы? Укыдың. Менә дигән квартирада яшисең. Эшкә министр кебек йөреп киләсең. Әлегә хәтле син хөкүмәттән аласың да аласың гына. Ә үзеңнең нәрсә биргәнең бар? Бер ел эшлим, дисеңме? Ул әле, энем, алган бурычларыңны түләү генә. Инде машиналы да буласың килә.

— Әллә машина алу гаепме?

— Гаеп түгел, ал гына. Тик аңарчы маңгай тирең түгеп эшләргә кирәген онытма. Менә мин гомер буе эшләдем. Идел аша гына да дүрт күпер салдым, инде бишенчесен башладым. Иң зур байлыгым — шул минем, машиналарың бер якта торсын,— диде Факия, улы шикелле итеп егетнең чәчен туздырып куйды, сүзем бетте дигәндәй урыныннан кузгалды.

Юк, бүген ул алар янына бөтенләй башка нәрсәләр турында сөйләшергә дип килгән иде бит. Бөтен җирдә экономияле эшләү турында сүз бара. Газеталар көн дә шул турыда язып торалар. Идарәгә килдеңме, аның турында сүз булмый калмый. База начальнигы Владимир Иванович Ролихның «Фая Исламгалиевна, резервларны карагыз»,— дип искә төшермәгән көне юк. Бер уйласаң, барын да үлчәп, чамалап, норма белән тоталар югыйсә, цементны да, арматура чыбыкларын да, экономиялим дип проекттагыдан ким салып булмый. Алай да, чынлап еласаң, сукыр күздән яшь чыга, ди халык. Балта осталары әнә опалубка такталарыннан кат-кат файдаланырга тәкъдим керттеләр. Бетончылар да цементны суга чылатмый, җилгә чәчми саклап тоту чараларын күрергә булдылар. Арматура бәйләгән вакытта чыбык очларын кыскарак калдырырга мөмкин бит. Егетләр янына әнә шул турыда киңәшергә дип килүе иде аның.

Эштә төрле чак була. Әмма ни генә әйтсәң дә, үз эшен бик ярата Факия Хәбироза. Моннан егерме җиде ел элек кәрәк тотып җир казый башлаган авыл кызы — хәзер инде атаклы мастер — үз тормышыннан бик канәгать. Аның хезмәте кешеләргә юл ача. Үзе дә гел юлда, сәфәрдә ул. Бәхетле тормыш дәвам итә. Юл кешесе һаман да юлда әле.

Мария Елизарова

# СӘЛАМӘТЛЕК САГЫНДАГЫ МАЙОР

Казахстандагы Петропавловск шәһәре. 1924 ел. Яшь көч әллә ни күп булмаса да, шәһәрдә комсомол ячейкасы эшли башлый. Андагы үндүрт яшь җилкенчәкнең берсе Әшрәф була. Яңа гына комсомолга кергән кызга шәһәрдә пионер отрядын оештыру бурычы йөкләнә.

Әшрәф үзенә тапшырылган эшне зур тәвәккәллек белән башкара. Озак та үтми, егерме бала, тантаналы вәгъдә биреп, муеннарына кызыл галстук бәйләп йөри башлый. Әшрәф аларның иң ышанычлы тәрбиячеләренә әйләнә. Кыз үзенең пионерларына «бәләкәй коммунарларым» дип эндәшүчән була. Революцион чорның кайнарлыгы белән рухланган балалар, үзләрен бу исемгә лаек тоту өчен, Әшрәф нәрсәгә өйрәтсә, шуны йотып алырдай үзләштерәләр, бик авыр шартларда да «Социалистик җәмгыять мәнфәгатен яклардык» көрәшчеләр булырга әзерләнәләр.

Әшрәфне кечкенә · пионерлар гына түгел, комсомол яшьтәшләре дә хөрмәт итә. Кыз үзе исә аларга иң якты хыялы турында сөйләргә ярата.

— Мин сезнең янда озак яши алмам,— ди ул.— Бер-ике елдан хәрби училищега китәм.

— Ташла әле!— диләр аңа.— Кыз бала хәрбилеккә ярыймыни?

— Менә күрерсез!..

Күңел түрендә әллә кайларга китеп, күз күрмәгән эшләр башкару теләге ятса да, Әшрәф комсомол оешмасының үзәгендә кайный. Ул ячейканың сөлектәй егетләре арасында кызлардан бер ялгызы була. Аңа тапшырылган бурыч та җиңелләрдән түгел. Балаларын пионерга кертергә бирәү дә ашыкмый. Яшь совет властена каршы көчләр шактый җитди комачаулыклар тудырып тора. Кулак, мулла-мунтагай,

вак буржуй балалары Әшрәф эшенә дә аяк чала. Хәтта шәһәр интеллигенциясенең дә бер өлеше балаларны пионер хәрәкәте тәэсиреннән сакларга тырыша. Әллә нинди куркыныч хәлләр белән янап, алар егет-кызларны — комсомолга керүдән, балаларны пионерлар сафларына басудан тыярга азапланалар. Үз вазифаларын үтәүдә янып-көеп йөрүче комсомоллар турында гайбәт тараталар, аларның карикатураларын ясап, стеналарга ябыштыралар.

— Кешедән оялмасагыз, аллаһы тәгаләдән куркыгыз! — дип яныйлар алар.— Кыямәт көнне нинди җәза алачагыгызны чамалагыз!

Вәгазь вакытында муллалар надан халыкны өркетеп калырга ашыгалар.

— Балаларны дәнсезләр кулына бирсәгез, гөнаһысы үзегезгә төшәр...

Стрижов фамилияле бер кулак яшьләрне советка каршы котыртырга әерүче тырыша. Аның карчык әнисе дә хатын-кызлар арасында үгет-нәсихәт алып бара, аңа оныгы ярдәм итә. «Стриж» кушаматлы бу малай үз тирәсенә җыелган хулиганнар белән бергә пионерга кергән балаларны эзәрлекли. Аулак почмакта очраган пионерларны кыйнап-кыйнап ташлыйлар, кызыл галстукларын салдырып алып ерткалыйлар.

Әшрәфкә башта «Стриж» белән очрашырга туры килми. Аңардан бәла-каза күргән пионерларны кыз тынычландырырга тырыша.

— Курыкмагыз! Комсомоллар ул хулиганнарны акылга ничек утыртырга икәнен белерләр,— ди.

Көннәрнең берсендә исә «Стриж» аларның пионер отряды каршына килеп чыга. Балалар, тигез сафка басып, җыр җырлап, барабан кагып, урамнан үтәләр. Рәт башында, маршка атлап, Әшрәф бара. Өстендә кыска кара юбка белән яшел гимнастерка, иң өстеннән чалындырып, портупея кигән, башына кызыл кыекча бәйләгән вожатыйга бөтен урам сокланып карап тора.

Шул чагында отрядка Васька-«Стриж» якынлаша, Әшрәф белән рәттән атлап бара башлый. Балалар вожатыйларын кисәтәләр.

— Әшрәф апа, «Стриж» бит бу, сак бул!— диләр.

«Стриж» берни дә булмаган кебек Әшрәф белән рәттән бара да бара, марш ритмы белән тәмам мавыккан кеше кебек кылана. һәрхәлдә Әшрәф шулай уйлый: «Менә, менә, шундый тәртипсез малайларны да үз эшебезгә кызыктыра алсак, ничек шәп булачак!» — дип шатлана. Нәкъ шул чакта «Стриж» киң иттереп атлап баручы Әшрәфкә аяк чала да үзе күздән дә югала. Кыз таш юлга чатнап барып төшә. Тез башлары суелып чыга, терсәкләре каный башлый, авыртуына һич чыдарлык түгел, тик Әшрәф тешен кысып түзә, яшь күрсәтми. Вожатый ярдәмчесенә: «Сез мәктәпкә бара торыгыз, мин сезне куып җитәрмен!» — ди дә комсомол ячейкасы штабына китә.

Комсомоллар бары бер булып:

— Хәзер үк эзләп табарга да тукмап ташларга кирәк аны!— диләр.— Ул хулиганны башкача акылга утыртып булмас.

— Сез бигрәк кызык инде,— ди Әшрәф.— Хулиганга каршы хулиганнарча көрәшмәкче буласыз. Без андыйларга юлыбызның дөреслеген аңлатырга тиеш.

Әмма кызның «Стриж» кебекләрне дөрес юлга бастыру теләге алай тиз арада гына тормышка ашмый әле...

Комсомоллар шәһәр халкы арасында да чыгышлар ясыйлар, наданлыкны бетерүгә каршы көрәшәләр, якын-тирәдәге авылларга да барып-барып кайталар. Бу бригадаларны коралланган коммунистлар җитәкли, чөнки кайбер авылларда Колчактан калган акгвардиячеләр яшеренеп ята. Кайчак сугышырга да туры килгәли, комсомоллар һәлак та булгалый. Әмма Владимир Ильич Ленинның яшьләргә карата әйткән: «Укырга, укырга һәм укырга!» дигән сүзләрен тормышка ашыру эше туктамый. Ачлык, ялангачлык, җимерекелекләргә карамастан, комсомоллар аң-белем алырга, үз белгәннәрен башкаларга җиткерергә тырышалар. Комсомолның Петропавловск өешмәсе иң өметле егет-кызларны җыеп, Казанга укырга җибәрә. Әшрәф тә шулар арасына кертелә.

Казан университетының медицина факультетына укырга кергәч, кызның җәмәгать эшләрендәге активлыгы тагын да киңрәк колач ала. Укудагы тырышлыгын, фән белән кызыксынуын исәп тотып, ректорат Әшрәф Закировна Дәүләткилдиеваны

аспирантурада калдырырга карар чыгара. Гаҗәеп мавыктыргыч фән дөньясы кызга үзенең капкаларын ача. Әмма...

1941 елның июне. Сугыш башлануның икенче көнендә үк барлык медиклар Совет армиясе хезмәткәрләре итеп белдерелә. Әшрәф тә хәрби кием кия. Казан гарнизоны госпиталендә фронт өчен медицина частьлары оештырыла. Врачлар, шәфкать туташлары, санитарлар, ишегалдында, яңа гына госпиталь начальнигы итеп билгеләнгән хәрби врачның чакыруын көтә.

Запастагы III ранглы хәрби врач Әшрәф Дәүләткилдиева кыр хирургия госпиталенә җибәрелә. Баш хирург итеп — Юрченко, госпиталь начальнигы итеп Сивцов билгеләнә, комсомол секретарьлыгына коммунист Кадыйровны сайлыйлар.

Бу коллектив турында Әшрәф гаҗәеп матур истәлекләр сөйли иде. Госпиталь хезмәткәрләре арасында урнашкан дуслык, күңелләрдә шул мөнәсәбәтләрдән туган мәрхәмәт хисләре Әшрәфнең җанын гомере буе рәхәтләндереп яшәделәр.

Кыр хирургиясе госпитале оештырылып, аларны ай буе бу һөнәрнең нечкәлекләренә өйрәтәләр. 1941 елның августында алар фронтка чыгып китә. Мәскәүдә госпиталь Төньяк-Көнчыгыш фронттагы 34 нче армиягә беркетелә.

Юлда барганда ук, вагоннарда кызыл хач билгеләре булса да, фашистлар госпитальне бомбага тоталар. Зур станцияләрдә хәл аеруча кискенләшә.

Әшрәф фаҗигале бер вакыйганы аеруча еш искә алып сөйли иде. Юлга кузгалыр сәгатьне көтеп торганда гына: «Барыгыз да вагоннардан чыгыгыз!» — дигән команда яңгырый. Күз ачып-йомганчы якты күк йөзен дошман самолетларының кара күләгәсе томалап ала. Бомбалар шартлавыннан бөтен тирә-юньне дәһшәт каплый. Самолетлар, китмәгәндә пәйда булган кебек үк, тиз арада китеп тә баралар, тик тимер юл эштән чыгарылганлыктан, алга бару мөмкинлеге бетә. Врачлар җайлы транспорт көтеп торырга да теләмиләр: аларны яралы сугышчылар көтә бит! Ватылмый калган җиһазларны барлыйлар да, җигүле бер ат табып, юлга чыгалар.

...Көзге көннәр госпитальгә яңа кыенлыклар алып килә. Сазламыклар тагын да җеби, күлләр ташып, юлларны күмә, алга бару авырая бара. Әмма медиклар бер дә тукталып тормыйлар, тоташ койган яңгыр астында да юлларын дәвам иттерәләр. Дошман эзәрлекләвеннән котылу өчен, аларга бары тик төннәрен генә хәрәкәтләнергә, кара урманнар эченнән, кеше үтмәслек чытырманлыклардан үтәргә туры килә. Арып-талып, юешләнеп, аякларын кырдырып, тиешле пунктка җитү белән, госпиталь эшләрен җайга салырга тотыналар. Бернечә җиргә — палатка, аларга ике катлы ятаклар көйлиләр, уртага тимер мич, өстәл һәм бернечә урындык куела. Палатка корырга да, землянкалар казырга да, сәндерәләр ясарга да алар барысы бер булып тотына: начальник та, санитар да, врач та — һәркем эшкә җиң сызганып катнаша. Йокыга вакыт бөтенләй тими башлый. Тамак ялгап алырга да бернечә минут кына булаләр. Бер урындагы эшләр беткәч, яңадан юлга җыеналар, госпитальне яңа җирдә корып җибәрәләр.

Яралылар күп килә. Җәрәхәтләрне бик тиз эшкәртергә, бәйләргә, тиешлесенә операция ясарга кирәк. Еш кына кан салырга, күп очракта үз каныңны бирергә туры килә. Операция өчен билгеләнгән бүлмә ишеге төбендә дежурный тора. Анық: «Керегез! Чираттагы кеше керсен! Чираттагыны алып керегез!» — кебек сүзләре яңгырап кына тора.

Кыз кешегә мондый шартларга иялөнү ифрат авыр: ул бомбалар шартлаган мизгелләрне үткәреп җибәрү, ул имән баганасыдай ирләрнең җан бирү газабына шаһит булу, ул яралыларның ыңгырашуы, ярдәм сорап ялваруы — барысы да, бер караганда, врачның ихтыяр көчен сындырып ташлар кебек. Әмма Әшрәф үз-үзен тотышы, кыен хәлләрдән чыгу ысулларын тиз табуы һәм ныклыгы белән ир-егетләргә дә үрнәк күрсәтә.

Сугыш кырында ике ел вакыт уза. Госпиталь — һаман хәрәкәттә. Инде юл — Көнбатышка, җиңүгә таба борыла. Хәзер алар тоташ икешәр-өчәр атна бер урында эшлиләр. Аннары кабат кузгалалар, акрынлап дошманның үз оясына таба хәрәкәт итәләр. Юлда мич торбалары гына тырпаеп калган, көле күккә очырылган авыл урыннары, чокыр-чакырга әйләндерелгән басулар, тау-таш өемен генә хәтерләтүче шәһәрләр очрый. Дошман самолетлары госпитальне һаман эзәрлекли,

бомбага тота. Кыз инде тыныч тормышның ниндирәк икәнлеген дә онытkандай була. Эш, эш, эш, берәзлексез бары тик эш кенә. Җентекләп уйлап, пөхтәләп башкарыла торган эш. Яралы сугышчы сыкранганда, Әшрәф тә сызлана, һәр авыруның кичерешләрен үз йөрәге аша да үткәрә. Берсендә, «Керегез!»— дигән сүз яңгырагач, операция бүлмәсенә... «Васька-Стрижны» күтәреп килеп керәләр.

Әшрәф артка чигеп куя, Стрижов та врачның теге чактагы үткен комсомолка икәнлеген танып ала, Әшрәфтәге олыгаюны, җитдилекне дә сизеп өлгерә. Берберсенә эндәшә алмый торалар. Әшрәф:

— Ни булды?— дип сорый.

— Кулым...

Берничә врач «Стриж»ның яралы кулын карый. Берсе:

— Кисеп алмыйча котылырлык түгел,— дип куя.

Әшрәф ашыгып каршы төшә.

— Юк! Ярамый!— ди.— Аңа сыңар кул белән кыен булачак. Бик тырышсак, мөгаен, саклап калырбыз. Шулаймы, иптәш Стрижов?

«Васька-Стриж» иреннәрен көчкә кыймылдатып: «Рәхмәт!» — ди.

Кулдагы җәрәхәтне чистартып, тиешле дәваны ясаганда, тәненең авыртуына чыдый алмыйча, «Стриж» елап җибәрә. Әшрәф тә егетнең хәле бик авыр икәнен белә белүен, тик, үзендә көч табып, елмайгандай итә, тынычландыру әмәлен дә табып өлгерә.

— Ә-ә,— ди ул.— Син аяк чалгач, беләсеңме, минем тез башым ничек авырткан иде? Еламадым бит. Син дә түз!

— Авыртудан еламыйм. Оят миңа. Зинһар, кичерегез!

— Танышыгызмыни, Әшрәф Закировна! — дип сорый ассистент.

— Бу — минем яшьлек «дусты».

Озатканда Әшрәф аңа врачларның соңгы сүзен тапшыра.

— Сиңа, Вася, кабат фронтка барырга туры килмәс инде,— ди.— Туган якларга китәрсең, анда тагын да дәваланырсың. Петропавловскига кайтырсыңмы икән?

— Әйе. Шунда кайтам, Әшрәф Закировна.

— Күргән-белгәннәргә сәлам әйтерсең!

— Сәлам әйтү генә түгел, сезнең батырлык турында да сөйләрмен...— «Стриж»ның тавышы калтыранып куя.— Тик сез мине теге чактагы җүләрлегем өчен кичерегез генә...

Кыр госпиталендә ясалган операцияләр арасыннан тагын берсе хәтердә аеруча ачык саклана. Егерме өч сәгатькә сузылган ул операция вакытында кыз яралы сугышчы тәненнән унтугыз кыйпылчык алган.

Шундый шартларда госпиталь врачлары Әшрәф белән берлектә «Хәрби кыр терапиясе белешмәсе» дигән чоры өчен ифрат кирәкле китап язалар. Китап Мәскәүдә басылып чыга.

Әшрәфнең сугышчан юлы Кенигсберг шәһәренә кадәр барып җитә. Җиңү көнен ул медицина хезмәтләре майоры дәрәҗәсендә каршылый. Тыныч тормышка исә 1946 елда гына әйләнеп кайтырга туры килә. Ул көнне күкрәгенә Сугышчан Кызыл Байрак, II нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм сигез медаль таккан, тәмам гаскәри кыяфәтле кызны тануы шактый кыен булыр иде.

Сугыштан соң Әшрәф Дәүләткилдиева кабат Казанда, врачларның белемен камилләштерү институтында эшли башлый. Институтта йөзләрчә рәхмәт хатлары саклана. Берсенә генә күз салып алыйк.

«Хөрмәтле Әшрәф Закировна!

Безгә укыган тирән эчтәлекле лекцияләрегез, һичнн белән чагыштыргысыз практик күрсәтмәләрегез өчен ихлас күңелдән зур рәхмәт Сезгә! Алар хәзер безнең көндәлек эштә бик нык ярдәм итәләр...

Сәламәтлегегезне саклагыз! Сезгә озын гомер, иҗади уңышлар телим...»

Көннәрнең берендә Әшрәф «Васька-Стриж»дан да хат ала.

«Исәнмесез, Әшрәф Закировна!»— дип язган ул.— Врачыбыз сезнең институтта укып кайткан икән. Адресны шуннан алдым. Ул Сезнең зур эшләр башкаруыгызны сөйләде.

Үзем заводта эшлим. Ике балабыз да — пионерлар...»

1980 елның кырыс бер көне Әшрәфне безнең арадан мәңгелеккә алып китте. Әмма аның фидакарьлеге, ул терелткән авырулар рәхмәте күпләр хәтерендә озак сакланыр.

## БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

Рафаэль Мостафин

# ПЕРСПЕКТИВАНЫ ЮГАЛТМЫЙК

Аяз Гыйләҗевның мәкаләсе — әрнеп кычкыру, авырткан йөрәкнең сыкравы ул. Авторның нинди нәтиҗә ясавы бу эмоциональ һәм ихлас күңелдән язылган мәкаләнең башында ук күренә: «Хәлебез һич тә тынычланырдай түгел, тынычлану зарарлы!»

Мәкаләне укып чыккач, мин гади генә, һәркем кабатлап карый алырлык тәҗрибә ясадым: Татарстан язучыларының соңгы съездлары материалларын, соңгы биш-алты елда әдәби ел йомгакларында проза турында укылган докладларны, шулай ук «Казан утлары» журналы буенча ярты ел саен үткәрелеп торган күзәтүләрне алып карадым, докладчылар ясаган нәтиҗәләрнең астына сызып чыктым. Укучыларны озын-озын цитаталар белән ялыктырмыйм, болай да ышанырлар дип уйлыйм: бу чыгышларның һәркайсында — берсендә генә дә калмыйча! — татар прозасының яңа уңышлары турында сөйләнә. Докладчылар татар әдәбиятында реализмның үсүен һәм баюын, тематик диапазонның киңәюен, художество осталыгының күтәрелүен, чынбарлыктан фәлсәфи мәгънә табуның активлашуын билгеләп үтәләр. Әлбәттә, кимчелекләр турында да әйтелә һәм вакыты белән шактый усал да итеп әйтелә. Әмма бу «аерым кимчелекләр», күпчелек докладчылар фикеренчә, гомуми оптимистик картинага һич тә йогынты ясый алмый.

Бу ни дигән сүз — бөтен рота дөрес атламый, бер поручик кына дөрес баса булып чыгамы?

Ныклап уйлап карасаң, монда зур капма-каршылык юк. Бөтенесе авторларның кайсы ноктадан каравына, дөресрәге, аларның әсәрләргә нинди критерийларга таянып бәя бирүенә бәйле.

Җәйнең матур бер көнендә куе урман буйлап барабыз дип күз алдына китерик. Челтәр-челтәр абагалар бил тиңентен булып утыра, хуш исле артыш куаклары калкыбрак тора, сыгылмалы чикләвек чыбыклары, зифа миләшләр инде тагын да биегрәк, буй җитәрлек түгел. Җиз кәүсәле наратлар һәм ап-ак тәнле каеннар күккә кадәр үк сузыла кебек, алар пәһлеван булып күренәләр. Тик менә сез бераздан ачык урынга чыгасыз, калкулыкка күтәреләсез һәм шунда инде сиек кына, юка гына бер урманнан барганлыгыгызны аңлыйсыз. Ерак-еракта үсеп утырган, башы күккә ашкан дәү агачларны сез хәзер генә искәрәсез, әлеге урман эченнән барганда, алар күзегезгә ташланмаган, һәм сез аларның барлыгын да белмәгәнсез икән.

Миңа А. Гыйләҗевның мәкаләсе әдәбиятыбызга менә шулай — кошлар очкан биеклектән, бөтен совет һәм хәтта дөнья әдәбияты казанышлары югарылыгыннан күз салырга тырышу булып күренә. Әлбәттә, болай якын килгәндә, ниндидер мөһим әйберләр күренми дә кала, кайбер җитди детальләр бөтенләй күздән дә югала. Әмма шулай бер өстән карамыйча булмый, перспектива тойгысын югалтмас өчен, болай итү ара-тирә булса да кирәк.

Прозаикның кайбер бәяләре миңа субъектив, берьяклы булып тоела, ләкин аның чыгышының гомуми пафосын мин тулысынча уртаклашам. Әйе, без кайвакыт әйләнә-тирәбездәге вак урманнан югары күтәрелә алмыйбыз, үз «агачларыбызны» — Чехов, Бунин, Достоевский кебек язучылар һәм, дөнья әдәбияты классиклары турында әйтеп тә тормастан,— Ч. Айтматов, В. Быков, Н. Думбадзе, Ю. Балтушис, В. Шукшинның иң яхшы әсәрләре кебек биеклекләр белән чагыштырып карамыйбыз. Хәлбуки, шулай чагыштырып караганда, картина бөтенләй башка.

Хәер, тиз агышлы җанлы әдәби процесс картинасын бер караш белән генә колачлап алуы бик кыен. Бу, беренчедән, әдәбият даими хәрәкәттә булганга, үсеп, яңарып торганга шулай. Зур өметләр багланган язучыларның кисәк «тыны бетә», алар тырышып-тырмашып үзләрен кабатлый башлыйлар. Мәкалә авторы моны Хәниф Хәйруллин иҗаты мисалында ышандырырлык итеп күрсәтә. Җәмит Рәхимов иҗаты белән дә шундыйрак хәл булды. Ул әйбәт кенә язылган «Өлешемә тигән көмешем»

повесте белән бар кешенең игътибарын җәлеп итте, аннан соңгы «производство повестьлары», инде тәнкыйтьтә билгеләп үтелгәнчә, шактый йомшаграк язылган булып чыкты. Мине Азат Ганиевнең озак язмый торуы да борчый. А. Гыйләҗев аны бик хаклы рәвештә күп нәрсә көтәрлек авторларның берсе дип саный.

Киресенчә, «урта кул» дип саналган авторлар да чынбарлыкны аңлавыбызга бер өлеш кертә алган, әдәбиятның үсешендә эз калдырган әсәр тудырып куялар. «Каты токым» романын язганчы, Шамил Бикчурин, мәсәлән, икенче пландагы язучы булып исәпләнеп килде. Мин А. Гыйләҗевның бу романны санга сукмавы белән һич тә риза түгел. Художник буларак, бу әсәр А. Гыйләҗевкә шәхсән ошамаса да, ул Ш. Бикчурин романының әдәбиятыбызда гадәти бер күренеш кенә түгел икәнен кире кага алмый. Аның РСФСР язучылары съездларының берсендә зур сөйләшү предметына әверелүе, Казанда һәм Мәскәүдә кат-кат басылып чыгуы, Чехословакиядә дөнья күрүе дә очраклы хәл түгел. Роман эшчеләр сыйныфы турындагы иң яхшы әсәр өчен ВЦСПС премиясенә лаек булды. Кыскасы, шундый романнар күбрәк булсын иде!

Менә тагын бер мисал. Прозаик Мәҗит Рафиковның исемен татар әдәбияты турындагы мәкаләләрдә бик сирәк күрәсең. Хәлбуки, нәкъ менә аның кыска гына лирик новеллалары соңгы елларда чит илләрдә тәрҗемә ителде һәм дөнья күрде. Әдәбиятыбызның вәкаләтле вәкилләре булып, алар Һиндстан, Бангладеш һәм кайбер башка илләрнең вакытлы басмаларында урын алдылар.

Шуңа күрә дә әдәбиятта күрәзәлек итү — шактый хәтәр эш. Мин мәкалә авторының теге яки бу язучы алга таба ничегрәк үсәр дигән кайбер юрауларына скептикларча карыйм.

Икенчедән, әдәбият торышының бер кеше күзе белән генә күрелгән картинасы һәрвакыт субъектив була. Өстәвенә, художник никадәр остарак һәм талантлырак булса, картина да шулкадәр субъективрак. Кайчакта укучылар теге яки бу әсәргә төрлечә бәя бирелүенә аптырыйлар һәм хәтта ачуланалар да. Әмма монда гаҗәпләнер нәрсә юк. Лев Толстойның Шекспирны танымаганлыгын, Чехов Горькийның күп кенә әсәрләрен кабул итмәгәнлеген, «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәтендә Галимҗан Ибраһимовның Тукай турындагы сүзләрен хәтергә төшерик. Һәр конкрет очракта бу бәяләмәләр художникның зәвыгы, күңел тартуы, дөньяга карашы яки тормыш позициясе белән аңлатыла. Объектив хакыйкать күп кенә субъектив хакыйкатьләрдән җыела. Шуңа күрә теге яки бу әсәргә дә, тулаем әдәби процесска да дөрес бәя бирүгә фикерләр көрәшенең, төрле ракурслар һәм карашлар бәрелешенең диалектик процессында гына ирешергә мөмкин. Вакытны иң объектив һәм гадел тәнкыйтьче итеп санау юкка гына түгел. Нәкъ менә вакыт чын сәнгать әсәрләренә булган хаксыз һөҗүмнәрне дә, бер көнлек китаплар адресына буш мактауларны да чүп урынына җилгәрә.

Мин Аяз Гыйләҗевның моннан унбиш еллар элек Нурихан Фәттахның стиленә һәм иҗатына үтергеч бәя бирүен, хәтта «Чаян» журналында бу хакта зәһәр фельетон белән дә чыкканын хәтерлим. Ә хәзер шул ук Фәттахны ул «беренче разрядлы язучылар» арасына керткән. Нурихан Фәттах бу еллар эчендә шулкадәр нык үзгәргәндер дип уйламыйм. Дөресрәге, А. Гыйләҗевның үз карашы үзгәргәндер.

Шулай итеп, әдәби процессның үзгәрүчәнлеген һәм бәяләрнең субъективлыгы котылгысыз булуын хәтердән чыгармыйча, Аяз Гыйләҗев артыннан без дә калку урынга (әлбәттә, бу инде Гыйләҗев калкулыгы түгел, башкасы булыр) күтәрелик һәм әдәбиятыбызга кошлар очкан биеклектән күз салып карыйк.

Мәкалә авторы әдәбиятыбызда өч биеклек, әйбәт җимеш бирә торган өч агач күрә: Ә. Еники, М. Мәһдиев һәм Н. Фәттах. Әйе, тулаем алганда, Гыйләҗев белән килешеп була, болар чыннан да зур һәм үзенчәлекле художниклар. Ләкин шул ук вакытта бу язучыларның бер генә әсәре дә, әйтик, Ч. Айтматов, М. Кәрим, М. Слуцкис, А. Нурпеисов әсәрләре кебек, гомумсоюз күләмендә киң яңгыраш алмады әле... Монда гаеп тәрҗеманең сыйфатында гынамы, әллә хикмәт әсәрләрнең ниндидер эчкәрге, тирәндә яткан үзлекләрендәме? Бу сорау минем өчен ачык кала.

Шунда ук башка сораулар да туа. Хәзерге татар прозасының бөтен картинасы, А. Гыйләҗев уйлаганча, калкып торган шушы «өч нәратка» гына кайтып каламы? Ни өчен, Әмирхан Еникинең психологик анализ осталыгын дөрес билгеләгән хәлдә, автор, әйтик, Гомәр Бәширов кебек биеклеккә күз йома? Хәлбуки, Г. Бәшировның «Намус» романы чит ил телләренә бик күп тәрҗемә ителде, анда чын милли һәм олы характерлар тасвирланган. «Намус» чагыштырмача күптән язылган булса, аннан соң Г. Бәширов әдәбиятыбыз өчен этап булган «Туган ягым — яшел бишек» әсәрен язды. Этап дигәннең мәгънәсе шунда: язучы безнең әдәбиятта гына түгел, бөтен совет әдәбиятында да беренчеләрдән булып халыкның әхлакый традицияләре, татар крестьянының тормышында, көнкүрешендә, холык-фигылендә булган якты, сәламәт, тормышчан нәрсәләр турында уйлана. Ниһаять, иң яңа мисал — Г. Бәшировның «Казан утлары»ның 1981 елгы беренче санында басылган «Сарут» хикәясе. Бу әсәрне соңгы еллардагы иң яхшы хикәяләрдән берсе итеп санаучыларга мин тулысынча кушылам.

Инде А. Гыйләҗев татар әдәбиятының бөтенсоюз күләмендә нинди яңгыраш алуы турында сүз башлаган икән, нигә соң ул арабыздан күптән түгел генә киткән Габдрахман Әпсәләмов әсәрләренең гаять киң популярлыгын күрми яки күрмәмешкә салына? Әпсәләмов әсәрләренең русча тиражы берничә миллион экземпляр тәшкил итүен искә төшерик — бу җәһәттән аның белән безнең бер генә язучы да, хәзер-

гелэр генэ түгел, классиклар да ярыша алмый. Украинада китап укучылар арасында үткәрелгән социологик тикшеренүнең нәтиҗәләре матбугатта игълан ителгән иде инде. Әпсәләмовның исеме башта анкетага кертелмәгән булса да, анкета тутырган барлык укучыларның яртысы диярлек аны үзләренең иң яраткан язучысы дип язып куйган.

Мондый тикшереп карау илебезнең башка өлкәләрендә һәм республикаларында үткәрелсә дә, нәтиҗә якынча шул ук булыр иде дип уйлыйм. Әпсәләмов китапларын бөтен илдә укыйлар. Әлбәттә, художник яки стилист буларак, Әпсәләмовка төрлечә карарга, аның иҗат манерасын кабул итәргә яки итмәскә мөмкин. Әмма аның әсәрләренең киң катлау укучыларга йогынты ясавы бәхәссез.

Кызганычка каршы, бездә укучы фикерен һәм укучы ихтыяҗын өйрәнү эше әле һаман да начар куелган. Без күбрәк үзебезнең субъектив фикерләребездән, укучылар белән аз-маз гына аралашу тәҗрибәбездән чыгып эш итәбез. Әмма төгәл саннардан һәм бәхәссез булган объектив күрсәткечләрдән башка да бер нәрсә ачык: әсәрнең эстетик әһәмияте белән аның укучылар арасындагы популярлыгы тигез дип карарга ярамый. Бездә әсәрләрнең художество сыйфатлары белән Әпсәләмовтан һич тә калышмаган прозаиклар аз түгел (Мирсәй Әмирне, Фатих Хөснине, Ибраһим Газины һ. б. искә төшерү дә җитә). Аларның иң әйбәт әсәрләре барысы да русчага тәрҗемә ителде. Әмма алар Әпсәләмов романнары кебек киң яңгыраш алмадылар. Монда эш нәрсәдә соң? Укучыларның зәвыгы үсмәгәнлектәме, әллә китапларның иҗтимагый, танып-белү һәм тәрбия ягын исәпкә алмыйча, эстетика күзлегеннән карап кына якын килүебезнең бик үк дөрес булмавындамы? Бу мәсьәлә шулай ук фикер алышуга һәм ачыклауга мохтаҗ.

Монда сәнгать әсәрләренең туган телебездә һәм тәрҗемәдә бердәй яңгырамавын да истә тотарга туры килә. Шигъриятне яраткан теләсә кайсы татар укучысыннан кемне иң күренекле татар шагыйре итеп санавы турында сорап карагыз. Күпчелек, уйлап та тормыйча, Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан, Сибгат Хәким исемнәрен атар дип уйлыйм. Шул ук сорауны рус укучыларына, Казан китапханәләренә даими йөрүчеләргә генә булса да биреп карагыз. Абсолют күпчелек Җәлил исемен телгә алыр, һәм бик азлар гына башка исемнәрне искә төшерер. Чыннан да, поэтик талант дәрәҗәсе ягыннан Җәлил санап үтелгән шагыйрьләр белән бер сафта тора, ә популярлыгы һәм миллионлаган укучыларга йогынтысы буенча аның поэзиясе үзенә бер төрле. Драматургия өлкәсендә дә шуны ук күзәтергә мөмкин. Татар театрларының сәхнәләрендә кайсы драматургларның әсәрләре аеруча уңышлы барды? Нәкый Исәнбәт, Хәй Вахит, Шәриф Хөсәенов Туфан Миңнуллин исемнәрен әйтсәм, ялгышмам дип уйлыйм. Ә бөтенсоюз сәхнәсендә Диас Вәлиевнең «Дәвам» («Сиңа тормыш бүләк итәм») дигән пьесасы иң көчле яңгыраш алды. Аны илебезнең илледән артык театры, шул исәптән башкала театрлары да куйды. Бу — моңарчы безнең драматургиядә күрелмәгән хәл. Нәкъ менә шушы пьеса белән татар драматургиясе чын-чынлап бөтенсоюз мәйданына чыкты. Ә бит Казанда бу пьесаны кую әллә ни уңышлы үтмәгән иде. Мәскәүнең Ермолова исемендәге театры Казанга гастрольгә алып килгәч кенә, пьеса публикада киң яңгыраш тапты, матбугатта да зур резонанс алды һәм Тукай премиясенә лаек булды.

Сүз уңаенда тагын бер нәрсәгә тукталыйк. Кайчакта аерым язучылардан шундый сүз ишетергә мөмкин: «Мин татар укучысы өчен язам һәм әсәрем русча ничек яңгырар — бу мине артык борчымый. Ошый икән, киң яңгыраш таба икән — бик әйбәт. Ошамый икән — түзәрмен, чөнки минем өчен иң әһәмиятлесе — үз укучыма тәэсир итү». Бер караганда, бу ышандырырлык та сыман (әлбәттә әгәр язучы хәйләләми, бөтенсоюз укучысының битарафлыгына рәнҗүен тышкы ваемсызлык белән капларга тырышмый икән). Әмма хикмәт шунда: безнең шартларда бөтен кан тамырлары бергә кушылган күпмиллэтле совет әдәбияты барлыкка килгәннән соң, гомумсоюз укучысының кабул итүе, үзәк тәнкыйтьнең югары бәя бирүе, хәтта үзәк матбугатта басылып чыгу гына да — язучының үзе өчен дә, аның әсәренең язмышы өчен дә кирәкле факторлар. Мәсәлән, А. Гыйләҗевның «Өч аршин җир» повестен безнең тәнкыйтьчеләр башта бик сагаеп каршы алганнар иде. «Дружба народов» журналында басылып, журналның премиясенә лаек булгач кына аңа караш үзгәрә башлады. Иртәме, соңмы, Р. Төхфәтуллин һәм Р. Кутуй хикәяләрә белән дә шул ук хәл булды. Яңалык, гадәттән үзгәлек, иске традицияләрне вату төсмере булган һәр нәрсә үзенә кыенлык белән генә юл яра. Үзәк матбугатта яклау тапкач, бу яңа нәрсә үз ягында да җиңелрәк тамыр җибәрә.

Әле телгә алынган язучыларга бәйләп булса да, татар әдәбиятының кошлар очкан биеклектән күренә торган картинасына әйләнеп кайтыйк.

А. Гыйләҗев аңлаешлы сәбәпләр белән үзе турында искә алмый. Хәлбуки, ул М. Мәһдиев, Н. Фәттах, Г. Ахунов һәм язучыларыбызның хәзер инде әйдәп баручы урта буынының башка вәкилләре белән берраттан татар прозасының алгы сафында бара. Аның «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» дигән повестьлары соңгы еллар прозасында күренекле вакыйга булды. Художество осталыгы үсү могъжизасендә генә түгел, тормышның яңа катламнарын ачу, хәзерге чынбарлыгыбызның актуаль проблемаларын кую ягыннан алганда да вакыйга булдылар алар.

Автор үзенең мәкаләсендә Гариф Ахуновны да телгә алмый — бу юлы инде сәбәпләре аңлашылмый, чөнки берничә ел элек кенә А. Гыйләҗев үзе үк зур мәкалә белән чыгып, анда Г. Ахунов турында «күренекле прозаикларыбызның берсе» дип язган иде. Чыннан да, Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Идел кызы» романнары, «Чиләвек төше» һәм «Ардуан батыр» повестьлары бүгенге көннәр героен аңлауда, прозабызның тематик диапазонын киңәйтүдә сизелерлек яңалык булды. Мәсәлән, «Идел кызы» романында Габбас мулла образының сурәтләнүен мин үзенчә кыюлык дип саныйм. Моңа кадәр бездә дин әһелләре ач күзле, комсызлар, артта калган фанатиклар һәм эксплуататорлар итеп кенә сурәтләнә иде. Гәрчә муллалар арасында да төрле кешеләр булган. Халык арасыннан чыкканнары, гади халыкка кендеге белән берекәннәре дә, Шиһап Мәрҗани тибындагы мәгърифәтчеләр, галимнәр дә, Габбас мулла кебек, юллар чатында калучылар, искедән ваз кичеп, яңаны кабул итә алмаучылар да булган. Бәлки моңа охшаш фикерләр элек тә әйтелгәндер, әмма Г. Ахунов бу фикерне эмоциональ, образлы итеп бирә, киң даирә укучыларга илтеп җиткерә.

Мәкалә авторы прозабыздагы Рафаил Төхфәтуллин иҗаты кебек биеклек турында да ләм-мим сүз әйтми. Аның «Җиләкле аланнар» повестеның үзәк журнал «Знамя» битләрендә басылып чыгуын, аннары «Советская литература» журналының бу әсәрне бик күп чит ил укучыларына тәкъдим итүен хәтергә төшерик. Һәрхәлдә, Р. Төхфәтуллинның күп кенә хикәяләре һәм повестьлары — бөтенсоюз әдәбияты югарылыгыннан караганда да күренеп торган биеклекләр.

Шушыңа ук Рөстәм Кутуйның да күп кенә хикәяләрен өстәп булыр иде. Алар үзәк матбугатта басылып чыктылар, чит телләргә дә тәрҗемә ителделәр. Кайберәүләр, русча язуын сәбәп итеп, Р. Кутуйны татар әдәбиятыннан аерырга тырышалар. Әмма бит Ч. Айтматов та русча яза. Иң әһәмиятлесе шунда: Р. Кутуй безнең чынбарлыгыбыз (Казан, Татарстан районнары) турында яза, милли характерлар тудыра. Мәсәлән, Р. Кутуйның Салих Сәйдәшев белән очрашу турындагы бер дигән хикәясе һәм Туфан турындагы бик матур лирик эсселары минем хәтеремә кереп калды. Бу әсәрләр дә әдәбиятыбызның вәкаләтле вәкилләре һәм аларны исәптән чыгарып ташлау — ким дигәндә, акылсызлык булыр иде.

Боларның һәммәсен бергә кушып карасаң, картина ул кадәр үк аяныч булып күренми. Моңа талантлы һәм үзенчәлекле язучыларның икенче сафын: М. Юнысны, В. Нуруллинны, А. Ганиевне, М. Галиевне һ. б. кушыйк. Дөрес, күңелдәгесен яшермичә әйткәндә, бу «һ. б.» дигәннең әллә ни аңлатмавын танырга туры килә. Яшьләрнең кайсысы прозабызның иртәгәге көнен билгеләр икән дип текәлебрәк карый башласаң, ирексездән күңелне шик баса. Беренчедән, яшьләрнең иң зур күпчелеге шигырьдән башлый, проза язучылар берән-сәрән генә. Икенчедән, прозага килүчеләр арасында менә мин дип торган иҗади шәхесләр бик тә аз. Осталык, күп укыганлык, эрудиция, тәҗрибә, хәтта материалны белү дә — болар һәммәсе — ирешеп була торган нәрсәләр. Ә менә иҗади шәхесне, индивидуальлекне инде аптекада сатмыйлар. Язучының үз йөзе юк икән, аңардан кайчан да булса үзенчәлекле һәм әдәбиятыбызны баетырлык әсәр чыгарына ышануы кыен. Резервның зәгыйфьлеге,— минемчә, прозабызның иң авырткан җире. Боларның һәммәсе турында да ныклап уйларга кирәк.

Шулай итеп, тагын кабатлыйм, минемчә, прозабыз ул кадәр үк аяныч хәлдә түгел. Ләкин бәла шунда: безнең әдәбияттагы хәтта иң биек дигән «наратларыбыз» да совет һәм дөнья әдәбиятының киңрәк фонында караганда еш кына уртачадан узмаган гади агач булып, кайчакта куак кына булып күренә.

Менә ун елдан артык инде мин «Дружба народов» журналының редколлегия члены булып торам. Бу еллар эчендә татар әдәбиятының күп кенә әсәрләре редколлегиядә тикшерелде, проза бүлегендә каралды. Һәм еш кына шулай килеп чыкты: бездә әсәр алга таба бер адым, «җитди өлеш» һ. б., һ. б. дип танылган, республика бүләкләренә лаек булган. Ә күп милләтле совет прозасы фонында ул йомшак дисәң, йомшак түгел, гадәти генә бер әйбер булып күренә. Ахыр чиктә редколлегия членнары башка республика язучыларының тирәнрәк, философик яктан баерак әсәрләренә өстенлек бирәләр.

Әйе, хәтта иң яхшы үрнәкләренә карап кына фикер йөрткәндә дә, безнең әдәбиятка әле Балтик буе республикаларының әдәбияты, грузин, әрмән прозасы белән, хәтта казакъ һәм кыргыз әдәбияты кебек чагыштырмача яшь әдәбиятлар белән дә ярышу кыен.

«Дружба народов»та әрмән прозаигы Грант Матевосян әсәрләрен генә алыйк. Бу уңай белән тәнкыйть «фолкнерча язу манерасы» дип язды. Фолкнерны һәм Матевосянны параллель куюю бик ышандырырлык булып күренде, һәм беркем дә моңа каршы төшәсе итмәде. Безнең прозаикларыбыздан кайсысы шундый чагыштыруга тарта алыр иде икән — мин белмим.

Менә тагын бер гыйбрәтле мисал. Соңгы елларда бездә мемуар әдәбият киң үсеш алды. А. Гыйләҗев телгә алган истәлек китапларыннан тыш бездә Шәйхи Маннурның, Мирсәй Әмирнең кызыклы автобиографик әсәрләре һәм башка әсәрләр барлыкка килде. Мин бу китапларга зур хөрмәт белән карыйм. Тормыштан китәр көннәре якын икәнен сизгән кебек, әдәби аксакалларыбыз үз тормышлары турында үзләре сөйләргә, киләчәк буыннарга үзләренең күңел, фикер байлыкларын, күзәтү-

ләрен, тормыш тәҗрибәсен ачып салырга булганнар. Әмма «Дружба народов» журналы редакциясендә бу истәлекләрнең кайсын да булса бирерсен басып чыгару турында мәсьәлә куелгач, бүлек редколлегиясе Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» дигән автобиографик повестен өстенрәк күрде. Мостай Кәрим повесте сәнгать ягыннан да көчлерәк, философиясе белән дә баерак һәм ялыктыргыч сөйләп барудан да азат булып чыкты.

Әйе, монда кемгә дә үпкәләрлек түгел. Журнал редакциясе күп милләтле совет әдәбиятында булганнарның иң яхшысын гына, гомумсоюз масштабында ниндидер яңалык алып килгәннәрен генә басарга юнәлеш алды. Журналның зур уңышларга ирешүе һәм соңгы елларда авторитеты үсү дә бәлки редакциянең элек саклап килгән география принцибыннан ваз кичүендәдер.

Моннан берничә ел элек «Советский писатель» нәшриятында күренекле рус тәнкыйтьчесе, филология фәннәре докторы, милли әдәбиятлар буенча танылган белгеч В. Оскоцкийның «Романның байлыгы» дигән монографиясе басылып чыкты. Бу хезмәт милли әдәбиятлар материалында хәзерге совет романы проблемаларына багышланган. Автор бу катлаулы синтетик жанрның проблемаларын тикшергәндә украин (О. Гончар, М. Стельмах), белорус (И. Мележ, Я. Брыль), молдаван (И. Друцэ), казакъ (А. Нурпеисов) һәм башка әдәбиятлар тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итә. Шактый калын гына китапта бер татар язучысы да телгә алынмый, безнең бер роман исеме дә аталмый. Китапны укып чыккач, мин ничектер шулай автордан аның ни өчен безнең әдәбият материалын мисалга алмавы белән кызыксындым, бәлки ул аны җитәрлек белми генә торгандыр? Валентин Оскоцкий үзенең җавабында татар әдәбияты яңалыкларын белүен, әмма сөйләшү өчен совет романының юлын билгели торган иң югары, этап, булырдай әсәрләрне генә сайлаганлыгын әйтте. Аның карашынча, татар әдәбияты әсәрләре арасында андыйлар табылмаган.

Тәнкыйтьчене субъективлыкта гаепләргә мөмкин булыр иде, әмма, кызганычка каршы, мондый хәл В. Оскоцкий китабы битләрендә генә түгел. Әйе, А. Гыйләҗев хаклы: татар әдәбияты әсәрләренең үзәк матбугат битләрендә зур сөйләшү предметына әверелүе бик сирәк була. Безнең язучыларның исемнәре бөтенсоюз съездларында да телгә алынмый диярлек. һәм арттa калу елдан-ел ныграк сизелә.

Бу артталыкның конкрет нәрсәдә чагыла икәнлегенә формулировка биреп карыйк.

А. Гыйләҗев бәлане иң элек төссезлек басып китүдә, урта кул язучыларның бик ишле булуында күрә. Әйе, безнең китап һәм журнал битләрендә хәзер күрәләтә халтураны очратмыйсың диярлек. Күпчелек язучыларыбыз югары белемле, язучылык һөнәренең серләрен дә белә. Хәзер хәтта башлап язучылар да хата җибәрмиләр, сюжет кора беләләр, кызыклы диалоглар бирәләр. Әмма художество ачышлары, нык күтәрелешләр, А. Гыйләҗев сүзләре белән әйткәндә, фикер кардиограммасындагы «пиклар» бик тә, бик тә сирәк. Буало сүзләре төшә: «Синең хәтәр сәнгатеңдә, о әдип, аеру кыен бу — начар, бу — урта дип».

Әлбәттә, урта кул язучылар һәрвакыт булган һәм булыр дип, әдәбият чынлыкта гел биеклекләрдән генә тормый, тора да алмый дип үзеңне юатырга була. Мәсәлән, рус әдәбияты кебек нык үскән әдәбиятта әллә урта кул язучылар азмы? Күтәрелешләр, биеклекләр үзләре дә әдәби процессның төп өлешен тәшкил итә торган уртача дәрәҗә өстендә генә калкып торырга мөмкин бит. Әмма болай дип үз-үзеңне юату белән генә әдәбиятыбызда урта кул язучылар тон бирүдән туктамый, ә бу — әдәбиятның гомуми дәрәҗәсен түбәнәйтә, аңа төссезлек бирә.

Прозабызның икенче җитди кимчелеге — күп сүзлелек, сузынкылык, кызыксыз сөйләп бирү. Үз арабызда без әле моның белән ничек кирәк алай килешәбез, чөнки күпсүзлелеккә күнеккәнбез, кайчакта хәтта моны искәрмибез дә. Әмма әсәр рус теленә тәрҗемә ителә һәм яңа сферага, бөтенсоюз әдәбияты сферасына күчә икән, өлеге кимчелек шунда ук күзгә күренә башлый. Шулай да була: 18—20 табаклы калын гына роман 5—6 табаклы юка повесть кисәгенә әйләнеп кала. (Мәсәлән, М. Хәсәновның «Юллар, юллар...» романын тәрҗемә иткәндә шулай булды).

Эдуард Касыймовның «Томан аша» һәм «Һаваларда тургай» романнарын да мисал итеп китерергә мөмкин. Э. Касыймовның бөтен иҗатына А. Гыйләҗевның гел тискәре бәя генә бирүе белән мин килешмим. Э. Касыймовның мәкалә авторы телгә алган әсәрләреннән тыш, мин «Көмеш язулы кылыч» һәм «Бир кулыңны, дустым» дигән кечерәк кенә, әмма эчтәлекле повестьларын, күп кенә хикәяләрен һәм очеркларын уңышлы дип атар идем. Аның химиклар турында язган «Чулман — оныклар елгасы» дигән романы турында да, русчага тәрҗемә ителгәннән соң, җирле һәм үзәк матбугатта күп санлы уңай фикерләр әйтелде, һәм ул ВЦСПСның эшчеләр сыйныфы турындагы иң яхшы әсәрләр өчен бөтенсоюз премиясенә лаек булды. Ләкин Гыйләҗевның күп яктан хаклы булуын да танырга туры килә: Касыймов язучы буларак соңгы елларда үсми диярлек, бер урында таптана, уртача дәрәҗәдән югары күтәрелә алмый. Аның әсәрләрендә күпсүзлелек, кирәксез тәфсилләүләр, хаҗәте шуның кадәр генә булган диалоглар, артык күренешләр һәм ялыктыргыч эпизодлар тулып ята. Игътибарга лаеклы факт: тәрҗемә процессында 13 һәм 17 табаклы ике романнан 21 табаклы бер роман барлыкка килгән. Шулай итеп, әсәр яртылаш диярлек кыскарган һәм моңардан откан гына. Юк, югары очыш килеп чыкмаган, әлбәттә, әмма суы саркып торган ике романнан бер урта кул әсәр барлыкка килгән.

Бу — әлбәттә, иң күзгә бәрелеп торган, иң ачык мисаллар. Әмма теге яки бу әсәр русчага тәрҗемә ителгән саен нәрсәдер кыскартыла, нәрсәдер кабат языла яки үзгәртеп эшләнә. Ә бу әлеге әсәрнең оригиналда эшләнеп бетмәгән килеш басылуы турында сөйли. Безнең романнар һәм повестьлар композиция кәпшәклегеннән җәфа чигә. Аларга драматизм, детальләрнең тирәнлеге җитми. Еш кына безнең прозаиклар укучының уйлый белүенә, акыл сәләтенә ышанып бетмиләр, бөтенесен аңлатып бирергә, чәйнәп каптырырга тырышалар. Әсәргә яңа персонаж килеп керү белән, аның биографиясе тәфсилләп бирелә, сюжетта яңа борылыш сизелү белән, язучы үткәнгә әйләнеп кайтуны, моның ни өчен болай килеп чыгуын аңлатып бирүне бурыч итеп саный. Ә иң мөһиме — күп кенә әсәрләребезгә яңалык һәм фикер тирәнлеге, чынбарлыкны фәнни төшенү җитми. Әсәрнең тирәнлеге һәм саллылыгы теманың үзеннән генә түгел, хәтта тормыш материалларыннан да түгел, ә бәлки язучының чынбарлыкта нәрсә күрүеннән, аның әйберләргә һәм күренешләргә карашыннан, аларга ничек мәгънә бирүеннән килә бит.

Фикеребезне дәлилләү өчен, конкрет бер әсәр — Ш. Бикчуринның «Тирән катлам» романы мисалында прозабызның типик кимчелекләрен карап үтик.

Бу роман уңышлы чыксын өчен, бөтен шартлар да җитә иде кебек. Алдагы роман белән Ш. Бикчурин кызыклы һәм актуаль әсәр иҗат итәргә, үз илебездә генә түгел, чит илдә дә киң яңгыраш табарга сәләтле икәнлеген исбатлаган иде. Яңа романы өчен ул бүгенге үзәк темаларның берсен — Көнбатыш Себер нефтен үзләштерү һәм союзкүләм әһәмиятле булган бу бурычны үтәүдә Татарстан нефтьчеләренең ролен сайлаган. Автор нефть эшен эчәсеннән җебенә кадәр диярлек белә, нефть якларында яши һәм әсәрләренең геройлары белән көн саен диярлек очрашып тора. Ул материалны берничә ел махсус өйрәнде, булачак әсәрендәге вакыйгалар урынына барды, әсәр өстендә басылып эшләде.

Ләкин Ш. Бикчуринның яңа романын укый башлау белән, канәгатьсезлек хисе кичерәсең. Алдыбызда бик кыенлык белән «булавка ярдәмендә» генә укыла торган төссез, чи, кәпшәк һәм озынга сузылган әсәр икәнен аңлыйсың. Ирексездән шундый фикер туа: автор алдагы романы өлешенә тигән уңышны кабатларга тырышып караган (исемнәрнең охшашлыгы гына да шул хакта сөйли). Әмма әдәбиятта шомарган юллар юк, ул һәрвакыт таныш булмаган өлкәгә юл ачу. Бер тапкыр табылган алымнарны, теманы, материалны һ. б. кабатларга тырышу сәнгатьчә икенчелеккә әверелә, уңышсызлыкка китерә.

Алдарак мин роман темасының мөһимлеге һәм актуальлеге турында сүз алып барган идем. Ләкин шушында ук В. Г. Белинскийның мәкаләләрендә һәм күзәтүләрендә үткәрелә торган бер фикерне искә төшерәсе килә: автор үзенең әсәрендә нинди генә матур идеяләр, нинди генә мөһим иҗтимагый мәсьәләләр күтәрмәсен, сәнгатьлелек булмаса, анда матур фикерләр дә һәм мәсьәләләр дә була алмый, алар рәтләп башкарылмаган әйбәт ният кенә булып калалар. Чыннан да, әсәрне укырга мөмкин түгел икән, укучы аны беренче битләреннән үк ябып куя һәм кәефсезләнеп читкә ташлый икән, мөһимлек һәм актуальлек турында нинди сүз булырга мөмкин? Монда темага, дәресрәге, аның белән спекуляция ясауга карата әчке протест уятып, укучы каршында теманың бәясен төшерү турында гына сүз барырга мөмкин.

Әйе, тема ул, әсәрдә **нәрсә турында** язылудан бигрәк, тормышның теге яки бу катламын аңлауга авторның үзеннән **нәрсә кертүе**. Әйтик, «Каты токым» романында татар нефтен үзләштерүнең башлангыч чоры турында гына түгел, ә бәлки эшчеләр коллективының формалашуы турында сүз бара иде. Эчке монолог алымы ярдәмендә автор бригададагы һәркемнең башта үзен аерым итеп тоюын күрсәтә алган. һәркайсының үз максаты, үз уйлары. Берсе күбрәк акча җыюны кайгырта, икенчесе спортта уңышларга ирешү турында баш вата, өченчесенә берни дә кирәкми, хатыннар артыннан сөйрәлергә җай гына булсын, дүртенчесе, гомумән, бригадага очраклы рәвештә генә эләккән һәм хәзер яңадан авылга кайту турында хыялланә. һәркайсы үзенә үзе баш, барысы да бер-берсеннән һәм мастердан канәгать түгел, хәер, мастерны да алардан канәгать дип булмый. Ә менә бергәләп эшләү, күп кенә кыенлыкларны, аварияләрне җиңү процессында әкренләп бер-берсенә ярашу бара. Автор ургак максатның эгоистик максатларны һәм мотивларны кысрыклавын күрсәтә. Зурдан булмаса да, аларда бик мөһим психологик үзгәрешләр бара, очраклы рәвештә генә җыелган кешеләрдән **коллектив** формалаша. Нәкъ менә шушы сыйфат романны Татарстаннан ерактагы укучылар өчен дә кызыклы итте, яраттырды.

Яңа романда исә язучы шундый борылыш таба, темага үзенчә якын килә алмаган. Саф информацион бурычлар — Себер нефтен үзләштерүнең ничек баруы турында сөйләү, берничә әдәби персонаж мисалында бу эштә татар халкы вәкилләренең катнашуын күрсәтү иң алгы планга куела. Шул рәвешчә, роман урынын очерк материалы алып тора. Роман очерк кебек кабул ителә, ләкин ялыктыргыч, сузынкы, кәпшәк очерк итеп.

Романдагы уннарча биткә сузылган һәм очерк-публицистика, ә кайчакта газета информациясе характерындагы бөтен-бөтен бүлекләр әнә шуннан килә. Автор Себер нефтен ачу һәм үзләштерә башлау турындагы китаплар, брошюралар һәм публикацияләрнең эчтәлеген популярлаштырып сөйләп чыга, чынбарлыкны сурәтле чагылдыру кызыксыз сөйләү белән алмашына. Хәер, баш герой Курамшинның Себергә килүен күрсәткән башка бүлекләрдә дә геройның күз уңына ни эләксә, шуны вагы-төяге

белән язып чыгу эш-хәрәкәттән өстенрәк тора. Чынлыкта, романның яртысыннан артыгында баш герой эш итми, үзен берничек тә күрсәтми, ә бәлки китәргәме яки калыргамы дип баш ватып кына йөри.

Ш. Бикчуринның «Тирән катлам» романы прозабызның тагын бер җитди кимчелеген — зур характерларның, замандашларыбызның күренекле матур образларының булмавын ачык күрергә ярдәм итә. Шуннан башка проза ваклана һәм бетүгә йөз тота. Романның баш герое Курамшин да безнең алга вак һәм кызыксыз кеше, командировкаларда дон-жуанланып йөрүче бәндә булып күз алдына баса. Икенче дәрәҗәдәге персонажлар да хәтердә калмый. Автор аларның ниндидер физиологиягә кагылышлы сыйфатларын гына ассызыклап күрсәтә: берсе — туймас тамак, икенчесе «ак эш» эзләп йөри, өченчесе — кыймылдар-кыймылдамас авыраяк һ. б. Мондый очсызлы һәм әдәбиятыбыз күптән белеп онытkан алымнар белән ерак барып булмый, билгеле.

Инде без «производство темасына» язылган шуның ише спекуляцияләр белән килешеп торабыз икән, төссезлек һәм сәнгатьсезлек белән дә килешәбез дигән сүз. Ә болар бер Ш. Бикчурин романына гына хас күренешләр түгел.

Без әдәбиятыбызның гасырлар буена килгән бай тарихы бар дип кабатларга яратабыз. Әйе, Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов исемнәре — татар әдәбиятының гомуми тигезлеге өстендә калкып торган биеклекләр генә түгел, алар совет Көнчыгышының күп әдәбиятлары өчен дә якты маякларга әверелделәр.

Ләкин игътибарга лаеклы бер күренешне билгеләп үтәргә туры килә: революциягә кадәр үз әлифбалары да булмаган күп кенә халыкларның әдәбиятлары соңгы унъеллыклар эчендә ныграк үскән әдәбиятларны куып җитте генә түгел, еш кына хәлләрдә узып та китте. Кыргыз һәм казакъ әдәбиятларын гына алып карагыз. Ч. Айтматов, А. Нурпеисов, Ә. Алимҗанов, О. Сөләйманов, С. Санбаев исемнәре генә түгел, ә күпләгән яшь прозаиклар да һәм бу әдәбиятларның гомуми дәрәҗәсе дә, минем уемча, күп кенә борынгы әдәбиятлар, шул исәптән Урта Азия әдәбиятлары дәрәҗәсеннән шактый югарырак.

Очраклылыкмы бу? Юктыр дип уйлыйм. Традицияләр — куәтле, шифалы көч ул, әмма дөрес, иҗади үзләштергәндә генә. Шул ук традицияләр, әгәр дә алар белән масайсаң, алар белән генә чикләнә һәм тирә-ягыңдагы бернәрсәне дә күрми башласаң, аяктагы тышауга да әверелергә мөмкин.

Яшь республикаларның язучылары үткәндәге традицияләр белән азрак бәйләнгән, шуңа күрә алар ныграк үскән әдәбиятлар тәҗрибәсе белән кызыксынудан туймыйлар, рус һәм дөнья әдәбиятларының иң яхшы казанышларын, алымнарын кыюрак файдаланалар. Бөтен яңа, алдынгы нәрсәгә аларда ишекләр киңрәк ачык, һәм аларның өстенлеге дә әнә шунда.

Шунысын онытмыйк, новаторлык — шул ук традиция ул. Ләкин новаторлык яңаны, моңарчы булмаганны эзләүдән, инде урнашкан традицияләрне инкарь итүдән, күнегелгән, озакка сузылган карашларны җиңүдән башка мөмкин түгел. Безнең прозага иң элек менә шул — алга барудагы кыюлык, бөтен яңага «ачык тору», гасырыбызның әхлакый һәм фәлсәфи эзләнүләре югарылыгында хәрәкәт итү җитми дә инде.

Кыскасы, безнең прозадагы хәл бер яклап караганда, бик канәгать булырлык сыман. Ел саен үзәк нәшриятларда татар язучыларының 15—20 һәм аннан да күбрәк китаплары басылып тора (ә элегрәк елга нибары бер-ике китап тәрҗемә ителә иде). Әдәбиятыбызның күп кенә әсәрләре бөтенсоюз күләмендә бүләккә һәм премиягә лаек була, чит илләрдә басыла. Әмма шуның белән тынычланып калу һич тә ярамый. Артта калуның бик җитди билгеләре дә бар. Әлеге кимчелекләрне һәм йомшак якларны ачыклау, уңышлырак алга бару өчен бу хакта бар тавышка туп-туры итеп әйтергә кирәк.

## Фоат Галимуллин

# МӨМКИНЛЕКЛӘР БАР!

Шактый кызыклы, әйтергә кирәк, югары нотадан башланып китте бу сөйләшү. Моңа, әлбәттә, Аяз Гыйләҗевның кайнар да, динамикалы да, шул ук вакытта бәхәсле дә чыгышы беркадәр сәбәп булгандыр. Шулай да, минемчә, төп сәбәп тирәндәрәк ята: прозабызның язмышы, абруе дигән олы проблема соңгы елларда һәммәбезнең уртак гаменә әверелде, бу турыдагы уйлануларыбыздан мөлдерәмә тулы буа, ниһаять, ерылып китте... Проблема зур, һәркемдә минем генә көч җитмәс дигән уй да бар, шуңа күрә беренче чыгышларда аны хәл итәргә алынудан бигрәк, көн тәртибенә кую өстенлек итә кебек.

А. Гыйләҗевның «Әтәч менгән читәнгә...» повесте басылып чыккач, бу әсәр уңаеннан басылган бер рецензия дә «Хәйретдин агай чаң кага...» дип исемләнгән иде. Инде килеп, язучы үзе: «Прозабыз артка кала!» — дип безне җай гына яшәп яткан җиребездән сискәндереп җибәрде. Дөрес, ул бу өлкәдәге уңышларны күрми дип әйтеп булмый. Киресенчә, үз рухына туры килгән аерым язучыларны күкләргә күтәреп мактый, икенчеләрен кисkenлек белән «уртачалар» рәтенә төшереп куя. Шунысы әйбәт: әдәби әсәрләрне бәяләүдә ул олы критерийлар куя. Әйе, әдәбият күгендәге зур йолдызлар янында кайбер прозаикларыбызның тоныкланып калуы да бик мөмкин. Язучы үткен фикерләрен «күз чыгарырлык» итеп тә әйтеп куйгалый. Монда үзенә күрә бер психологик момент та игътибарга алынмый калмыйдыр. Әгәр язучыларга әсәрләрендәге кимчелекле якларны коллегасы әйтсә, алар моны гадәттә тынычрак кичерәләр, әллә ни күтәрелеп бәрелмиләр. Үзе яза торган кеше әйтсә дә урынында, диптер инде. Шул сүзләрнең чиреген генә булса да тәнкыйтьчедән ишетсә, авторның хәзер бала йоннары кабара. Менә син башта әйбәт итеп үзең язып күрсәт, аннан соң минем әсәр хакында хөкем йөрт, янәсе. Тәнкыйтьнең ролен бу рәвешле аңлаучыларны А. Гыйләҗев мәкаләсеннән дә күреп була. Кайбер язучылар «тузга язмаган әкәмәтләр укмаштырып язып куя да, «Роман яздым! Менә дигән әсәр!» дип, банкетлар уздыра башлый. Аларга тәнкыйть сүзе әйтеп кара син бүген! Шунда ук жалоба белән чаба башлыйлар! Тәнкыйть йомшак булу аркасында бездә күпләр прозаик булып йөри...» — ди ул. Монда дөреслек бар. Гомумән, тәнкыйть язучының шәхесенә карап түгел, әсәрдән чыгып кына язылырга тиеш. Шулай булмаса, А. Гыйләҗев әйткәнчә, «чины олы кеше шәп яза!» булып чыгуы да бар. Чын язучы бервакытта да тәнкыйтьтән курыкмый, аны акыл бизмәнендә үлчәп карый да, файдалы дип тапса, күңеленә салып куя, игътибарлы булганы өчен тәнкыйтьчегә рәхмәт әйтә. Д. И. Писарев әйткәнчә, «черегән әйбер генә тәнкыйть кагылудан куркып тора». Әйе, язучыларның тәнкыйтькә дөрес мөнәсәбәте әдәбиятны, бу очракта прозаны, үстерүгә ярдәм итә торган бик әһәмиятле мәсьәлә ул.

Хәзер бездә әсәрләрнең идея-эстетик дәрәҗәсен бәяләүдә бер критерий ныклап гамәлгә кереп бара, ул да булса — әсәрнең үзәк нәшриятларда басылып чыгуы. А. Гыйләҗев мәкаләсеннән дә бу ачык күренә. Монда хакыйкать юк түгел. Ни өчен дигәндә, Мәскәү, Ленинград нәшриятлары йомшак әсәрләрне басарга бик атлыгып тормыйлар. Димәк, кабул ителгән икән, ул роман-повестьлар гомумсоюз укучысы зәвыкларына туры килә дигән сүз. Анда илебезнең төрле милләт язучыларының аеруча уңышлы дип табылган әсәрләре дөнья күрә дә. Әмма бу өлкәдә хәл ителәсе мәсьәләләр артыгы белән күп бит әле. Бөтен эш югары таләпләргә җавап бирерлек тәрҗемәчеләргә барып терәлә. Бар син, Такташны оригиналь яңгырарлык итеп тәрҗемә кылып кара! Ф. Хөснинең челтәрле, бизәкле, йөгерек телен бөтен колоритын саклап тәрҗемә итү дә — бик кыен эш. Х. Туфан, Ә. Еники әсәрләре белән дә шул ук хәл. Уңышлы тәрҗемә итү — әсәрне яңадан язу белән бер. Г. Ахуновның «Хәзинә» романы Мәскәүдә Рәшит Ахунов тәрҗемәсендә чыккач, бу әсәргә кайберәүләр өр-яңадан игътибар иттеләр. Бу вариант оригиналга аеруча тәңгәл килә, димәк, әсәрнең халыкчан рухын укучыга тулырак җиткерә.

Кайбер язучыларыбыз, Мәскәүдә китабын чыгаруга ирешкәч, масаеп китә. Әсәрләрне үзәк нәшриятларга тәкъдим итү эшен язучылар союзы үз кулына алса, бу

өлкәдә тәртип яхшырыр иде. Шул вакытта «җаен белә торган» кеше түгел, бәлки намуслы иҗат белән мәшгуль язучыларның әсәрләре Бөтенсоюз укучысына тизрәк ирешер иде. Бу үз чиратында прозабызның идея-эстетик дәрәҗәсен күтәрүгә дә уңай йогынты ясаячак.

Тагын бер мәсьәләне күтәреп куясы килә. Әсәрләрнең сыйфатын яхшыртуда китап укучыларның да ярдәме тиергә мөмкин, һәм ничек кенә әле! Укучы әсәрне гадәттә кызык тоелса укый, мавыктырмаса читкә алып куя. Аны юк-бар белән алдап булмый. Нигезенә бик яхшы идея салынса да, әгәр сәнгать көче чамалы булса, укучының күңелен биләмәсә, теге яки бу әсәр үзенең иҗтимагый функциясен үти алмый. Әмма ничектер бераз кыюсызрак безнең укучы. Үз фикерләрен авторга, газета-журналларга сирәк яза, язса да — билгеле бер дипломатия белән, йомшак кына әйтә. Язучыларга аларның әсәрен ошаткан укучыдан гына хат килә. Язучыларның укучылар белән очрашуы да шул рухтарак уза. Бәлки, компетентлык җитмәс дип шикләнү дә бардыр. Тагын бер сәбәп бар: ул — безнең халыкта элек-электән ташка басылган сүзне олылау. Басканнар икән, димәк, яхшыдыр, миңа гына барып җитмидер дип уйлый ул. Аннары татар укучысы бүген үзенең әдәбиятка сусавын рус телендә чыккан әсәрләрнең иң яхшылары белән баса. Шуңа күрә ул кайсыбер төссез әсәрләрне укып та тормый, алар турында фикерен дә әйтми, дау да күтәреп йөрми. Уйласаң, уйланырлык бит бу!

Прозаның хәзерге көн таләпләреннән калышуының тагын бер сәбәбе — фәнни-техник революция нәтиҗәсендә җәмгыять үсешендә һәм дөнья күләмендә бара торган катлаулы процесслар җирлегендә кеше аңында, үз-үзен тотышында, яшәү рәвешендә килеп чыккан нюансларны сурәтләүнең яңа формаларын табып җиткерә алмауда. Ч. Айтматовның соңгы романы ни өчен шулай уңыш казанды? Чөнки аның үзәгендәге проблемалар, автор сурәтләргә теләгән геройлар кыю, яңача хәл ителгәннәр. Аны укыганда баш миендә бертуктаусыз фикерләү процессы бара. Моңа кадәр үзең дә уйлап йөргән кайбер нәрсәләрнең автор тарафыннан билгеле бер бөтен хәлендә ачып бирелүе таң калдыра. Ул гына да түгел, язучы, гадәти сюжет кысаларыннан чыгып, вакытны узып китә, яки, киресенчә, халыкның зур тарихыннан җәүһәр булырлык гыйбрәтләрне алып, әсәр тукымасына сала. Шул рәвешле, бүгенге кешеләр үткән һәм киләчәк призмасына куеп яктыртыла. Әсәрдәге фикер хәрәкәтенең көче укучыны әсир итә.

Ч. Айтматов әсәрләренең төзелеше һәм формасы, вакыт узган саен, үзгәрә бара. Чөнки төрле чордагы тормыш материалын бертөсле буяулар белән биреп булмый. Язучыны иҗат зенитында менә шушы мәгънәдәге динамика яшәтә. Ә бу җиңел эш түгел. Укучының игътибарын яулап алу үзе бик авыр булса, шул игътибар үзәгендә күп еллар буе саклану аннан да авыррак. Биредә язучының осталыгы аның художник буларак өлгергәнлеге белән генә түгел, гражданлыгы белән бергә килеп кушыла. КПССның XXVI съездында язучыларыбыз алдына нәкъ әнә шундый олы мәгънәдәге бурыч куелды да. «Партия иң яхшы әсәрләргә хас гражданлык пафосын, кимчелекләр белән килешмәүне, сәнгатьнең җәмгыятебезне дулкынландыра торган проблемаларны хәл итүдә актив катнашуын хуплый»[1]. Л. И. Брежнев съездда сөйләгән докладында тамашачыларның һәм укучыларның әдәбият-сәнгать әсәрләрендә үз фикерләренә һәм кичерешләренә аһәңдәшлек табарга, совет характерының иң яхшы сыйфатлары гәүдәләнешен күрергә теләвен әйтте. Ә бу олы бурычны үтәү, мәгълүм булганча, тормышны яхшы белүгә бәйле. Партия съездыннан соң без иҗатыбызга яңача карарга тиеш булдык, һәр язучы үз иҗат планын чор таләп иткән бурычлар яктылыгында тагын бер кат җентекләп карап чыккандыр. Съездан соң тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевнең «Иртәгәсе көнне кайгыртып» дигән мәкаләсендә ул бурычларның иң әһәмиятлеләреннән берсе болай формалаштырылган иде: «Әдәбиятта күп тапкырлар кабатланып килгән сюжет, тема, характер һәм мөнәсәбәтләрнең яңа вариацияләрен уйлап чыгарудан кискен рәвештә борылырга, чынбарлыкны китаптан, сәнгать әсәрләреннән, истәлекләрдән — икенчел чыганаклардан түгел, тормышның үзеннән өйрәнергә. Язмыш һәм вакыйгаларның барышын ничек булган шулай теркәп бару түгел, шуларның асылына төшенеп, шуларга нигезләнеп чор һәм буыныбызның үзгәлеген, яңалыгын үзгә һәм яңа характерлар аша чагылдырырга». («Социалистик Татарстан», 1981, 25 октябрь).

Тормышны белү — командировкага барып, бер-ике ай эчендә сурәтләү объектының күзәтеп өйрәнү дигән сүз түгел. Бәлки, аның да азмы-күпме файдасы бардыр. Тормышны белү — сурәтләү объектының һәм күтәрәсе проблемаларының ана сөте белән каныңа сеңгән булуы. Шундый сеңү юк икән, аны берниндн өстән-өстән күз йөртү белән ала алмыйсың.

Әйтик, Шукшин да Шукшин дибез, аны чорыбызның иң үзенчәлекле, чын халык тормышын тирәннән каерып алып, күңелеңә кереп утыртырлык дәрәҗәдә күрсәтеп бирү осталыгына ия дибез, иҗатта аңа йөз тотарга чакырабыз. Ул нәрсә турында язган? Себер һәм аның кешеләре турында. Югыйсә Шукшин башкалада яшәгән, әдәбият-сәнгать дөньясында кайнаган. Әмма әдәби иҗатында нигездә үз күңеленә бала чактан ук якын, аңлаешлы булган туган як кешеләрен үз итә, аларның күңел дөньясын белә, аңлый. Ул геройларның теле дә, гореф-гадәтләре дә үзләренеке.

[1] КПССның XXVI съезды материаллары. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981, 65 бит.

Татар әдәбиятына килгәндә, Г. Бәширов, Ф. Хөсни иҗатларын алып карыйк. Бөтен барлыклары белән авыл балалары — иҗатлары да авыл кешеләренә багышланган. Авылны җиде буынына җиткәнче нечкә тоючы сүз рәссамнары. М. Мәһдиев иҗаты турында яратып сөйлибез икән, ул да бер темага тугрылыклы — сугыш вакыты һәм аннан соңгы авылны бүген аннан да тәфсилле кем белә?

Ә менә кайбер язучыларыбыз, мәсәлән, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Б. Камалов, М. Хәбибуллин, Ә. Баянов, Э. Касыймов һәм башкалар тормышның төрле өлкәләренә күз төшерәләр, үз иҗатларының артык киңәеп китүенә юл куялар. Дөрес, бу авторлар бүгенге әдәбиятыбызның төп көчләре, алар иҗаты әдәбиятыбызның хәзерге йөзен, зурлыгын билгели. Ләкин шулай да, диапазонны тарайту исәбенә тирәнлеккә омтылсак, безнеңчә, моннан әдәбият отар гына иде. Бу — иҗат көчләребезне, талантларыбызны рациональ файдалануның магистраль юлы булырга тиеш. Шул уңайдан С. Хәким сүзләренә колак салыйк. «Минемчә, язучының, шагыйрьнең тормышта озаклап өйрәнә торган үз өлкәсе, үз темасы булырга тиеш,— дип яза ул.— Икенче төрле әйткәндә, әдиптән дә чынбарлыкны билгеле бер өлкәсендә специальләшү сорала. Очраган бер темага әсәр язарга алынучы авторга зур өметләр баглавы, аның иҗатыннан җитди нәтиҗәләр көтүе кыен» [1].

Борчылырлык күренешләрнең тагын берсе шул — без әле күп очракта тормыш проблемаларын тотып алып, аларның кеше язмышларына тәэсирен, ягъни проблеманы герой аша күрсәтеп бирә алмыйбыз. КамАЗ төзүчеләргә багышлап язылган әсәрләрне генә алыйк. Алар сан ягыннан шактый. Ә. Баянов, М. Хәбибуллин, Б. Камалов, М. Хәсәнов, Р. Солнцев бер-бер артлы роман-повестьлар бастырдылар. Ләкин язучыларыбызның кайсысы: «Мин гасырыбыз төзелешен иңенда күтәргән камазчылар алдында художниклык һәм гражданлык бурычымны үтәдем»,— дип әйтә ала? Әлеге әсәрләр укылалар, кайсылары мавыктыралар да. Ә киң яңгыраш ала алмадылар. Хикмәт авторларның гигант төзелештә әлеге дә баягы командировкада гына булуларында. Әле 1976 елда ук Г. Ахунов болай дигән иде: «КамАЗны алсак, аны әдәбиятта күрсәтүдәге төп кимчелекне мин болай күз алдына китерәм. Әдипләр бу төзелештә бик мәһабәт бер бина тирәсендә йөргәндәй йөгереп йөриләр, нинди зур, нинди мәһабәт дип сокланалар, әмма эченә кереп карарга базмыйлар. Шул сәбәпле җисем азрак, соклану, тел шартлату күбрәк булып чыга» [2]. Бу сүзләр сиксәненче еллар өчен дә актуаль булып кала бирәләр. Биредә тормышны өйрәнүне Г. Әпсәләмовча аңлау зарур. «Репортер өчен ике атна да җитә торгандыр, ә язучыга кешеләрне өйрәнер өчен еллар кирәк. Кеше бит деталь түгел, аның җаны уйнап тора, салават күпере төсләренә кереп, күзләрне дә чагылдыра, кайчак сукырайта да. Кыскасы, кешеләргә озак карарга, аларның күңел нечкәлекләрен анык белергә кирәк» [3].

Аерым кешенең үзенә генә хас характеры булган кебек, һәр төзелешнең дә аны башкаларыннан аерып торучы үзенчәлекләре була. КамАЗ кебек төзелештә ул бигрәк тә шулай. Ә төзүчеләр бу автомобиль гигантын күтәрү дәвамында аңа гына характерлы ниндирәк проблемаларны хәл иттеләр соң? Шуларны ачыклыйк.

Беренчесе, биредә төзелеш эш сызымнары буенча башланды, техник проектлаштыру төзелеш белән бергә алып барылды.

Икенчесе, багана фундаментлары бораулап утыртылган субайлар белән алыштырылды. Бу да эш процессында гамәлгә кертелде.

Кыскасы, чынбарлык үзе әдәби әсәр өчен проблемаларның кискеннәрен, аларны тормышка ашырганда, кешеләрнең кемлеге ачылачагын тәэмин итәрдәйләрен язучылар кулына китереп тоттырды. Эш барышында проектлауның дәвам итүе төзүчеләр һәм проектлаштыручылар арасында нинди генә фикер каршылыклары, бәхәсләр, конфликтлы ситуацияләр китереп чыгармагандыр дисең? Булдымы шуларның берсен әдәби әсәр үзәгенә куеп сурәтләү? Юк, булмады. Ә бит бәхәстә дөреслек туа, конфликтта характер ачыла.

Ә менә икенче проблеманың язмышы бәхетлерәк булды кебек. Ул, прозаикларыбыз күзеннән читтә калса да, драматург Диас Вәлиевне җәлеп итте. Дөрес, бу турыда үзенең «Урамнар киңәя» повестенда Б. Камалов та искә алып уза, әмма аңа эстетик әһәмият бирми. Д. Вәлиев исә бу техник яңалыкта катлаулы идея-эстетик концепцияләрне ачып бирү, совет кешеләренең әхлакый, профессиональ, политик җитлеккәнлекләрен күрсәтү мөмкинлеге күрде. Зур проблемалар янында эре характерлар ачыла башлады. Язучы үз геройларын чынбарлыкны чагылдыручылар гына түгел, ә дөньяны үзгәртеп коручылар итеп сурәтләде. Аның үз бурычын әнә шул рәвешле олы итеп аңлавы әсәрнең көчле иҗтимагый-эстетик яңгырашына нигез булды.

Күргәнебезчә, КамАЗның тышкы күренешенә генә соклану, өстә ятканны гына күрү калку геройлар тудырырга ярдәм итә алмый.

Соңгы вакытта Феодосий Видрашку «Набережные надежды» дип аталган әсәр язды («Новый мир» журналы, 1982, 4 нче сан, 5—123 битләр). Ул аны «хәзерге Чал-

---

[1] Әшчеләр сыйныфы һәм әдәбият. Түгәрәк өстәл артында сөйләшү.— Социалистик Татарстан, 1976, 27 июль.

[2] Әшчеләр сыйныфы һәм әдәбият. Түгәрәк өстәл артында сөйләшү.— Социалистик Татарстан, 1976, 27 июль.

[3] Кашапов Г. Кайгыртучан остаз.— Социалистик Татарстан, 1982, 15 август.

лы күренешләре» дип атый. Исеменнән үк күренгәнчә, әсәр документаль нигездә язылган бик күп бүлекләрдән тора. Реаль кешеләр турында язу авторның язучылык фантазиясен чикли кебек. Ләкин, Г. Әпсәләмов әйткәнчә, андый геройларны «тормыш үзе шундый югарылыкка күтәргән, аларда совет кешеләренең уртак сыйфатлары шулкадәр көчле тупланган, алар, язучы тарафыннан гомумиләштерелмичә дә, әдәби әсәр герое булып керә алалар»[1]. Әсәрнең үзәгендә — шәһәр партия комитетының беренче секретаре Рәис Кыямович Беляев һәм «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе начальнигы Евгений Никанорович Батенчук. Дөнья күләмендәге зур төзелеш җәелдерелгән шәһәрнең политик һәм производство житәкчеләре булган бу шәхесләрнең гап-гади кешеләргә хас тормышы белән танышу укучы өчен бик кызыклы. Һәр бүлектә, һәр җөмләдә авторның сурәтләгәннәргә ачык позициясе, хикәяләү осталыгы, публицистик кайнарлыгы, лириклык көче сизелә. Бу әсәр безнең язучыларның файдаланылмаган, эшкә җигелмәгән мөмкинлекләре турында да сөйли. КамАЗ төзүчеләргә багышлап моңа кадәр язылган проза әсәрләре сәнгатьлелек ягыннан әллә ни югары бәя ала алмагач, язучыларыбызны әлеге тема бераз өркетеп җибәрде кебек. Әмма бу турыда язу, олы төзелештән иҗат өчен илһам алу безнең гражданлык бурычыбыз булып кала бирә.

Әдәбиятыбызның иҗат көчләре, аерым алганда прозаиклары күп, алар алдына таләп һәм бурычларның зурдан куелуы да табигый. Халкыбызның талантлар чишмәсе һәрвакыт мул булды, ул алга таба да саекмас. Урта буын әдипләр эзеннән Ә. Гаффар, М. Галиев, Ф. Гыйльметдинов, Г. Кашапов, Р. Вәлиев, Р. Кәрами кебек яшьләр килә. Алар, безнең карашыбызча, бүгенге тормышны, хәзерге геройларны сурәтләүдә иркенрәк эш итәләр, заманга яраклы формаларны уңышлырак табалар. Яшьләребез тагын да кыюрак, хезмәт сөючәнрәк булсыннар иде. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәсе турында»гы карарында: «Совет кешеләренең яңа буынны рух һәм вакыт буенча үзләренә якын булган, сәнгатьчә ачыш дип кабул ителердәй, кешеләрнең эш-гамәлләренә тәэсир ясардай, халык язмышын чагылдырырдай уңай геройга мохтаж»,— дип әйтелгән икән, бу ихтыяҗны канәгатьләндерүдә яшьләргә йөз тоту дөрес булыр.

Миң еш кына мәрхүм И. Газиның «Юл барганда» дигән мәкаләсенә мөрәҗәгать итәм. («Социалистик Татарстан», 1968, 19 сентябрь). Күләме белән артык зур булмаган чыгышында ул әдәбиятыбыз алдында торган бурычларны бер фокуска туплап, үтемле итеп әйтә белгән. Юл барганда туктап уйланып алу безгә дә ярдәм итәр дип өметләник.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!**

**Бүгенге проза проблемаларына багышланган сөйләшү дәвам итә. Сездән хатлар, язмалар, мәкаләләр көтәбез.**

[1] Кашапов Г. Кайгыртучан остаз.— Социалистик Татарстан, 1982, 15 август.

Нил Юзиев

# ГАҖӘЕП ТАЛАНТ

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әхмәт Фәйзине без күбесенчә шагыйрь буларак искә алырга күнеккәнбез. Аның татар шигъриятен үстерүдәге, баетудагы эшчәнлеген һәм кабатланмас якты талантын әдипләр дә, әдәбият галимнәре дә, укучылар да югары бәяләделәр. «Әхмәт Фәйзи — барыннан да бигрәк шагыйрь, татар совет поэзиясендә аерым урын биләгән шагыйрь,— дип язган иде Сибгат Хәким шагыйрьнең өч томлыгына кереш сүзендә.— Әдәбият фәне белгечләре, һичшиксез, беренче сүзне аның шагыйрьлегеннән башлап китәрләр. Ул әле, дөресен әйткәндә, тиешенчә өйрәнелмәгән һәм тиешенчә бәя бирелеп җиткерелмәгән шактый катлаулы, үзенчәлекле шагыйрьләрнең берсе». (I том, Казан, 1964, 6 бит).

Чынлыкта шулай булып чыкты да: әдәбият галимнәре Әхмәт Фәйзи турындагы җитди сүзне аның шигырьләреннән һәм поэмаларыннан башлап киттеләр. Тәлгат Галиуллинның «Заман сулышы» (1979) исемле монографиясендә Әхмәт Фәйзи поэзиясе хаклы рәвештә төп урыннарның берсен алып тора. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында да шагыйрь иҗаты турында кандидатлык диссертациясе языла.

Белүебезчә, Ә. Фәйзинең әдәби мирасы поэзия белән генә чикләнми. Ул — гаҗәеп мул талантлы әдип. Үзенең кырык елдан артыкка сузылган иҗат эшчәнлеге дәверендә Ә. Фәйзи татар әдәбиятының күп тармакларында тирән эз калдырды. Хәзер инде, ниһаять, әдипнең поэзиядән башка өлкәләрдәге эшчәнлегенә дә игътибарлырак булырга, аларын да җентекләп өйрәнергә вакыт җиткәндер. Шушы фикергә нигезләнеп, мин бу юлы игътибарымны әдип иҗатының моңа кадәр күләгәдәрәк кала килгән кайбер өлкәләренә, иҗатының һәм тормыш юлының ачыкланып җитмәгән кайбер фактларына юнәлтмәкче булам. Сүзне әдипнең башлангыч чор иҗатыннан алып китү урынлы булыр.

Ә. Фәйзи үзе исән чакта тормышы һәм иҗаты турында берәр әсәр яки хезмәт язарга өлгерә алмады. Шул сәбәпле аның биографиясендәге аерым фактларны күп төрле чыганакларга таянып кына ачыкларга мөмкин.

Ә. Фәйзинең сеңелесе Зәйнәп апа Фәйзиевада әдипнең башлангыч иҗат адымнарын ачыкларга ярдәм итә торган аерым материаллар очрый. Менә, мәсәлән, кадрларны исәпкә алу буенча гадәттә тутырыла торган официаль кәгазь. Әдип анда 1911—1915 елларда Уфада мәдрәсәдә укуы, 1915—1917 елларда рус-татар мәктәбенә йөрүе, 1917—1921 елларда рус урта мәктәбендә укуы турында язган.

«Ул еллар...» дип исемләнгән истәлекләрендә (1957) Ә. Фәйзи гимназиядә уку елларына, шул чор атмосферасына конкрет туктала: «Укытучыларыбызның күпчелеге демократ карашлы кешеләр булу сәбәпле, безне, берничә ярлы укучыны, алар үз шефлыкларына алдылар, һәм без аларның үзара төзегән «ярлы укучыларга ярдәм» кассасы хисабына укыдык. Тора-бара гимназия гади совет мәктәбе булып әверелде». Шунысын да өстәп әйтү кирәктер: Ә. Фәйзи гимназия укытучылары белән бәйләнешен соңыннан да дәвам итә. Татар гимназиясенең шул вакыттагы директоры, Пе-

дагогия фәннәре академиясенең член-корреспонденты профессор В. А. Кондаков белән дуслыгы әдип гомеренең соңгы көннәренәчә сузыла. Мәскәүдә яшәүче әдип үзенең укытучысына хатлар язып тора, русча басылган әсәрләрен җибәрә. Ә. Фәйзи архивында әдипнең остазына язган тугыз хаты бар. Хатларында ул үзенең иҗат уңышлары турында хәбәр итә, Мәскәүдәге рәсем күргәзмәләре хакындагы фикерләре белән уртаклаша, остазына хөрмәт сүзләрен җиткерә. «Алдынгы рус тәрбиясе миңа да үзенең могҗизалы тәэсирен сиздереп узды, миндә иҗатка кызыксыну уятты...» — дип әдип үзенең Уфада гимназиядә укыган елларын искә төшерә. Ә. Фәйзинең яшьтән үк иҗатка тартылуында, талантының тиз ачылып китүендә, чыннан да, алдынгы рус культурасының зур йогынтысы булды. Әдип үзе әлеге күренешне «могҗиза» дип атый икән — тикмәгә түгел. Моңарчы безнең әдәбият белемендә бу «могҗиза»ның күп төрле фактлар җирлегендә расланып ачылганы юк әле.

Ә. Фәйзи үзенә көчле тәэсир ясаган укытучылары арасында гимназиянең ул вакыттагы укыту бүлеге мөдире, татар теле мөгаллиме Закир Шакировны да искә ала.

Уфадагы әдәби мохит, татар гимназиясе Әхмәт Фәйзине чын мәгънәсендә иҗатка уята һәм рухландыра. Иҗатының юл башы аның шушында: ул шунда беренче өйрәнчек шигырьләрен һәм пьесаларын яза, русчадан тәрҗемә итүе дә шушы елларда гимназиядә башлана. «Әдәбият түгәрәге төзеп җибәрдек һәм «Безнең дөнья» дигән журнал оештырдык,— дип искә ала шагыйрь үзе истәлекләрендә.— Хәтеремдә, без аны өч телдә атап, русчасын — «Наш мир», немецчасын «Унзере велт» дип яза идек... Әдәбият түгәрәге дә, журнал да үзенең төп юнәлеше итеп революцион идеяне, совет идеясен алды». Бәхеткә, шагыйрь архивында әлеге журналның бер саны — 1920 елгы январь саны сакланып калган. Анда Ә. Фәйзинең «Кыш, кит!», «Кар кеше» кебек берничә шигыре һәм хикәягә охшаш язмасы урнаштырылган. Аерым кешеләр кулында бу журналның башка саннары да саклануы ихтимал. Аларны табу шул чорда Уфада булган әдәби мохитне тулырак танып-белергә, шул тирәлектә каләмнәре чарлана башлаган яшь иҗат көчләренең беренче адымнарын конкретрак күзәтергә ярдәм итәр иде. Архивта сакланган автобиографиясендә (1936) Ә. Фәйзи «семьяда һәм мәктәптә кульязма журналлар, газеталар чыгаруы» турында язып үтә. Язучы иҗатының чишмә башын ачыклау өчен ул кульязма чыганакларны табу шулай ук зур әһәмияткә ия.

Архивта Ә. Фәйзинең беренче драматик әсәре — «Матурлык дөньясында» комедиясенең кульязмасы саклана. Ул да Уфадагы татар гимназиясендә уку дәверенә карый. Әмма аның язылу вакыты матбугатта төрлечәрәк билгеләнеп йөри. Ф. Хөсниның «Әхмәт Фәйзи — драматург» исемле мәкаләсендә (1956) «Матурлык дөньясында» комедиясе 1918 елда иҗат ителгән дип әйтелә. «Совет Татарстаны язучылары» белешмәсендә дә (1957) әсәр шушы дата белән күрсәтелгән. Әлеге ике хезмәтнең дә шагыйрь үзе исән вакытта дөнья күрүен һәм авторларның әдипнең үзе белән киңәшүләрен искә алсак, бу датаның шулай күрсәтелүенә ышаныч кимеми. Ә менә Ә. Фәйзи әсәрләренең өченче томында комедиянең язылу вакыты 1920 ел дип куелган. Кайсысы дөрес? Бу факт киләчәктә тагы да төгәлрәк ачыкланырга тиеш. Ә хәзергә мин үзем язучының хәтеренә нигезләнгәнгә караганда документаль чыганакларга таянып хәл ителгән датаны — 1920 ел датасын дөреслеккә якынрак дип исәплим. Беренчедән, архивтагы кульязма — авторның үз кулы белән язылган һәм дәфтәр тышына да датаны автор үзе куйган. Икенчедән, кульязма дәфтәр эчендәге газета рецензиясе дә шушы датаны раслый. Рецензиянең баш өлеше юк. Нинди газета икәнлеге дә билгеле түгел. Шул елларда Уфада чыккан «Яшь юксыл» булуы ихтимал. Ул 1921 елның 15 апрелендә басылган. Рецензиядә пьесага һәм спектакльгә уңай бәя бирелә: «Бу кечкенә комедия Уфада икенче баскыч эш мәктәбенең өченче группасында укучы Әхмәт Фәйзи тарафыннан язылган. Әсәрнең язылуы шома, теле матур. Бу әсәргә үлчәгәндә, язучыда яхшы гына талант барлыгы сизелә. Яшь язучыга якты истикъбал теләмичә үтеп булмый». «Өченче группа укучысы» дигән гыйбарә үзе үк 1919—1920 нче уку елына ишарә ясый түгелме? Пьесаның язылу вакыты белән куелу арасының якынлыгы да, рецензия басылу датасы да кульязма дәфтәрдә күрсәтелгән вакытның дөрескә чыгуын раслый.

«Матурлык дөньясында» комедиясе Уфада гына түгел, Оренбург сәхнәсендә дә уйнала. Бу турыда да архивта кайбер фактлар сакланган. Кульязма дәфтәрнең иң ахыргы битенә автор тарафыннан түбәндәгечә язып куелган: «Оренбургта яшь татар язучылары түгәрәге тарафыннан ачлар һәм ярлы татар язучылары файдасына 7 сентябрьдә (1922) Шәрык институты залында куелды. Уйнаучылар:

Хәзрәт — Ченәкәй.

Абыстай — Сафина.

Ибраһим — Фәйзи.

Авыл малае — Муса Җәлил».

Ә. Фәйзинең Оренбург чоры бик аз вакытны эченә ала (1921 елның августы — 1922 елның декабре). Ачлык сәбәпле, ул Көнчыгыш институтында укуын ташлап, Төрекмәнстанга китәргә мәҗбүр була. Күрүебезчә, архивтагы кайбер чыганаклар Ә. Фәйзинең Оренбург чорын да беркадәр тулырак күзалларга булышалар. Шунда ул яшь татар язучылары түгәрәгендә катнаша, беренче тапкыр Муса Җәлил белән очраша һәм дуслаша. Аның шагыйрь Төхфәт Ченәкәй белән Уфада башланган танышлыгы һәм якынлыгы Оренбургта да дәвам итә. «Матурлык дөньясында» комедиясен куюда өч яшь әдипнең (Ченәкәй, Җәлил, Фәйзи) катнашуы да шушы якынлык турында сөйли.

Архивта Ә. Фәйзинең Төрекмәнстанда яшәү чоры (1923) турында да байтак мәгълүматлар табарга мөмкин. Мәсәлән, анда әдипнең 1923 елны алып барган көндәлек дәфтәре сакланган.

Икенче бер документ — 1922 елның 14 апрелендә Полторацк шәһәрендә ач балалар файдасына оештырылган әдәби-музыкаль кичәнең программасы. Игъланнан күренүенчә, бу кичәдә Ә. Фәйзи ялгыз җыр белән катнашкан һәм «Пугачев» исемле бер пәрдәле спектакльдә Салават ролен башкарган. Пьесаның авторы күрсәтелмәгән. Аны Ә. Фәйзи үзе язмады микән? — дигән сорау тууы да табигый, чөнки бу елларда инде аның пьесалар язу тәҗрибәсе дә, үзе язган әсәрләрдә төп рольләрне башкару тәҗрибәсе дә бар. Әмма хәзергә бу фикерне ныклы итеп дәлилләрлек фактлар җитәрлек түгел. Һәрхәлдә, Ә. Фәйзинең Пугачев хәрәкәтенә багышланган пьесада уйнавы аның үзе өчен бөтенләй эзсез үтмәгәндер дип уйларга кирәк. Соңрак «Пугачев Казанда» исемле тарихи пьеса яза башлау өчен оеткының шул вакытларда ук салынган булуы да мөмкин!

Фатих Хөсни бик хаклы язганча, «Уфада, Оренбургта, аннары Төрекмән сахраларында, Ашхабад, Тәджән шәһәрләрендә берүк вакытта язып та, артист булып уйнап та йөргән Әхмәтне, 1924 елларда Уфада һөнәр патронатында яшәгән чагында ук балалардан труппа төзеп, шул труппа өчен бер пәрдәлек, ике пәрдәлек кечкенә-кечкенә пьесалар коеп торучы Әхмәт Фәйзине кем генә театр өчен туган кеше димәс икән!»

Архив материалларын актарганда, миңа Ә. Фәйзи тормышының нәкъ шул чорына караган, үз вакытларында Уфа яки Донбасс театр труппалары тарафыннан куелып йөртелгән, әмма матбугатта басылмаган бик күп пьесалары белән очрашырга туры килде. Шуларның берсе — «Газетчы Вәли». Бу әсәрнең кульязма дәфтәрләрдә ике күчермәсе бар. Дәфтәр тышына: «Яшьләр театрыннан өченче китап. Уфа. Патронат»,— дигән сүзләр теркәлгән. Язылу вакыты күрсәтелмәгән. Әдип үзенең автобиографиясендә 1924 елны 8 ай Уфада балаларның уку-һөнәр мәктәбендә (патронатта) тәрбияче һәм бүлек мөдире булып эшләве турында яза. Димәк, бу пьеса да 1924 елны язылган һәм балалар тарафыннан куелган булып чыга. Пьесада ачлык еллардагы ятим балалар көнкүреше һәм аларга Совет дәүләтенең ярдәм кулы сузуы сурәтләнә.

Шул еллардагы агиттеатр пьесалары рухында язылган икенче әсәре — тугызынчы январь вакыйгаларына багышланган «Канлы якшәмбе» пьесасы. Бу әсәрнең дә кульязмасы архивта саклана. Ул аны Донбасста халык мәгарифе системасында эшләгән дәверендә язган. Кульязманың ахырында язылу вакыты: «1924 ел, 4 декабрь, Сталино»,— дип күрсәтелгән.

Үзләренә килгән саен, Зәйнәп апа миңа яңа папкалар чыгара тора. Аларның эчендә исә — Ә. Фәйзинең 20 нче елларда язган пьесаларының яңадан-яңа кульязмалары. Менә иң нык гаҗәпләндергәне — ул пьесаларның сан ягыннан күплеге, үз

вакытында Уфа, Оренбург, Мәскәү, Донбасс сәхнәләрендә уйналулары һәм алар турында театр-драматургия тарихына караган хезмәтләрдә бер сүз дә әйтелмәве. Ул пьесаларның һәрберсенә тукталып, анализлап үтү мөмкин түгел, биредә мин укучыларны ул әсәрләрнең исемнәре белән генә булса да таныштырып үтүне кирәк саныйм. Менә аларның минем күзгә чалынганнары:

1. Трагедия. 2. Им-том. (Комедия). 3. Бибикамал ханым. (Комедия). 4. Мокамай дәрес хәзерли. (Бер пәрдәле пьеса). 5. Ярдәм төркеме. (Бер картиналы пьеса). 6. Сарайларга сугыш. (Комедия). 7. Чәчәкләр китердек. (Балалар пьесасы). 8. Кызыл васыять. (Драма). 9. Күмер батыр. (Эшчеләр пьесасы). 10. Кечкенә дәһриләр. (Яшьләр пьесасы). 11. Урам кочагында. (Балалар пьесасы). 12. Париж — Версаль. (Бер пәрдәле пьеса). 13. Ил күкрәгендә. (Өч пәрдәле пьеса). 14. Ишәй белән Кушай. (Бер пәрдәле пьеса). 15. Ташландык пристань. (Бер пәрдәдә). 16. Кара сакал. (Ике картиналы балалар пьесасы). 17. Умырзая. (Өч пәрдәле комедия). 18. Мәрмәр кисәге. (Өч пәрдәле комедия). 19. Биби. (Өч пәрдәле пьеса). 20. Беренче карлыгач. (Пьеса). 21. Гыйффәт Зарская. (Дүрт пәрдәле пьеса). 22. Чуен чаң. (Дүрт бүлекле роман-пьеса).

Ә. Фәйзинең 20 нче елларда язган пьесаларын санап үтү генә дә аның театр белән бәйләнеше никадәр тыгыз булганлыгы, драматургиягә һәм агиттеатрга гаять зур әһәмият бирүе турында сөйли. Театр һәм драматургия белгечләре киләчәктә әдипнең бу чор драматургиясен дә читләтеп үтмәсләр һәм тиешле бәяләрен бирерләр дип ышанырга кирәк.

Ә. Фәйзинең югарыда искә алынган пьесаларының байтагы агиттеатрга карый. Безнең бу өлкәгә хәзергәчә тиешле игътибар юнәлткәнебез юк әле. Ә бит агиттеатр очраклы рәвештә генә тумаган! Чорның таләбе шулай булган — халыкны агарту өчен, яңа рухта тәрбияләү өчен зарури рәвештә барлыкка килгән ул. Чор таләбен искә алып, күренекле әдипләр (Г. Камал, К. Тинчурин, һ. Такташ һ. б.) агитпьесалар язганнар. Ә. Фәйзинең агитпьесалары да шул чорның ихтыяҗына җавап буларак туганнар, үз вакытының эстетик таләпләрен канәгатьләндергәннәр.

30 нчы еллардагы татар совет драматургиясе турында язылган хезмәтләрендә Ә. Фәйзинең нигездә «Тукай» драмасы гына телгә алына. Хәлбуки, Ә. Фәйзи бу елларда да театр белән якын бәйләнештә яши, күп кенә пьесалар һәм либреттолар иҗат итә, үзен житди драматург буларак таныта. Бу елларда ул бигрәк тә комедия жанрында актив эшли. Аның «Төтен» сатирик комедиясе, мәсәлән, үз вакытында клуб сәхнәләрендә уңыш белән бара. Автор аны Татар дәүләт театрына да тәкъдим итеп карый. Ул вакытта театрның директоры һәм художество җитәкчесе булып эшләгән Риза Ишморат сатирик әсәргә нигездә уңай бәя бирә, тәнкыйть фикерләре дә әйтә. Ә. Фәйзи, тәнкыйтькә колак салып, әсәрен төзәтеп тә карый — архивта сакланган берничә варианты әнә шул эш процессын ачыклыйлар. Әмма, ни өчендер, сатирик әсәр барыбер театрда куелмый. «Төтен» — Ә. Фәйзи иҗатында гына түгел, гомумән, татар совет драматургиясенең үсеше өчен дә принципиаль әһәмияткә ия булган әсәр иде. Автор аны Маяковскийның «Кандала», «Мунча» кебек әсәрләре стилендә, шул әсәрләр тәэсирендә иҗат итә, драматургиядә шарж, карикатура алымнарын куллануның үзенчәлекле юлларын таба.

Ә. Фәйзинең «Түрәкәй» исемле өч пәрдәле сатирик әсәренең машинкада латин хәрефләре белән басылган нөсхәсе дә саклана. Ул укыла-укыла тузып-кыршылып беткән. Шушы ук елларда ул «Каеннар яфрак ярганда» исемле өч пәрдәле комедия, «Әлмисаков һәм К» исемле өч пәрдәле водевиль, «Югарылык» һәм «Беренче елмаю» исемле комедияләр иҗат итә. Архивта бу комедияләрнең берничәшәр вариантлары бар — ул нөсхәләр драматургның комедия жанрын үзләштерүгә житди каравы, әдәби осталыгын чарлауга әһәмият итүе турында сөйлиләр.

Комедия өлкәсендә Ә. Фәйзи күп һәм даими эшләп килсә дә, татар драматургиясендә ул нигездә үзенең тарихи пьесалары — «Тукай» һәм «Пугачев Казанда» драмалары белән таныла. Ике чорның ике олы тарихи шәхесенә багышланган әлеге драмалар әдипнең исемен күренекле драматург буларак күтәрәләр.

Бөек Ватан сугышы чорында да Ә. Фәйзи драматургия өлкәсендәге эшчәнлеген туктатмый. Сугышның беренче айларында ук ул (1941 ел, 23 декабрь) «Шамгун Тавысов» комедиясен тәмамлый. Архивта аның политик шарж алымнары белән язылган «Акылсызлар йортындагы вакыйга» исемле комедиясенең русча кульъязмасы саклана.

Бу әсәрендә автор фашизм идеологларыннан үтергеч көлә. «Үз ялганнарының корбаннары» комедиясендә дә вакыйга Бөек Ватан сугышы көннәрендә бара...

Сугыштан соңгы елларда Ә. Фәйзине шул чорның әхлак мәсьәләләре үзенә ныграк тарта. 1947 елны ул «Отышлы кияү» комедиясен иҗат итә. 1951 елны — «Күршеләр», 1955 елны «Сәйдә апа» комедияләре языла, 1957 елны ул «Рәүфә» драмасын тәмамлый. Әмма шул чорның театр тәнкыйте игътибарны семья эченә юнәлтеп, әхлак мәсьәләләрен күтәреп чыгуны бик өнәп бетерми. Бу яктан «Рәүфә» драмасы гына бәхетлерәк язмышка очрый: ул 1957 елны Татар дәүләт академия театрында уйнала.

Архивта Ә. Фәйзинең Ленинград блокадасы вакыйгаларына багышланган «Камалган шәһәр» драмасының кульъязмалары да бар.

Ф. Хәсни бик дөрес язганча, Ә. Фәйзинең «Уфада «Матурлык дөньясында» исемле ике пәрдәлек комедия белән башланган драматургиясе Агыйдел кебек бик күп борылышлар ясый-ясый, тугайлар һәм җәйләүләр аркылы үтеп, безнең көннәргә кадәр килеп җитә, «Тукай», «Пугачев Казанда», «Рәүфә» драмаларына кадәр күтәрелә».

Әхмәт Фәйзи архивындагы материаллар белән танышып утырганда, әдәбиятчы һәм күренекле кино эшлеклесе Виктор Шкловскийның бер хатына килеп юлыктым. Ул 1941 елның 11 июнендә язылган:

«Хөрмәтле Михаил Ильич!

Иптәш Фәйзинең «Тукай» либреттосы яхшы сценарийның нигезе була ала. Бездә «Булат батыр»дан соң татар ленталары очраган юк. Бу әйбердә рус һәм татар культураларының бәйләнешен ныграк күрсәтергә кирәк. Казанда Ленин укыган, Горький, Киров, Лобачевский һ. б. булган.

Сценарий өстендә хәзер үк эшли башлаячакбызмы — шуны хәбәр итүегезне сорыйм.

Виктор Шкловский».

Кечкенә язмадан да шактый кызыклы һәм гыйбрәтле фактлар ачыла. Бөек Ватан сугышыннан алдагы елларда ук Габдулла Тукай турында нәфис фильм куелырга уйланылган икән. Шушы фикерне шагыйрь архивындагы икенче бер документ та раслый. СССР Халык Комиссарлары Советы янындагы кинематография комитетына Татарстан хөкүмәте исеменнән җибәрелгән эш кәгазендә (1940 ел, 15 август, №4129) «Тукай» кинофильмын чыгару мәсьәләләре буенча Әхмәт Фәйзинең консультант итеп билгеләнүе язылган. Документлардан аңлашылганча, 1940—1941 елларда «Тукай»ны чыгару буенча конкрет эш тә башланган. Тик В. Шкловскийның «сценарий өстендә хәзер үк эшли башлаячакбызмы?» дип сорап язган хатыннан соң унбер көн үтү белән башланып киткән Ватан сугышы гына бөек шагыйрьнең образын кинода гәүдәләндерергә комачаулый.

Бу хатлардан икенче әһәмиятле факт та — Әхмәт Фәйзинең кино сәнгате, кино эшлеклеләре белән дә якыннан танышлыгы, аның хәтта фильм өчен сценарий язуы, бөтенләй яңа өлкәдә каләм тибрәтүе дә ачыла. һ. Такташның традициясен шагыйрь бу юнәлештә дә дәвам итәргә омтылган икән!

«Тукай» киносценарие кечкенә Апушның, яңа чыпталар төялгән арба өстенә утырып, Казанга килүен, атлы абзыйның базар мәйданында: «Асрамага бала бирәм, кем ала?» — дигән сүзләрне кычкырып торуын сурәтләгән күренешләр белән башланып китә. Тукайның сабый чагы — әсәрнең прологы гына. Язучы Г. Тукайның биографиясен хронологик рәвештә ачу белән мавыкмый, бөтенләй башка юл сайлый. Төп вакыйгалар Габдулла Тукайның 1907 елның көзендә Казанга килүе белән генә башлана һәм шагыйрьнең үлеме белән тәмамлана. Сценарийга нигез итеп Ә. Фәйзи үзенең «Тукай» драмасын — шундагы коллизияләрне, образларны алган. Дөресрәге, драмасын да, киносценарийен да бер үк чордарак — сугыш алды елларында иҗат иткән ул. («Тукай» драмасы 1938 елны тәмамлана һәм 1939—1940 ел сезонында Татар дәүләт академия театрында куела).

«Тукай» пьесасы һәм киносценарие өстендә бер үк вакытта эшләү һәр ике әсәргә дә тирән эз салган. Бер яктан, ул пьесаның кинематографик фикерләүгә бик якын булуына этәргән. Күренеш, эпизодларның күплеге, аларның тиз алышынып торуы — композициядәге һәм сюжет корудагы бу үзенчәлек, шиксез, Ә. Фәйзинең кино сәнгате белән мавыгуыннан килә. Ул бу елларда җитди рәвештә кино сәнгатен, аның теориясен өйрәнә, яңа чыккан фильмнарны карап бара. «Тукай» пьесасын сәхнәләштерүче режиссер Сарымсаковка ,язган хатларының берсендә, мәсәлән, шундый юллар бар: «...Ә пьесаны сәхнәләштерү ничек бара, Сарымсак? Кайбер күренешләрне әдәби яктан эшкәртүгә, үзгәртүгә мохтаҗ түгелсеңме? Бүген «Ленин 1918 елда»ны карадым (минә әле яңа гына шуны карап кайтуым). Картина мин көткәнгә караганда да әйбәтрәк булып чыкты. Мин еладым да, көлдем дә. Чын сәнгать! Картина ышанмаслык дәрәҗәдә тормышчан. Бу — Ленин турындагы иң яхшы фильм. Безнең спектакль дә дәреслекне шундый тирән ачсын иде, туйганчы еларлык һәм көләрлек булсын иде!»

Кинематографик фикерләү белән мавыгу пьесада драматик хәрәкәтнең үзенчәлекле корылуына этәрсә, шул ук вакытта ул пьесаның үз вакытында тәнкыйть ителгән композицион таркаулыгын да китереп чыгарган сәбәпләрнең берсе булган.

Икенче яктан, «Тукай» сценариен язганда Ә. Фәйзи «Тукай» драмасын иҗат итү тәҗрибәсеннән дә нык файдалана. Мосфильмның сценарий бүлегенә җибәргән хатларының берсендә ул «Тукай» драмасының Казан һәм Уфа тамашачылары тарафыннан җылы кабул ителүе, хәзерге вакытта пьесаның өр-яңа вариантын эшләве турында хәбәр иткән икән,— бу һич тә очраклы хәл түгел. Драманың уңышлы һәм көчле яклары киносценарийның да көчле яклары булып әверелә. Драматик конфликтның кискенлеге, Тукайны коеп куйган шагыйрь итеп кенә түгел, ә ихтыяр көченә ия булган көрәшче, җәмгать эшлеклесе итеп сурәтләү, аны икеләнүләре, эчке каршылыклары аша ачу, социаль фонның һәйбәт сурәтләнүе — киносценарийның да көчле яклары. Әмма сценарийда драманың көчле яклары белән бергә андагы йомшаклыклар да чагыла. Бу аеруча С. Рәмиев образын гәүдәләндерүдә күренә: ул драмада да, сценарийда да ихтыярсыз, көчсез, ахырда охранкага сатылган бәндә итеп бирелгән. Тарихи чыганаклар шагыйрьне бу рәвешчә сурәтләүгә каршы киләләр. Ә драманың җитешсезлеге итеп саналган күп эпизодлылык, вакыйганың төрле урыннарда баруы һәм тиз алышынып торуы сценарийның табигый хасияте һәм отышлы яклары булып киткән.

Әмма «Тукай» сценарие драманың кино теленә күчерелгән үзгәрешсез варианты гына түгел. Драмадан ул нык аерыла да. Мәсәлән, драмада Тукайның дуслары арасында Фатих Әмирханны күрми идек. Ә сценарийда ул Г. Камал, Х. Ямашев, эшчеареволюционер Михайлов, Гафуровлар белән бергә шагыйрьнең якын дусларыннан берсе һәм революцион рухлысы итеп сурәтләнгән.

Ни өчен соң Ә. Фәйзи Әмирханны пьесада күрсәтми? Тәнкыйть, драманың беренче варианты куелу белән (1939 елны ук), Ф. Әмирханның пьесага кертелмәвен әсәрнең бер кимчелеге итеп күтәреп чыга бит. Тик икенче куелышта да Әмирханга урын табылмый.

Әгәр «Тукай» драмасының кулъязма вариантларына игътибар итсәк, анда без Ф. Әмирханны очрата алабыз. IX күренеш менә шулай башланып китә: «Тукай бүлмәсе. Тукай, Камал, Солтан, коляскада Фатих һәм тагын ике кеше. Колахметов тәрәзәдән карап тора. Ямашевның үлүенә бер ел тулу уңае белән дуслары аны искә алу көненә җыелганнар. Тукай Ямашны сагынып, аңа багышланган шигырен укый. Скрипкада «Ямашны сагыну» дигән көй уйнала». Пьесаның кулъязмасында Фатих тагын берничә урында телгә алына, ул Тукайның иң яхшы дусларыннан берсе буларак гәүдәләнә. Сәхнәгә куелганда һәм басмада болар төшерелгән.

Ә сценарийда, әйткәнебезчә, Әмирхан әһәмиятле образларның берсе булып урын ала. Моны нәрсә белән аңлатырга? Шушы рухтагы сорауларга Ә. Фәйзи пьесаны тикшерүгә багышланган киңәшмәдә (1942 елның 16 апрелендә) болай дип җавап биргән: «Бирелә чыгыш ясаучылар ни өчен Кариев юк, ни өчен Әмирхан юк диләр. Аларның пьесага кертелмәвен шуның белән аңлатырга кирәк: әгәр аларны да өстәсәк, Камал образы төссезләнер һәм аны кабатлау булып чыгар иде. Мин натуралистик юлдан китәргә теләмәдем».

Бу хәлнең икенче сәбәбе дә була. Ф. Әмирханның 1907 елда авырый башлавы мәгълүм. «Ничек итеп аны коляскада авыру килеш сәхнәгә кертәсең. Сәхнәдә үзен шартлы куела, аның үз законнары бар»,— дип сөйли Ә. Фәйзи артистларга, Әмирхан турында сүз чыккач [1].

«Тукай» драмасы вариантларын һәм «Тукай» сценариен тикшергәч, бер нәтиҗәгә киләсең: Ә. Фәйзи һич тә Фатих Әмирханның татар иҗтимагый фикер үсешендәге ролен кечерәйтергә теләмәгән. Ф. Әмирханның пьесага керү-кермәвен ул сәхнә законнарына бәйләп, пьесаның характеры белән аңлата. Тукайны һәм аның көрәштәшләрен кинода гәүдәләндергәндә исә Ә. Фәйзи кинематографик фикерләүгә таяна. Кинематографиянең театрга, сәхнәгә караганда мөмкинлекләре күбрәк тә, үзгәрәк тә. Шуңа да драмага сыя алмаган образ киносценарийда үзенең коляскалары белән дә бик табигый рәвештә урын алган.

Пьесада драматик хәрәкәт диалог аша гына тормышка аша. Киноэкранда сүздән башка да драматик хәрәкәт бирелергә мөмкин. Диалогны киномонтаж тулыландыра, аппаратның кеше йөзендәге, күзендәге кечкенә генә үзгәрешләрне дә тотып ала һәм әһәмиятле нәрсәләргә төп игътибарны юнәлтә алуы сурәтләүдә киң мөмкинлекләр ача. Ә. Фәйзи дә сценарием язганда кинематографик хәрәкәтне яхшы тоеп, аның үзенчәлекле табигатен аңлап эш иткән. Дөрес, автор әле драма тәэсиреннән тулысынча арынып бетми, вакыт-вакыт пьеса язу юлына да төшеп киткәли. Шулай да сценарийда кино өчен отышлы күренешләр дә аз түгел. Менә бер мисал:

«Тукай Ямашев квартирасына бара, ләкин ул, гадәттәгечә, өйдә юк...

Тукай үзенең бүлмәсендә. Аны күңелсез, төшенке уйлар биләп алган. Ул үзен шагыйрь буларак халыкка кирәкми икән дигән фикергә килгән. Ә ул халыкка хезмәт итүдән башка тормышны күз алдына да китерә алмый. Димәк...

Тукайның күзләре кем тарафыннандыр өстәлдә калдырылган кәгазьгә төшә:

«Бүген 11 дә китәм. Әгәр пристаньга төшәргә кирәк дип санамасагыз, хушыгыз! Әминә».

Тукай, вакытның соң булуына һәм юлның ераклыгына карамастан, караңгыда абына-сөртенә пристаньга йөгерә.

Тукай пристаньга килеп җиткәндә генә пароход кузгалып китә.

Идел яры. Таң ату күренеше. Биек кыя тауда хәрәкәтсез басып торган кешенең силуэты. Шәүлә яктырганнан-яктыра бара. Ул пароход китеп югалган якка күзләрен текәгән Тукай булып чыга. Аннан соң ул күз карашын кыя астындагы шаулы йөгерек дулкыннарга күчерә.

Шул урыннан ерак та түгел, большевиклар оешмасының яшерен җыелышы бара... Михайлов, Лена приискасындагы канлы вакыйгаларга бәйле рәвештә бөтен Россия буенча күтәрелгән стачка һәм забастовка дулкыннары турында сөйли...

Тукайның күз алдыннан (дулкыннар фонында) үткән тормышына бәйле истәлекләр уза: Казанга беренче аяк басуы һәм шунда туган шатлыклы минутлары, яшьләр белән беренче танышуы. Әминә белән очрашу күренешләре...»

Биредә, күрүегезчә, диалог юк. Шуңа карамастан драматик хәрәкәт бар, һәм ул кинематография мөмкинлекләреннән файдаланып, оптик күрүгә нигезләнеп, шактый киеренке итеп төзелгән. Вакыйга, күренешләр биредә тиз агышлы һәм үтә хәрәкәтчән. Без Тукайның бүгенге рухи халәтен дә күрәбез, уйлары аша үткән көннәргә дә сәяхәт кылабыз. Драмада, әлбәттә, боларны (шагыйрьнең үткәннәрен яки аның шәһәр буенча йөрүләрен) кинодагы шикелле күрсәтеп булмас иде. Пьесада сүз яки ремарка белән әйтелеп кенә үтелгән детальләр сценарийда кинематографик образга, драматик хәрәкәткә әверелгәннәр. Драматизмны Тукайның газаплы уйланулары да, хакыйкать эзләп Ямашев янына баруы да, аны таба алмыйча кире өенә кайтуы да, төнлә үзенең бәхете-мәхәббәте артыннан пристаньга чабуы да, хәтта төн дә, кыя тау да, дулкыннар да тудыра.

Идел дулкыннары бер контекстта безгә шагыйрь күңелендәге ярсулы «дулкыннарга» ишарә ясый. Гадәти табигать көченнән ул тирән эмоциональ көчкә ия булган

---

[1] Тукай образын башкарган И. Гафуров сөйләгән истәлекләрдән

образга әйләнә. Икенче бер контекстта дулкын төшенчәсенең мәгънәсе тагы да үзгәрә. Ул бөтен ил буенча күтәрелгән халык хәрәкәтен гәүдәләндерә, революционер Михайловның политик стачкалар турында сөйләгән сүзләренә образлы бәйләнештә килә.

Ә. Фәйзинең архив материаллары арасында тагын берничә киносценарий табылды. Берсе аның «Тарих рычагы» дип исемләнгән. Җәя эчендә «Яшел манара» дигән икенче исем дә куелган. Ә. Фәйзи үзе әсәрнең жанрын «алты кисәктән торган киноповесть» дип билгеләгән. Сценарий саран детальләр, әмма шактый киеренке вакыйгалар аша илдәге олы социаль үзгәрешләрне, тарихны тудыручы көчләрне ачып сала.

...1919 ел. Кызыл гаскәр, мең газаплар күреп, акларга каршы һөҗүм сугышлары алып бара. Көзге пычрак. Снаряд шартлаулары. Үлгән атлар. Үтерелгән кешеләр. Күренеш кабат алышына. Һәм без солдат котелогын, котелокка тыгылган өч-дүрт кашык һәм сыек балык шулпасы күрәбез. Зур планда — шуышучы тиф бете.

Без әсәрнең конкрет геройлары белән дә очрашабыз. Аларның берсе — ак офицер Ильяс. Ул погоннарын ертып ташлап, крестьян киемнәренә киенеп, фронттан кача. Вакыйгалар ерак тылга — Ильясның әтиләре авылына күчә. Зариф карт продразверсткадан үзенең ашлыгын яшерә. Аның улы Гариф — комсомолец. Ата белән бала арасында конфликт Гарифның яшерелгән ашлык турында ячейкага барып әйтүеннән соң аеруча кискен төс ала. Ләкин әле бу — конфликтның башы гына. Абыйсы Ильясның авылга кайтуы, аның кулаклар кубызына биюе белән вакыйгалар, социаль көрәш тагы да куера. Ике бертуган көрәшнең ике ягына баса...

Киноповесть комсомолец Гарифларның җиңүе, әтисенең һәм авылдагы башка күпләрнең дә милекчелек һәм дин карашларыннан арынып, коллектив хуҗалыкка аяк басулары, культуралы тормышка омтылуларын сурәтләү белән тәмамлана.

«Тарих рычагы»ның язылу елы күрсәтелмәгән. Үзенең конфликты, стиле һәм образларның сурәтләнүе буенча ул егерменче елларның икенче яртысында язылган әсәрләргә охшаш. Автор үзенең төп игътибарын аерым геройларның күңел дөньясына, психологиясенә түгел, ә социаль төркем һәм сыйныфларның көрәшенә, алар арасындагы каршылыкны ачуга юнәлтә. Шуңа күрә дә образлар шәхси үзенчәлекләре белән ачылуга караганда, социаль-политик көрәштә тоткан урыннары яки шул көрәштәге нинди дә булса киеренке бер вакыйгага катнашулары белән аерылалар. Болар барысы да киноповестьның язылу вакытын егерменче елларның ахыры яки 1930—1931 еллар дип билгеләргә мөмкинлек бирә.

Ә. Фәйзи 30 нчы елларның ахырында нәфис кино өчен тагын бер әсәр — «Пәйгамбәр Әюп һәм итекче Сафа» исемле сценарий иҗат иткән. «Тарих рычагы» белән чагыштырганда, авторның әдәби осталыгы үсүе күзгә ташлана. Ул социаль көрәш күренешләрен сурәтләү белән генә чикләнми, геройның социаль психологиясен ачуга да нык әһәмият бирә. Шәхесне тирәнрәк тикшерергә омтылу әсәрнең проблемасында, сюжет корылышында да күренә: автор төп герой итеп итекче Сафаны ала, аның революцион вакыйгалар барышында сыйнфый аңы үсүен җентекләп сурәтли.

Башка сценарийлары шикелле үк «Пәйгамбәр Әюп һәм итекче Сафа»да беркайда да басылмаган. Шулай да «Сафа» драматик поэмасын белгән укучылар әсәрнең төп эчтәлеге белән нигездә танышлар. Чөнки киносценарий «Сафа» драматик поэмасына нигезләп, аның белән бер үк вакыттарак язылган. Биредә дә нигездә шул үк вакыйгалар, шул үк образлар, әмма инде алар киноэкран мөмкинлекләреннән чыгып баетылганнар.

Кино «күзе» безгә артиллерия канонадасын да, сугыш барган шәһәр күренешен дә, большевикларның өндәмәләре ябыштырылган урамнарны да күрсәтә, эшчеләрнең шәһәр төрмәсен һәм комендатураны камап штурм белән алуларын да ачып сала. Кинематографик фикерләү, күрүебезчә, язучының алган проблемасын чишү буенча иҗат мөмкинлекләрен беркадәр баетыбрак җибәргән.

Сценарий белән поэманың бер вакыттарак язылуларына һәм поэмада кинога хас алымнарның очрауларына таянып, кинематографик фикерләүнең «Сафа» драматик поэмасына да тәэсире турында сөйләргә мөмкин булыр иде.

Ә. Фәйзи гомеренең соңгы елларына кадәр татар халкының ике бөек улы — Тукай һәм Җәлилгә багышланган фильм булдыру турында хыялланды. Җәлил турында кино чыгару буенча аның Мәскәүдәге киноосшмалары белән сөйләшүләр алып баруы да

мәгълүм. Әхмәт Фәйзи архивында Муса Җәлилгә багышланган киносценарий планы да табылды.

Ә. Фәйзи үзе исән вакытта хыялларының тормышка ашуын күрә алмады. Әмма барлык киносценарийлары да әнә шундый уңышсыз финал белән тәмамланды дип әйтү дөрес булмас иде. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының 150 еллык юбилеена багышлап, Ә. Фәйзигә документаль кино-очерк язарга заказ бирәләр. Сценарий Булат Гыйззәтуллин белән берлектә языла, һәм аның буенча 1954 елны документаль фильм куела.

Ә. Фәйзинең синтетик сәнгать төрләреннән балет һәм опера өлкәсендәге әдәби эшчәнлеге кино сәнгате белән чагыштырганда күп уңышлырак һәм нәтиҗәлерәк булды. Балет дөньясына ул кыю рәвештә Тукай шигъриятен алып керде, Тукай образларын сәнгатьнең башка төрләрендә яңгыратуга үзеннән зур өлеш кертте. Бу яктан иң беренче чиратта Тукайның «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп язылган шул ук исемдәге балет либреттосын искә алырга кирәктер. Композитор Ф. Яруллинның шушы әдәби сюжетка таянып иҗат иткән балет музыкасы бик тә бәхетле язмышлы булып чыкты. Казанда гына түгел, Мәскәү, Ленинград сәхнәләрендә дә куелган һәм зур уңыш белән барган «Шүрәле» балеты татар халкының горурлыгына әверелеп, күпмиллэтле совет музыкасының алтын фондында урын алды. «Шүрәле» балеты Франция, Канада кебек илләргә дә барып чыкты. Аның шундый киң популярлыкка ирешүендә, әлбәттә, балетның әдәби сюжетын язган Ә. Фәйзинең дә күпмедер дәрәҗәдә өлеше бар. 50 нче елларда Ә. Фәйзи композиторларның игътибарын Тукайның икенче бер күренекле әсәренә — «Печән базары яхуд яңа Кисекбаш» поэмасына юнәлтте. Ул язган «Кисекбаш» либреттосына таянып, композитор Р. Гобәйдуллин яңа балет иҗат итте. Ул әсәр дә сәхнәгә менде һәм татар балет театры тарихында истәлекле спектакльләрнең берсе булып калды.

Татар опера драматургиясе һәм опера театры тарихы турында сүз алып барганда да Әхмәт Фәйзи исемен читләтеп үтеп булмый. 1939 елны ачылган Татар дәүләт опера һәм балет театры үзенең беренче сезонын Ә. Фәйзи либреттосына Н. Җиһанов тарафыннан язылган «Качкын» операсы белән башлап җибәрә. Пугачев чоры һәм шул вакытлардагы татар крестьяннарының авыр тормышлары, ирек өчен көрәшләре турында сөйли торган әлеге әсәрне җәмәгатьчелек уңай бәяли: «Качкын» операсының куелышы — татар совет культурасы тарихында зур вакыйга»,— дип язды үз вакытында М. Җәлил. Ә. Фәйзинең тарихи темага иҗат иткән әсәрләре генә түгел, совет чынбарлыгын яктырткан әсәрләре дә татар композиторларын яңа опералар иҗат итәргә рухландырды. Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын гәүдәләндергән «Шагыйрь» либреттосына Н. Җиһанов опера яза, һәм ул 1947 елны куела да. Әмма спектакль бигүк уңышлы дип табылмый. Шагыйрь батырлыгы темасын Ә. Фәйзи соңрак та дәвам итә. 1953 елны, Җәлил исеме акланганнан соң, ул кабат әлеге әсәренә кайта һәм аны яңа материаллар нигезендә бөтенләй үзгәртеп эшли. Башта «Үлемнән көчлерәк» дип исемли, аннары либреттосын төп героеның исеме белән «Җәлил» дип атый. Опера 1957 елны Татар дәүләт опера һәм балет театрында куела. «Җәлил» операсы Мәскәүнең Зур театрында да, Прага сәхнәсендә дә яңгырый. Либреттистның һәм композиторның иҗади дуслыгы нәтиҗәсендә туган бу героик опера, татар сәнгатенең яңа казанышы буларак, музыка дөньясында югары бәя алды.

Ә. Фәйзидә көлкегә нигезләнгән музыкаль әсәр иҗат итү нияте дә көчле була. Бу ниятен тормышка ашыру эшенә ул Җәүдәт Фәйзи белән сугышка кадәр үк тотына, әмма кинәт башланган сугыш музыкаль комедиянең тәмамлануына комачаулый. Шулай да либреттист та, композитор да эштән туктамыйлар. Колхозчы яшьләрнең бәхетле тормышлары турында сөйли торган «Акчарлаклар», музыкаль комедиясе 1944 елны Татар дәүләт опера һәм балет театрында куела. Сугыштан соң да Ә. Фәйзи музыкаль комедиясен камилләштерүне дәвам итә һәм 1949 елны әсәрен театр өчен яңабаштан язып чыга.

Ә. Фәйзинең опера өчен либреттолары болар белән генә чикләнми. Сугыш алды елларында ук ул, халык иҗаты әсәрләренә нигезләнеп, «Зөлхәбирә» исемле драматик поэма иҗат итә. Бу әсәрендә татар хатын-кызларының революциягә кадәрге

кызганыч язмышы үзәктә торса, шул чорда язылган «Сафа» либреттосында инде халыкның үз язмышын яклап көрәшкә күтәрелә башлавы да сурәтләнә.

Татарстан китап нәшрияты Әхмәт Фәйзинең биш томнан торган әсәрләр җыелмасын басып чыгаруны планлаштырды. Бу җыелмада мул талантлы әдибебезнең күп яклы иҗаты элекке басмаларына караганда тулырак яктыртылачак. Укучылар Ә. Фәйзинең моңа кадәр үзләренә билгеле булмыйча килгән күп кенә әсәрләре белән дә танышырга мөмкинлек алачаклар.

Тууына 80 ел тулган көннәрдә без Әхмәт Фәйзинең күпкырлы иҗатын тагын бер кабат күздән кичерәбез, аның татар әдәбияты үсешенә керткән зур өлешен ихтирам хисе белән билгеләп үтәбез.

# ӘХМӘТ ФӘЙЗИ КЫРЛАЙДА

1950 елның җәй башларында без, бер төркем колхозчылар, Кырлай авылына юл төзү эшенә килдек. Мин Каратай кушаматлы ат белән таш ташырга билгеләндем. Юл төзү бригадиры бик тәфсилләп, эленке-салынкы йөрмәскә, норманы үтәү өчен эш мәйданына берничә километр ераклыктан көнгә кимендә егерме йөк таш алып килергә кирәклеген аңлатты. Норма үтәлсә 1,25 хезмәт көне язылачак икән. Кырлайга килүнең икенче көнендә иртәнге сәгать дүртләр тирәсендә эшкә керештек. Төйибез дә китерәбез ташны, төйибез дә китерәбез. Нормада каралган ташны мин Каратай белән көндезге сәгать икеләрдә ташып та бетердем. Ат хәйран ук талчыкты. Аны бераз ял иттерем дә, төнлә ашату өчен печән чабып кайтыйм дип, урманга киттем. Бераз җир үткәч, бер җәяүлене куып җиттем.

— Абый, урманга барасың мәллә? Әйдә, утырыгыз,— дидем аңа, атны туктатып.— Минем дә урманга барыш.

— Шундый исәп белән чыккан идем шул,— дип, ул минем уң ягыма менеп утырды һәм кем булуым, урманга нинди исәп белән баруым турында сорашты.

— Атка печән хәстәрләп кайтырга барам. Бер уңайдан Габдулла Тукай җиләк җыеп йөргән урыннарны да карап кайтырга исәп бар,— дидем мин аңа. Бу сүзләрне ишеткәч, аның йөзе яктырып китте, елмаеп куйды:

— Яхшы ниятләр белән барасың икән, әйдә, шагыйрь йөргән җирләрне бергәләп карарбыз,— диде юлдашым миңа таба борыла төшеп. Шуннан соң ул күзлеген салды да, аны әрә-әрә кулъяулыгы белән сөртте, тагын киеп куйды.

— Энекәш, синең исемең ничек була соң әле?

— Нәҗип.

— Алай икән. Нәҗип, бир әле бер гәҗит,— диде ул шаяра төшеп.

Юлдашым уен-көлкене ярата торган кеше булып чыкты. Тора-бара ул әңгәмәне Габдулла Тукайга күчерде. Миннән аның кайсы шигырьләрен яттан белүемне сорады. Юлда барганда аңа «Таз» шигырен һәм «Мияубикә» әсәреннән бер өзек сөйләдем. Урманга җитәрәк «Шүрәле» әкиятенең Кырлай урманнарына кагылышлы урыннарын яттан укыдым.

Без кечкенә генә бер аланлыкта туктадык. Мин атка печән чапканда, теге абый, кесәсеннән блокнот чыгарып, аңа нәрсәләрдер язгалады. Атны дилбегә белән арканлап куйдым да, әлеге абый белән урман хозурлыгын күзәтә башладык. Ул үзе бер ни дә белмәгән кеше сыман миннән гел сораштырып тора:

— Бу нинди агач була соң әле?

— Әлмә агачы ул, абый.
— Ә монысы?
— Өрәңге.
— Менә биредә үскәне нинди куак?
— Ул кара зелпе.
— Ә бусы?
— Чыпчык миләше.
— Карале, син, энекәш, барысын да беләсең икән.— Ул тагын рәхәтләнеп көлеп куйды. Аннан соң кайбер үләннәрне сораштырды. Аларны белүем дә аның күңеленә хуш килде.
Урманнан кайтышлый ул дилбегәне үз кулына алды. Атны юырттырып карады, үз көенә генә баргызды, кызулаткалап та алды. Авыл башына җиткәч, арбадан төшеп җәяү генә бара башлады һәм, бер тыкрыкта минем белән хушлашып, колхоз идарәсенә таба китте. Ул шагыйрь һәм язучы Әхмәт Фәйзи булган икән. Мин бу хакта ахырдан гына белдем һәм аның шундый гади кеше икәнлегенә исем китте.

Чандыр гына гәүдәле, шаян сүзле, уенчан бу кеше миңа иртәгесен кибеттә очрады. Ул вакытта ипине юл төзү эшендә катнашучы кешеләргә дә талон белән бирәләр иде. Менә ул кибеткә керде дә прилавка янына килде. Кибетче хатын ипине үлчәү тәлинкәсенә салып үлчәп бирә. Бу хәлне шактый күзәтеп торгач, Әхмәт ага Фәйзи сатып алучыларга берничә сорау бирде:
— Икмәкне күпмешәр аласыз?
— Кеше башына сигез йөз граммнан.
— Алай гына җитәме соң?
— Җитә, артып та кала әле.
— Ә артканын нишләтәсез?
— Анысын да ашап бетерәбез.
Әхмәт абый мондый сүзләрне ишеткәч, нәкъ үзенчә генә беркатлылык белән көлеп җибәрде дә:
— Икмәк бик кадерле, аның кадере кимемәс,— дип кибеттән чыгып китте.
Ул җәйдә илебездә колхозларны эреләндерү эше башланып киткән иде. Бу вакыйга «Тукай-Кырлай» колхозын да читләтеп үтмәде. Без әнә шул Кырлай авылында торып, таш юллар салган вакытка туры килде ул хәл. Кырлай урамнарына ике колхозны берләштерүгә багышланган җыелыш булачагын игълан иткән белдерүләр куелды. Колхозчылар арасында ыгы-зыгы купты. Берәүләр «эреләнмәскә» кирәк, дисәләр, икенчеләре бу яңалыкны яклап сүз йөрттеләр. Кайберәүләр исә битараф булып калырга исәп тоттылар.
Булачак җыелыш Әхмәт ага Фәйзине дә кызыксындырган. Ул клубка килү белән алдан өченче рәттәге эскәмиягә яшьләр янына килеп утырды. Тора-бара сүз тагын шагыйрь Габдулла Тукай иҗатына күчте. Әхмәт ага Тукай хакында кемнең нәрсә белүе белән кызыксынды.
Стенада Тукайның ниндидер бер үзешчән ясаган начар гына портреты эленеп тора иде.
— Бу рәсем Тукайга охшамаган,— дидем мин.
Икенче бер агай миңа каршы чыкты:
— Синең Тукайны күргәнең бармыни. Бәлки ул шагыйрьнең нәкъ үзе кебек итеп ясалган рәсемдер әле.
— Бик алама рәсем бит бу, Тукай алай ямьсез булмаган ул,— дип, бер егет мине яклап чыкты.
Шул вакыт колхоз председателе Фәсәхәт Сафина сәхнәгә куелган трибуна артына күтәрелде. Безнең Тукай турындагы бәхәсле әңгәмә өзелде.

**НӘҖИП МАДЬЯРОВ.**

# ТОРМЫШКА МӘДХИЯ

Татарстан китап нәшрияты «Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты» сериясеннән җыентыклар бастырып чыгара башлады. Сериянең нәкъ менә Фәнис Яруллин[1] иҗаты белән ачылуы символик мәгънәгә ия.

**Бик күп минем танышларым:**
**Иң түгрысы — сагышларым,**
**Аннан кала — язмышларым,**
**Аннан кала — табышларым,**
**Аннан кала — балкышларым.**

**Мин гел шулар арасында.**
**Тотынып шул танышларга,**
**Гомер дигән юлдан барам**
**Язмышлардан — табышларга,**
**Сагышлардан — балкышларга.**

Иң нечкә күңел кылларын тибрәтәчәк уен коралын көйләгән төгәл бер камертон сыман, әлеге юллар укучыны алдагы әсәрләрне кабул итәргә әзерли. Бу аһәң, бер шигырьдән икенчесенә күчеп, беркадәр моңсу, әмма эчкерсез һәм якты лейтмотив булып сузыла.

Китапка шагыйрьнең төрле елларда язылган шигырьләре тупланган, һәм бу, үз чиратында, аның иҗатын тулырак күзалларга, үзенчәлекле якларын тагын да яхшырак сиземләргә мөмкинлек бирә. Ленин, туган ил, туган җиргә булган мәхәббәт, сугыш һәм тынычлык, бәхет, аның асылы, хезмәт кешесенең фидакарьлеге — китапта киң чагылыш тапкан төп темалардан әнә шуларны санап үтәргә мөмкин.

Шагыйрьнең лирик герое заман сулышын йөрәге белән тоеп, андагы һәр үзгәрешне, һәр яңалыкны күңел түреннән кичереп яши. Ул уй-фикерләрен, теләк-омтылышларын, үз замандашлары алдына бөек Ленин тарафыннан куелган бурычлар яктылыгында дөресли.

**Карашында аның үзенә хас**
**Бик ягымлы гына җитдилек:**
**— һәр адымым дөрес булсын дисәң,**
**Ил сулышын той син,— ди кебек.**

Хәзерге тормышыбызның матурлыгын, киләчәк елларның яктылыгын да ул нәкъ менә Ильич образының күңелләрдә мәңге сүнми-сүрелми яшәвендә, аның зирәк акылының гасырлар үткәч тә бөтен кешелек дөньясын яктыртуында күрә.

**Тик бер нәрсә истә яхшы калган,**
**Онытмыймын һаман бер көнне:**
**Ильич уты керде авылыбызга,**
**Почмак саен якты бәркелде.**

**...Күңелем минем, бер дә киметмичә,**
**Шатлыкларын саклый ул кичнең.**
**Шул яктыда күрдем елмаюын.**
**Мин кадерле, якын Ильичның.**

Туган илгә, туган җиргә һәм туган туфракка чиксез мәхәббәт белән сугарылган шигырьләр дә укучыны битараф калдырмый. Ир-егетнең көч-куәте дә, дошманнарны җиңәр дәрман-кодрәте дә туган илдән, туган туфрактан килә, ди шагыйрь. Әлеге шигырьләрдән чыга торган төп нәтиҗә әнә шундый.

**Күкрәгемдә көчем кимемәс,**
**Горур башым түбән иелмәс;**
**Аһ-зар сүзе чыкмас телемнән,**
**Аерылмасам туган илемнән.**

Әйе, читтә йөргәннәрнең сагындырып төшләренә керер өчен, яулаган матур эшләренә матур бәя бирер өчен, керләнгән күңелләрне сафландырыр өчен дә «ямьле, мәрхәмәтле туган ягы кирәк кешегә!» Тормыш ямен, яшәеш асылын туган җирдә үзең яраткан хезмәт белән илһамланып яшәүдә күрә шагыйрь.

**...Ә бервакыт кинәт аның**
**Бетте эше.**
**Менә шунда бик нык эру**
**Сизде кеше.**

Һәм әнә шул кинәт аруны, талчыгуны сизмәс өчен берөзлексез эшли шагыйрь, туктамый иҗат итә. Шахтер егет тау токымнарын актарган кебек, ул вакыт белән дә, егәре белән дә исәпләшмичә, бихисап сүз рудаларын актара, кеше күңелендә асылташ булып балкырдай асыл сүзләр эзли.

**Әгәр йөрәгең таш булса,**
**Хисләрем булыр тамчы.**
**Тамармын да тамармын мин**
**Таш тишелеп чыкканчы.**

**Әгәр йөрәгең боз булса,**
**Ут булырмын, тор белеп.**

[1] Ф. Яруллин. Танышлар арасында. Татарстан китап нәшрияты, 1980 ел.

**Янармын да янармын мин**
**Бозың беткәнче эреп.**

Чыннан да, шагыйрьнең самими, керсез хисләре безнең йөрәкләргә җылы шигырьләр булып тама. Андый минутларда шагыйрь күңеле — соң чигенә җитеп киерелгән скрипка кылыдай. Дустанә бер кагылып кына кит аңа, ул сиңа бөтен моңын түгәргә әзер.

**Йөрәгемдә бүген шуңа бәйрәм,**
**Шатлыкларым шуңа күбәйде:**
**Бер кешегә дустым артты бүген,**
**Бер кешегә дөньям киңәйде.**

Бары тик үзе олы җанлы булган кеше генә башкаларның да олы җанлылыгын, олы йөрәклелеген күрә, тоя белә, аңлый ала. Китапка кергән «Рәхмәт сезгә, игенчеләр», «Бер сүз әзлим», «Ышанам», «Сулыш», «Гел балкытыр идем кояшны» кебек шигырьләр — шагыйрьнең әнә шундый олы җанлылыгы хакында сөйләүче ялкынлы дәлилләр.

Гомумән, биредә урын алган бик күп әсәрләрне ике сүз белән генә «Тормышка мәдхия» дип атасак, ялгыш булмастыр кебек. Шигырьләрне укыганда, авторның тормыш, яшәү турындагы тирән фәлсәфәсе уйландыра, аның оптимизмы күңелләрне сөендерә. Шагыйрь гаҗәп үткер күзле, сизгер күңелле. Беренче карашка төссез күренгән, башка берәүләр бөтенләй игътибар да итмәгән гади генә деталь яки образ аша ул үз замандашын борчыган, уйландырган дөньякүләм әһәмиятле мәсьәләләрне яктырта, канатлы сүз ярдәмендә аларны ачып бирә. Бу җәһәттән шагыйрьнең «Яшел бәбкә», «Туган җир», «Аерылмасам әгәр» кебек шигырьләре аеруча игътибарга лаек.

Әйе, шагыйрь үз максатына ирешкән. Китап элекке танышлары арасына кәтеп алынган кунак булып кайтты. Ул Татарстанда да, күрше республикаларда да үзенең яңа укучыларын, яңа танышларын бик тиз тапты.

**Җәүдәт ДӘРЗАМАНОВ.**

# КЫЗЫКЛЫ ДА, ГЫЙБРӘТЛЕ ДӘ

Габделхәй Сабитов — балалар һәм зурлар әдәбиятына шактый өлеш керткән, төрле жанрларда уңышлы иҗат итеп килгән язучы. Шулай да прозаик һәм драматург буларак күбрәк билгеле ул. Язучының «Тармаклы яшен» җыентыгына[1] да һәр ике жанр төренә кергән, ә адресат ягыннан караганда, балалар һәм зурлар өчен язылган әсәрләр тупланган.

Үзенең хикәяләрендә әллә ни әһәмияткә ия түгел кебек күренгән гади генә күренешне, очракны ала да, тәләгән фикерен шуңа бәйләп, матур гына итеп әйтеп бирә автор. Җыентыктагы «Чын дәфтәр», «Кәккүк ялгыша икән», «Айбаш», «Бизәкле чиләк» хикәяләре нәкъ әнә шул юнәлештә үстереләләр. Койма буенда аунап яткан зәңгәр тышлы дәфтәр, малайлар янында бөтерелеп уйнаучы кәкре койрыклы эт, стенада эленеп торучы пошй мөгезе, каядыр адашып калган кара айгыр — беренче карашка ис китәрлек булмаган хәлләр өлеге хикәяләрдә язучының үткен күзенә эләгеп, аның оста каләме тәэсирендә укучыны гыйбрәтле уй-фикерләр эченә алып кереп китәләр.

Г. Сабитов иҗатының характерлы бер сыйфаты — табигатьне, үсемлек һәм тереклек дөньясын сизгер күңел күзе белән күрә белү. Юк, язучы табигать могҗизаларын күреп, тасвирлап кына да калмый: ул табигать серләренә юл ача, әйләнә-тирәдә сокландыргыч бай тормыш күрергә өйрәтә. Геройлар белән янәшә басып, куе урманнар эчендә, биек таулар арасында, зәңгәр сулы күл буйларында йөри автор. Үзе күргән, үзе тапкан табигать дөньясының сокландыргыч җанлы картиналарын яңадан-яңа төсмерләр салып, характерлы детальләр ярдәмендә тасвирлап бирә ул. Әмма бу — гади тасвир гына түгел. Бу — ярату, мәхәббәт. Туган җиргә, табигатькә, тереклек дөньясына мәхәббәт. Язучы күңелендә бала вакыттан туган шул олы мәхәббәт әдәби әсәр юлларына төшеп, укучы күңеленә күчә. Укучы кеше әгәр бала икән, аның күңелендә табигатькә, тереклек дөньясына карата иң изге тойгылар уяна. Әгәр укучы өлкән кеше икән — табигать аның алдында әлегә кадәр ул күрә алмый калган яклары һәм ул үзе дә сизмәстән: «Мин ничек әлегә кадәр моны күрмәгәнмен!» — дип куя.

Язучының әсәрләрендә табигать дөньясы үзенең төрле төсмерләре, буяулары белән яши. Аның күзләре — әле сытык чырайлы, әле алтын; җәйләре — әле авызын ерган кояш белән балкый, әле җиде аждаһа башына охшаган тармаклы яшеннәре белән килеп керә; язы исә, ярсынып, изүләрен чишеп җибәрә. Хикәяләрдә култыклашып баскан наратлар, ак керфекле, сары күзләре белән дөньяга караган ромашкалар, яшь юкәләрнең уфалла арбасы артыннан сыгылып төшеп, башлары белән урам тузанын себереп кайтуы — болар барысы да укучы күз алдында гәүдәләнә.

Язучының «Ай сукмагы» исемле әкият драмасы аеруча кызыклы. Табигать көчләре бу әсәрдә кешеләштереп биреләләр,

[1] Г. Сабитов. Тармаклы яшен. Татарстан китап нәшрияты, 1981 ел.

алар явыз көчләргә каршы кеше белән бергә сугыш ачалар.

Табигатьне кешеләштереп бирү Г. Сабитовның башка хикәяләрендә дә бар. Бары тик халык әкиятләрендә генә яшәгән Урман бабай, Таңсылу кыз, Алып батыр, урман шүрәлеләре, җиде башлы аждаһалар — истә калырдай образлар булып, әсәргә килеп керәләр. Әкият геройлары белән бергә татар халкының борынгы гореф-гадәтләре, ырымнары да язучы игътибарыннан читтә калмый. «Әпсен-төпсен. Урман суы салкын су! Мине тотма, шуны тот»,— дип, өч кат кабатлыйсың да, күлмәк ертыгыннан бер җеп алып, суга ташлыйсың («Йолдыз яктысы»), «Башта бусагадан мәчене кертергә кирәк»... («Туй бүләге»).

Г. Сабитов кеше күңелен, кеше психологиясен оста итеп тасвирлый. Ләкин язучы бу очракта да табигатькә, терәклеккә дан җырламый калмый. «Туй бүләге» хикәясендә, мәсәлән, буяучы кыз Гөлүсә җанлы табигатьне кешеләр яшәгән бүлмәнең стеналарына күчерә. Тик менә кешеләр шатлыгы белән сөенеп яшәгән, яхшы күңелле, уңган Гөлүсәнең акчаны күп нәрсәдән өстен күргән Тәнзилә каршында җиңелеп, нәүмиз калуы гына — укучы өчен көтелмәгәнрәк хәл. Хикәяне укыганда, намусына турылыклы булган Гөлүсәне кызгану хисе уяна. Шул ук вакытта сорау да туа. Ә нигә әле усал Тәнзилә Гөлүсәнең яраткан һәм аңа лаек булган егете Мөҗәһиткә кияүгә чыгарга тиеш тә, шундый матур бүлмә аларның икесенә булырга тиеш? Рухи көчкә ия булган уңган кызны язучы кирәгеннән артык кызганыч хәлдә калдырмыйммы икән?

«Йолдыз яктысы» хикәясенең төп геройлары — 12—14 яшьлек малайлар. Ләкин алар электр утын өйләргә үткәрү өчен каешлы көпчәк белән трактор динамосыннан башка тагын бик күп нәрсәләр кирәклеген ничек белмиләр икән? Югыйсә, күрше Кушкаен авылында гына да өйләргә электр тогы биек багана башларына тартылган чыбыклар буенча бара бит.

Җыентыкка тарихи-революцион темага язылган «Гарасат» пьесасы да кертелгән. Татар-башкорт авылларыннан Себергә куылган гади крестьяннар — бу әсәрнең төп геройлары. Алар арасында соңгы ризыгын ачлар белән бүлешкән Мирсәлим бабай, Зөлфәт, Әлми, Сабир да, халыкка авырлык килгәндә, күбрәк байлык туплап калырга тырышкан Сәлмән дә бар. Чит җирләрдәге татар крестьяннары Рузанов кебек рус эшчеләренең дөрес юл күрсәтүләре нәтиҗәсендә, ачыктан-ачык байгуraларга каршы чыгалар һәм прискадагы башка милләт эшчеләре белән берләшәләр. Зур тарихи әһәмияткә ия булган 1912 елгы Лена вакыйгаларының үзәккә алынуы һәм аның эшчеләргә тәэсирен күрсәтү — биредә бик мөһим. Язучы бу вакыйгаларның килеп чыгу сәбәпләрен дә, эшчеләрнең ничек яшәүләрен дә кабатланмас геройлар аша укучы күңеленә үтеп керерлек итеп сурәтли. Бу көрәш күп корбаннар белән тәмамлана. Ләкин татар эшчеләренең күңелләрендә төшкенлек түгел, ә бәлки менә мондый өмет кала:

**Каныгызда кызыл гөлләр чәчәк атар...**

Әйе, бу гарасат, дәһшәтле күкрәү булып, еракларга яңгырады, еракларга ишетелде. Бу күкрәү йоклаган акылларны уятты. Иелгән башлар күтәрелде, изелгән, кимсетелгән җир уллары күктә Чулпан йолдыз янганын күрделәр. һәм ул йолдыз ялкынлы чакыру авазы салды: «Әй, җир уллары, торыгыз, уяныгыз! Изге көрәшкә, зур бәхет өчен яуга берләшегез!..»

Әсәрдә зур өмет һәм җиңү ышанычы белән яңгырый бу сүзләр...

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә: Г. Сабитов балалар өчен дә, зурлар өчен дә әһәмиятле, кызыклы проблемалар күтәрә. Укучының хыял дөньясын баетуда, матурлыкны тоярга, туган ягын сөяргә өйрәтүдә язучы әсәрләренең өлеше зур.

**ӘЛФИНУР ЗИННӘТУЛЛИНА.**

# САБЫР КАНАТЛАРЫ

Әдәбиятта «хатын-кыз шигърияте» яки «хатын-кыз прозасы» дигән төшенчә яшәми. Язу эшенә алынган хатын-кызларга ташламалар ясарга безнең хакыбыз юк. Бу җәһәттән ышанып әйтергә була: Сажидә Сөләйманова иҗаты — татар әдәбиятының горурлыгы, йөз пакьлыгы. Ул Мозаффарияләр очырган шигърият кошын яңа биеклеккә, зур әдәбият күгенә күтәрде.

60 нчы еллар башында безнең поэзиябез күп кенә яңа исемнәргә баеды. Менә шул вакытта артык куадарланмыйча гына һәм гаҗәеп тыйнаклык белән Сажидә Сөләйманова да шигърият ишеген шакыды.

**Бәхетең артырмы, күренсә**
**юлның азагы!**
**Газаплар булсын —**
**яңаны**
**эзләү**
**газабы.**

[1] С. Сөләйманова. Сабыр канатлары. Татарстан китап нәшрияты. 1981 ел.

Менә шушы юлларда ук инде шагыйрәнең башкалар салган юлдан бармыйча, үз юлын, үз җырын табарга тырышып эзләнүен сизеләргә мөмкин.
Менә аның 1963 елда язылган «Машинада атлар» дигән шигыре:

**Кара тасма юл сузылган,**
**ике якта кар.**
**Машиналар узышалар,**
**машинада атлар...**

Карап торышка, һич тә гаҗәпләнерлек урын юк кебек. Сугым сараена яки базарга алып бару өчен машина арбасына төялгән мал-туар кемне шаккатырсын икән?! Тик без шигырьне дәвам итик:

**Юл ташларын ат ташыды,**
**таныш һәрбер чаты —**
**кара күздә тездән батып,**
**чыгалмыйча атты.**

**Пар кыңгырау чылтыратып**
**юртыр гына чаклар...**
**Машиналар чаба юлдан,**
**машинада атлар.**

Соңгы елларда татар әдәбиятында, бигрәк тә шигърияттә, ат образы гаять зур эволюция кичерде. Образ яңа мәгънә төсмерләре белән баетылды, заманча яңгыраш алды. С. Сөләймановның бу шигырене бер төрле генә аңлатма бирү дә дөресләккә хилафлык китерү булыр иде. Шулай, шигырьне шигырь итүдә образларның күп сыйдырышлы, ассоциатив мәгънәле булуы төп шартлардан берсе икәнен тагын бер мәртәбә ышанасың.
Шагыйрә иҗатында социаль-психологик анализның көчәюе дә нәкъ менә шушы шигырь язылган елларга туры килә. Шигырьләрнең фәлсәфәсе тирәнәя, образлар тагын да конкретлаша төшә. Менә аның атаклы рус шагыйрәсе Марина Цветаевага багышланган шигыреннән бер өзек:

**Ә кояшта таплар**
**чит күзләрнең**
**Күзлегеннән кара күренә...**
**Юлдаш булсаң, йолдыз булыр идең**
**туган-үскән илнең күгендә.**

С. Сөләйманова биредә татар укучысына Марина Цветаева дигән зур шагыйрә барлыгын тагын бер мәртәбә искәртә һәм шигъриятнең җәмгыятьтә тоткан урыны турында тирән гомумиләштерү ясый.

**Ә бөркеткә һәрчак ук тибелә.**
**Очып төшә кызыл каурыйлар...**
**Күк барында —**
**җирдә уклар да бар,—**
**тыныч яшимени шагыйрьләр.**

Шагыйрәнең икенче бер шигырендә ниндидер куркыныч сагалавын тоеп хәвефләнү мотивы урын ала:

**һәр авазы серле шагыйрәнә,**
**Җир әйләнә, ә ул үзәктә,**
**ей тирәсендә дию түен**
**йөрәгенә басып күзәтә.**

**Шул йөрәктә тагын ничә укчә!**
**Үксеп чыга аннан җыр, ютәл...**
**Йөрәгемнән сикереп, җиргә чумдым,**
**Ахматова түгел мин — бүтән.**

Үз вакытында Саҗидә Сөләймановапы Анна Ахматова, Зөлфия кебек мәшһүр шагыйрәләр белән тиңләү очраклары булды. Бу чагыштырулар бер яктан, С. Сөләймановапы шигърияттә зур фигура булуына ишарә ясаса, икенче яктан, аның иҗаты да Ахматова, Зөлфия кебек киң яңгыраш табарлык дигән фикер уята иде.

**Соңгы патрон әле атылмаган,**
**онытылма, йөрәк, хушланма!**
**Гадел атлы әткәм аманәте —**
**соңгы патрон —**
**соңгы дошманга!**

Менә шуның кебек күп кенә шигырьләр дә шагыйрә аерым кеше язмышы аша бөтен совет халкының героик язмышын сурәтләү югарылыгына ирешә.
Әйе, Саҗидә Сөләймановапың үз тормышы һәм иҗаты да халыкка фидакарьләрчә хезмәт итүнең гүзәл бер мисалы. Киләчәктә дә шагыйрәнең шигъри авазы көчәйгәннән-көчәя барыр. Без моңа олы шигърияткә ышанган кебек ышанабыз.

**Газинур МОРАТОВ.**

# РЕВОЛЮЦИЯ КАҺАРМАНЫ

Татар халкының гражданнар сугышы елларында кыюлык һәм фидакарьлек үрнәге күрсәткән данлы уллары арасында Хөсәен Мәүлетов исеме күренекле урын алып тора. Кама буенда ярлы гаиләдә туып үскән Хөсәен Мәүлетов катлаулы һәм авыр тормыш юлы үтә. Ул Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында чыныга һәм политик яктан үсә, Уралдагы революцион вакыйгаларда актив катнаша. Соңрак легендар Фрунзе гаскәрләре сафларында ул Көнчыгыш фронтта һәм Урта Азиядә Совет власте дошманнарына каршы сугыша. Сугышларда күрсәткән кыюлыгы һәм тапкырлыгы өчен ул ике тапкыр Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.
Язучы Вазих Исхаков, Хөсәен Мәүлетовның тормыш юлына мөрәҗәгать итеп, яңа кызыклы фактлар таба, герой шәхесендәге яңа сыйфатларны ача. Аның Татарстан китап нәшриятында чыккан «Кама егете»[1] повесте — моңа ачык дәлил.

[1] В. Исхаков. Кама егете. Татарстан китап нәшрияты, 1981 ел.

Китапның беренче битләреннән үк автор безне каһарман яшәгән мавыктыргыч дөньяга алып кереп китә. Хәтергә уелып калырдай мисаллар ярдәмендә ул кискен социаль конфликтларның асылын ача. Повесть герое — ленинчы-большевик Хөсәен Мәүлетовның тынгы белмәс эшчәнлеге әнә шул катлаулы социаль-политик фонда күрсәтелә. Бәян итүдә хронологик эзлеклелекне сакламастан, автор төрле отышлы алымнар куллана. Әйтик, кирәк дип санаганда, ул тарихка һәм персонажларның үткәненә экскурс ясый. Болай эшләү хикәяләүне мавыктыргыч итә, укучыны да кызыклы информация белән баета. Аннан соң мондый типтагы әсәрләрдә тарихи дөреслек белән иҗади фантазия арасындагы нисбәт дөрес булу бик мөһим. Автор оптималь нисбәтне таба алган һәм геройның тормыш юлын чагылдыру процессында аңардан уңышлы гына файдаланган.

Китапта без Мәүлетовлар гаиләсенең, ярлы тормыштан качарга теләп, Чистайдан Пермьгә күченүен күрәбез. Аннары Хөсәеннең шәһәр мәдрәсәсендәге уку елларын, Алафузовлар фабрикасы конторында эшләвен күздән кичерәбез. Тагын уку. Бу юлы инде Хөсәен — Казандагы Учительская школада. Вак буржуалар оешмасы — Җәмгыяте хәйрия — сәләтле егетне Казанга укырга җибәргәндә, әлбәттә, үз максатларын алга сөрә. Егеттән ялкынлы революционер чыгар дип ул чагында кем уйлаган соң!

Хакыйкатькә юлны үз тәҗрибәсе аша, аңлы рәвештә табарга күнеккән Хөсәен Мәүлетов — комиссариатта эшлиме, фронтның алгы сызыгында сугышамы, авыр яралардан дәваланып ятамы — ул һәркайда көрәшче булып, хезмәт халкын яклаучы булып кала. Каһарман тормышыннан алынган конкрет фактлар моңа ышандыра. Мәсәлән, М. В. Фрунзе заданиесе буенча ул чит ил интервентлары һәм Колчак белән союзда торган милли-буржуаз «Алаш Урда» хөкүмәтен безнең якка аудару өчен төзелгән интернациональ отряд командиры итеп билгеләнә. Хөсәен Мәүлетов бу заданиене уңышлы башкарып чыга һәм батырлыгы өчен беренче Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Юк, Хөсәен Мәүлетов ялгызак батыр гына түгел. Геройның сугышчан иптәшләре Якуб Чанышевка, Гали Касыймовка, Госман Фәхретдиновка һ. б.ларга китапта шактый ук урын бирелгән. Әсәрне укыганда без үзәк Мөселман комиссариаты башында торган Мулланур Вахитовның зур оештыру эшчәнлеген тоеп торабыз.

Повестьның үзәгендә художество көченә ия образ тору, әсәрнең фоторәсемнәр белән баетылган булуы китапны мавыктыргыч һәм җиңел укыла торган итә. Чиста, бай әдәби тел белән язылу, матур стиль дә — авторның казанышы. Китап укучылар тарафыннан җылы каршыланыр дип уйлыйбыз.

**Ренат НӘБИЕВ.**

# НИЗАМИ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Азербайҗанның бөек шагыйре Низами исеме бөтен совет халкы тарафыннан тирән ихтирам белән телгә алына. Аның әсәрләре яратып укыла, иҗаты уртак байлык буларак кабул ителә. Тууына сигез йөз кырык елдан артык вакыт узса да, тарих агымының барлык сынауларын үтеп, Низами безнең белән бергә яши. Ул кешене якты идеаллар белән һәм тыныч, дуслыкта яшәргә чакыра. Шуңа күрә дә яңа дөнья төзүче совет кешесе Низамины зурлап, аның алдында баш ия.

1947 елда үткәрелгән Низами юбилее бөтен совет әдәбиятының зур бәйрәме төсендә булды. Шул вакытта Низамины татар укучысына тагын да якынрак җиткерү өчен чаралар да күрелде. Низами әсәрләреннән үрнәкләр матбугат битләрендә урын алды[1], «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасы татар телендә аерым китап булып басылып чыкты[2]. Низами әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүне Н. Исәнбәт һәм М. Максуд кебек зур каләм осталары башкарды. М. Максуд татарча басылган «Ләйлә белән Мәҗнүн» поэмасында «Азербайҗан халкының даһи шагыйре» дигән мәкалә багышлады. Ул мәкалә поэмадан өзекләр белән бергә авторның сайланма әсәрләр җыентыгына да кертелде.

М. Максуд үзенең бу мәкаләсендә, Низами иҗатына югары бәя бирү белән бергә, аның мирасының әле дә кешелек дөньясы интересларына хезмәт итүе һәм тагын да көчлерәк яңгыраш алуы турында яза. «Низаминың,— ди ул,— коллыкка һәм гаделсезлеккә каршы, кешенең кешелеген мыскыл итүгә каршы әйткән ялкынлы сүзләре хәзерге чорның тираннарын — империалистларын да бик нык камчылыйлар. Аның хезмәт сөю, иптәшлек, дуслык һәм мәхәббәт турындагы сокландыргыч шигырьләре бүген дә актуаль яңгырыйлар. Менә шуңа күрә дә үлемсез шагыйрь Низами бөтен җир шарында бәхетле азат тормышның тулы тантанасы өчен көрәштә прогрессив кешелек дөньясының алгы сафларында бара».

Шулай итеп, Низамины татар укучысына якынайтуда тагын да бер зур адым ясалды. Моннан соң да Низами игътибар үзәгендә була, чөнки татар әдәбияты үткән озын юлны Низами эзләреннән читтә карау һич тә мөмкин түгел. Бу — хакыйкать, моның шулай икәнлеген фактлар үзләре сөйли.

Кырыгынчы елларда татар укучыларын Низами иҗаты белән яхшылап таныштыручыларның берсе көнчыгышны өйрәнүче әдәбиятчы-галим Бакый Халит булды. Б. Халитның шагыйрьнең юбилее уңае белән язылган мәкаләсе[3] татар әдәбият белемендә Низамины өйрәнүдә җитди тикшеренү булып тора. Автор Низами иҗатын шул заман җәмгыятенең торышы, андагы социаль процесслар, халыкның изүчеләргә төрле төстә каршылык белдерүләре яссылыгында тикшерә, әсәрләренең тирән гуманистик идеяләр белән сугарылганлыгын ача һәм алардагы образларының алдынгы идеаллар белән илһамланып яшәгәнлекләрен күрсәтә. Ул шагыйрь иҗатында социаль-философик, утопик карашларның урын алуына да туктала, язучының стиле, иҗат методы кебек катлаулы мәсьәләләр һәм ул алып килгән яңалыклар турында да фикер йөртә. «Романтизмга бирелгән Низами,— ди ул,— искиткеч катлаулы фантастик матур образлар иҗат итә; романтик каһарманнарның язмышларын, тойгыларын, психологияләрен, рухи кичерешләрен тасвирлауда тиңдәшсез оста художник

[1] Низаминың «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы (үрнәкләр).— Совет әдәбияты. 1947, № 9, 84—87 битләр (Н. Исәнбәт тәрҗемәсе).

[2] Низами Ганҗәви. Ләйлә белән Мәҗнүн. М. Максуд тәрҗемәсе. Таттосиздат, 1950.

[3] Бакый Халит. Низами. Тууына 800 ел тулуга карата.— Совет әдәбияты. Казан, 1940. № 9—10, 126—135 битләр.

була. Феодализмның тончыктыргыч авыр шартларында романтизм Низами өчен кислород кебек зарур иде... Искиткеч батырлар, фантастик каһарманнар тормышы турында эпик поэмалар язу чорында романтик поэмалар иҗат итүне башлап җибәрә һәм Фирдәүси традицияләренә юл баглый».

Низами кебек дөньякүләм классикның иҗат методы хакында әле бөтенләй диярлек сүз бармаган бер вакытта Бакый Халитның ул хакта башлап фикер йөртүе шулай ук искә алынырга тиеш. Татар әдәбиятчылары аннан элегрәк тә Низами иҗатына мөрәҗәгать иттеләр. Г. Рәхим һәм Г. Газиз, совет властеның беренче елларында ук «Татар әдәбияты тарихы»н төзегәндә, Низами йогынтысы астында язылган төрки телдәге «Мәхзәнел-әсрар»га махсус тукталып, аңа аерым бүлекчә бирделәр. XIV йөз азагы — XV йөз башында яшәп иҗат иткән харәземле Хәйдәр, Низаминың «Мәхзәнел-әсрар»ыннан файдаланып, шул исемдә әсәр язган. Бу хакта ул үзе дә:

**Мин ки пешердүм бу ләзиз [1] ашны,**
**Шәйх Низамидин алып чашни [2],—**

дип, ачыктан-ачык әйтә.

Хәйдәрнең «Мәхзәнел-әсрар»ы [3] беренче мәртәбә 1857 елда Казанда Иосиф Готвальд тарафыннан басылган һәм барлык төрки халыклар дөньясына таралырга юл алган. Урта Азиядә бу әсәрнең кулъязмалары булуы хәзергә билгесез, соңгы елларда Татарстанда аның яңа бер кулъязмасы табылды.

Татар халкының алдынгы укымышлылары Низами иҗатын башка төрки халыклар даирәсенә җиткерүне дә күз алдына тотып эшләделәр. Мәсәлән, 1902 елда Казан университеты типографиясендә «Мәшһүр гашыйк, мәгъшук Ләйлә илән Мәҗнүн хикәясе» дигән китап басыла. Бу — Низаминың атаклы «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасының эчтәлеген шул вакыттагы төрки-татар әдәби телендә сөйләп биргән хикәя була. Хикәянең авторы Фатих Халиди: «Ушбу мәшһүр «Ләйлә вә Мәҗнүн» китабыны Россиядә булган мөселманнар төркисенә тәртип кылдым» [4],— дип белдерә.

Ләйлә белән Мәҗнүннең Низами әсәрләреннән килә торган мәхәббәт маҗаралары турындагы хикәятләрнең борынгы чорга караган үрнәкләре дә бар. Мәсәлән, 1973 елда археография экспедициясе Татарстанның Арча районыннан Ләйлә һәм Мәҗнүн хакындагы легенданың XVIII йөзгә караган татарча кулъязмасын табып алып кайтты [5].

Әгәр дә без тарихка күз салсак, татар әдәбиятының Низами иҗаты белән бәйләнүе бик ерактан килгәнен күрербез. Татар халкының бабалары — болгарлар азербәйҗаннарның бабалары угызлар белән якын мөнәсәбәттә булганнар. Ибне Фазлан болгар ханы Алмышның угызлар гаскәр башлыгы кызына өйләнгән булуын хәбәр итә [6]. XII йөзнең беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе Әл-Гарнати болгар сәүдәгәрләренең азербәйҗан кылычларын алып кайтулары турында яза. Идел тамагындагы Саксин шәһәрендә кырык угыз кабилә кешеләре, болгар һәм суварлар бергә яшиләр, болгар өмире шәһәр үзәгендә урнашкан, һәркайсы халыкның үзләренең мәчетләре, галим-голәмалары бар [7],— ди ул.

Ш. Мәрҗани язганча [8], XIII йөздә Болгарда яшәп иҗат иткән Хәсән Болгари (Әш-Шәйхел — Имам Хуҗа Хәсән бине Гомәр) исемле билгеле галим чыгышы белән Азербәйҗанның Гәнҗә шәһәреннән булып, Болгарда күп еллар төрле фәннәр белән шөгыльләнгән, дини һәм дөньяви әхлак, фән мәсьәләләре буенча барган бәхәсләрнең башында торган һәм хөр фикерләре өчен мәчет манарасыннан ташлап үтерелүгә хөкем ителгән, тик дуслары ярдәмендә генә үлемнән качып котылган. Болгарның үз галиме саналып, ул тарихка Хәсән Болгари исеме белән кергән.

---

[1] Ләзиз — татлы.
[2] Чашни — аш тәмләткеч.
[3] «Мәхзәнел-әсрар». Казан, 1857, 11 бит.
[4] Мәшһүр гашыйк, мәгъшук Ләйлә илән Мәҗнүн хикәясе. Казан, имп. университет типолитографиясе, 1902, 45 бит.
[5] Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов М. Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссасының татарча варианты.— Казан утлары. 1979, № 6, 170—171 битләр.
[6] Ковалевский А. П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921—922 гг. Харьков. 1956, 129 бит.
[7] Путешествие Абу Хамида Ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131—1153 гг.). М., 1971, 27, 56, 58 битләр.
[8] Ш. Мәрҗани. Мөстәфадел-әхбар. 1. Казан, 1897, 83 бит.

Икенче яктан, Афак исемле кыпчак кызы Низаминың бердәнбер сөйгән хатыны булган. Афак (борынгы болгарча язылышы — Афа) исеменең болгар кабер ташында теркәлгән булуы да кызыклы факт. Азербәйҗаннар белән татарлар арасында барган бәйләнешләр, культура һәм сәүдә мөнәсәбәтләре соңга таба да тукталып тормаган[1].

1969 елның маенда Татарстанда Азербәйҗан культурасы атналыгы башлану уңае белән Д. Г. Җафаровның: «Безнең халыклар борынгыдан инде үзләренең этник һәм рухи гомумилеге белән билгеләнә иделәр»[2], дип язуы бик дөрес булды. Азербәйҗан һәм татар фольклорының, әдәби ядкәрләренең үзара керешүләре — борынгы вакытлардан килгән законлы күренеш. Шуның нәтиҗәсе буларак, Себер татарларында «Күроглы»ның аерым варианты барлыкка килгән, «Дәдә Коркыт» дастанының тәэсире Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына да кагылган[3]. А. Самойлович һәм Ә. Нәҗипнең бу әсәрнең барлыкка килү урыны итеп угызлар белән тыгыз бәйләнештә булган төбәкне чамалаулары[4] бер дә гаҗәп түгел. Н. Хисамов та бу галимнәр фикеренә кушыла һәм Зөләйха образын сурәтләүдә, сарай эче бизәкләрен бирүдә «Кыйссаи Йосыф» авторына Низами әсәрләренең тәэсире булганлыгын да билгели. Низаминың социаль-утопия карашларының болгар-татар язучылары иҗатына йогынтысы турында исә безнең элегрәк басылган хезмәтләребездә сүз булган иде[5].

Низаминың урта гасыр татар әдәбиятына ясаган йогынтысының иң күркәм үрнәкләреннән берсе — аның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасының XIV йөздә шагыйрь Котб тарафыннан ясалган төрки телдәге тәрҗемәсе. Бу тәрҗемәнең иҗади башкарылганлыгы, ягъни анда Котбның үзенең дә оригиналь өлешләре булганлыгы фәндә инде исбат ителгән нәрсә.

Поляк галиме А. Зайончковский илленче елларда Котб әсәренең кулъязма фотосын транскрипция һәм сүзлеге белән аерым китаплар итеп бастырып чыгарды. Котб иҗатын өйрәнүдә тюрколог Ә. Нәҗипнең дә зур эш башкарганлыгын әйтергә кирәк. Ленинград университеты профессоры Г. Таһирҗанов 1946 елда бу әсәр турында кандидатлык диссертациясе язган иде. Автор, эзләнүләрен дәвам иттереп, соңгы вакытта «Котб һәм аның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре» дигән яңа хезмәт игълан итте[6].

Галим бу хезмәтендә Котбның шагыйрь буларак зур каләм остасы икәнлеген күрсәтә. Шулай булмаса, ул Низами кебек бөек сүз сәнгаткяренең гаять катлаулы сурәтләр, образлы картиналарны эченә алган «Хөсрәү вә Ширин» кебек шедеврга тотынмаган булыр иде. Һәрхәлдә, Котб Низами поэмасындагы гаҗәеп образлар дөньясын төрки укучысына җиткерә алырлык талант көченә ия булган. Котб иҗатын бу яктан өйрәнүдә Х. Миңнегуловның да күп өлеше бар[7]. Госман Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е турында мәкаләләр язу белән бергә, бу поэманы ул гарәп язуында ике кисәктә бастырып та чыгарды[8]. Болар барысы да Котб иҗатын өйрәнүдә һәм аны Низами белән бәйләнештә карап татар укучылары арасында популярлаштыруда мактауга лаек эшләр булды.

Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е төрки халыкларга Низами мирасының серле дөньясына үз телләре аша үтеп керергә киң юл ачкан. Е. Э. Бертельс, аның әһәмиятен күрсәтеп: «Монгол биләмәләренең көнбатыш өлешендә бу — беренче дөньяви әсәр, һәм аны дөньяви әдәбиятның алга таба үсеше өчен юл билгеләгән шактый уңышлы тәҗрибә дип атарга мөмкин»[9],— дип бәяләде.

Танылган зур галимнең бу әсәр турында әйткән сүзләренең хаклыгына аерым төрки әдәбиятларының үсү тарихы ачык мисал Г. Таһирҗанов: «Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре болгар-татарларның һәм Урта Азиядәге кайбер халыкларның әдәбият-

---

[1] Казанская история. М.-Л., 1954, 135 бит.

[2] Җафаров Д. Г. Ленин сызган юлдан.— Социалистик Татарстан. 1969, 25 май.

[3] Хисамов Н. Ш. Поэма «Кыйсса-и Йусуф» Кул Али: Анализ источников сюжета и авторского творчества. М., 1979, 213—214 битләр.

[4] Самойлович А. Н. Очерки по истории туркменской литературы.— В кн.: Туркмения. т. 1. Л., 1929, 137 бит; Наджип Э. Н. О языке памятника начала XVIII века «Кысса-и Юсуф» Али.— Советская тюркология. 1976, № 2, 88 бит.

[5] Кара: Абилов Ш. «Кутадгу Билик» в булгаро-татарской литературе.— Советская тюркология. 1970, № 6, 88 бит.

[6] Таһирҗанов Г. Тарихтан — әдәбиятка. Казан, 1979, 95—169 бит.

[7] Миңнегулов Х. Ю. Котб иҗаты. Казан дәүләт университеты (КДУ) нәшрияты, 1976.

[8] Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте. I—II. КДУ нәшрияты, 1970—1971. (Басмага хәзерләүчеләр — Х. Госман һәм З. Максудова); Котб — Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары. Уку-укыту әсбабы. КДУ нәшрияты (Төзүчесе — Х. Госман), 1981.

[9] Бертельс Е. Э. Литература народов Средней Азии от древнейших времен до XV века н. э.— Новый мир. М., 1939, № 9, 272 бит.

лары үсүгә дә бик нык тәэсир иткән истәлекләрдән саналырга хаклы»[1], дип билгеле һәм аның Мөхәммәдъяргә булган йогынтысы турында да кагыла.

Низаминың татар әдәбиятына ясаган йогынтысы турында профессор М. Гайнуллин да мәкаләләрендә сүз алып бара[2], Х. Госман Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасының тәэсиренә карата болай ди: «Шул заман арасында (ягъни әсәр язылган вакыттан бирле.— Ш. А.) аның традицияләре безнең поэзиябез үсешенә гаять тирән һәм күркәм эз салып киткән»[3]. Низаминың социаль-утопик карашлары болгар-татар шагыйрьләренә аеруча тәэсир иткән. Җәмгыятьтә төрле катлау кешеләре арасында тугәннарча тату, тигез, хөр, мул яшәү идеясен күп акыл ияләре, шагыйрьләр алга сөргән, һәм татар шагыйре Мөхәммәдъяр да ул идея белән хыялланган. Урта гасыр авторларында идея уртаклыгы, якынлык һәм мотивлар аваздашлыгы бар икән, ул һич тә берсе икенчесен кабатлау булмаган. Бу заманның әдәбият практикасында яшәп килгән традиция көче хакында сөйли. Ләкин идеяне һәр автор үз җәмгыяте куйган таләпләргә җавап буларак эшкәрткән, аны укучыга җиткерә алырлык сәнгатьчә форма да уйлап тапкан, яңа әсәр барлыкка китергән.

Низами иҗатында гадел идарә итү, хөр яшәү, кешелекле булу, хезмәтне олылау, хатын-кызны тиң күрү һәм турылыклы мәхәббәт идеясе алга сөрелә. Әмма аларның барысы да кешелек җәмгыятен гадел идарә итү нигезендә савыктыру турындагы үзәк идеягә килеп тоташа. Менә шундый киң иҗат мирасының балкышы аңа мөрәҗәгать иткән күпләрне рухландырган, яңа әсәрләр иҗат итәргә илһамландырган. Үзара әдәби йогынтыны шул мәгънәдә аңларга кирәк тә. Әдәби йогынты тышкы яктан сизелеп тормаска да мөмкин. Шигъри юлларның янсә әдәби текстларның тәңгәл булуы шарт түгел. Әмма мотивлар бердәмлеге, аларның үзара килешүе, образ янсә аерым сурәтләрдәге детальләр якынлыгы булырга тиеш. Мәсәлән, Кол Галинең киң күңелле һәм гадел Йосыф образы бу сыйфатлар белән Низаминың Хөсрәү һәм Ширин образларына бик якын. Хөсрәү тәхеткә утыргач, гадел идарә итә, илдә тынычлык урнаша, кимсетелгәннәрнең күңелен таба, залимнәргә каһәр-ачу яудыра. Ширин идарә итә башлагач, халык шатлыкка ирешә, тоткыннар азат ителә, золым тыела, салымнар туктатыла.

Йосыф та, Ширин кебек, илдә гадел хөкем урнаштыра, җәбер-җәфаны бетерә, игеннәр китерә, авыр вакытларда амбарларны ачтырып, халыкны ач үлемнән коткарып кала.

Кол Галидә, Низамидагы кебек, гуманистик идеяләр көчле чагылган. Низами гуманизмының үз җирлеге булса, Кол Гали гуманизмының да үз тарихи нигезләре булган. Кешегә кешеләрчә карау, аның акыл көчен олылау һәм хезмәтенең бөек әһәмиятен күрә белү — бу сыйфатлар бер яктан, авторның тормышчан позициясе белән бәйләнгән булса, икенче яктан, халык массасын золымда интектергән социаль-иҗтимагый шартлар гуманистик карашларның үсүенә дә сәбәпче булган. Шул алдынгы идеяләрне укучыга сәнгатьчә чаралар аша җиткерүдә безнең шагыйрьгә Низами өлге булган.

Татар халкының социаль-философик фикер үсешендә Низаминың роле зур. Бу шагыйрь Мөхәммәдъяр иҗаты аша да ачык күренә. Низами «Искәндәрнамә» поэмасында үзенең хыял җимеше булган утопик җәмгыятьнең үрнәк картинасын тасвирлый. Әсәрнең каһарманы Искәндәр, җирдә бәхет иле эзләп йөргәндә, ерак төньякта шундый өлкәгә очрый. Анда йортлар, кибетләр йозаксыз, хәтта маллары да көтүсез, гаскәр юк, читләргә сугыш белән бармыйлар; кешеләр ирекле, алар гаделлектән башканы белмиләр, мөкерлек, алдау, икейөзлелек юк, тапканны үзара тигез бүләләр, бер-берсенә ярдәм кулы сузалар, закон каршында һәркайсы тигез.

Низами бәхетле җәмгыятьне әнә шулай итеп күз алдына китерә. Мөхәммәдъяр да «Нуры содур» поэмасында гадел идарәнең җимеше итеп, шундый җәмгыять картинасын сурәтли. Гадел идарә итү нигезендә золым, фетнә бетә, җимерекләкләр төзекләнә, ил чәчәк ата, байлык арта, аннан һәркем тигез өлеш ала, барлык халык

---

[1] Таһирҗанов Г. Тарихтан — әдәбиятка, 95 бит.
[2] Гайнуллин М. Дуслыкта — көч, Татарстан китап нәшрияты, 1973, 138 бит; аның ук: Татар әдәбияты үсешенә йогынты ясаган кайбер әдәби фактлар.— Совет әдәбияты, 1957, № 7, 87, 90 битләр.
[3] Госман Х. Алты йөз ел элек.— Совет әдәбияты, 1962, № 12, 137 битләр.

җитеш, мул тормышта рәхәт кичерә. Бу күренешләрне Мөхәммәдъяр дә, Низами кебек үк, үз җәмгыяте тәртипләренә каршы куя, шул юл белән илне савыктырырга тели [1].

Күренә ки, шундый зур социаль-философик мәсьәләләрдә дә Низами безнең Мөхәммәдъярга хыялланып очен канат биргән.

Кол Галидән башлап, болгар-татарларның алдынгы язучылары Низаминың фарсы телендәге әсәрләрен дә яхшы белгәннәр һәм алардан рухи азык алганнар.

Хәзерге вакытта Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә ф-326 (2391 саны белән Низами «һәфте пәйкәр» поэмасының 1020) 1611—12 елда күчерелгән кулъязмасы саклануы да шул хакта сөйли булса кирәк. Моңа Мөхәммәдъяр иҗаты да мисал була ала. «Нуры содур» поэмасы үзенең төзелеше белән Низаминың «Мәхзәнел-әсрар» һәм «Җиде гүзәл» поэмаларын хәтерләтә. «Нуры содур»да һәм «Җиде гүзәл»дә, аерым бүлекчәләрнең бер үк исемдә булулары белән бергә, фикер агышында да якынлык бар. «Төхфәи мәрдан» поэмасының башламында авторның үз күңеле белән сөйләшүе, язмыш белән бәхәскә керүе дә Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендәге керешкә охшап китә.

«Төхфәи мәрдан»да Мөхәммәдъяр кешене югары, бөек бер зат саный, аның кешелекле булуын төп сыйфаты итеп карый. Бу караш та Низаминың «Мәхзәнел-әсрар» һәм «Җиде гүзәл»ендәге төп мотивка бик якын.

Низаминың барлык әсәрләрендә дә хатын-кызның әхлак сафлыгы, турылыклы мәхәббәте, олы җанлы һәм хәтта батыр рухлы булуы да сурәтләнә. Алар арасында ирләрдән югары торганнар да күп, ди автор.

**Бик күп гүзәл хатыннар бар арыслан кук,**
**Ирләрдән дә хатын-кыздан калышкан күп.**

(«Хөсрәү вә Ширин»нән өзекләр. Н. Исәнбәт тәрҗемәсе).

Мөхәммәдъярда да хатын-кызлар һәр эштә ирләр белән тиң. Алар, кешелеклелекнең иң гүзәл сыйфатларына ия булып, һәртөрле батырлыкларны эшләргә сәләтле итеп сурәтләнә. Шуның өчен дә:

**Тел вә күңлеңне игри [2] кылма кешегә,**
**Йөзең бер кыл кәрәк иркәк, тешигә,—**
(«Төхфәи мәрдан». 60 б.)

дип кисәтә дә шагыйрь.

Низами мирасы татарның соңгы чорлардагы шагыйрьләре өчен дә уңдырышлы бакча булган. Ул тәэсир өзелеп тормаган, аны һәр буын яңача кабул иткән. Низаминың әхлак турындагы аерым өйрәтмәләре XVIII йөз башы татар шагыйре Габди шигырьләренә дә үтеп кергән. Ә XIX йөзнең урталарында иҗат иткән Габделҗаббар Кандалыйга Низаминың мәхәббәт каһарманнары тагын да якынрак булган. Кандалыйның лирик герое үзенең хисләрен сөйгәне Бәдигага, барысы да үтәчәк диген фаталистик караште торып, мәхәббәт кебек олы тойгыларның кичерелмәскә тиешлеген аңлатырга тырыша. Герой үзен Низами персонажлары хәлендә калганлыгын аңлата.

**Дәхи Мәҗнүн тотып күп гыйшкы мәйле,**
**Дәюр ирди: И Ләйле лә! И Лейле!**
**Дәхи борын заманда үтте Фәрһад,**
**Ки Ширин атлы кыз өчен итте фөрйад.**
**Ки мән дәхи бу арага төзелдем,**
**Бәдигам! дип, өзелдем дә өзелдем [3],—**

ди ул.

---

[1] Бу турыда кара: Н. Ш. Абилов. Идеи социальной утопии в наследии татарских мыслителей Средневековья.— В кн.: Из истории татарской общественной мысли. Казань, 1978, 56—61 битләр.
[2] Игри — кәкре, чалыш. Күчерелмә мәгънәдә — ялган.
[3] Кандалый Г. Шигырьләр. Казан, 1960, 164 бит.

Шагыйрь Дәрдмәнд иҗатында исә Низами тәэсиренең гаять үзенчәлекле, тирән һәм сәнгатьчә бик нечкә сыйфатларга үрелеп бирелүенә шаһит булабыз. «Бүзләрем маналмадым» шигырендә лирик герой, тормыш дулкыны агышында көчле кичерешләргә бирелеп, үзенең хәлен Мәҗнүн һәм Фәрһадныкына караганда да аянычрак сизә һәм:

Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад,
Бер янып ат алдылар,
Мин гарип мең кат янып та —
Яндыга саналмадым,

дип аваз сала.

Низаминың татар шагыйрьләре иҗатына тәэсире хакында сөйләгәндә, шул ук Дәрдмәнднең тагын бер шигыренә тукталмый үтү мөмкин түгел. «Хикәяи гыйшык» дип аталган ул шигъри юлларны Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн» поэмасы йогынтысында иҗат ителгән классик үрнәк итеп карарга мөмкин.

Дәрдмәнд үз карашы нигезендә вакыйганы күңеле аша үткәргән, аңа үзенең тойгыларын, кичерешләрен салган, яңа образ, картиналар иҗат иткән, нәтиҗәдә берәүдә дә кабатлана алмаган бөтенләй яңа әсәр барлыкка килгән.

Бөек Тукай да үзенең иҗатында намуслы мәхәббәтнең Ләйлә һәм Мәҗнүн, Фәрһад һәм Ширин кебек классик образларыннан поэтик чаралар буларак файдаланды. Тышкы матурлык яисә көчле мәхәббәтне сурәтләгәндә ул аларны чагыштыру өчен алды. Мәсәлән:

И кояш! Ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,
Бер чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.
Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,
Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә.

(«Бер рәсемгә»).

Шуның белән бергә, Тукай үзе яшәгән капиталистик җәмгыятьтә чын сөю һәм мәхәббәт өчен шартлар булмавы, кешелекнең бу югары һәм изге хисләренең тапталган, кимсетелгән булуы турында:

Калмасын дуслык, мәхәббәт, чын сөешмәк дөньяда,
Бу — җәһәннәмдер, түгел Ширин илә Фәрһад җире.

дип ачынып язды.

Тукай гасырлар буена килгән традицион мәхәббәт образларын үз заманы тәртипләренә каршы кую белән бергә, аларны әле хәл ителмәгән, ләкин киләчәктә хәл ителергә тиешле зур социаль мәсьәләләр белән дә бәйләп аңлатты.

Татар әдәбиятының олы маягы Г. Ибраһимов «Кыйссаи Йосыф», «Таһир һәм Зөһрә» кебек әсәрләргә анализ ясаганда аларның мәхәббәт геройларын Низаминың Ләйлә һәм Мәҗнүн кебек классик персонажлары белән чагыштырды, аларны үрнәк итеп куйды.

Шулай итеп, татар әдәбияты үткән тарих юлына күз салсаң, аның Низами иҗаты белән тыгыз бәйләнештә булганлыгы күренә. Низаминың анда мактаулы урыны, якты эзләре бар. Бөек шагыйрьнең югары сәнгатьчә эшләнгән җәүһәрләреннән үрнәк алу һәм аның йогынтысын кабул итү өчен татар әдәбиятының үзендә дә бай җирлек, көчле традиция яшәп килгән. Башка әдәбиятлар белән үзара бәйләнештә үсү процессында татар әдәбияты нәфис, яңа сыйфатларга ия була һәм сәнгатьчә камиллеккә ирешә барган, яңа поэтик образлар иҗат иткән, дөньяны танып-белү сәләтен арттырган. Моның шулай икәнлеге азәрбайҗанның бөек улы Низами Гәнҗәвинең татар әдәбиятына ясаган шифалы йогынтысы мисалында да ачык күренә.

ШАКИР АБИЛОВ.

# Сәвия Михайлова

# ДАВЫЛГА ТАБА

*Саф, шифалы яз вәгъдә итүче һава исе килдеме, бу, мөгаен, Уралдан һәм Казаннандыр... Андагы университетлар рухы, яшь профессорлар һәм студентлар рухы — искиткеч шәп...*

А. И. Герцен. «Провинциаль университетлар» дигән мәкаләсеннән. 1861 ел.

Патша Россиясе шартларында илдәге аз санлы университетлар белем-мәгърифәт учакларына гына түгел, ә гомумпрогрессив хәрәкәтнең башында торучы, гаять мөһим пропаганда һәм культура-агарту үзәкләренә әвереләләр. Билгеле булганча, В. И. Ленин да университетларның революциягә кадәрге эшчәнлегендә үк җәмгыять үсеше белән тыгыз бәйләнеш күрә һәм аларны «сәяси ризасызлык» белдерүче мәркәзләрнең берсе дип саный. Иске Рәсәйнә әнә шундый унике университет — унике шәм яктырта. һәм аларның берсе нәкъ менә Казанда — Идел—Урал буйларының борынгы экономик, сәүдә, политик һәм административ үзәгендә ачылуы аерым бер әһәмияткә ия. Чөнки бу төбәк иң беренче чиратта милли ягы белән үзенчәлекле: биредә дистәләгән телдә сөйләшүче халыклар, бер-берсеннән политик һәм административ киртәләр белән аерылмаган хәлдә, зур гаилә булып яшәүләрен дәвам итәләр. Казанда университет ачылу әлеге чуваш, мари, мордва, удмурт, татар, башкорт, казах һ. б. халыкларның белем һәм культурасын күтәрүдә, милли аңын үстерүдә, фән һәм матбугатчылык эшенә мөмкинлекләр тудыруга бик зур ярдәм күрсәтә. Без бу мәкаләдә, архивтан яңа табылган мәгълүматларга һәм фактларга нигезләнеп, шушы ярдәмнең ничек оештырылуы һәм нинди нәтиҗәләр бирүе турында сөйләрбез.

Университет ачылгач та, аңа Идел буе, Кавказ арты, Урта Азия, Урал һәм Себер төбәкләрен берләштергән зур уку округы белән җитәкчелек итү вазифасы йөкләнә. Ә бу округта элек-электән эшләр бик шәптән тормаган: мәктәпләрдә бердәм укыту программасы юк, укытучыларның күпчелеге — руханилар, аларга методик ярдәм күрсәтелми, уку йортлары да, халык саны белән чагыштырганда, бик аз. Эш менә шул кимчелекләрдән арына бару юнәлешендә оештырыла. Иң әүвәл, 1804 елгы Мәктәп уставы белән, мәктәпләрнең дәүләт системасы урнаштырыла. Алар белән идарә итү өчен университетта училищелар комитеты төзелә. Н. И. Лобачевский, И. М. Симонов, П. С. Кондырев кебек күренекле профессорлар әлеге комитетка сайланалар. 1811 елга округтагы мәктәпләр саны 45 тән 61 гә җитә, иң мөһим җиде мәктәп (халык училищесы) гимназия итеп үзгәртеп корыла. Шул вакытка кадәр бердәнбер булып килгән Казан гимназиясе үрнәгендә Иркутскида (1805), Әстерханда (1806), Нижний Новгородта (1808), Сембердә (1809) һәм Тоболда (1810) гимназияләр ачыла. Гимназияләр Пенза, Пермь, Вятка шәһәрләрендә дә төзелә.

Мәктәпләрнең һәм гимназияләрнең матди хәлен яхшырту, укытучылар әзерләү һәм методик әдәбият булдыру өчен халыктан иганә җыюда да университет зур эш башкара. Кешеләрнең белемгә омтылуы көчле, фәнгә ихтирамы тирән,— уку-укыту эшләрен җайга салу өчен акча, йортлар, мебель, китаплар бүләк итәләр. 1816 елда, мәсәлән, университет советында Иркутск губернасының Түбән Колыма крепостенда яшәүчеләр үтенече тикшерелә: алар көмеш акча белән 835 сум 50 тиен иганә җыюларын хәбәр итеп, шул акчага балаларын укыту өчен мәктәп ачуны сорап язалар. 1863 елда университет инициативасы белән Казанда татар мәктәбе ачу өчен дүрт меңсумга якын акча җыела, ә шәһәр җәмгыяте шул мәктәпкә 700 сажин җир бүлеп бирергә карар чыгара (ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасв., сакл. бер. 9223, 43 бит). Аерым кешеләрнең университетка ышаныч һәм өмет белән карауларын дә-

лиллә торучы мисаллар да күп. Мәсәлән, Подшивалов дигән бер крестьян агай мәктәпкә үзенең агач өен бүләк итә һәм ел саен иң фәкыйрь гаиләләрдән килгән өчәр укучыны үз хисабына яшәтә.

Университет ректоры һәм зур галим дәрәҗәсенә ирешкәч тә, Н. И. Лобачевский мәктәпләрнең эшен тикшерүдә үзе катнаша, мәктәп бинаалары төзелешен һәм ремонтлауны күзәтеп, кирәк булганда ярдәм оештыра. П. С. Кондырев Казан губернасының бөтен мәктәпләрен диярлек йөреп чыга, ә Кавказ губернасына халык мәгарифе эшен җайга салу өчен җибәрелгән Е. П. Манасеин халыктан мәктәпләр файдасына 60 мең сум иганә җыелуына ирешә. Себер халыклары өчен мәктәпләр ачуда да Казан университетының фидакарь хезмәте күп кергән. 1825 елда инде Казан уку округында барлыгы 10 гимназия, 2 зур училище, 78 өяз мәктәбе һәм 2 кечкенә уку йорты булуы мәгълүм (биредә әле бары дворяннар өчен генә булган уку йортлары исәпкә алынмый). Университет ачылган вакытлар (1804 ел) белән чагыштырганда, укучылар саны — өч, ә укытучылар саны дүрт тапкыр чамасы арта. Әлеге уку йортларында рус булмаган милләт вәкилләреннән дә шактый кешегә белем алу мөмкинлеге тууын исәпләсәк, патша хөкүмәтенең «инородец» халыкларны караңгылыкта тотарга омтылу политикасына каршы университет алып барган эшчәнлекнең әһәмияте тагын да тулырак күз алдына килә.

«Халыклар төрмәсе» шартларында да, мәгърифәт яктысына тартылу тәэсирендә, милли мәктәпләр ачу проектлары дөньяга килә башлый. 1818 елда университет профессоры П. С. Кондырев белән көнчыгыш разряды адъюнкты Ибраһим Хәлфин тәкъдим иткән бер проект үзенең кыюлыгы һәм камиллеге белән игътибарны җәлеп итә. Ул проектта «бары иманалы» кешеләрнең балалары өчен генә Казанда үзәк татар мәктәбе оештыру идеясе алга сөрелә (ТАССР Дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасв. сакл. бер. 962, 24 бит). Ләкин бу идея Халык мәгарифе министрлыгында кискен каршылыкка очрый. Андый мәктәп ачкан тәкъдирдә, әлеге укучыларны салым түләүчеләр катлавыннан чыгарырга туры киләчәк, ә моның өчен законлы нигез юк бит, дип дәлилли үзенең каршы фикерен министр.

Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов һ. б. ларның татарлар өчен дөньяви мәктәпләр кирәклеген искәрткән проектлары, Казан университетында И. Хәлфин шәкерте булган Айса Бикмаевның кыргыз-казах балаларына дөньяви белем бирүче мәктәп ачу тәкъдиме, профессор Ф. Эрдманның, К. Фойгтның Казанда Шәрык институты оештыру идеясе мәгълүм (бу хактагы документлар ТАССР Дәүләт архивында саклана: 92 фонд, 1 тасв. саклау бер. 2916, 5170; китаптан укырга мөмкин: «Воспоминания об И. А. Алтын-Сарине Н. Ильминского».— Казан, 1891, 47 бит.) Патша самодержавиесе, мөселман руханиларының реакцион канатына таянып, әзлекле рәвештә әлеге тәкъдимнәрне кире кагып тора, ләкин вакыт агышын, халыкның белемгә омтылу көчен җиңә-туктата алмый. Татар һәм башка милләт балалары өчен дөньяви уку йортлары ачылу көннәнкөн ышанычлырак төс ала. XIX гасыр урталарына авылларда татар мәктәпләре 430 га җитә. Башкорт училищесы өчен бина салу озакка сузылганлыктан, университет советы 90 башкорт малаен төрле шәһәрләрнең уку йортларына урнаштыруга ирешә. 1853 елда Уфа гимназиясендә татар теле кафедрасы булдырыла (ТАССР Дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасв., сакл. бер. 7439). Мордва, калмык, чуваш, мари һ. б. халыклар өчен мәктәпләр ачу юнәлешендә дә Казан университеты зур кайгыртучанлык күрсәтә һәм заманына күрә шактый уңышка ирешә. Мәсәлән, Әстерханда 50 укучылы калмык мәктәбе һәм әрмән училищесы оештырыла. Мондый мисалларны бик күп китереп булыр иде.

Университет тырышлыгы һәм ярдәме белән 1876 елда Казанда татар укытучылар мәктәбе ачылу халкыбыз тормышында ифрат зур роль уйный. 1917 елга кадәрге чорда бу мәктәп 389 укытучы әзерләп чыгара. 1904 елны нәкъ менә биредә татарларның беренче социал-демократик түгәрәге оеша. Казан укытучылар мәктәбендә төрле елларда М. Корбангалиев, Г. Әхмәров, Р. Газизов, М. Фазлуллин, Н. Мөхетдинов кебек галимнәр һәм педагоглар, Х. Мәүлетов, Я. Чанышев кебек гражданнар сугышы каһарманнары, шулай ук беренче татар большевигы Х. Ямашев һәм пролетар язучысы Г. Коләхметов укыган.

Казан университеты укытучылары һәм галимнәре, халык мәгарифе дошманнары белән көрәшә-көрәшә, фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр: мәктәпләр өчен программалар, хрестоматияләр, дәреслекләр, методик әсбаплар төзиләр, укучыларның белемен тикшерү системасы эшлиләр, алар төрле халыкларның грамматикасын һәм сүзлекләрен төзүгә зур өлеш кертәләр: татарларда моны Сәгыйт һәм Ибраһим Хәлфиннәр, С. Куклэшев, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Ш. Әхмәров һ. б.лар эшли; чувашлар өчен — С. Михайлов, Н. Золотницкий, И. Яковлев; мариларга — В. Васильев, П. Еруслаанов, И. Маляров, С. Нурминский, Т. Семенов... Әлегәчә үзенең язуы янсә тел дәреслекләре булмаган күп кенә халыкларның беренче әлифбалары һәм грамматикалары Казан университеты типографиясендә басылып чыга. Университет галимнәренең хезмәтләре һәм алар язган дәреслекләр төрле тәбәкләрнең уку йортларында беренче ярдәмлек сыйфатында йөри. Мәсәлән, Н. В. Поповның монгол телендә төзегән арифметика дәреслеге гимназияләрдә, бурят мәктәпләрендә киң кулланыла. Ә бит күп кенә телләрдә, шул исәптән монголларда да, әле математик терминнар бөтенләй булмаганын искә алыйк; мондый киртәләрне университет галимнәре кыю җиңеп чыгалар. Алар төзегән дәреслекләрнең даны Идел һәм Урал буй-

ларында еракка тарала, Урта Азия, Кавказ халыкларына яктылык алып бара, хәтта чит илләрдә дә лаеклы кулланылыш таба.

Рус булмаган халыкларның аң-белем дәрәҗәсен үстерүгә Казан университетының дөнья күләмендә танылган көнчыгыш разряды галимнәре керткән өлешне бәяләп бетерүе дә кыен. Шуның өстенә, алар төзегән дәреслекләр буенча Европа студентлары көнчыгыш телләрен үзләштерә, Казан галимнәренең хезмәтләре немец, француз һ. б. телләрдә чыгучы чит ил журналларында басыла. Шәрык белеме өлкәсендә Европаның 37 университеты Казан белән даими бәйләнештә тора. 1843 һәм 1845 елларда Казанда булып киткән күренекле фин галиме Матиас Кастрен шул чорда: «Казан университетында Европага танылган ориенталистлар бар, һәм якын киләчәктә Шәрыкка кагылышлы гаять мөһим гыйльми проблемаларның нәкъ менә биредә хәл ителәчәгенә нык ышанам»,— дип яза [1]. Аның сүзләре дөрес булып чыга. Көнчыгышны өйрәнүнең тәҗрибәле, зур үзәкләре — Берлин, Вена, Лондон, Париж — иң мөһим мәсьәләләрдә Казан университетына, аның М. Френ, А. Казимбек, И. Хәлфин, И. Березин, О. Ковалевский, М. Мәхмүдов кебек галимнәренә йөз тоталар.

Ректор Н. И. Лобачевский тырышлыгы белән университетның көнчыгыш разрядына Европа белеме алган һәм шәрык культурасын яхшы белгән укытучылар — татар, төрек, фарсы, гарәп, әрмән һ. б. милләт вәкилләре туплана. Алар рус һәм Европа культурасының алдынгы традицияләренә таянып эш итәләр, Идел буе халыклары арасында прогрессив идеяләр һәм карашлар таралуына зур өлеш кертәләр. Университет ориенталистлары шәрык халыкларына, аларның культурасына зур хөрмәт белән карыйлар, тарихларын тирәнтен өйрәнәләр. Шәрык белеме башка халыкларны кимсетүгә корылган рәсми политика белән кискен көрәш эчендә үсә, гади кешеләрнең милли аерымлыкларын санга сукмыйча бер-берсенә дустанә мөнәсәбәтенә нигезләнә, ил күләмендә куәт алып килүче азатлык хәрәкәте белән бәйләнештә яши.

Казан университеты галимнәре җирле халыкларның культура һәм әдәбият тарихын җитди тикшерүгә зур игътибар бирәләр, халык иҗатын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнүне фәнни нигезгә куялар. Университет бу төбәктәге культура тормышына эзлекле һәм көчле тәэсир ясарга омтыла, шәһәрнең иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтенә юнәлеш бирүче үзәккә әверелә бара. Биредә төрле темаларга лекцияләр укыла, җыелышлар һәм фәнни диспутлар үткәрелә, университет кабинетлары һәм музейлары һәр якшәмбедә, шәһәр кешеләре өчен махсус ачыла. 1830 елдан башлап университет китапханәсе дә гомумшәһәр китапханәсе дип игълан ителә, теләгән кешегә аның хәзинәләреннән файдалану мөмкинлеге тудырыла.

Казан университетының «караңгылык патшасындагы якты нур» булуы, иҗтимагый тормышта тоткан роле җирле матбугатка нигез салу өлкәсендәге эшчәнлеге белән дә тагын бер кат раслана.

Университет адъюнкты, яңалык өчен көрәшергә һәрвакыт әзер торган, киң карашлы һәм тирән белемле И. И. Запольский әле 1808 елда ук рус һәм татар телләрендә газета чыгару проектын тәкъдим иткән була. Аның идеясен университет советы да, губернатор Б. А. Мансуров та яклый. Ике елдан патша Россиясенең министрлар кабинеты Казанда газета чыгара башларга рөхсәт бирә, ләкин... бары рус телендә генә. Шул рәвешле, 1811 елның 19 апрелендә «Казанские известия» газетасының беренче саны дөнья күрә, 19 нчы саныннан башлап, аны нәшер итү эшен университет үз кулына ала. «Казанские известия» провинциядә чыга башлаган өченче матбугат органы була һәм үз төбәгенең иҗтимагый-мәдәни тормышында зур роль уйный. 1812 елгы Ватан сугышы турындагы мәгълүматлары белән ул бүген дә кыйммәтле тарихи чыганак булып кала. 1812 елда шушы газетада А. В. Суворовның «Җиңү фәне» (№ 35), М. И. Кутузов чыгышлары (№ 37), К. Минин һәм Д. Пожарский эшчәнлеге турында хәбәрләр басыла. «Казанские известия» сугыш хәрәкәтләре барышын даими яктыртып килә, шәһәрдә биш мең кешедән торган ополченецлар отряды оештырылуы хакында сөйли.

Адъюнктлар М. Рыбушкин белән М. Полиновский чыгарган «Заволжский муравей» исемле фәнни-популяр һәм информацион журнал да рәсми матбугатка каршы юнәлештә эш итүе һәм эчтәлеге белән нык үзенчәлекле. Аның эшендә университетның танылга галимнәре (К. Ф. Фукс, Ф. И. Эрдман һ. б.лар) актив катнаша. Биредә басылган материаллар арасыннан рус булмаган халыклар тарихына кагылышлылары аеруча игътибарга лаек тоела. Болгар һәм Казан ханлыгы тарихы, башкорт, чуваш, чирмеш, вотяк, кыргыз һәм казакъларның көнкүреше, татар-башкорт җырлары, борынгы татар язулары...— әлеге материаллар менә шундый төрле темаларга багышланган. Журнал шулай ук Көнбатыш Европа, Америка, Шәрык авторлары иҗатына киң мәйдан бирә. Шәрык әсәрләрен Салихҗан Күкләшев тәрҗемә итеп бирә. «Казанский муравей»ның подписчиклары Казаннан алып Камчаткага кадәр булуын да искәртеп үткәндә, аның йогынтысы никадәр киң мәйданга таралуын күз алдына китерүе кыен булмастыр.

Шул ук елларда университетта төрле прогрессив юнәлешле җәмгыятьләр, түгәрәкләр оеша һәм уңышлы гына эшли башлый. Мәсәлән, Н. М. Ибраһимов, П. С. Кондырев һ. б. лар төзегән әдәбият сөючеләр җәмгыяте («Общество любителей Отечественной словесности») Идел буенда яшәүче башка халыклар арасында рус һәм

[1] N. A. Kastren. Nordische Reisen und Forschungen. Spt. 1856, S. 21.

дөнья әдәбияты казанышларын пропагандаларга омтыла, әлеге халыкларның авыз иҗатын җыюга зур әһәмият бирә. Шушы җәмгыятьтә С. А. Аксаков үзенең әдәби эшчәнлеген башлый.

Университет стеналары эчендә төрле җәмгыятьләр оешуны билгеле бер дәрәҗәдә социаль, рухи һәм политик омтылышлар уртаклыгын белдерүнең үзенчәлекле формасы итеп карарга кирәк. Бу — узган гасырның 60 нчы елларында һәм аннан соңрак күтәреләчәк куәтле ташкынга — Казан студентларының массалы революцион чыгышына таба көч җыя-җыя йөгерүче беренче гөрләвекләр. Университетта үткәрелә торган әдәби-музыкаль кичәләрдә Казандагы «Земля и Воля» комитеты җитәкчеләре, политик сөргенгә җибәрелгән кешеләр катнашуы җәмгыятьнең төрле катлауларында самодержавиегә каршы настроениеләр, карашлар формалашуына зур этәргеч ясаган, әлбәттә. Бу кичәләрдән килгән керем ярлы студентлар һәм гимназистлар, ятимнәр йортлары, китапханәләр, кызлар мәктәпләре файдасына җибәрелгән. Ул акчаның бер өлеше революцион подполье ихтыяҗларына тотылган, бер өлеше якшәмбе мәктәпләренә бирелгән.

Асылда университет студентлары инициативасы белән ачылган якшәмбе мәктәпләре турында аеруча басым ясап әйтергә кирәк. Арада иң прогрессив юнәлешлесе студент (соңрак «Земля и Воля»ның Нижний Новгород бүлеге җитәкчесе) Н. Копиченко тәкъдиме: ул «түбән катлау кешеләре, шулай ук татарлар күп яшәгән Суконный бистәсендә якшәмбе мәктәбе ачу идеясен күтәреп чыга. Төрле милләт балаларының бергә укуы алар арасында дуслык-якынлык бәйләнешләре урнашуга нигез була, аларга хезмәт халкының уртак омтылышларын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. «...Рус малайлары аңлавынча, аларның шәрикташе — татар малае... башкалар кебек үк кеше һәм туган,— дип яза «Современник» журналы, әлеге эшчәнлекне бәяләп.— Уртак ниятләр һәм теләкләр белән яшәүче, бер үк максатка омтылучы бу күмәк гаиләгә карап торуы күңелле». (1861, 85 том, 355 бит). Н. Копиченко үзе 700 дән артык баланы сыендырган якшәмбе мәктәбенең эшен җитәкли. Университет студентлары бу юнәлештәге эшчәнлекләрен Казан белән генә чикләмиләр, Астрахань, Вятка, Саратов, Сембер, Пермь һ. б. төбәкләрдәге якшәмбе мәктәпләренә дә турыдан-туры ярдәм итәләр.

Казан университетында өстенлек иткән прогрессив атмосфераны, алдынгы карашлы профессорлар һәм студентларның нәтиҗәле эшчәнлеген дәлилләп торган мисаллар бик күп. Сүз уңаенда аларның янә берсен генә — 1877—1878 елгы рус — төрек сугышы вакытында ярдәм фондына студентлар һәм укытучылар тарафыннан 18 мең сумнан артык акча җыелуын, үзләре теләп сугышка китүчеләр сафында университет укытучылары һәм студентларының да булуын билгеләп үтәргә мөмкин.

Патша хөкүмәтенең реакцион басымына каршы торып, Казан университеты төрле юллар һәм алымнар белән культура, мәгърифәт, фән һәм идея-политика өлкәсендәге актив көрәшен дәвам итә, Идел — Урал буйларындагы күп милләтле халык массаларының иҗтимагый фикерен формалаштырып, аңа юнәлеш биреп килә. «Күпчелектә ярлы студентлардан»[1] торган бу уку йорты революцион хәрәкәт үзәкләренең берсенә әверелә. XIX йөз урталарыннан башлап, университет кафедрасыннан крепостное право өшәкелекләре ачыктан-ачык фаш ителә, Н. Г. Чернышевский, Н. А. Добролюбов, А. И. Герцен идеяләре пропагандалана, ниһаять, бөредә, бөтен халык алдында профессор А. П. Щапов крепостное правоны юк итәргә чакыру ташлый. Щапов лекцияләре уңаеннан, мәсәлән, Г. В. Плеханов: «Искиткеч дәрәҗәдә кызыклы факт, һәм ул безнең университетлар тарихында бердәнбер хәл түгел микән әле»,— дип яза.

Алдынгы һәм хөр карашлы укытучылар белән аралашу, аларның лекцияләрен тыңлау студентлар өчен революцион рух мәктәбе була. Сходкалар, революцион түгәрәкләр һәм җәмгыятьләр оештыру, тыелган китаплар тарату, башка шәһәрләрнең демократик яшьләре белән хезмәттәшлек...— Казан студентларының революцион активлыгы менә шундый формаларда чагыла. Һәм бу чыгышлар, очраклы гына күренеш булып калмыйча, әзлекле юнәлешкә буйсынган, ачык максаты билгеләнгән, көчәйгәннән-көчәя баручы, оешкан хәрәкәт төсен ала.

Казан студентларының революцион активлыгы, әлбәттә, тагын кайбер шартлар белән бәйләнгән. Шулардан иң беренчесе, мөгаен, 60 нчы елларда университетта укучыларның җитмеш процентка кадәресе социаль чыгышы белән разночинецларга (ягъни дворян булмаган сословиеләрдән чыккан интеллигентларга туры килүендәдер. Ә ул чорда, В. И. Ленин билгеләп үткәнчә, разночинецлар — гомумроссия демократик хәрәкәтендә иң төп, массовый рәвештә катнашучы катлам булып тора. Шуның өстенә, революцион настроениеләр кайнаган Казан турында сүз барганда, бу төбәкнең Россия мәмләкәтендә үзенчәлекле урын тотуын да истән чыгарырга ярамый. Идел — Урал җирләрендә телләр, гореф-гадәтләр, культуралар гына түгел, диннәр төрлелеге һәм каршылыгы да үзен нык сиздерә, һәм шуның бер нәтиҗәсе буларак, хезмәт халкына икеләтә авыр йөк — социаль изү өстенә милли-рухани басымны да күтәрергә туры килә. Бу хәл, үз нәүбәтендә, азатлык өчен көрәшнең бирдә аеруча зур потенциаль көч белән баруына сәбәпче була. Шулай ук революцион атмосфера тууын тизләтеп, Казан аша каторга һәм сөрген юлы үтә, царизмга каршы эшчәнлекләре өчен сөрелгән кешеләрнең бер сыену урыны да Казан була...

[1] «Русское слово», 1860, № 3, от. II, 38 бит.

Күпмилләтле төбәктә ачылган университетның эшчәнлегенә әнә шулай төрле көчләр, төрле факторлар тәэсир итә. Шуңа күрә, әйтик, студентларның социаль характеристикасы белән генә чикләнмичә, милли чыгышларына да игътибар итү бик зарури. Дөресен әйткәндә, бу — әлегәчә анык хәл ителеп, ачыкланып бетмәгән катлаулы мәсьәләләрнең берсе. Чөнки, патша хөкүмәте алып барган колониаль политиканың бер чагылышы буларак, үз вакытында студентларның этник чыгышы (милләте) санга сугылмаган, теркәп калдырылмаган. Шуңа күрә соңгы елларга кадәр махсус һәм фәнни-популяр әдәбиятта, Казан университетында революциягә кадәр белем алган башка милләт вәкилләре бармак белән генә санарлык дигән фикер хөкем сөрде. Күп төрле чыганаклардан эзләнү нәтиҗәсендә, ниһаять, университет тәмамлаган татар студентларының 6 гына түгел, ә 92 булганлыгы ачыкланды (әлбәттә, польша һәм литва татарларын исәпкә алмаганда). Әле бу санны да иң соңгы чик дип раславы читен, вакыт үтү белән, яңа эзләнүләр нәтиҗәсендә, татар студентларының саны да, социаль чыгышы һәм политик карашлары да, иҗтимагый-политик һәм революцион чыгышларда катнашу дәрәҗәсе дә төгәлрәк билгеләнергә тиеш.

Университет студентларының милли составын белү Россиядәге азатлык өчен көрәш хәрәкәтендә рус булмаган халыкларның өлешен өйрәнү өчен кирәк. Хәзергә билгеле булган мәгълүматлар, архив документлары исә татар студентларының азатлык хәрәкәтендә, царизм белән көрәштә актив катнашулары турында сөйли. Мәсәлән, әле крепостное право хакимлек иткән чорларда ук Ибраһим Хәлфин белән Салихҗан Күкләшев рус һәм поляк революцион хәрәкәте белән бәйләнештә торалар (бу хакта тулырак мәгълүматны 1972 елда Казанда басылган «Историография федосеевских марксистских кружков Поволжья» дигән китаптан табарга мөмкин). Крепостное право тәртипләре җимерелеп төшкән елларда татар студентлары хөкүмәткә каршы чыгышларда актив катнашалар. Прокламацияләр тараткан өчен, Казан студентлар землячествосының танылган җитәкчеләре белән бергә, М. Котлыбаев, И. Рәҗәпов, А. Габделгалләмов университеттан чыгарыла. Крестьяннарны азатлык һәм тигезлек өчен көрәшкә чакырган прокламациянең авторы Курбаковский (А. Щапов шәкертләренең берсе) белән элемтәләре өчен Сәлахов фамилияле татар студенты жандармнар кулына эләгә. Бу фактлар башка халыкларның да милли аңы үсүе, дини киртәләргә дә карамастан, бөек рус халкына якынаерга һәм аның культурасын үзләштерергә омтылуы, һәртөрле изүгә каршы көрәшкә кушылуы турында сөйли. Россия халыкларының самодержавиегә каршы бердәм көчкә әверелә баруына нигез әнә шундый шартларда салына.

# МӨХӘММӘТ ГАЛИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Мөхәммәт Гали — Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк авыл тормышы турындагы хикәяләре белән танылган, революция җиңүенең беренче елларыннан алып совет матбугатында актив эшли башлаган әдип. Аның сан ягыннан күп булмаган, ләкин үзенчәлекле стильдә иҗат ителгән хикәяләре, кыска-кыска очерклары, берничә драма әсәре һәм, ахыр килеп, әдәбият тарихын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләре татар культурасында лаеклы урын алды.

М. Галинең каләм тибрәтә башлавы Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укыган елларына туры килә. Аның «Авыл тормышы» исемле беренче әсәре 1911 елда «Йолдыз» газетасында басылып чыга.

Һаман да эзләнгән, яктылыкка омтылган яшүсмер Мөхәммәт 1912 елның урталарында Казаннан Оренбург шәһәренә китә, атаклырак уку йортларыннан саналган «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга урнаша. Ныклы тәртип урнаштырылган булуы, программасына яңа фәннәр укыту кертелүе ягыннан бу мәдрәсәнең даны читкә таралган булса да, 1905 елгы беренче рус революциясеннән соң уяна башлаган яшьләрне инде әлеге шартлар гына канәгатьләндерә алмый. «Хөсәения» шәкертләренең 1912 елда баш күтәрүендә Мөхәммәт Гали дә катнаша, мәдрәсәне ташлап чыгучылар белән бергә Оренбург урамында эш эзләп йөри. Ләкин эш таба алмаганлыктан һәм башкача яшәргә мөмкинлекләре дә булмаганлыктан, яңадан мәдрәсәгә кайтып керергә мәҗбүр була.

Казан һәм Оренбург мәдрәсәләрендә уку, бигрәк тә шәһәрдә яшәү М. Галинең иҗат эшенә керешүенә беркадәр юл ача.

«Хөсәения» мәдрәсәсендәге әдәбият мөгаллименең ярдәме белән, 1914 елны «Аң» журналында «М. Гали» имзасы белән бер-бер артлы ике хикәя басылып чыга. Һәм шул көннәрдән алып, М. Гали имзасы белән «Аң» журналында хикәяләр еш кына күренә башлый. Дөрес, аның бу башлангыч иҗат чорында язылган хикәяләрендә зур социаль проблемалар куелмаган. Аларның әһәмияте, беренче чиратта, яшь язучының табигать күренешләрен шактый оста тасвирлавында һәм үзенә таныш авыл көнкүрешендә булган кайбер якларны образлы, укырга күңелле итеп сөйләп бирә алуында иде.

1914 елда башланган империалистик сугышны, барлык хезмәт ияләре шикелле, М. Гали дә зур ризасызлык һәм тирән нәфрәтләнү белән каршы ала. Автобиографик белешмәсендә күрсәтелгәнчә, ул 1915 елда, «сугышка эләкмәс өчен», Украинага барып, тимер рудникларына кара эшче булып керә. Аннан Әстерхан аша Бакуга килеп, нефть промыселларында эшли. Ниһаять, Бохара якларына барып чыгып, анда грузчик була. Шуннан армиягә алына, 1916 елның февралендә фронтка озатыла, Австрия, Румыния фронтларындагы сугышларда катнаша. Төрле җирләрне күрү, бигрәк тә солдат хезмәтендә булу М. Галине тормышка ачыграк күз белән карарга өйрәтә, политик карашлары үсүгә дә ярдәм итә.

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәч, 1917—1918 елларда ул туган ягында (хәзерге Балык бистәсе районының Олы Елга авылында) башлангыч мәктәптә укыта. Гражданнар сугышының иң җаваплы елларында һәм ил хуҗалыгын аякка бастыру чорында М. Гали, бөтен көчен журналистлык хезмәтенә биреп, шул вакытның татар совет матбугатында иң актив эшләүче, актуаль темаларга мәкаләләр, очерклар биреп баручы язучылардан берсе була. Мөхәммәт Гали газеталарда эшләүне,

яшь Совет дәүләтенең беренче елларында матбугат аркылы киң массаларга тәрбия бирүне иң җаваплы эшләрнең берсе итеп карый. Соңыннан да ул үзенең журналистлык хезмәтен иҗат эшчәнлегенең иң әһәмиятле бер өлеше дип саный.

Халык массалары белән бергә эшләү, газеталарга килгән күп сандагы хәбәрләр белән якыннан танышу М. Галигә тирән эчтәлекле тормышчан хикәяләр язарга булышлык итә. Ул 1919 елда «Кызыл Армия» газетасында басылган «Сәмигыл карт» исемле бер хикәясендә үк үз вакытының авыл тормышында барган социаль үзгәрешләрне шактый тулы һәм уңышлы сурәтләп бирүгә ирешкән иде.

Мөхәммәт Гали иҗатында иске авылны, аның гореф-гадәтләрен хикәяләү зур урын алып тора. Аның бу тармактагы әдәби эшчәнлеге гражданнар сугышы чорында башланып, 20 нче елларда тагы да киңәя. «Хикмәт хәзрәт» (1918), «Яңгырсыз елларда» (1921), «Пожарныйлар» һәм «Көтүчеләр» (1923) хикәяләре — әнә шуңа мисал. Аларның теленә Мөхәммәт Галичә җыйнаклык, пөхтәлек хас.

Колхозлашу чорында язган хикәяләрендә дә («Чәчүлек сукканда», «Таз Шәрәфи», «Рәхмәтулла тегүче» һ. б.) язучы иске тормышның караңгы якларын бик еш искә ала, совет чорында үсеп килгән яңа авылны, яңа рухлы кешеләрне аңа контраст итеп куя.

М. Гали совет чорында үскән яңа кешеләр турында үзенең очеркларында да дулкынланып сөйләде («МТС басуларында», 1933; «Беренче класс укчысы», 1940 һ. б.). Элек грузчиклыкта эшләгән, совет чорында күренекле галим булып үсеп җиткән профессор Гыйлем Камайга багышлап язылган очерк аерым китап булып та басылды («Ул үсте», 1936).

Хәсәен Уразиков белән бергә иҗат ителеп, 1945 елда сәхнәгә куелган «Каюм Насыйри» пьесасы Мөхәммәт Галинең драматургия өлкәсендә дә уңышлы гына эшли башлавын күрсәтә. Ул, гомумән, пьеса язудан тыш та атаклы татар галиме К. Насыйри яшәгән чорны өйрәнүгә зур көч куя, аның кульязмаларын җентекләп тикшерә, әсәрләрен җыеп бастырып чыгаруда актив катнаша. Ахырда, шул чорны җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә, «Каюм Насыйри» яки «Бөек мәгърифәтче» исеме белән зур бер роман язу уена килә. Ләкин вакытсыз үлеп китүе аркасында (1952), ул әсәр тәмамланмый кала.

М. Гали татар совет әдәбияты белеме өлкәсендә беренче буларак зур күләмле монография язып чыга. Классик драматург һәм күренекле совет язучысы Галиәсгар Камалның тормыш юлын һәм иҗат мирасын өйрәнеп язылган монография бай фактик материалга нигезләнүе белән генә түгел, олы иҗатка дөрес бәя бирүе ягыннан да үзенчәлекле иде. Аның күпләр әдәби әсәрләрне тикшерүдә тик социологизм методы белән генә мавыккан вакытта басылып чыгуы исә бигрәк тә әһәмиятле иде.

Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүгә дә М. Гали үзеннән зур өлеш кертте. Аның «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» дигән сатирик поэма турында язган зур гына хезмәте мәгълүм. М. Галинең Тукайны күреп белгән, аның белән бергә үскән бик күп кешеләрнең истәлекләренә таянып язылган хезмәтләре дә игътибарга лаеклы. Алар бөек шагыйрь биографиясен тулыландыруда, аның җанлы образын тудыруда әле дә кыйммәтле чыганак булып тора.

**МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИН,**
РСФСРның атказанган фән эшлеклесе.

# ЗӘЙНИ ШАҺИМОРАТОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Зәйни Шаһиморатов (Ш. Зәйни) — театр һәм драматургиябез тарихында мәгълүм эз калдырган әдипләрнең берсе. Аның зур гыйбрәт һәм эстетик ләззәт бирүче пьесалары нигезендә куелган спектакльләрне тамашачы яхшы хәтерли.

Ш. Зәйни үз иҗатына һәрвакыт зур җаваплылык белән карады, әсәрендә чагылдырачак тормышны җентекләп, бөтен нечкәлекләренә кадәр өйрәнеп, белеп язды. Шуңа күрә аның «Таң җыры», «Гөмбәз асты серләре», «Раушан», «Уеннан уймак», «Хәят», «Йосыф-Зөләйха», «Энҗе бөртекләре», «Тугыз гашыйк», «Хәзрәт үгетләргә килде» әсәрләре тормышчан эчтәлекләре, табигый агышлары белән үзенчәлекле.

Драматургның беренче иҗат тәҗрибәләре 1935—36 елларда Татар театр техникумын тәмамлап республика Халык иҗаты йортында эшли башлаган чакларыннан ук башлана. Зәйни Шаһиморатов тамашачыларны җәлеп итәрлек скетчлар, бер пәрдәлек пьесалар, үткен һәм тапкыр телле эпиграммалар, шулай ук курчак театры өчен пьесалар да яза. Аның 1937—38 елларда татар халык әкиятләре нигезендә язган «Шүрәле» исемле драма-балладасын Казан курчак театры зур уңыш белән сәхнәгә куя һәм бу спектакльне нәни тамашачылар яратып, бик кызыксынып карыйлар. Балаларга олы шатлык бирүче бу төр иҗат эшчәнлеген дәвам иттереп, ул «Мәч-мәчин» һәм «Айтуган» исемле пьесаларын яза. Бу пьесалар Казанда гына түгел, Башкортстанда, Уфа курчак театрында да зур уңыш белән бара. Сугыштан соң да Ш. Зәйни Курчак театры белән иҗат дуслыгын өзми. Бөек Ватан сугышында гитлерчы фашистларга каршы героик көрәшләрен чагылдырган «Кечкенә партизаннар» исемле драматик балладасын яза.

Зәйни Шаһиморатов үзе дә кыска сроклы пехота училищесын тәмамлаганнан соң, ут сызыгына баса, Мәскәү янындагы, Калинин фронтындагы аяусыз сугышларда катнаша. Сталинград оборонасында да, Курск дугасында да, шулай ук Польша, Чехословакия, Австрия халыкларын илбасарлардан азат итү һәм Берлинны алу өчен барган сугышларда да үз-үзен аямый көрәшә.

...Сугышка кадәр үк, әле театр техникумында укыган чагында ук Зәйни Шаһиморатовны яхшы белә идем. Сугышта, һич көтмәгәндә, 1944 елны кабат күрешү бик күңелле булды. Фронтта күргәннәр, баштан кичкән хәлләр, туган яктан килгән хәбәрләр турында сөйләшеп утырдык. Аның фронтта фашист өерләренә каршы барган авыр сугышларда күрсәткән батырлыклары, берничә тапкыр үлем куркынычы кичереп тә, үзенең тапкырлыгы, кыюлыгы аркасында гына исән калуы шатландырды мине. Зәйни Шаһиморатов безнең янга — «Ватан намусы өчен» исеме белән чыгарыла торган фронт газетасының татар редакциясенә килергә теләгән белдерде. Фронт редакциясе шартларында кече лейтенант Зәйни Шаһиморатов үзен кыю солдат та, эшен яхшы белеп, төгәл башкаручы журналист та итеп күрсәтте.

Сугыш тәмамлангач, безнең редакция бер елдан артык Австриянең башкаласы Вена шәһәрендә эшләде. Зәйни Шаһиморатов Вена театрларына, концерт залларына йөрде, ул кызыксынмаган берниндн матурлык, берниндн сәнгать әсәре юк иде диярлек. Шул кызыксыну аны Моцарт яшәгән, «Фигароның өйләнүе» кебек атаклы әсәрләрен язган йортка да, гүзәллеге белән барлык кешеләрне әсир иткән Вена урманнарына, зәңгәр Дунай буйларына да алып барды. Зәйни Шаһиморатов сәнгатьне, гомумән олы талантлар иҗат иткән гүзәл әсәрләрне яратуы белән бергә табигать матурлыгына да гашыйк иде. Шушы мәхәббәт аны зур иҗатка рухландырды.

Бөтен гомерен Социалистик Ватаныбызның үсешенә, ныгуына, иминлегенә багышлаган, бөек Ленин идеяләрен тормышка ашыру өчен армый-талмый көрәш алып барган каләмдәш дустыбыз бүген инде безнең арабызда юк. Әмма безгә, халкыбызга кадерле мирас булып калган, ул озак еллар буе үзенә хас тырышлык, җентеклелек, җаваплылык белән иҗат иткән әсәрләре бар.

Зәйни Шаһиморатовның әдәби мирасын булдыру, аның әсәрләрен дөньяга чыгару безнең зур бурычыбыз булып кала.

РИЗА ИШМОРАТ.

## Изаил Зарипов

# ТУГАН КӨН

ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ



Бала үзенең туган көнен, Яңа елны көткәндәй, зарыгып көтә. Рәмзия дә туган көнен зарыгып көтте. Әтисенең:

— Кызым, туган көнеңне син ни өчен яратасың?— дигән соравына:

— Барысы да киләләр. Барысын да сыйлыйсың. Үзең дә сыйланасың. Барысы да бүләк алып килә,— дип җавап бирде.

Быел апрель аенда Рәмзиягә биш яшь тула. Исмәгыйлевләр бу көнгә алдан ук әзерләнә башладылар. Рәмзия иртә саен күзен ача да:

— Туган көнгә тагын күпме калды,— ди.

Кызыйның яраткан ризыкларына инде заказлар да бирелде. Өстәлне алты кешелек кенә хәзерләргә булдылар. Кунакларны үзләренең ишегалдыннан һәм Рәмзиянең бакчасыннан гына чакырырга сөйләштеләр. Күбрәк чакырырга әниләре рөхсәт итмәде.

Туган көн килеп җитте дигәндә генә әнисенең эшендә күптән көтеп йөргән санаторийга яна торган путевка барлыгы беленде. Әнисе икеләнеп калды: туган көнне дә үткәрәсе бар, путевканы да кулдан ычкындырасы килми. Рәмзиянең дә кәефе кырылды: әнисе ясаган пилмәннәр булмагач, нинди туган көн инде ул?

Бу хәл Илгиз Идрисовичны сөендерде генә: әтисенең аны ничек яратуын күрсен әле кызы.

— Уйлап та торма, әнисе, бар,— диде ул хатынына.— Бер дә борчылма, үзебез ерып чыгарбыз.

Ә бакчага барганда, кызына әйтте:

— Әниеңә дәваланырга кирәк. Барып кайтсын. Ә без туган көнгә пилмәнне шундый күп пешерербез, бөтен дусларыңа да җитәр.

— Бөтенесен дә чакырабызмы?— дип очынды Рәмзия.

— Әйе, бөтенесен дә,— дип ант итте әтисе.

— Кадрияне дәме?

— Кадрияне дә!

— Наташаны да?

— Наташаны да!

— Әлфияне дә?

— Әлфияне дә!

— Розаны да?

— Розаны да!

— Сәлимәне, Светаны, Алсуны, Зөлфияне, Венераны дамы?

— Әйе, аларны да!— Бу исемнәрдән әтисенең башы ук әйләнә башлады.
— Гуляны да?— дим дәвам итте кызы.
— Гуляны да!
— Юк, әти, Гуляны чакырмыйк.
— Нигә, кызым?
— Аның, әти, борыныннан ага.
— Минемчә, ул — бик пөхтә кыз,— диган булды әтисе. Гуляны ул бөтенләй белми иде.
— Пөхтә сиңа. Аңа әле өченче яшь кенә китте.
— Ә Зөлфиягә ничә?
— Ул инде өченче класста укый.
— Хм,— дип куйды Исмәгыйлев.— Кызым, ә ул Зөлфия дигәне синең компаниягә зуррак булмасмы соң?
— Юк! Зөлфия Гуляны бик ярата. Аның борынын сөртә. Гуля башка берәүгә дә сөрттерми.
Саный торгач, ике яшьтән унике яшькә хәтле унбиш кыз җыелды.
Табигатенә хас киң күңеллелек белән Исмәгыйлев эшкә керeште. Күрсен әле кызы әтисенең ничек яратканын!
Хатынын озаткач, Илгиз Идрисович кияүгә чыкмаган ике балдызын, хатынының ахирәтен һәм күрше хатынын ярдәмгә дәште. Иртәгә туган көн дигәндә, алар эшкә тотындылар. Биш йөз пилмән ясалды, дерелдәвек, винегрет, салатлар әзерләнде. Аннан тыш милли ашлар кибетеннән чәкчәк, бавырсак, ике гөбәдия, пирожныйлар сатып алынды. Лимонад, томат согы, шоколад конфетлар һәм башка шуныңише әйберләр дә табылды.
Мәҗлес башланырга бер сәгать каларак, Илгиз Идрисович рестораннан магнитофон хәтле ике торт та алып кайтты. Тортлар белән ишегалдыннан үткәндә, бер көтү кыз авыны күзләрен елтыратып озатып калдылар. Бу минутта һәр баланың күз алдында үтә дә тәмле торт тора иде.
Тортлар күренгәч, Рәмзия кулларын чәбәкли-чәбәкли сикеренде. Ишегалдында көткән иптәшләрен тизрәк өйгә чакырып кертәсе килде аның. Балкып, кабаланып, әтисе артыннан ул да йөгереп керде, мәҗлесне тизрәк башлап җибәрүне үтенде.
Барысын да тикшереп чыкканнан соң Исмәгыйлев кызының битеннән, борын очыннан үбеп алды да:
— Әйдәле, кызым, күзеңне йом әле,— диде.
Кызы күзләрен йому белән, ул шкафтан хатыны киткәч сатып алынган берничә кесәле, замоклы, күкрәгенә чәчәкләр, гөмбәләр төшерелгән нейлон куртка тартып чыгарды. Аннан шулай ук хатыны киткәч сатып алынган Буратино башлыгын алып киде. Башлыкның очында матур гына чук та бар иде. Шушы кәяфәтендә әти кеше кызы каршына чүгәләде дә:
— Ку-ку!— диде.
Кинәт күзен ачып җибәргән кызый күптән хыялланып йөргән әйберләрне күреп алды. Теге вакытны кибеттә әнисе алмый киткән әйберләрне әтисе кайдан белгән диген. Менә бит нинди аның әтисе! Кызый башта ышанып бетмичә генә кулын сузды, аннан бөтен гәүдәсе белән бүләккә тартылды һәм шул чакны әтисе, тореодор хәрәкәте ясап, куртканы кинәт бер якка авыштырды да кызның кочагында калды. Рәмзия, әтисен кочаклап, бер-ике үпте дә тагын, тагын кочаклады. Бу тамашаны күзәтеп торучыларның күзләреннән яшьләр бәреп чыкты.
— Менә ничек яраталар икән аны әтисе белән әнисе,— диде күрше хатын.
— Юк, мине әти генә шулай ярата,— диде Рәмзия, бүләкләрне күкрәгенә кысып.

Аннан ул кабаланып ишегалдына чыкты.

Эреле-ваклы унбиш кыз Исмәгыйлевлар квартирына әйтелгән вакытта шалтыраттылар. Илгиз Идрисович ишекне зур итеп ачты да өлкән кунакларны каршылагандай:

— Рәхим итегез, кадерле кунаклар!— диде.

Кунаклар, берәм-берәм кереп, кыяр-кыймас кына стена буена тезелештеләр.

— Кызым, әйдә, кунакларыңны кара,— диде Исмәгыйлев. Ләкин Рәмзия алар арасында юк иде. Хуҗа кеше, балдызына ымлап: «Әйдә, утырта башла»,— диде. Кызлар нигәдер тартыналар, теләр-теләмәс кенә чишенәләр иде.

— Тизрәк, тизрәк,— дип, хуҗа балдызын ашыктырды. Кунаклар, бүләкләрне кулдан-кулга күчергәләп, чишенә башладылар. Кечкенә Гуля гына Рәмзия кайтып кермичә башлыгын салдыртмады. Күп үгетли торгач, Зөлфия аны, ниһаять, чишендерде, әмма кызый башлыгын барыбер салдыртмады.

Ә Рәмзия һаман юк та юк.

Ишектә кинәт звонок чылтырады. «Ул!»— Ләкин бу Рәмзия түгел иде әле. Монысы күрше йорттан Света булып чыкты. Рәмзия аның белән үткән көзне генә дуслашты, аннан нигәдер аралары бозылды. Рәмзия дуслыкны кабат яңартырга тели иде, күрәсең.

— Әйдә, Светик, түрдән уз,— диде Исмәгыйлев.— Рәмзия синең белән түгелмени?

— Юк. Ул бездән Томаларга китте.

Тома дигәне моннан ике квартал ары тора иде. Үткән елны кызлар кинәт йөрешүдән туктадылар. Димәк, кызый монысы белән дә дуслыкны ялгап җибәрергә тели. Шулай да, дипломатик сөйләшүләрне бетереп, аңа өйгә кайтырга вакыт түгел микән. Ә залда ике яшьтән унике яшькә чаклы уналты кыз гөҗләшә. Һәркайсының бүләкне Рәмзиянең үз кулына тапшырасы килә.

Ишектә тагын звонок чылтырады. «Бусы, мөгаен, улдыр!»— Ләкин монысы Тома иде.

— Исәнме, Тома! Менә молодец! Ә Рәмзия кайда соң?— диде әти кеше.

— Ул бит бездән Наиләләргә китте.

Бу йортта торганда, Наилә Рәмзиянең иң якын дусларыннан санала иде. Кышын алар икенче йортка күчтеләр. Хәзер өч квартал ары торалар бугай.

Ишектә бер-бер артлы звоноклар чылтырап кына торды. Залда инде егермедән артык бала җыелды. Килгән кунакларның төрле яшьтә булуы Исмәгыйлевне борчый ук башлады. Төрле зурлыктагы өстәл һәм урындыкларны каян табып бетерергә? Иң элек Илгиз Идрисович өстәлне зурайтты, биегрәк урындыклар куеп чыкты. Кечерәкләр өчен дә балалар бүлмәсеннән бәләкәй өстәл һәм урындыклар чыгарды. Янәшә куелган ике өстәл баскычка охшап калды. Бу килеш бик тә ямьсез иде. Шунда хуҗа кеше өченче өстәлдән тегү машинасын идәнгә куйды да, аякларын тиз генә кисеп, ике өстәл арасына китереп кушты. Өстәлләр хәзер җыйнак кына баскычны хәтерләтәләр иде. Хатын-кызлар табын әзерләргә кереште, ә бала-чага, үзләренә урын чамалап, аяк астында буталды. Барысы да тиздән табынга киләсе тәмле-тәмле ризыкларны көтәләр иде.

Ә Рәмзия һаман юк. Исмәгыйлев үзенең ярдәмчеләрен кухняга җыйды да көтелмәгән бу хәлдән ничек чыгу хакында киңәшеп алды. Халыкны сыйлый башларга фик вакыт иде.

— Бәлки пилмәнне салырга вакыттыр?— диде хуҗа кеше.

— Таралып бетсен дисеңмени?!— дип куйды олы балдызы.— Бәлки ул әле тагын бер сәгатьсез кайтмас.

— Алайса, салкын кабымлыкларны чыгарыгыз,— дип тә ашыктырып карады хуҗа.

— Алар зурлар түгел ич?— Монысы хатынының ахирәте иде.

— Һич югында лимонад булса да ачыгыз.— Хуҗа бирешергә теләмәде.

— Ач карынгамы?— дип сүзгә кушылды күрше хатын.— Соңыннан чәй ташып җаның чыгар?

— Алайса, гөбәдия, бавырсак, чәкчәк булса да куегыз.— Хуҗа һаман үзенекен итте. Ләкин шунда кече балдызы да телгә килде:

— Рәмзия аларны музыкадан соң гына чыгарырга кушты.

— Ул нинди музыка тагын?

— Аның сюрпризы бар: ул сезнең өчен «Чижык-пыжик»ны өйрәнде.

— Шайтан алсын ул... «Чыжык-пыжык»ны.

— «Чижык-пыжик»ны?

— Ну, миңа барыбер...— Исмәгыйлев кулыннан власть ычкынуга көенеп, күз кыры белән өстәл тирәли күңелсезләнеп утырган балаларга карап алды.— Куегыз инде берәр нәрсә, болай бит тиздән эскәтерне ашый башлаячаклар. Торт чыгарыгыз!

— Кем инде татлыдан башлый,— дип каршы төште олы балдызы.— Соңыннан пилмәнне ашамаячаклар бит.

— Ашамаса, үзебезгә күбрәк калыр. Куегыз тортны! Әлегә — берне! Суыткычтан торт алып, хатынының ахирәте залга чыгып китте. Тортны кая куярга белми аптырап торганда, Гуля тотты да бармагын тортка батырды.

— Дөрес, Гуля, шулай кирәк!— дип хуплады аны Исмәгыйлев, кечкенә өстәлгә ымлап.— Монда куегыз!

Торт өстәлгә куелу белән, унлап кул аңа сузылды. Гуля торт өстендәге тәмле розаны эләктермәкче генә иде, Зөлфия аның кулын тотып алды.

— Башта борынны сөртик, ә менә хәзер башлыкны салсак та була.

Башлык астыннан идәнгә открытка очып төште. Бу Гуляның әтиәнисе тарафыннан Рәмзиянең үз кулына тапшырырга дип кисәтеп бирелгән открытка иде. Көтелмәгән бу хәлдән Гуля, кулларын бутыйбутый, кычкырып елый башлады. Күзендә яшь күренде. Зөлфия каушап калды, шундук аңа башлыкны кидертте, тынычландырырга тырышты. Ләкин кызый, башлыкта открытка юклыгын күреп, тагын да ачулырак кычкырды. Әмма шунда өстәл астында яткан открытканы күреп алды да ялт кына урындыгыннан шуып төште.

Тортны якынрак күчерү турында хыялланып утырган кызларга шушы берничә секунд та бик җиткән иде. Кызый открытка тотып, өстәл астыннан чыкканда, торт инде күршеләр кулында иде. Гуля моны кичерә алмады, кинәт елаудан туктады һәм, соңга калудан курыккандай, күрше өстәлгә омтылды. Нурия тортны өлешләргә бүләм дип кенә торганда эскәмиягә менеп баскан Гуля, кулындагы открыткасы белән сузылып, чәчәкләп бизәлгән торт өстен актарып ук ташлады.

Тавыш! Елау! Көлү! Күз яшьләре! Бу мәхшәргә кухнядан хуҗа атылып чыкты. Сукалап ташланган тортны күреп алды. Торт хәзер сүтелеп таркалган иске кәрзинне хәтерләтә иде. Балаларның каушаган йөзе, кинәт урнашкан бу сәер тынлык нинди дер дәһшәт якынлашуын сөйли иде шикелле.

Шунда звонок чылтырады. Балаларның йөзендә өмет чагылып узды. Олылар коридорга ташланды.

Исмәгыйлев ишекне шундый итеп тартты ки, аз гына тышка атылып чыкмый калды. «Әй, кызым, кызым!..» димәкче иде ул, әмма каршысында биш яшьләрдәге ят кызны күреп, тукталып калды. Кулын кесәсенә яшергән дә күзләрен тутырып тик карап тора аңа кызый.

Авырлык белән үзен кулга алып, кызның борын төбендә ишекне шапылдатып япмыйча көчкә тыелып калды Илгиз Идрисович.

— Исәнмесез,— дип пышылдады кызый.

— Сиңа кем кирәк, үскәнем?

— Миңа Рәмзия,— диде кызый боек кына.

— Син аны беләсеңмени?

— Әйе.— Кызый бөтенләй каушады.

— Ә исемең ничек соң? Ничек дисең?

— Римма,— диде кызый ишетелер-ишетелмәс кенә.

— Син дә, акыллым, туган көнгә килдеңме?

— Ие,— диде кызый.

— Нигә аны баштук әйтмәдең соң?— диде ул, кызны квартирага кертеп.— Менә бит, ә...

Шул вакыт берничә кыз кычкырып җибәрделәр:

— Әнә ул, әнә!

— Рәмзия кайтып килә!

— Әнә ул!

Илгиз Идрисович тәрәзәгә барып капланды. Рәмзия күрше ишегалдыннан койма ярыгы аша бу якка чыгып килә иде. Үз ишегалларына чыккач та ул әле өйгә кайтырга ашыкмады. Үткән елны ук чыгарылып куеп, хәзер инде яртылаш кар астында калган комод артына кереп яшеренде. Курткасы буялып беткән, чуклы башлыгы бөтенләй юк.

Исмәгыйлев очып диярлек тәрәзә төбенә менде, форточкага башын тыкты да ачулы тавыш белән:

— Рәмзия,— дип кычкырды.

Кызы дәшмәде.

— Өйгә кайт, тиз бул!

Кызы — ләм-мим.

— Рәм-зи-я!— Егермедән артык кыз бер булып аваз салдылар.

Монысына да Рәмзиянең исе китмәде. Комод янына җайлабрак чүмәште дә муенын якасына яшерде.

— Өйгә кайт хәзер үк, кире беткән нәмәрсә!— дип кычкырды Исмәгыйлев бар көченә.

Менә Рәмзия теләр-теләмәс кенә урыныннан купты. Шунда күрше ишегалдыннан:

— Тюк-тю-лю-люк,— дигән аваз ишетелде.

Рәмзия үпкәләп тәрәзәгә карап алды: «Синең аркада таптылар». Бер-ике секундтан койманың теге ягында кызлар тавышы яңгырады.

— Синең чират, синең чират,— диешеп, алар кул чабалар иде.

— Без кача-кача уйныйбыз бит, эти,— диде Рәмзия, тәрәзәгә карап.— Тагын азрак уйныйм инде. Печтек кенә, ярыймы?

— Бүген нинди көн икәнен син беләсеңме?

— Ой!— дип куйды Рәмзия.— Онытканмын...

Моны ишетеп, ул бар көченә өйгә йөгерде. Күрше ишегалды кызлары да аңа иярделәр. Менә баскычта әлсерәгән, кызарынып пешкән Рәмзия белән тагын биш кыз күренделәр. Өс-башларыннан су тама. Рәмзиянең киемен дә танып булырлык түгел. Әтисе үзгәргән тавыш белән:

— Туган көнең белән, кызым,— диде.

— Гафу ит, әтием.

— Их син... Рәмзиям.

Үз бүлмәсенә үтеп, Илгиз Идрисович тел астына валидол таблеткасы куйды, аннан ишекне ачты да:

— Пилмәнне салыгыз!— дип әмер бирде.

Моны ишетеп, балдыз дигәне балкон ишеген ачты, капланган ризыкларга кызыгып, шул тирәдә сикеренгән чыпчыклар, песнәкләр, өркеп, күрше балконнарга күчтеләр. Балдыз берничә урында тишкәлән-

гән кәгазьләрне ачып-ачып карады да, иидер сөйләнә-сөйләнә, пилмән, дерелдәвек, салат кебек тәмледән-тәмле ризыкларны кухняга кертә башлады. Шунда кулыннан ычкынып, бер мискасы авып китте, кар өстен бизәп, савыттан бераз винегрет түгелеп калды.

Берничә минуттан барысы да әзер иде инде. Мәҗлесне башларга бик вакыт иде. Балалар утырышты, ыгы-зыгы да, тавышлар да кимеде. Исмәгыйлев, хуҗа кеше буларак, кулына рюмка урынына ялгыз канәфер чәчәге тотып, табын алдына чыгып басты, хатын-кызлар ишек төбендә укмаштылар.

— Балалар!— диде ул, үзенә төбәлгән утыз өч пар риясез күз карашыннан дулкынланып.— Балалар! Кызым Рәмзия һәм аның дуслары! Без бүген монда...

...Ә бу вакыт балконда өйгә җыелган балалар кадәр песнәк һәм чыпчык, Рәмзиянең шатлыгын уртаклашкандай, чәчәкләр булып ак кар өстенә сибелешкән винегретларны чүплиләр иде.

# ӘДӘБИ ПОСТТА БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ

КПССның XXVI съезды әдәбият алдына куйган бурычларны һәм КПСС ҮКның «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән элемтәсе турында»гы мәгълүм карарын тормышка ашыру җәһәтеннән чыгып, «Казан утлары» журналы республикабызда яңа корыла башлаган Атом электр станциясе белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштырды. Редакциянең очерк һәм публицистика бүлеге хезмәткәрләре, Татарстан Язучылар союзының Брежнев шәһәре бүлекчәсендәге язучылар станция төзелешендә булдылар, бу эшне әйдәүче җитәкчеләр белән очрашып киңәштеләр.

Төзелешне үз иңнәренә алган «Камгэсэнергострой» берләшмәсе җитәкчеләре һәм төзүчеләр «Казан утлары» журналының, язучыларның Атом электр станциясен салучылар хезмәте белән кызыксынуларын хуплап каршы алдылар. Нәтиҗәдә коллективлар арасында «Иҗади хезмәттәшлек. килешүе» төзелде. Ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

**«Казан утлары» журналының һәм Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр коллективының иҗади хезмәттәшлек килешүе**

**Татарстан язучылар союзының әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-политик «Казан утлары» журналы, КПССның XXVI съезды карарларын һәм КПСС ҮКның «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән элемтәләре турында»гы карарын тормышка ашыру җәһәтеннән, үзенең әдәби постын оештыра һәм сәхифәләренә «Татарстан АЭСе — журналның әдәби посты» дигән даими рубрика кертә. Бу рубрикада Татарстан атом электр станциясе төзелешендәге мөһим мәсьәләләргә һәм аларны чишү алымнарына багышланган язмалар басылачак.**

**Төзүчеләр һәм энергетиклар коллективы журналның бу башлангычын хуплап каршы алдылар.**

**Татарстан АЭСе формалашу проблемаларын хәл итүдә уртак ихтыяҗны күздә тотып, шушындый килешү төзелә.**

**Хезмәт коллективлары үз өсләренә түбәндәге бурычларны алалар:**

**1. «Казан утлары» журналының хәбәрчеләрен һәм аның тарафыннан төзелешкә командировкага җибәрелгән язучыларны каршыларга, аларга тиешле ярдәмне күрсәтергә. Журнал хезмәткәрләрен АЭС төзү мәсьәләләренә кагылышлы мөһим чараларга, әдәби кичәләргә, укучылар конференцияләренә чакырырга.**

**2. Төзелеш белгечләренең, инженер-техник работникларның һәм төзүчеләрнең журнал белән хезмәттәшлеген тәэмин итәргә.**

**3. Журналда басылып чыккан материаллар белән үз вакытында танышырга һәм анда күтәрелгән мәсьәләләрне кичектермичә хәл итә барырга.**

**4. АЭС турында журналда чыккан язмаларны төзелешнең күптиражлы газетасы, җирле радио челтәре аша пропагандаларга.**

**5. Ел саен «Казан утлары» журналының очерк һәм публицистика жанрында басылган иң яхшы язмасына АЭСның 200 сумлык премиясен бирә баруны оештырырга. Премияне хезмәт коллективлары вәкилләреннән сайлап оештырылган махсус Совет карары нигезендә бирергә, аны алдагы ел башында тантаналы әдәби-музыкаль кичәдә тапшырырга.**

«Казан утлары» журналы үз өстенә түбәндәге бурычларны ала:

1. Татарстан АЭСе төзелешендә килеп чыккан катлаулы проблемаларны чишүгә багышланган язмалар биреп барырга. АЭС төзелешендәге коллектив вәкилләрен редакциядә уздырыла торган әһәмиятле чараларга чакырырга.

2. Татарстан АЭСе төзелешендә әдәби түгәрәк оештырып, аңа Татарстан Язучылар союзы һәм «Казан утлары» журналы тарафыннан даими шефлык тәэмин итәргә, түгәрәк членнарының иң яхшы әсәрләрен системалы рәвештә журналда бастырып чыгарырга.

3. Татарстан АЭСе китапханәсен Татарстан язучыларының яңа китаплары белән баетып торырга.

4. Социалистик ярышта җиңеп чыккан алдынгы участокларны, бригадаларны һәм төзүчеләрне журналның «Мактау грамотасы» белән бүләкләргә. Ярышта җиңүчеләрне бүләкләү өчен ел саен журналның 5 данә еллык подпискасын булдырырга.

«Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис.
«Камгэсэнергострой»ның йортлар салу комбинаты начальнигы М. Бибишев.
«Атомэнергострой»ның партком секретаре Р. Кәтиев.
«Камгэсэнергострой»дан 63 нче СМУның 7 нче участок начальнигы Р. Сәләхов.

13 январьда журнал редакциясендә шушы килешүне раслауга һәм аңа кул куюга багышланган киңәйтелгән утырыш булды. Утырышка «Камгэсэнергострой» берләшмәсеннән йортлар төзү комбинаты начальнигы Марат Бибишев, 63 нче СМУның 7 нче участок начальнигы Рәис Сәләхов, «Атомэнергострой» идарәсе партия комитеты секретаре Рифкат Кәтиев, «Татэнерго» идарәсе управляющие Николай Баныкин, КПССның Татарстан өлкә комитеты инструкторы Ринат Закиров, республиканың дәүләт төзелеш комитеты председателе Павел Саначин, журналның яңа оештырылган әдәби посты штабы членнары һәм редакциянең бүлек редакторлары катнашты.

Килешүгә кул куелгач, утырыштагылар яңа төр электр станциясе, энергетиклар һәм төзүчеләр яшәячәк яңа шәһәр турында әңгәмә корып җибәрделәр. Әдәбиятчылар төзүчеләр һәм энергетиклар коллективлары вәкилләренә үзләрен кызыксындырган сорауларны бирделәр.

**Ренат Харис,**

журналның баш редакторы:

— Билгеле булганча, Татарстан — илкүләм, хәтта дөньякүләм әһәмиятле төзелешләргә, промышленность предприятиеләренә шактый бай республика. Бездә самолетлар төзү берләшмәсе, мәшһүр КамАЗ, төрледән-төрле химик продукция җитештерү комбинатлары бар. Нефть, газ чыгару һәм аны эшкәртүдә дә данныбыз ил чикләреннән чыгып китте. Татарстанда Урыссу һәм Зәй ГРЭСлары, Түбән Кама ГЭСы, күпсанлы куәтле ТЭЦлар бар, һәрхәлдә, энергия чыганакларыбыздан зарланырлык түгел кебек иде. Инде килеп, республикада атом электр станциясе сала башлау нинди ихтыяҗларга бәйле? Иң элек шул хәлгә ачыклык.

**Николай Баныкин,**

«Татэнерго» идарәсе управляющие:

— Дөрес, Татарстан энергия чыганакларына бай регионнардан санала. Ул илнең мул энергия бирә торган беренче ун өлкәсенә керә. Чагыштыру өчен шунысын да әйтим: ил энергетикасына өлеш кертүче төбәкләр йөзләп безнең, шулар арасында алгы сафта бару — безнең республиканың горурлыгы, әлбәттә. Икенче яктан карaганда, бу — табигый хәл, чөнки энергетика халык хуҗалыгының теләсә кайсы тармагын үстерү юлында беренче таяныч булып тора. Бәхеткә каршы, безнең республикада бу хакыйкатьне совет властеның беренче елларында ук дөрес аңлаганнар. Беренче станция 1925 елны Казанның хәзерге Татарстан урамында төзелә. Аның җегәре нибары 5 мең киловатт иде. Аннары, ГОЭЛРО планы буенча 1 нче җылылык электр үзәге (1-ТЭЦ) салынган. Ул инде, үз чоры өчен, шактый куәтле, 12 мең кат көчкә ия була. Татарстанның көчле энергетикасы шуннан башлана. Аңа нигезләнеп, яңа заводлар сафка кертелә.

Нефть промышленносте алга киткәч, Урыссу, Зәй ГРЭСлары булдырылды. Зәйдәге станция, безнең үз ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерүдән тыш, илнең бердәм энергия системасына да мул өлеш кертә башлады. Гаҗәеп кызык бу үсеш: энергиягә бай булу республикада хуҗалыкның яңадан-яңа тармакларында алга китешне тәэмин итә, икенче яктан исә, промышленность үсеше үзе энергиянең яңа чыганакларын табуга этәрә. Әйтик, КамАЗ кебек гигантны корганда, без иң элек бу төзелешкә яңа ТЭЦ салырга мәҗбүр булдык. Аның янында ук Түбән Кама ГЭСы сафка керде.

**Мансур Вәлиев,**

журналның тәнкыйть бүлеге редакторы:

— Шуңа өстәп, авылларны электр энергиясе белән тәэмин итүнең ничегрәк торуын да әйтсәгез иде!

**Николай Баныкин:**

— Урынлы сорау. Хәзерге авыл хуҗалыгы да электр энергиясеннән башка алга китә алмый. Бәхеткә каршы, безнең бу мәсьәләне хәл итүдә дә уңышларыбыз бар. Ун еллар элек республиканың авыллары тулысынча электрлаштырылды. Күпсанлы ярдәмчел вак станцияләр салынды. Кыскасы, безнең Татарстан хәзер ел саен ГОЭЛРО планында максат итеп куелганнан 4 тапкыр артыграк электр энергиясе җитештерә.

Инде беренче сорауга якынрак килик, Татарстанда атом станциясе салу нинди ихтыяҗларга бәйле соң? КПССның XXVI съездында илне төп куәте атом-төш мөмкинлекләреннән алына торган яңа төр электр станцияләрен булдыруга зур игътибар бирелде. Билгеле ки, җылылык электр станцияләрендә ягыла торган табигый ресурслар чикләнгән. КПСС ҮКның ноябрь Пленумында бу мәсьәлә кабаттан яңартылып телгә алынды, энергетикабызны үстерергә, ныгытырга кирәк диелде. Шул яктан чыгып караганда да, илдә атом электр станцияләрен салу — ифрат дәрәҗәдә кирәкле чара. Шуларның берсе Татарстанда төзелергә тиеш дип табылган икән, моның тормышчан сәбәпләре бар. Беренчедән, бездә мондый корылмаларны башкарып чыгарлык инженерлар һәм төзүчеләр күче, гаять абруйлы, тәҗрибәле коллективлар үсеп җитте. Бу очракта мин иң элек «Камгэсэнергострой» берләшмәсен күздә тотам. Икенчедән, Татарстанның үзәктә булуы да әһәмиятле. Бездә җитештерелгән куәтләрне илнең бердәм энергетика системасына тоташтыру да уңай. Аннары мондагы табигать шартлары да атом электр станциясе салырга мөмкинлек бирәләр. Аларның беренчесе — Кама суы. Станциягә бик күп су кирәк булачак.

**Рәшит Әхмәтҗанов,**

журналның хатлар бүлеге редакторы:

— Яңа төзелеш турында ишеткән укучылар Кама буена атом электр станциясе салу табигатькә зарар китермәсме икән, дип сорап язалар.

**Николай Баныкин.** Бу нәрсә турыдан-туры безнең үзебезгә бәйләнгән. Атом электр станцияләренең эшләү үзенчәлеге безгә электән таныш булган җылылык электр станцияләренеке кебек үк. Аерма — ягулык төрендә генә. Бу аерма исә табигать файдасына. Атом электр станцияләренең морҗаларыннан бернинди дә төтен чыкмаячак, димәк, тирә-юньгә начар газлар таралмаячак. Станция ихтыяҗына тотыла торган су, махсус чистарткычлар аша үткәрелеп, аерым сусаклагычларга җибәреләчәк. Анда хәтта балык үрчетергә дә мөмкин булачак. Гомумән, станцияне салу белән бергә үк, бу тирәлекнең табигатенә зыян-зарәт китермәслек чараларны тормышка ашыру планы да карала. Алга куелган һәр эшне җиренә җиткереп үтәргә генә кирәк.

**Кояш Тимбикова,**

журналның очерк һәм публицистика бүлеге редакторы:

— Шундый зур мәсьәләләрне хәл итәчәк кадрлар тәрбияләү ягы ничегрәк тора соң? КамАЗ салучыларның бер өлеше, төзелеш түгәрәкләнә башлагач, заводларда эшли башлаган иде. Атом электр станциясе төзелешендә дә мондый күренеш булырмы?

**Рифкат Кәтиев,**

«Атомэнергострой» идарәсенең партком секретаре:

— Бу — катлаулы мәсьәлә. «Атом» төшенчәсе безнең өчен ят булып тоелса да, станциянең эшләү ысуллары җылылык станцияләренеке кебек үк, аерма ягулыкның башка төрле булуына гына кайтып кала. Безнең исә җылылык электр станцияләребез дә, аларның белгечләре дә бар. Реакторлар белән эш итүчеләр махсус әзерләнәчәк, әлбәттә.

Тик мин иптәшләрне кисәтеп куярга тиешмендер, мөгаен: атом электр станцияләрен салу шактый озак вакыт сорый. Без 1982—1983 нче елларда, нигездә, әзерлек эшләрен генә алып барабыз: йортлар салу комбинаты төзүчеләр яшәячәк шәһәрнең беренче биналарын торгыза башлады, безнең идарә кешеләре станция бинасын

төзегәндә кирәкле терәк базаны кора. Шунлыктан хәзергә безнә атомчы кадрларны кайдан алу мәсьәләсе борчымый, алар 90 нчы еллар башында гына кирәк булачак. Хәзер безгә төзүчеләр кирәк, төзүчеләр. Шулай бит, Рәис?

**Рәис Сәләхов,**

«Камгэсэнергострой»ның ЙТК 63 — СМУ 7 — участок начальнигы:

— Әйе шул. КамАЗ төзелешенә, беренче игъланнар яңгырау белән үк, илнең төрле якларыннан бик күп төзүчеләр килде. Сайлап алырга да мөмкинлек бар иде. Хәзер миңа безнең участокка отделочниклар кирәк. Брежнев шәһәреннән әллә ни күп китереп булмый, алар инде урнашканнар, үз эшләре бар. Оста, уңган, сабыр холыклы, үзем шунда яшәячәкмен, дип килгән буяучыларны, сылаучыларны, ташчыларны кочак җәеп каршылар идек. Кызганычка каршы, хәзергә андыйлар аз. Станция — Бөтенсоюз удар төзелеше түгел, без аны үз көчләребез, ягъни Татарстан төзүчеләренең үз коллективы белән башкарып чыгарга тиеш. Инде менә «Казан утлары» журналы белән ике арада дуслык-хезмәттәшлек килешүе төзелгән икән, аның аша без укучыларга үз ихтыяҗларыбызны җиткерә алабыз. Бу бик әйбәт, минемчә. Журналдан укып, безнең оешмага эшкә килергә, атомчылар шәһәрен салуда катнашырга теләүчеләр табылса, рәхим итсеннәр!

**Ренат Харис.** Алай, укучыларга әйтер сүзләр дә куерып киткәч, без хәзер яңа шәһәрнең нинди булачагын да сурәтләп бирергә тиешбездер. Кайда, ничек итеп салыначак ул?

**Павел Саначин,**

Татарстан дәүләт төзелеше комитеты председателе:

— Шәһәрләр салуда безнең тәҗрибә шактый бай. Соңгы 15—20 ел эчендә төзелгән Түбән Кама, Брежнев шәһәрләренә күпләр кызыгып карый. Атом электр станциясен салучылар, соңра аны эшләтүче энергетиклар яшәячәк шәһәр дә кешеләрне сокландырырлык булачагына ышандыра алам мин. Дөрес, монда да кыенлыклар күп. Шәһәр проектын Мәскәүнең академик Борис Рафаилович Рубаненко җитәкчелегендәге фәнни-тикшеренү институты өлгертергә тиеш. Хәер... ул проектны көтеп тормадык торуын, Марат Шакирович әйтүенә караганда, шәһәрнең беренче йортларына кешеләр керә дә башлаган инде, яңа мәктәп, почта, телеграф эшли. Мунча салалар.

**Марат Бибишев,**

«Камгэсэнергострой»ның йортлар салу комбинаты начальнигы:

— Борис Рафаилович безнең мөстәкыйльлекне үзе дә ярата ул. Аннары, без бит шәһәрнең ниндирәк буласын яхшы беләбез инде. Күзне йомсам, минем күз алдына Каманың таулы яры буендагы үзәнлек куеныннан калкып чыккан шул яңа шәһәр килеп баса. Урынны проектлаучы оешма вәкилләре белән бергә сайлап йөрдек. Башта тау башындагы тигез җиргә салырга тәкъдим иттеләр. Ризалашмадык. Җиде җил үзәгендәге йортларда яшәүчеләр безне гомер буе каһәрләрләр кебек тоелды. Ике калкулык арасындагы, су яссылыгыннан йөз метрлар гына өстәрәк торган борынгы Кама Аланы авылы урынына тукталдык. Авылның тирәсендә тагын вак-вак калкулыклар бар. Шәһәрнең йортлары да бер яссылыкка гына салынмаячак. Кешенең элек-электән формалашкан теләк-омтылышларын искә алырга кирәк, минемчә. Урман куены, су буе — борын-борыннан кешенең яратып төпләнә торган урыннарыннан саналган. Аның бу омтылышы яңа шәһәрләр салганда да безнең истән чыкмаска тиеш.

**Фәннур Сафин,**

журналның сәнгать бүлеге хезмәткәре:

— Атомчылар шәһәре Брежнев, Түбән Кама шәһәрләренә охшаш булачакмы яки нинди яклары белән аерылып торачак?

**Марат Бибишев:**

— Беренчедән, яңа кала Брежнев шәһәре кебек зур түгел. Аңарда башка төр промышленность тармакларын үстерү күздә тотылмый. Бу хәл үзе үк аны Брежневтан шактый үзгә итә. Аның силуэты гаҗәеп матур булачак. Монда бер, ике, өч, биш катлы йортлар, җиде, тугыз, ундүрт катлылар белән аралашып, искиткеч эффектлы күренеш ясаячаклар. Шәһәр үзәккә таба биегәя барачак. Урамнар озын да, төз дә түгел, ә кеше табигатенә хас төстә, бормалы-сырмалы итеп төзеләчәк. Йорт-

ларга газ кертелмәячәк, барлык ихтыяҗлар өчен электр энергиясе бирелэчәк. Шәһәрнең башка яклар белән элемтәсе, юллар челтәре заманның иң камил ысулларына нигезләнәчәк...

**Марсель Галиев,**

журналның проза бүлеге редакторы:

— Яңа шәһәр төзелешендә Татарстанга хас архитектура элементлары, милли орнаментлар файдаланылачакмы?

**Павел Саначин.** Бу нәрсә безнең һаман да хәл итеп алмый тора әле. Әдәбиятта, сәнгатьтә милли традицияләрне заманга яраклаштырып файдалану, аларны үстерү шактый уңышлы бара. Ә менә архитекторларыбыз һичничек уртак фикергә килә алмыйлар. Моңа Татарстан архитектурасы тарихын өйрәнеп җиткермәү дә комачаулый булса кирәк. Казан төзүче инженерлар институтын да эшкә тартырга иде!

**Марат Бибишев.** Институт — белгечләр, төзүчеләр әзерли торган оешма, алар безнең карамакка җибәреләэ, эшне без башкарырга тиеш. Тик, кызганычка каршы, хәзергә архитекторларыбыз төзүчедән калыша, бу өлкәдә мактанып бер сүз дә әйтеп булмый.

**Ренат Харис.** Сизелеп тора: без журнал битләрендә олыдан кубып сөйләрлек башка тармакка килеп кагылдык. Төзелешләребезнең архитектура мәсьәләсен киләчәк сөйләшүләргә калдырып, хәзергә без уебыз белән яңадан Кама буена кайтыйк. «Казан утлары» редакциясендә оештырылган әдәби постның штабы төзелештәге һәр яңалыкны укучыларга җиткереп торачак. «Татарстан АЭСе — журналның әдәби посты» рубрикасында төзелеш каһарманнары сурәтләнгән очерклар, язучыларның бу төзелешкә багышланган публицистик мәкаләләре, төзүчеләрнең чыгышлары бирелеп барачак.

Редакция авторлардан яңа төзелешкә лаек, тирән эчтәлекле, сәнгатьчә иҗат ителгән язмалар көтә.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ТУГАНДАШ КУЛЬТУРАЛАР БӘЙРӘМЕ

Казанда Идел буе һәм Урал ягы автономияле республикаларының Беренче музыка фестивале булып үтте. СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган әлеге зур культура бәйрәмендә Башкортстан, Мари, Мордовия, Татарстан, Удмуртия, Чувашстан автономияле республикаларыннан, шулай ук Мәскәүдән килгән күренекле композиторлар, музыка белгечләре, башкаручылар катнашты.

Казан дәүләт консерваториясенең Актлар залында музыка фестивален ачу тантанасы булды. Аны фестивальнең оештыру комиссиясе председателе, Татарстан АССР культура министры И. Н. Алиев ачты.

Музыка фестивалендә катнашучылар Казан шәһәре предприятиеләрендә эшчеләр белән очраштылар, республикабыз башкаласының истәлекле урыннарын карадылар.

Илебез юбилеена багышланган зур культура бәйрәме М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында Идел буе һәм Урал ягы автономияле республикаларының сәнгать осталары концерты белән тәмамланды.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ — ӘДӘБИ ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

21—22 декабрьда Эстония ССРда СССР Язучылар союзы идарәсенең әдәби тәрҗемә Советы пленумы булып узды. СССР төзелүгә 60 ел тулуга багышланган бу пленум Эстониянең башкаласы Таллинда башланып китте һәм илебезнең иң өлкән университетларының берсе урнашкан Тарту шәһәрендә дәвам итеп, шунда үзенең эшен тәгәлләде. Төрле Союздаш республикалардан килгән әдәбият белгечләре, тәрҗемәчеләр, әдәби тәнкыйтьчеләр тарафыннан пленумның төп темасы булган «Әдәби тәрҗемә: тарихи тәҗрибә һәм алда торган проблемалар» дигән мәсьәлә буенча өзерләнгән сөгермәдән артык чыгыш тыңланды. Пленумда татар язучысы, РСФСР Язучылар союзы идарәсенең әдәби тәрҗемә Советы җаваплы секретаре Гәрәй Рәхим «РСФСР автономияле республикалары, өлкәләре һәм милли округлары әдәбиятларында тәрҗемә эшенең торышы» дигән мәсьәлә буенча чыгыш ясады.

## БӨЕК ЮБИЛЕЙГА БАГЫШЛАП

23 декабрьда Мәскәү шәһәренең Н. А. Некрасов исемендәге Үзәк публичный китапханәсендә СССР төзелүгә 60 ел тулуга багышланган әдәби кичә үткәрелде. «78 телдә сөйләшүче әдәбият» исемле бу кичәне илебезнең танылган әдәби тәнкыйтьчесе, СССР Язучылар союзы идарәсенең милли әдәбиятлар буенча секретаре Юрий Суровцев алып барды. Кичәдә Мәскәү шагыйрьләре Евгений Долматовский, Леонид Латынин, грузин шагыйре Хута Гагуа, үзбәк шагыйре Сабит Мадалиев, кыргыз прозаигы Муса Мораталиев һәм татар шагыйре Гәрәй Рәхим чыгыш ясадылар.

## РӘССАМНАР СЪЕЗДЫ

6 январьда Казанның Актерлар йортында Татарстан рәссамнарының IV съезды булды. Татарстан АССР Художниклар союзы идарәсенең отчеты турындагы докладны ТАССР Художниклар Союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев, ревизия комиссиясе председателе Р. В. Нурмөхәммәтов ясадылар.

Съездда КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, РСФСР Художниклар союзы идарәсе секретаре В. Н. Телин катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

Съездда ТАССР Художниклар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составлары сайланды.

Яңа сайланган идарәнең беренче утырышында Татарстан АССР Художниклар союзы идарәсе председателе итеп Ә. И. Тумашев, җаваплы секретарь итеп В. П. Аршинов сайланды.

## МАКТАУЛЫ БҮЛӘК

Татарстан китап нәшриятында балалар өчен рус телендә басылып чыккан «Заяц на зарядке» («Физзарядка ясый куян») дигән шигырьләр җыентыгы өчен шагыйрь Шәүкәт Галиев Халыкара бүләк — Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы дипломга лаек булды. Шул уңайдан шагыйрьне һәм Татарстан китап нәшрияты коллективын РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары С. Михалков, А. Алексин, В. Александров кайнар котладылар һәм яңа иҗат уңышлары теләделәр.

# КӨЧЛЕ КЕШЕЛӘР

СССР халык художнигы, СССР художество академиясе член-корреспонденты рәссам Харис Якупов үзенең әсәрләрендә нигездә республикабыз тарихына һәм аның бүгенге көненә караган иң зур вакыйгаларны тасвирлый. Рәссам иҗат иткән әсәрләрдән «В. И. Ленинның Татарстан автономияле республикасы төзелү турындагы Декретка кул куюы» (1950, Лотфулла Фәттахов белән бергә язылган), Муса Җәлил образына багышланган «Хөкем алдыннан» (1954), «Татарстан алтыны», «Чаллы гүзәлләре» (70 нче еллар) инде күптән республикабызның сынлы сәнгать музее залларында лаеклы урын алдылар, хрестоматияләргә керделәр.

«Мулланур Вахитов исемендәге колхозның алдынгы кешеләре» сериясенә кергән «Көчле кешеләр», «Көтүчеләр» картиналарының геройлары — тормыш-көнкүрешебездәге конкрет кешеләр. Бу әсәрләрендә рәссам эзлекле рәвештә кешенең җиргә бereкәнлеге, холык-фигыльләр күркәмлеге, авыл эшчәннәре хезмәтенең матурлыгы һәм бөеклеге турында сөйли.

«Көчле кешеләр» (1963) картинасында сыер савучы хатын-кызларның күмәк портреты тасвирланган. Әсәр авторның югары сәнгатьчә нәкыш салу культурасын, декоратив алымнардан оста файдалануын, төсләр белән эш итә белү осталыгын дәлилли.

Зөбәрҗәттәй җемелдәп-балкып торган яшел чирәм. Анда бер төркем кызлар сурәтләнгән. Аларның кояш нурлары белән өретелгән зифа буйлары, төз, матур гәүдәләре, көчле кулларының юнәлешләре, кызыл йөгертелгән ачык-күе төсләр хәрәкәте — һәммәсе бергә кушылып, тулы божра хасил итәләр. Мондый композицион алым сурәттәге кызларның бер-берсенә бәйләнешен, аларның рухи берлеген, эчке халәтләренең уртаклыгын ачып бирергә ярдәм итә. Күлмәк-алъяпкычларындагы ак, алсу, күе кызыл, кызгылт-кара төсләрнең җанлы катнашмасы, йөзләрдә уйнаган балкышлар һәм тукымадагы буяу өермәләре әсәрнең нык, тотрыклы композициясенә хәрәкәтчәнлек өстиләр. Алар образларның эчтәлеген баету белән бергә хезмәт кешесенә хас булган эчке матурлыкны да калку рәвештә сурәтләп бирәләр.

Рәссам үзе тасвирлаган кешеләргә сокланып, сөеп карый, аларның табигать үзе куйган сафлыгына, гүзәллегенә мәдхия җырлый. Хатын-кызларның йөзен тасвирлаганда пумала йөреше назлы, салмак булса, яшеллек муллыгын, тирә-як җисемнәрен, кием-салымны сурәтләгәндә исә аның хәрәкәтләре көчәеп, ярсып китә. Халык сәнгатенә хас ялкынлы, якты төсләр образларга үзенчәлекле бер самимилек өсти, милли колоритны баета һәм героиняларадагы ташып торган шатлыклы ашкынуны, аларның күңелен биләгән хезмәт дәртен, татар кызларына хас оялу хисен нечкәләп сынландырып бирергә ярдәм итә. Кызлар — искиткеч якты төсләр, хәрәкәт, шатлык катыш борчылу һәм кояш тулы дөньяның җанлы бер өлеше булып кабул ителәләр.

Күренешнең бер почмагына кайры савыттагы ак, сары, зәңгәр кыр чәчәкләре ясап куелган. Бу деталь авторның образлы итеп әйтәсе килгән фикерен ачыклый: картинадагы кызлар да шулай туган җир күкрәгеннән шытып чыккан саф, садә чәчәкләрне хәтерләтәләр.

Новаторлык билгеләрен эченә алган «Көчле кешеләр» Татарстан сәнгатенең иң күтәренке рухлы, оптимистик әсәрләреннән санала.

**Р. ШАҺИЕВА,**
**Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.**

●


Тышлыкның дүртенче битендә рәссам Харис Якупов портреты.

Р. Мансуров слайдлары

# Бәхетем башкаласы

**ИЛГИЗ ЗАКИРОВ** музыкасы

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ** сүзләре




2

Сөенечем, шатлыгымны
Сәгатьләрең гел санасын.
И Казаным, син бит минем
Хыялым башкаласы.

Кушымта.

3

Йөрәкләргә утлар салып
Без китәбез, син каласың.
И Казаным, син бит минем
Бәхетем башкаласы.

Кушымта.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)